# КАЗАН УТЛАРЫ

2
ФЕВРАЛЬ
1979

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

2
ФЕВРАЛЬ
1979

## Бу санда

Ә. МАЛИКОВ. Медальләр. Шигырьләр . . . . 3
Ә. БАЯНОВ. Аязучан болытлы һава... Повесть . . 7
С. ХӘКИМ. Яңа шигырьләр . . . . . . . . 89
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Гөлбадран. Повесть. . . . 93
Я. ИГЕНӘЙ. И гүзәл гамь. Шигырьләр . . . 123
Р. ПОБЕРЕЖНЫЙ. Зәңгәр конверт. Хикәя . . . 126

ОЧЕРКЛАР

С. ШАКИР. Утлы еллар әле дә хәтердә . . . . 130
К. ТИМБИКОВА. Казан кызлары . . . . . . 141

СӘНГАТЬ

Ш. МОНАСЫЙПОВ. Татар скрипка сәнгате . . 149

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

С. СӨЛӘЙМАНОВА. Шагыйрь — заман баласы 155
Р. НИЗАМИЕВ. Шагыйрьләргә заман текәлгән . 162

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Г. КУДАШЕВ. Камиллек һәм нәфислек юлыннан 167
Л. ЯФАРОВ. Тукайча төгәллеккә . . . . . . . 172

СҮЗ ХИКМӘТСЕЗ БУЛМАС...

Ә. БУЛАТОВ. «Нужа калач ашата» . . . . . . 176
Й. ГӘРӘЙ. Чөйгәне шоңкар булган. . . . . . 176

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ВӘЛИЕВ. Дөньяның гамьнән башка ямь юк 179
Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. Житди хезмәт . . . . . . 181

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Г. ЛАТЫЙП. Безнең сыер. Шигырьләр . . . . 185
УКУЧЫЛАР СҮЗЕ . . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 23/X-1978 ел. Басарга кул куелды 16/I-1979 ел. ПФ 09002. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83.544 экз. Заказ В-357. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

## Әдип Маликов

# МЕДАЛЬЛӘР

## Үзем булып калам

*Полкташ разведчик дусларыма*

Разведкада
Зәһәр салкында
Тәнем белән карны җылыттым.
Уздым дигәч утлы чикләрне,
Яңасына барып юлыктым.
Без һөҗүмгә кердек гаскәрсез,
Төн карасы белән камалып.
Приказ кыска:
— Тап син ачкычын
Дошман тылындагы каланың!
Күперләрен, урам чатларын —
Барлап йөрдем барсын күңелдән...
Мин үлемгә кердем,
меңнәрне
Саклап калу өчен үлемнән.
Кар төсенә кердем кайчакта,
Ком төсенә, яфрак төсенә.
Төсен үзгәртә бу — хамелеон
Дия алмады ләкин берсе дә.
Үзем булып калдым барыбер,
Алга уздым юлны тамгалап.
Расладым мин яшәү хокукын,
Дошманнардан илне аралап.
Көн уянса — башым сәфәрдә,
Җир сулышы бәрә йөземә.
Киләчәккә ялгыйм бүгенне,
Чалынмыйча дөнья күзенә.

## Солдатлар узганда

Солдатлар узалар, солдатлар!..
Уйларым яктыра, сафлана.
Минем дә йолдызлы яшьлегем
Бара күк шул тыгыз сафларда.

Аерылмас туганнар шикелле,
Гел бергә — ни генә күрсәң дә.
Егылсаң-торсаң да бер кайгы —
Туган ил язмышы җилкәңдә.

Һөҗүмгә керәләр солдатлар,
Тиң булып ярсулы ташкынга.
Йөрәкләр тынса да гел бергә —
Яталар бер йолдыз астында.

Җуелмас тарихның хәтере...
Туган ил чакырса тагын да,
Һөҗүмгә ташланыр үлгәннәр,
Җанланып миллионнар аңында.

Солдатлар узалар, солдатлар!
Уйларым яктыра, сафлана.
Минем дә йолдызлы яшьлегем
Бара күк шул тыгыз сафларда!

●

Ул дуслык окопта туганмы,
Походта, җырдамы — онтылган.
Солдатлар дуслыгы кайчакта
Башлана бер бөртек шырпыдан.

Учыңа яшереп җилләрдән,
Сызасың кадерләп соңгысын.
Тайгада кабынган учакның
Тоям мин хәзер дә җылысын.

●

Тормыш кичкән иргә таян! —
Өстен торыр ваклыклардан
Мәхрүм итмәс шатлыклардан.
Гаебең күреп сүксә-сүгәр,
Яратып бер сукса-сугар,
Яманнардан әмма яклар,
Һәлакәттән сине саклар.

Сугыш кичкән иргә таян!
Ул тубыктан кан эчендә
Җиңеп барган бар көченә.
Гаделлекне яклап барган —
Шул җанында аның калган.
Үзен илгә багышлаган —
Шуның белән ялгышмаган.

Таян
иле белән бергә
Үлем аша узган иргә!

## Медальләр

Хуҗасы биесә — бииләр,
Көлгәндә — чылтырап көләләр.
Хуҗасы мәйданга җыенса,
Көзгедән елмая медальләр.

Чыңлашып куялар моң гына,
Кинәттән йөрәкне сызлатып.
...Чыктыгыз иң хәтәр юлларга
Магнитлы тауларны кузгатып.

Чыңлыйсыз, әйтерсең яшенләп
Кылычлар кисешә һавада.
Кылычлар йөзеннән үткәреп
Сынады кешене замана.

Тудыгыз һөҗүмгә барганда
Ялкыннан, салютлар язынннан.
Җуелмас даныгыз ут белән
Калалар исеменә язылган.

Чыңлыйсыз... Чаң кага Хатыньнар:[1]
«Европа арынды хурлыктан!»
Әйтерсең меңләгән чишмәләр
Дан җырлый җиңүче халыкка.

Чыңлагыз, медальләр, чыңлагыз, —
Кырдагы башаклар җыры бу.
«Хәерле иртә!» дип уяткан
Башкала куранты чыңы бу.

Юлларда булыгыз, медальләр,
Аяклар талса да тынмагыз.
Мендәргә күчмәгез, медальләр,
Йөрәкләр катында чыңлагыз!

## Бер вагонда

Вагоннар да,
күңелләр дә
Бер ноктадан кузгала...
Купе саен пассажирлар
Гәп коралар үзара.

Арада яшь пограничник,
Сары каеш биләндә.
Кунакка я бөтенләйгә
Кайта булыр иленә.

Кителен дә салып карый,
Кырларга да күз сала.
Аның бөтен хәрәкәтен
Отып бара кыз бала.

---

[1] Хатынь — немец фашистлары тарафыннан яндырылып, халкы белән берга көлгә әйләндерелгән Белоруссия авылы. Хәзер анда мемориаль музей.

Төшәр төсле өске каттан
Очып кына, тиз генә.
«Кителеңә ак яканы
Тегәр идем үзем дә».
Күкрәгендә значоклар, —
Хезмәте бар егетнең.
Әнисенең улы кайта,
Яшь кызларның — өмете.
Чөйдә яшел фуражкасы,
Йолдызыннан нур тама.
Сөйләшәсе килә кызның
Сүзне салып уртага.
Егетне шул үз уйлары
Биләп алган, күрәсең.
Ул дөньяга болай гына
Ничек барып керәсең.
Күңеле бәлки бик еракта,
Хезмәт иткән яктадыр.
Бәлки туган як төсләрен
Көйгә салып кайтадыр.
Бәлки әле әтисе дә
Хәрби кеше булгандыр.
Европаны дер селкетеп,
Фашистларны кугандыр.
Очрашырлар ике солдат,
Сөйләшерләр туйганчы, —
Берсен-берсе генераллар
Баскычына куйганчы.
Пограничник абый кайта —
Кыз күңеленә таяныч.
Төшеп калыр кемдер алдан,
Шунсы менә аяныч.
Юллардагы ераклыкка,
Иминлеккә баш булып,
Кайта егет илләренә;
Чаба поезд ашкынып!

1978

## Әхсән Баянов

# АЯЗУЧАН БОЛЫТЛЫ ҺАВА...

ТУГАН ҖИР КӨНДӘЛЕКЛӘРЕ

## Узганнардан хатлар

### БЕРЕНЧЕ ХАТ



Исәнмесез, Әнис!

Бу хатны сезгә күптәнге танышыгыз, яшьлек дусларыгызның берсе яза. Исемемне әйтмичә торам. Әлбәттә, без күрешербез, сез мине тапмыйча калмассыз дип ышанам. Безнең ерактан өметсез кычкыруларыбызны ишетерсез дә, әгәр йөрәгегез инде ташка әйләнмәгән булса (күпме гомер үтте бит!), кайтып җитәрсез дип көтәм. Югыйсә, сез шәфкатьсез, артык каты кеше булып чыгар идегез. Электән сезне шактый белгәнгә күрә, сүзем даладагыдай югалмас дип ышанам.

Эш менә нәрсәдә, Әнис. Безнең районда шактыйдан инде чәрбе, сезнекечә әйтсәк, гаугалы көрәш дәвам итеп килә. Бик күптәннән инде. Үзегез дә ишетми калмагансыздыр. Аяусыз чыйкалаш аркасында, менә дигән әйбәт кешеләр, үзләре дә сизмәстән, мескен, кызганыч хәлләрдә калалар. Шуларның берсе миңа бик якын кеше, яшәү белән үлем арасына дигәндәй килеп эләкте. Ул дөреслек, гаделлек эзләп ялгышты. Шул сәбәпле, бөтен дәрәҗәсен югалтты. Һәм хәзер исә, бөтенләй кешелектән үк чыгарып ташламакчылар. Күрәләтә харап була кеше. Карап торып, кулларыбызны сузып торсак та, балаләрдән йола алмыйбыз үзен һәм инде ярдәм итә дә алмабыз, ахрысы. Бик күп комиссияләр тикшерде, бинһая журналистлар килде — хәтта язып та чыктылар. Тик берсеннән дә мәгънә чыкмады. Хәзер бердәнбер өмет — ул сез. Дөреслекне ачсагыз, гаделлекне тапсагыз, бары тик сез генә табачаксыз. Чөнки бу эштә үз мәнфәгатен кайгыртмый, курыкмый торган кеше генә файда китерә ала. Элекке танышлык буенча да, язган статьяларыгыз, брошюраларыгызны укып та шулай тоям. Хакыйкатьне ачыклап, берәр газетада бастырып чыгарсагыз, тәртип беразга гына

булса да урнашачак бит һәм сез шуның белән бөтен бер кеше гомерен саклап калган булырсыз, ә бәлки әле бер кешенекен генә дә түгелдер. Бәндәгә бер генә кабат бирелә торган нәрсәне — гомерне саклап калу хакында бара лабаса сүз! Безнең үтенеч! Шулай ук сез дә ишетмәссез микәнни? Соңга калу мисаллары инде булмады да түгел бит... Кайтсагыз, үзегез дә күрерсез, ышанырсыз...

Бүтән алай булмас дип, тиз арада безне табарсыз дип өметләнәбез. Өметләнәбез, көтәбез, ышанабыз.

Авылыбыз гозерен (бәлки әле бер авылныкы гына да түгелдер) үтәп сезгә хат язучы:

Яшьлек дустыгыз.

20 апрель, 1977 ел.

## ИКЕНЧЕ ХАТ

Хат башы, яз каршы.

Исәнмесез, сезки гыйззәтле Бәдыйгин әфәнде!

Безки үзегезнең елга аръягында гына яшәүче гражданка яза бу хатны шул хакта, ягъни җәмәгать иптәшебез булган Байслам Гыйбадулласы турысынарда. Сезгә чук-чук сәлам җәмәгатемнән, үземнән, балаларымнан вә күрше-тирәдән аермаенча һәм күктәге йолдызлар, җирдәге чәчкәләр санынча. Сәлам шушының белән тәмам. Сәламнән соң аз гына булган сүзләргә күчәм. Ягъни шул хакта, җәмәгать иптәшебез Гыйбадулла хакынарда. Ягъни шул хактадыр ки, безнең җәмәгать иптәшебез бик каты чир белән түшәктә ята. Аның тәне кычыта. Бармаган, күрмәгән төбәге, духтыры калмады инде иллә дә мәгәр берәү дә ярдәм итә алмады инде. Шулай булуга да карамастан, аның тереләсе килә. Ул сезгә хат язарга кушты — ярдәм итәсе кеше ул гына, ди. Без дә шуңарга ышанабыз. Нигә дип әйткәндә, сез аны бәләкәй чагыгызда бик каты каргаган булгансыз икән. Вә шул каргыш минем җәмәгатемәргә туры төшкән, чөнки ул үзе гаепле, сезне бер дә юкка бик нык рәнҗеткән икән. Сез аны каргагансыз, елан булып шуышып, кырмыска оясында үрсәләнеп җан бирегез, дигәнсез. Сез аңа, минем исемемне шунда искә алырсыз, хәтерләми калмассыз, иллә дә аллагыз да ярдәм итә алмас, шуннан кире инде ярдәмгә чакырып минем исемемне кычкырырсыз, ә мин ишетмәм, дигәнсез. Күкләр ярылганчы, сезнең өчен һәр ботагында ярты литр аракы асылынып торган калын урманнар калтыраганчы вә аяктан егылганчы акырсагыз да мин ишетмәм, и сезне бүтән беркем дә ишетмәс, ишетсә дә, ишетмәгәнгә сабышыр, килмәс, килсә дә, ярдәм итмәс, ярдәм итәргә теләмәс, теләсә дә булдыра алмас, һаман да шул аждаһадай боргаланып, бөтәрләнеп, аунап калырсыз һәм, акыра-акыра, башыгызны күккә сузган хәлдә җан бирерсез дә, гөрс итеп янә кырмыска оясына аварсыз да кырмыска оясы тирәсендә шоп-шома сөякләрегез генә ялтырап калыр, дип каргагансыз икән.

Хөрмәтле әфәнде!

Җәмәгатебез булган Гыйбадулла, чынлап та, кырмыска ояларына барып ятты, чынлап та, еландай бөтерелде-боргаланды, иллә җаны чыкмагач чыкмады. Көч-хәл белән аерып, күрше-тирә җыйнаулашып күтәреп кайттылар, рәхмәт төшкерләре. Ә Гыйбадулла исә янә шул урманга чыгып йөгермәкче, качмакчы бездән. Көчкә-көчкә тыеп калабыз. Кырмыскалар ашаса, тәненең әз генә булса да кычытуын, сызлавын киметә төшә, ашап бетерүләре яхшырак, җибәрегез, җибәрегез, дип исерек бәндәләр мисалында бәйләнә, бәргәләнә-бәргәләнә акыра, тарткалаша. Көчкә-көчкә җиңәбез. Үзебезгә берәр җиргә барырга кирәк булса, дилбегә-арканнар белән бәйләп калдырабыз. Без күрмә-

гәндә кырмыскалар, чыннан да, коры сөяккә калдырыр, дип куркабыз. Кайчакта, бик аз вакытка үзебез генә алып барып кайтабыз. Әй, аның шунда сөенүләрен, үрсәләнүләрен, уфтануларын, үкерүләрен күрсәгез! Ишетсәгез...

Шулай әкияттәге сымак интегә торгач, соңгы көннәрдә сине, синең каргышыңны хәтеренә төшерде. Сине ярдәмгә чакырып кычкырды һәм ул бакырудан гамәлдә дә урман-күк калтырады, җимерелеп, авып кына төшәсе калды. Иллә син ерак. Якын булсаң да, ишетер идең микән? Хаста җәмәгатем үзе: «Барыбер ишетмәс иде»,— ди.

— Әфәнде!

Бәндә бик кызганыч бит. Син аны гамәлдә коткара аласыңмы? Әллә юри генә әйткән идеңме? Шушындый да хәлдә кешене калдыру ярый торган эшме? Бигрәк тә сезнең кебек укыган кешеләр өчен? Бәндәне шундый хәлдә дә кызгана алмаган кеше нинди кеше булыр икән соң? Сезме шундый кеше? Юктыр андый адәм дөньяда, булмый торгандыр. Йөзләрчә чакрым арадан чакыру-кычкыруларыбызны ишетмәсәң, язганнарыбызны укырсың. Укырсың да уйга калырсың.

Йа раббы, шул мәлдә уйларыгызга ходай җылылык иңдерсен. Җылылык яралгысы җаныгызга күчсен дә, син, хөрмәтле әфәнде, безнең авылыбызга кайт. Авылыбызга кайткач, безнең өебезгә кил дә Гыйбадулла абыегыз баш очынарга басып, үзең белгән доганы укы вә каргышыңны аның тәненнән кире ал, чирләрен күккә очыр.

Тәңребез, раббыбыз, ходаебыз аты белән зинаһарлап сорыйбыз: кайтыгыз, тизрәк кайтыгыз. Шул өметләр белән яшәп калабыз.

Корычтай сәламәтлек телибез.

Хатны язучы Миңлекәшифә түтәгез дип белерсез.

Кәшифә апа әйтеп торганны язды: 5 а классы укучысы Әһлия Мозаффарова.

2 май, 1977 ел.

## ӨЧЕНЧЕ ХАТ

Исәнмесез, хөрмәтле Әнис абый!

Сезгә Җиреклекүл колхозы председателе Ильяс Җантурин яза. Борчуым өчен гафу итегез. Ләкин язмыйча да булмый, чөнки сезне бу эш белән кызыксына дип ишеттем. Минем сүздән башка дөреслек булмас дип беләм.

Уфа институтының агрономия факультетын бетергәч, егерме яшемдә мине «Партизан» колхозына баш агроном итеп кайтардылар. Авыл малаеның хыялын мөлдерәмә иткән бәхетнең үзе шушы бит инде — моннан ары миңа берни кирәкми. Басудагы һәр кыяк, һәр сабакның һәр буыны, һәр башак һәм аның һәр бөртеге — синең янында шыткан, синең күңелдән ашкан. Башкарган эшләрең, уйлаган фикерләрең, кичергән тойгыларың — барысы да күз алдында: тыңла, иңлә, буйла, бәхетле бул. Ләкин бу бәхет кыска гомерле булып чыкты. Ике ел узгач та, миңа кирәклене уйламыйча, миннән кирәклесе хакында сорадылар. Күз алдыгызга китерегез: сырма-куфайка кигән егерме дүрт яшьлек малай матайда көзге кыр иңләп чаба. Сезнеңчәрәк әйткәндә, бәхет киңлегендә оча ул. Кемнәр янындадыр тукталса да, киңәшсә, сорашса, кушса, үгетләсә, әрепләшсә-кычкырышса да, кимеме аның очышы, күзгә күренми җилпенгән канатлары ару дигәнне белми һәм беләчәк тә түгел. Ләкин шулай тоела гына ул. Кыр бетереп җилгән мәлдә, каршысына кара машина килә. Аны күрдеңме, шып тукта. Иптәш Рамазанов абзаң булыр бу. Үз алдындагы исеме шулай. Ә үзе юкта — абзый, хуҗа. Күрештек, матур гына сүзләр алмаштык. Хәвефләнерлек нәрсә сизелми иде. Тик азагы ямьсезрәк бетте, чөнки иптәш Рама-

занов машина алдына сөялде дә, үзенә хас сыек бер елмаюга шактый үк хәйләкәр караш өстәп, үзенә бик үк хас булмаганча, мактау сүзләрен кызганмас булды:

— Әйбәт эшлисең, яратып. Кырны лабораториягә әйләндерден, молодец. — Хәерлегәме дисез шуны?

Аның әйтеп бетергәнен сагаеп көтә-көтә, үзем дә анынчарак елмаям да (һәрхәлдә, миңа шулай тоела), сүз әйтергә өлгергәнче, мактауның нәтиҗәсен үк ишетәм:

— Безгә фән кушканча эшли торган председательләр кирәк.

Аңлашылды һәм... бетте баш.

— Юк, юк, минем өчен агроном эше җитеп арткан. Ә бүтәненә тәҗрибә җитәрлек түгел әле.

— Сиңа председатель буласың дигән кеше юк бит, кая чабасың?— Шул ук хәйләле караш, шаярта!

— Ә-ә, мин тагы... гафу итегез.

Ләкин, дөресен әйтим, шушында тәкъдименең чынга әйләнмәвеннән хәтта бераз гына кимсенеп тә куйдым шикелле. Менә бит ул кеше нинди — кирәкми, ә барыбер өмет итә... Яки: үзенеке булмасны да дәгъвалап яши... Аңламассың, белмәссең. Рамазанов әллә юри шул тойгы комсызлыгын уятырга тырышкан булдымы икән? Әгәр шулай булса, ул максатына ирешә дә язды, ахрысы. Шунда ук турыга китте:

— Гафу? Пожалуйста, Җиреклекүлгә председатель булып китәргә ризалык бирсәң, сүзсез гафу итәм.

Инде комсызланып та, инде елмаеп-көлеп кенә дә калу мөмкин түгел, инде дүрт аякны җиргә терәп чыгымлау фарыз. Шулай эшлим дә. Ләкин ул мине икенче көнне үк район үзәгенә чакыртып алды да (төптөгәл ике сәгатьтән соң инде мин җиңелгән, минем җилкәләр инде паласта), шул ук көнне Җиреклекүлгә үк дөбердәп барып төштек. Ундүрт авылдан торган колхозны икегә аерганнар да, башка чыга торганына мине чакыралар, имеш. Башта зурлык белән алдырмакчы булганнар да, хәзер ул мавыгу таркалды... Сәер, шул минутларда хәтергә борын заманда бер тапкыр да чыңламыйча гөрселдәп җиргә төшкән Патшакыңгырау килеп төште. Чамадан тыш зурдан купма, хур булуың бар— онытма, онытма.

Клуб. Вәкилләр — булачак һәр ике колхоздан. Бүленешү әллә ни зур каршылыкка очрамады — мал мактанырлык күп түгел икән. Әмма орденнары бар — шуны кая куярга, кайсы якка бирергә белмичә аптырашка калдылар. Бәхәсне туктатырлык чишелеш табылмагач, алга мине чыгарып бастырдылар:

— Нишлибез?

— Орден дисезме? Орден? Төп йортта калсын. Без, яшьләр — башка чыккан кешеләр — орденны үзебез алырга тырышырбыз. Безгә җаваплы эшләр тапшырган югары оешмалар ышанычын акларга тырышырбыз.

Алкышлар. Бәхәс шул ысул белән хәл ителде.

Төп йорт вәкилләре белән саубуллашкач, Җиреклекүлгә кайттык. Иптәш Рамазанов авылдагы барлык коммунистлардан ике көн элек үк ризалык алган булганга, гомум җыелышка туп-туры үзе тәкъдим итте. Чынлап та, бернинди каршы сүз әйтүче булмады. Гадәттә, мондый чакта гауга куба. Залда кичәге орден турында минем сүзләрне искә алулары колакка керде... Шуның да файдасы тиде шикелле. Бер сүз. Кайчак бөтенесен шул хәл итә. Һәм менә мин — Җиреклекүлдә.

Аны үз гомеремдә икенче кабат күрүем. Беренче күрешү монысына бик охшап бетмәгән...

Район үзәгендә, унынчы классны бетергән көннәрнең берсендә егерме чакрымлы шушы авылга мин бер чибәрне озата килгән идем. Велосипед белән. Хәтердә калган сурәт: өйләр иске, тәрәүле, гарип. Урамнар шәрә, чокыр-чакыр һәм бөтен нәрсә — кап-кара. Саубуллашкан чакта кызга:

— Авылыгыз бигрәк кара икән, — дигән идем, ул, исе дә китмичә:

— Ә син кил дә агарт! — дип кенә куйган иде.

Чукынмыш кызның юраганы юш килгәнне кара! Бу хәтле булса да булыр икән! Хәзер мин аңа, синең сүзне тыңлап килдем, дияр идем дә, күптән инде кыз үз авылында юк. Мин беренче курста укыганда ук кияүгә элдергән дә каядыр кала ягына китеп олаккан. Ләкин сүзләре калган: «Агарт! Кил дә агарт!» Тыңламый да булмас...

«Партизан»да хатын, ике бала барып алганны көтә. Ә мин, тиле, Зөлхиҗәләрнең өен барлап йөрим: капкалары тимер чыбыклар белән чорнап бәйләнгән, тәрәзәләрне такта томалаган... Ә әчтә чибәр кызның хатирәләре өшеп моңая... ялгызлыктан көзге җил сыман шыңшый. Менә сиңа Зөлхиҗә, менә сиңа яшьлек... Яшьлек? Әле соң мин егерме дүрт ел эчендә картаеп та куйдыммыни? Шулай, картайдым, шулай тиеш. Юк нәрсәне, булырга тиеш тә булмаганны бар итәргә тырышып эзләмә, шулай тиеш. Өй сал да хатыныңны, балаларыңны барып ал һәм эшлә, сүз бирдеңме — үтә. Шулай тиеш.

Йорт салырга сыңар кадак та юк. Квартирант булып буйдак хәлдә яши торасың. Йорт дигәненне оныт та зур хуҗалыкны кайгырт. Анысы бар, гәрчә хәле шактый ук мөшкел, башка чыгасы «малае»на өлкән председательнең игътибары, кулы җитмәгән: техника — тимер-томыр, исәптән төшкән соңгы трактор эскерт астында күмелеп калган. Эт белән дигәндәй эзләп, казып чыгардык. Ходай фәтва бирерлек итеп ремонтларга куштым. Артык зурдан кубу аркасында еллар буе рәтләнә, мантый алмаган ундүрт авыллы колхозны ундүрт ел иңләп-буйлап йөргән иске «Газик» — районда таркау калган бердәнбер колхозның бердәнбер автомобиле, калтыр-колтыр булса да кузгалды. Киттек. Киттек көзге пычракны ярып...

Малларны барлап куярга вакыт, ә Үрәзмәт атлы өлкән зоотехникның көзге бәйрәмнәрдә «ычкынган» чагы. Күрше авылдан әҗәткә икенче зоотехник сорап алдым. Рамил дигән яшь кенә егет сүз тыңлап килде. Шунысы хәтердә калган: аның килүе хөрмәтенә икенче көн таңында дуңгыз балалаткыч абзар җимерелеп төште — тыныч кына, тавышсыз-тынсыз. Гөрселдәве ишетелмәсә дә, өлкән зоотехник айнып адәм төсенә керде. Икәүләп эшкә тотындылар. Мәгәр безнең кесәләр кычкырып ук елады. Симерткеч абзарга ялгап араннар ясадык, ана дуңгызларны исән саклап чыктык. Ләкин үрчем дигәндә...

Вакыт алай ук тиз узмады. Ноябрь бит ул. Төп йорттан алган алты йөз сарыкны көтүе белән салам түбәле такта абзарга кайтарып тутырдык. Йөз процент исән чыктылар. Үрчемнең яртысы югалды, әлбәттә...

Кирпеч, цемент дигән нәрсәләр ул чакта сәер исемнәр буларак кына йөри иде бит әле. Иллә юк дип зарлана белмәдек — ике ел дигәндә, сәманнән ясап, сарыкны абзарлы, тавыкны кетәкле иттек. Әле дә сау тора шул абзарлар. Кирпеч абзарлар юешләнә, боларының эчләре копкоры. Нигезләре дә нык тора — бетон тасмалардан гыйбарәт, җирдән илле сантиметр калкытып салынган. Өч метр саен тимер торба утырттык. Шифер түбә. Сәманно-бетонный сарайлар дип йөртәбез. Ә сәрмая ягыннан карасак, аерата шәп — җиде мең тәңкә җитте. Кирпечтән салсаң, (кайчан булырын көт идең әле ничә ел!) җитмеш меңне чыгарып салырга тиеш идек. Ун мәртәбәгә кабатлап! Анысы килер көннәр куншылыгына калып торсын, дибез, малайкай.

Кыш. Каладагы бөтен танышларны йөреп, горурлык дигәнне шулай ук киләчәккә калдыра төшеп, яңа чәчкечләр юлладым. Абзый бу

кыланышымны ошатып: «Сәүдәгәр, эшкуар!» — дип «мактады» һәм «Харков-46» сортлы бодай орлыгын үзе табышты. Гидросистемалы, трактордан гына идарә ителә торган дүрт яңа культиваторны исә бары тик үзе генә юллап безгә бүләк итте. Кәгазьдә менә барысы бик җиңел табылды, ә чынында күпме ут йоттык!

Былтыр участоклар тырмалап кына чәчелгән. Бик үк тиз баерга насыйп түгел ул безгә. Киләсе ел өмете белән бәхетле бул, эшкуарлыкны ары табан үстерә төш. Кичерегез, ашыгып, алга йөгерелгән. Беренче күзгә яңадан кайтыйк әле — күп нәрсә шунда төенләнгән булып чыкты. Җилне мин шунда шактый мул чәчкән икәнмен — давыл җыеп алыр өчен.

Шул караңгы шыксыз көннәрнең берсендә минем квартирга Госман Фәсихов дигән кеше килеп керде. Озын балтырлы саз итеге, күн бүрек, кыска тун кигән кеше, яшь ягыннан минем тирәләрдә. Утырды. Мин чәй янына чакыргач, ялындырмый гына күчеп утырды һәм кесәсеннән шешә чыгарды.

Гомергә бер күргән кешегә каты бәрелү кыен бит — карышмадым. Кырлы стаканның яртысын капладык та сөйләшә башладык. Ул мине авылдагы хәл-әхвәл белән, кешеләр белән таныштыра. Кемгә ничегрәк эндәшергә, кемне сыйпарга, кемне камчыларга икәнен санап чыккач, өстәп куя:

— Сиңа әйбәт кенә, тыныч кына эшләп китәргә кирәк бит инде. Ә мин ярдәм итәрмен.

— Ярый, рәхмәт, — мин әйтәм, — үзем дә өйрәнермен, кешеләрне тиз таныйм мин.

— Дус булсак, шәбрәк килеп чыгар, кара аны, сынатма.

Аракыны калдырып чыкмакчы иде дә, аның куен кесәсенә тиз генә үзем тыктым:

— Мин моның белән дус түгел. Бигрәк тә хәзер.

— Дөрес, алай да була. Шәп. — Шулай дигәч, кулындагы сәгатен салып сузды. — Мә, алайса, монысы булсын танышу истәлеге.

— Юк, юк, рәхмәт, кирәкми.

— Сәгатең безнеңчә йөрсә, ялгышмассың. Курыкма, ал.

Монысы үзенә күрә янау микән инде? Шулай да сәгатьне кире суздым:

— Соңрак, бераз таныша төшкәч, үзем сорап алырмын. Башта минем сәгать белән йөреп карыйк. Килештекме?

— Килештек. Алай да була, шәп. Минем кулда — синең сәгать дип уйлыйк.

Фәсихов чыгып киткәч, хуҗабикә ападан бу кешенең кемлеген сораган идем, апа, «шуны да белмисеңмени?» дигәндәйрәк, әйтеп куйды:

— Ә? Бумы? Бу — синең булачак түрән.

— Минем булачак түрәм? Шушы ук авылда?

— Бу — гаделлек сакчысы. Синең бар эшеңне тикшереп торачак.

— Минем эшкә бөтен авыл контрольлек итәр. Аның өчен тагы бүтән оешмалар да юк түгел. Ә бу кеше...

— Монысы дабрабүле, бер тиен акчасыз... Күрерсең әле.

— Ә төп һөнәре?

— Төбе шундый инде аның.

— Ә тагы? Нинди эш белә?

— Белмәгәне юк. Киномеханик, сәгатьче, тракторист...

— Булса да була икән егетнең уңганы!

Мине ышанмады дип белдеме, апа сүзен ныгытырга тиеш тапты:

— Әйе, сәгать төзәтә. Самурай да төзәтә.

— Самурай? Анысы кем тагы?

— Кем дип... ни. Белерсең әле. Белдерә торганнар алар.

Фасихов Госман мин килгәнче үзен председатель итеп куйдыру кампаниясен башлаган булган һәм шул эшен туктатып та өлгермәгән чагы икән. Апа әйтеп бетермәгән һөнәрләре тагы калган әле: поездда кондуктор, авылда комбайнчы, агроном... Һәм... күптән түгел яңа һөнәре сизелгән. Элекке председательнең каядыр киткәнен чамалаган да бу, чарлак аша өй түбәсенә үрмәләгән, чолан башына узган. Өйдә — хатын, балалар, өйдә — мылтык. Хатын ишекне ачкан да чолан тактасы аркылы шатырдаган тавышка төзәп атып җибәргән, һәм гөрселдәп нидер килеп төшүгә куркып: «Үлде!» — дип кычкыра-кычкыра, янгын сүндерү алачыгына чапкан. Килеп карасалар, чоланда беркем юк. Ә шап иткән нәрсә элеп куелган ит, сыер билдәмәсе икән. Шуны алып чыкмак булганнар, күрәсең.

Каракның кем икәнлеге тәгаен билгесез. Иллә шул тирә көннәрдә бәйләнгән кул белән берәү йөри... Фәсихов дус. Күзләре бик тә карак мәченекен хәтерләтә, имеш.

«Самурай» дигәне — Сәлимгәрәй Байсламов икән. Анысы баш бухгалтер булырга хыялланган һәм хәзер дә шул теләгендә. Максаты — якында, кеше барыбер кирәк...

Фәсихов икенче кичне тагын килде. Бу юлы күчтәнәчсез генә һәм кыяфәте дә җитди иде. Хәбәре шул:

— Мин авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укыйм.

— Ничәнче курста?

— Өченче.

— Кара, сине агроном итеп тә куеп була икән бит, — дидем, бераз уйлап җиткермичә.

Үземне күпмедер тәҗрибәле агрономга исәпләгәнгә күрә, икенчесе шул дәрәҗәдә булса да ярар, иң мөһиме, кушылганны тыңлый, оештыра белсен, җоррак кеше булсын дип уйлый идем. Һәм тәкъдим аны гаҗәпләндермәде. Алай гына түгел, зуррагыннан ук баш тартмасын сиздерде:

— Алай да була. Партком секретаре да юк бит әле бездә.

Элекке председатель белән киңәштем. Ул Фәсиховка бер генә сүз белән характеристика бирде: «Оппозиционер».

— Җаваплы эш бирсәк, оппозиционер уңай көчкә әйләнмәсме? Тарткалашны булдырмау, тыныч яшәү чарасы да шул булмасмы?

— Курыксаң, шулай эшләп кара.

Курыкмыйм, ләкин шау-шуга вакыт кызганыч, барлык көчне көчсезлекне бетерүгә туплыйсы бар. Шулай да икеләнә идем әле. Секретарь булырлык кешене читтән китермәсләрме дип мөрәҗәгать иткәч:

— Урында табарга тырышыгыз, үзең дә читтән. Җирле патриотизмны рәнҗетә күрмик, — диде иптәш Рамазанов.

Ә Фәсихов кул арасында бутала, футбол уеныңдагы шикелле, ачык позициягә чыга да инде сүзсез генә һәм ярыйсы ук оста итеп, үзен тәкъдим итә. Партҗыелышта бюрога да сайланды. Бюро утырышында беренче тәкъдим менә — Госман Фәсихов. Тәкъдимнең нигезләре белән кызыксыналар.

— Институтта укый, актив. Сәеррәк гадәтләре бар дип сөйлиләр. Бәлки сүз генәдер. Сынап карыйк. Булса, төзәтергә тырышырбыз. Ышанычны аклый алмаса, без бит әле барыбыз да шушында, күз йомып тормабыз.

Каршы килүләр, икеләнү, бәхәсләр булды, тик чынлап сыналган кандидатура күрмәгәч, бүтәннәр дә минем «сынап карыйк» дигән формулировка белән канәгатьләнеп, Госман Фәсхи улы Фәсиховны партком секретаре итеп сайладык. Ә аның тәкъдиме буенча Сәлимгәрәй Байсламовны баш бухгалтер итеп куйдык.

Һәр икесенең моңарчы яшерен дип исәпләнгән дәгъвалары үтәлде. Уңышлар телик. Дәвам итик. Дөньялар тыныч булсын.

Ферма. Вәҗиһә исемле чибәр кыз, мине күрепме, савымны тәгәлләпме, кызыл почмакка керде. Мин, гадәтемчә, газета актарган булып, районлагы «маяк кызлар»ны аңа күрсәтәм. Вәҗиһә, ниятемне тиз аңлап, уйламыйча гына әйткәндәй тезеп китә:

— Механизация кертсәгез, тирес чыгарудан безне азат итсәгез, кул белән башак салудан коткарсагыз, сыерларның нәселен яхшыртсагыз, һич югы, нәселле өч-дүрт тана бирсәгез, үзем сава торган сыерларны арттыра алам. Биш елга билгеләнгән мең ярым центнер сөтне унбер сыердан дүрт елда савып бирәм.

Сүзләре нинди фикер кузгатканын уйламастан, чыгып та китте. Каян шундый тәгәллек? Кешене вак-төяк белән генә гомер үткәрә дип йөрсәң... жайсыз хәлдә калуыңны көт тә тор. Ә ул сиңа менә нинди тәгәл исәпләр китереп куя, ул синнән күбрәк уйланган булып чыга. Инде син аннан өйрән. Бер савымчы шулай әшли ала икән, башкалары нишләп булдыра алмасын? Алары ни әйтер? Председатель үзе ни әйтер? Ни? Уйла, туган, исәплә!

Ни исәпләргә белмирәк утырганда, тагын ишек ачылды да... баш күтәрсәм... Вәҗиһәдән дә ныграк каушатып, ят бер кыз килеп керде. Ят дип, үземне алдарга азапланам, әлбәттә. Нишләп ят булсын, бу авылда син үзең ят, ә ул әнә сиңа бурыч йөкли: «Агарт авылны!» — дип, зурларча хәйләкәрләнеп елмая.

— Зөлхиҗә!

— Исәнме, Ильяс. Нишләп болай аптырап утырасың? Ә?

— Авылыгызны ничек агартырга икәнен белмичә... Ә син?

— Мин сиңа булышырга кайттым.

— Озаккамы?

— Эш бирсәгез, озакка булуы мөмкин.

— Нинди эш кирәк сон?

— Теләсә кайсы. Менә шушында, савымчы итсәгез дә шәп булыр ие.

— Әйбәт. Молодец. Әйдә, бергә-бергә...

Шушы сүздә кызлар килеп керде. Вәҗиһә сөйләшкәндер инде, болары да аның баягы сүзләрен кабатлыйлар.

Председатель уйлый, исәпли. Председатель риза, мәҗбүр. Күз курка, кул эшли. Һәм бүгеннән соң кызлар арасында — Зөлхиҗә... Ферманың якынлыгы, матурлыгы тагын артачак.

Партҗыелышта көн тәртибе: кызлар таләбен үти алабызмы? Алабыз. Бишьеллык заданиесен дүрт елга бүлеп, сибеп чыктык та ниятне райкомга житкердек. Иптәш Рамазанов район буенча инициатива белән чыгарга тәкъдим итте. Безгә нәрсә — йөкләмә инде эшләнгән, шуны идарә утырышында расладык та райкомга җибәрдек. Район газетасында йөкләмә-мөрәҗәгать басылып чыкты. Тиз арада ул өлкә комитетына барып житкән. Атна-ун көннән соң республика күләмендә чыга алмыйсызмы, дип сораганнар.

Без риза — шул ук саннар бит.

Моңарчы эмблемасы ташбака булып килгән авылларыбыз республика масштабындагы инициаторларга әйләнде. Исәпләребез олы газеталарда эре хәрефләр белән басылып чыкты. Менә нинди сүзләр:

Производство күрсәткечләре югары булу белән бергә, социаль, мораль бурычлар да үтәлергә, хәл ителә барырга тиеш. Техниканы, инвентарьларны саклау, вакытны, байлыкларны экономияләү — әхлакый бурыч. Ярыш йомгакларын тикшергәндә, бөтенесе исәптә торачак: кеше буларак үстеңме? Квалификацияңне күтәрдеңме? Өченче класслы механизатор, икенче, беренче класска күчтеңме? Читтән торып техникумга яки кичке мәктәпкә, яки институтка укырга кердеңме? Һәркем үз профессиясе буенча газета-журналлар аламы? Экономик укуларга,

җәмәгать эшенә (пропагандист, агитатор, спортчы, үзешчән сәнгать һәвәскәре һ. б. эшләргә) катнашамы? — Барысы, барысы искә алыначак.

Бу күрсәткечләр бөтен авылга һәр вакыт билгеле булып торачак. Бигрәк тә — кешенең тәртибе: штрафка тартылсаң, милициягә, ГАИга эләксәң, сурәтеңне бөтен колхоз күреп, күзеңне ачырмаячак. Алама тойгыларыңны тыя, башыңны эшләтә бел. Буш вакытың техниканы рационализацияләштерүгә китсен, фикер үстерсен.

Бишьеллык азагында, тантана вакытында, хезмәтеңә хөрмәт билгесе булган алкышларга өстәп, беренче урынны алган савымчыга телевизор, икенчегә — радиола, өченчегә — транзистор, дүртенче, бишенчегә — кул сәгатьләре. Беренче механизаторга — мотоцикл, икенчегә — радиоалгыч һәм башкалар.

Беркөнне Зөлхиҗәне фермадан кайтышлый күреп:

— Ничек, авыл яктыра түгелме? — дип сораган идем, ул да:

— Яктыра, Ильяс, яктырачак болай булгач,— дип, күңелне күтәрмәкче иде, ләкин минем нигәдер кәеф кырылды гына.

Нигә икәнен ул узып киткәч кенә төшендем: кайчандыр минем өчен сөекле булган бу кыз... минем бу көннәремә үзе генә түгел, ниндидер ят кеше хатирәсе, дүртме-бишме яшьлек баласы белән килеп чыккан икән!

Хәлләр, тойгыларны нинди дә булса төеннәрдән, җайсызлыклардан коткару кирәге... мине рәнҗетә.... Ник, ник болай? Тфү, шайтан, адәм баласы үзе өчен күп чакта үзе табышмак. Ник икәнен үзе аңлата алмый ул... Факт шул: Зөлхиҗә синең өчен барыбер чит кеше түгел, ниндидер мәгънәдә барыбер кадерле ул синең өчен. Ник икәнен бүтән иркенрәк вакытта уйлап карарбыз. Синең әле башка проблемаларың җитәрлек. Шуның беренчесе — Фәсихов дустың...

Фәсихов фермага барган да, йөкләмәләрнең көндәлек үтәлешен сораша. Шулай мөмкин һәм тиеш. Ләкин ул ничек кылана? Салмак атлап, тамак кыра-кыра гына сөйләшкәч, олпат кешегә әйләнәм дип уйлый, бичара. Кыяфәтеннән кызлар чырык-чырык көлгәч, ачуы кузгала һәм үзенең бәләкәй нөсхәсенә кайтып, кыза-кыза кызара:

— Я, ни дип көләсең, тиле баш, чыпчык муен. Кая куйдың мескен башыңны, ник аны чүлмәккә алыштырдың? — Кызларның һәммәсенә диярлек бәйләнеп чыккач, Зөлхиҗәнең күзенә керердәй булып: — Сиңа ни җитми, ник тулмый сөт? — дип кычкыра.

— Кая тулмый сөт, чүлмәккәме? — дип шаяртмакчы булган кызга инде чын мәгънәсендә акыра юньсез:

— Андый-мондый җиргә түгел, чиләккә тулмый сөт, бидрәгә. Кая булсын тагы?

— Чиләк булмагач, ничек тулсын? Юк бит чиләк, җитми. Кайчаннан бирле туглыйбыз, май төшми сүздән.

— Минем эшем сезгә бидрә эзләү түгел.

— Утырып саварга урындыклар сорадык. Кайчаннан бирле.

— Урындык ясау да минем шөгыль түгел. Сез миңа сөт бирегез и шуның белән вәссәләм.

Шунда үзенең бәхетсезлегенә каршы, Зөлхиҗә:

— Синең эшең нинди соң? — дип, чынлап сорыймы, әллә шаярта гына микән?

Ләкин егетнең шаярырга вакыты юк:

— Минем үз эшем, мин — парторг!

— Парторг? — Инде куралэтә үртәп, Зөлхиҗә тагын мәзәк сорау ташлый: — Син киномеханик түгелмени?

Кызлар Госман өчен сәйләп тезә:

— Сәгать төзәтүче.

— Сурәткә төшерүче.

— Тракторист.

— Комбайнер.

Чукмарлар белән түгәрәкнең төрле ягыннан үзенә ташланган аучыларның кайсына ыргылырга белми аптыраган ерткыч җәнлек кебек, нишләргә белмичә, бер кызарып, бер агарып озак кына интеккәч, зәһәрләнеп, Зөлхиҗәне чукырга керешә Фәсихов.

— Син үзең кем? Юньле кеше читтән бала алып кайтамы?

— Ник әллә... — шаяруы йөзеннән китеп тә өлгермәгән кызның чырае әллә ничек елмаю белән елау кыяфәтен берләштереп, кызганыч төскә керә. — Әллә кеше иреннән аерылмый торамы? Бер дә...

— Ир... Булганмы ирең, юкмы, әллә бар булганы Җантуринмы? Без аны каян белик?

Нәрсә дә булса әйтә, җаваплаша алудан узган Зөлхиҗә, үксеп, чыгып кына котыла. Үкси-үкси, урам буйлап чаба. Күргән бер кеше хәйран гына кала, тел генә шартлата. Кая, ник йөгерә ул шулай?

Ник килгәнен оныткан Фәсихов китәргә азапланса да, кызлар, аны төрле яктан урап, күз ачырмыйча тиргәргә керешә:

— Кара син аны, оятсызны, ничек рәнҗетә кешене!

— Үзе парторг, имеш!

— Парторг булсаң, син аның ире булу-булмавын әллә кайчан белгән булыр идең, булмаганын белсәң дә эндәшмәс идең.

— Пычракка бутап ташламас идең.

— Җантурин җаныңны суырып алыр әле!

Фермадагы вакыйга миңа кич белән генә килеп житте. Идарәдә гадәттәге бер сөйләшеп, киңәшләшеп утыру гына иде. Киләсе яз хакында киңәш корабыз. Фәсихов та шунда.

Менә бервакыт каты-каты аяк тавышлары ишетелде, ишек артында: «Фәсихов шундамы?» дигән сорау яңгырады, ни дә булса уйлап өлгергәнче ишек ачылып, аннан Зөлхиҗә атылып керде һәм, туп-туры килеп, кулындагы ниндидер кәгазьне Фәсиховның битенә китереп капларга да өлгерде. Күз ачып йомган арада:

— Мә, укы, ирем булганмы-юкмы, шуннан соң белерсең, әшәке! — дип, шулай ук күз иярә алмастай тизлек белән чыгып та китте.

Язуны алып карасалар, бу, Зөлхиҗәнең судта иреннән аерылу сәбәпле, ата кешедән алимент түләтә торган карар булып чыкты. Зөлхиҗә шуны бөтен кеше алдында парторг битенә ябыштырды. Болай гына кала торган нәрсә түгел иде бу. Сораштырып карасак та, Госман үзе рәтле җавап бирә алмады — ык-мык.

— Котыргандыр. Мин каян белим аның ник дулаганын? — дип, гөнаһ белмәс кешедәй тик тора.

Икенче көнне фермага менсәм, унбер сыер савылмаган. Сәбәп — Зөлхиҗә эшкә чыкмаган. Парторгның ташбака кабырчыгын салып кына өлгергән колхозга беренче зур «ярдәме» иде бу. Кызлардан гауганың сәбәпләрен сорыйм. Эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, Зөлхиҗә янына үзем киттем.

Капка төбендә ике малай үз эшләре белән мәшгуль иде. Аларга игътибар итмәдем, дөресрәге, игътибар итмәскә тырыштым. Ләкин аларның берсе, менә шушы нечкәрәк тавышлы, кыз балаларныкы күк нәфис, матур йөзле бала миңа ни өчендер кинәт якын сыман тоелып китте. Кайчандыр үзем гашыйк булган таныш чалымнар булганга микән? Уйласаң, миңа аны якын итәрлек бер сәбәп тә юк лабаса. Бөтенләй ят кеше катнашкан...Ләкин аңлап булмаслык тойгы нәрсәдер сөйли сыман.

Капканы ачыйм дигәндә, бала телгә килде:

— Әнинең башы авырта, йоклый да алмый, эшли дә алмый, — дип куйды ул.

Бик аңлашыла иде монысы.

Зөлхиҗәнең чырайдан язган кыяфәте, яшьләреннән арынып өлгермәгән күзләре бөтенесен сүзсез аңлата иде. Мин килеп кергәч тә гаҗәпләнмәде һәм, тәрәзә төбенә мамык тутыруыннан тукталмыйча, кырыс кына исәнләште. Мин аның мондый салкын карашына күнекмәгән, әлбәттә, миңа кыен, мин әйтерсең гаепле. Кышкы салкыннардан котылу чарасы буларак куеласы эчке тәрәзәләре дә өйне җылытмас шикелле тоелды. «Ничек яшәрсең икән син бу салкын өйдә кыш буе һәм бер ялгызың?» Үзем дә сизмәстән, минем Зөлхиҗәне парлы итәсем килде шикелле. Ә ничек?

Ләкин Фәсиховның фермадагы сүзләрен ишетмәгән килеш, нәкъ менә шушы секундта бу өйгә ялгызым гына керүемнең хата эш икәнен чамалап, йомышны кыскарак тотарга тиеш таптым. Тәрәзә рамын күтәреп, җай белән кадаклар кагып ныгыткач, инде гүяки мораль хокук яулагач, хәлне сорашырга керештем. Сораша гына башлаган идем, яңадан еларга тотынды Зөлхиҗә:

— Җир күтәрмәстәй бозык кеше үзе, ни сөйләнә, ишетсәң, колак пәрдәләрең ярылырлык. Үзе тагы кычкыра.

— Ник кычкыра? — дип мәгънәсезрәк сорасам да, Зөлхиҗә йөз чөермәде, эшне аңлатуында булды.

— Шул кечкенә нәрсәләр аркасында кем уйлаган аны дөньяга сыймас олы гауга куптарыр дип. Ә хәзер ул минем кеше арасына чыгарлыгымны калдырмады.

— Ярый, аның әле тәҗрибәсе бик бәләкәй, ачуланмыйк.

— Ә тәҗрибәсеннән үзе бәләкәй булганны ник олы урынга куясыз? Чыпчык бөркеткә әйләнер дип беләсезме әллә?

— Бәлки үсәр, түзик, сабыр итик. — Зөлхиҗә шомырт күзләрендә ак ут уйнатып карагач, өстәргә тиеш таптым. — Ә сез әйткән чиләкләр булачак. Тиз, шушы ике-өч көн эчендә. Я, тотындыкмы эшкә? Малларның гаебе юк бит. Минеке дә.

— Юк шул, ярый инде синең хакка...

Сүзләрен әйтеп бетермәстән, эшен ташлап, юынгыч янына ашыкты һәм тиз арада күзләрен-битләрен юып сөртенгәч, малаен житәкләп фермага таба менеп китте. Миңа да шул якка барасы иде. Ләкин, ни өчендер, түбән очка таба атладым. Һәм шунда үзем дә аның һаман минем өчен куркыныч булып калганын аңладым. Димәк, бу йортка мин бүтән килмәячәкмен. Бу йортны кышка әзерләр өчен иң оста балтачыны җибәрсәм җибәрәчәкмен, ләкин... Гаҗәп инде бәндә... Әллә нинди гөнаһсыз, чиста матурлык белән тарта Зөлхиҗә күңелне — һаман укучы бала булып калды микәнни ул һәм шулай үсмер чактагыча саф матурлык булып калачак микәнни? Гомер юлына чыгып барганда очраган нәни серем минем. Шул кечкенә сер дә бикле калырга тиеш, югыйсә, бер гаепсез баланы шикле нәрсәгә әйләндергән кебек, шул ук усал телләр аңа да пычрак ыргытудан җиксенмәсләр. Болай булгач, алардан теләсә нинди этлек көтәргә мөмкин. Серне сакларга, сакларга кирәк — умырзаядай саф, гөнаһсыз, гаепсез хәлендә. Һәм...

Ары китик.

Госман дигән Фәсихов авылда ялгыз түгел, әшнәләреннән тыш, туганнары бар. Шуларның берсе — этиләре генә башка булган, бер анадан туган энесе Рәвит урманнан күрше колхоз утынын урлап кайткач, абыйсы шуны яшерешкән вакытта, икәүләп тотылганнар. Бүтән кеше булса, шомарак хәл ителәсе нәрсә, парторг өчен тагы гафу ителмәде — бөтен тирә-якка шаулап фаш ителде. Адым саен эшләгән аламалыкларын үземә дә күтәрешергә, артыннан кала торган җимерекләрен төзәтә барырга туры килә. Хикмәт, кырыкмаса-кырык эш артыннан көнтөн чабудан бигрәк, шул бәндә кузгаткан шау-шулардан чирли башладым. Институттан соң өч көн дә ял итмичә эшкә тотынуым искә төште һәм алда тагы да зуррак сынаулар торганын аңлагач, язгы көрәшләр-

гә үземне әзерләр өчен санаторийга китеп бардым. Кайтуыма Фәсихов бүтән кызыклы номерлар әзерләп куйган иде. Һәм мин инде аларын үз җаваплылыгыма кабул итә алмадым. Яңадан тиз генә санаторийга китү җае күренмәгәнлектән һәм инде дәвалану өчен теләк тә, вакыт та калмаганлыктан, егетнең «батырлыкларын» үз көчендә калдырдым. Райкомнан вәкил килеп житте. Хисап чоры ерак дип тормыйча, җыелышка куйдылар, секретарьлыктан азат иттеләр. Аны бу вазифага тәкъдим иткән кеше буларак, миңа кызарып кына утырырга калды, бөтенләй диярлек сүзгә катнашырга туры килмәде. Сәгатьче яки киномеханик булып яшәсә, үзенә дә, бүтәннәргә дә тынычрак, хәерлерәк булыр иде, ә дәгъвалары бүтәнчә булгач, менә нинди җаһйсызлыклар килеп чыкты. Табигый сәләт белән ныгытылмаган дәгъва харап итә кешене, харап итә... Җантурин абзый шулай сөйләнә хәзер.

Авыз пешкәч, инде житәкче эшкә якын китермәскә тиеш табылса да, иптәш Рамазановның: «Орлыкчы агроном итеп куй инде, таш атса да, аш атып кара, бәлки сабак алгандыр»,— дигән сүзеннән соң кискен уйдан кире кайтырга туры килде. Тик Фәсихов бу яхшылыкны да аңлап кабул итә алмады, ипидер шулай.

Яз. Агроном дигән Фәсихов орлыкны ашлама белән бутый һәм агу өстәп чәчкечләргә тутыра. Төгәл генә болгату мөмкин эш түгел — ашлама күбрәк, орлык аз, яки киресенчә. Элек шулай булган, Фәсихов шулай ук дәвам итмәкче. Эшкуарлыкны дәвам итеп, комбинирлашкан яңа чәчкеч «СУК-24» дигәнен кайтарткан идем. Анда орлыкка, ашламага — аерым әрҗәләр, икесе дә аерым, тигез коела — көйли генә бел. Шуның рәтен белмәгәнгәме, Фәсихов иске чәчкечләргә тотынган иде, бик тиз чик куйдым. Әмма яңача эшләргә өйрәткән өчен рәхмәт әйтергә тиешле кеше, киресенчә, кара коелып йөрде. Һавалыгы эшкә өйрәнергә комачау итә.

Чәчү алдыннан да, соңыннан да җирне кәтүкләүне керттем. Ә агроном исемен йөрткән кеше, җирне катырып куябыз бит, дип лаф ора. Аңлатам: «Кәтүкләгәч, орлыкны тиешле тирәнлеккә тигез төшерү җайлаша, чөнки җир тигезләнә, дым да озаграк саклана», — дим. Ә ул аңларга түгел, җиңелмәскә тырыша. Фактта үзем агроном, үзем механизатор — чәчкечләрне, культиваторларны көйләп йөрим. Каладан самолет чакыртып, бөртекле иген җиренең яртысыннан артыграгына, гектарга сиксән килограмм исәбеннән, күктән ашлама индердек. Әйтү ансат. Очучыларга ашламаны тизрәк сибеп бетерү дә акча алу кызык. Көз уңыш исәбен алар алмаячак. Карап тормасаң, тонна сыешлы бункерның фарсункасын теләсә нинди зурлыкта ачалар да әйләндерәләр генә. Кайчак күрше колхоз җиренә сиптерәләр. Нык тарткалашырга туры килде. Ә Госман дусның куллар кесәдә. Бөтенесенә — үзем...

Шунысын мактанып әйтә алам: самолет белән гербицит сиптерүне Фәсиховка тапшырмадым, яфраклы куак-агачларны харап иттермәдем. Җир өсте агрегатлары белән, анда да бик чүпле урыннарны гына эшкәрттек.

Урак.

Урак өсте життеме, минем тәҗрибәсезлек өскә калкып җанны кыздыра, әйтерсең ки челлә кояшы. Колхоз аерылган чакта безгә гел иске механизмнар эләгүнең төп сәбәбе — белем җитмәүдә. Инженер төп йортта калганлыктан, без сан ягын гына кайгыртканбыз. Наданлык фаш ителгәч, яңа комбайннар алырга, ярый әле, иптәш Рамазанов белән «Сельхозтехника» ярдәм иттеләр. Анысы да булды. Инде механизаторлар житми. Җилкә кашый торгач, тоттым да туган колхозыма — «Партизан»га чаптым:

— Агаем, зинһар ярдәм ит.

Үз ураклары бетеп бара иде инде — ярдәмгә килделәр. Менә дигән эшләп, хуҗаларга сабак, һөнәр дә калдырып киттеләр. Төзергә дә ке-

шеләребезне шулай кунаклар чакыра-чакыра өйрәттек. Хәзер аллага шөкер... Өйрәнергә теләүчеләр дә бар бит, әй генәм.

Шулай, инде мин Фәсиховның агрономлыгына исәп тотмыйм. Аның төп эше — ведомостьларга кул куя белү һәм мотоциклда теләсә кая тыр-тыр чаба тору. Шактый чапты шулай.

Иген чәчкән көннәр. Бодайның «Саратов-33» сортын һәм «Элита»-ны кыенлык белән тапкан идем. Икесен дә аерым чәчәргә куштым. Фәсихов чәчү нормасын бутаган — шуның аркасында, җир беткән, орлык калган. Ә ул, аптырап тормыйча, калган орлыкны шул ук җирләргә аркылыга чәчтергән!

Елап-ялварып алган «Элита»ны орлыкка чәчәргә кушкан идем. Унике гектар җиргә. Ә ул, ни уйлаптыр, анысын тәки белә алмадым, «Чишмә-210» белән кушкан. Шулай ул чәчүлек орлыкны яңадан юлларга мәҗбүр итте. Җитмәсә, шуны яшереп калмакчы. Фәрит исемле яшь механизатор килеп әйткәч, чәчләрем үрә торды. Бәлки гомеремдә беренче кабат, үземне белештермәс дәрәҗәдә ярсып бардым да чәчелеп бетә язган басу уртасында тегенең якасыннан эләктереп, җан сүрелгәнче тукмаган да булыр идем, ярый әле, Фәрит ирек куймады. Файда? Файдасы шул: икенче көнне кич Фәритне төнге сменага калырга кушкан да, тегесе көн буе эшләп алҗыган булу сәбәпле, бүтән эшли алмам, дип әйтергә өлгергәнче, монысы чынлап хәлдән тайган егетне кабинадан өстерәп тә төшергән һәм туйганчы тукмаган да. Үзенең дә күз төбендә зәңгәр мөһерләр пәйда булган, әлбәттә. Шуннан файдаланып, икенче көнне таң белән врачка, аннары халык судына тырылдап чапкан. Колхозны чәчүлек орлыксыз калдыру кебек уңышына оятсызлыкта анысыннан һич калышмаган икенче «җиңүгә» ирешкән: уттай эш өстендә менә дигән механизаторны трактордан аерды, бәдбәхет. Унбиш көннән соң Фәрит авылдан ук китмәкче иде, сизеп калдым да, чын мәгънәсендә ялварып кына калырга күндердем. Ә Госман дигән Фәсиховны, һәр ике батырлыгын искә алып, звеновод итеп күчердек. Акрынлап төп нөсхәсенә якынлаша кеше.

Соңгы көннәрдә «Волга»лы булуыбыз сәбәпле, эшләвемнең беренче аенда ук алган «Москвич»ны алдынгы бригадирларның берсенә сатарга карар иттек. Беренче урында барган бригада җитәкчесен, Заһитов дигән кешене чакырып сөйләштек. «Бәясе өч мең тугыз йөз сум. Ризамы?» — «Риза.» — «Киләсе идарә утырышында карар чыгарырбыз».

Ике авылыбызда культура йорты булдыру мәшәкатьләре белән калага барырга кирәк иде. Бер атна шунда йөреп кайтуыма — тагын яңалык: амбар каршында «Москвич» юк. Фәсихов алып китте, диләр. Заһитовны ничектер ахирләгән бу кеше һәм ахирәте Сәлимгәрәй аша акча да түләп өлгергән. Сәлимгәрәйне чакырдым — бәләкәй гәүдәсен бөтенләй бөрештереп, күздән үк югалмакчы иде, ләкин миннән ычкыну алай ансат кына түгел.

— Нишләп болай закон бозасыз?

— Үзләре килешкәннәр. Ә колхозга акча булгач барыбер түгелмени — советский акча бит.

— Кирәксә миңгә ярыл, тезлән, ялын, мәгәр «Москвич» үз урынында утырсын. Булдымы?

— Ярый, карарбыз.

Аның, әлбәттә, карарга нияте дә, куәте дә юк иде. Участковый белән сөйләшергә туры килде. Икәүләп барсак, ихата тулы машина частьлары чәчелеп ята, теләсәң ничек җый. Оясыннан чыгарга базмыйча мотоциклы белән булашкан Фәсихов янына үзебез уздык. Безнең беләнни өчен исәнләшә алмавын майлы кулларын сөртә-сөртә аңлатмакчы иде, без шунда ук турыдан киттек:

— Хәзер үк машинаны җый да амбар янына илт. Эшне катлауландырма, ялгышма. Килештекме?

— Барыбер сата идегез. Акча принято — өч мең дә тугыз йөз. Әллә бирәр тиене ким чыгамы?
— Гариза язган иденме?
— Бюрократияне җенем сөйми.
— Идарә колхозның иң алдынгы кешеләрнең берсенә сатарга дигән карар чыгарды. Ә син шундый маякмы?
— Булмаса, булырбыз.
— Нишләптер, бер дә булырлыгың күренми бит әле. Ә?
— Күренер, күренми калмас.
Күпме сүз әйтелмәсен, ул аларның берсен дә колагына элмәде. Кулындагы майлы чүпрәккә ябышты да катты. Сүзләр шак-шок бәрелә дә коела тегенә. Өстәвенә, рәнҗегән булып чыкты — звеновод буларак та эшен ташлады. Урынына бүтән кеше алдык.
Кыш үтте дә яз җитте. Чама белән тынычрак бер көнне миңа, суд утырышына килүемне сорап, кәгазь килеп төшмәс диген син. Законны бозган Фәсихов үземне судка биргән: «Фәлән сумга сатып алган автомобилем белән йөрергә рөхсәт итми, алты ай буе белгечлегем буенча эш бирелмәү сәбәпле, тик яткан көннәр өчен колхоздан акча түләтүегезне, «Москвич»ны законлаштырып, техник паспортын, техник талоннарын алып бирүегезне сорыйм».
Үзебезнең гаепсез икәнебезне раслау өчен шактый вакыт һәм сүз исраф итәргә туры килде!
Суд карары. «Шикаятегез нигезсез дип табылды. Эшләмәвегез бары тик үзегезгә бәйле. Колхоз автомобилен сатып алуыгыз гамәлдә законсыз. Автомобильне колхозга, аның хуҗасына кайтарып бирергә».
Шуннан соң егет бераз юашланды: «Нинди эшкә дә риза, тик автомашина гына бир — мең тәңкәлек запчасть кына алдым бит», — дип ялына башлады бу. «Карлы ихатада таралып ята торгач, тутыгып рәттән чыккандыр» дигән уй да туганлыктан, һәм шуңа «яхшылык эшләсәм, бәйләнүләреннән бәлки туктар» дигән өмет өстәлгәнлектән, идарәнең чираттагы бер утырышында үземнең шул карашымны белдердем дә, уйлаша торгач, Фәсиховның үтенечен канәгатьләндерергә тиеш таптык. Ләкин бу ташлама да аны тынычландыра алмады, ә бәлки яңа «җиңүләргә» генә рухландырган булып чыкты: кешечәнлекне ул йомшаклык белән бутый икән...
Бер көнне минем өстәлгә институт дипломын китереп салды — белгечлек буенча эш бирелмәсә, тагын судка бирәчәк, имеш. Тагын звено башлыгы вазифасын тәкъдим иттек, һәм ул тагын ризалашты. Иллә бер ай да үтмичә, бригадир белән чыя-пычак килгәннәр. «Җиде классны белемең белән миңа приказ бирмә!» — дип кенә җибәрә икән. Ә үзе, нәрәтләр дә язмыйча, кемнең эшкә чыкканын-чыкмаганын белмичә, эшләмәгәннәргә хезмәт хакы язып, эшләгәннәргә язмыйча, шау-шу кузгаткан. Бригада җыелышында тикшергәннәр дә эшеннән алганнар. Инде ул комбайнчы булып калды һәм менә шунда инде күрсәтте үзенең барлык «сәләтләрен» берьюлы! Моңарчы булганнары әле гөнаһсыз шаярулар гына булган, әй генәм!
Хикмәт шунда: Фәсихов комбайнчылар ярышында икенче урында бара һәм беренчелек өчен көрәшә. Тагын да хикмәтлерәге: штурвалда үзе сирәк күренә, кайчан карама — ярдәмче егет утыра. Бәйләнү булып чыкмасын дип, игътибар итмәскә тырыштым, иллә үз араларында низаг барыбер чыккан. Минем катнашмаскарак тырышуым өчен яңа «бүләк»: штурвалдан кача торган вакытларында авылдагы «гаделсезлекләр» хакында төрле җирләргә хатлар тарата торган ул.
Ашыгыч эш белән калага киткән чагымны юри сайлаганнар дияр сең: газетадан корреспондент килеп төшкән дә Фәсихов хатларындагы фактларны документлата тикшерү өчен баш бухгалтер Сәлимгәрәй Байсламовка кергән:

— Дөресме менә шушы саннар?

— Дөрес! — диган Сәлимгәрәй һәм сүзләрен документлар белән раслаган.

Баш бухгалтер үзе чыгарып салган документка ничек ышанмасын: корреспондент мин кайтканны көтәргә вакыт тапмыйча, китеп тә барган. Бигрәк шунысына кәеф кырылды: күп кенә кешеләр, хәтта моңарчы мин якын күргән кешеләр дә хәбәрченең шулай өстән-өстән генә сөйләшкән килеш нидер язарга алынуына гаҗәпләнмичә, кызык көтәләр. Хәтта нинди булса хилаф эш бардыр, дип шикләнүчеләр булды. Соңыннан үкенделәр үкенүен...

Җәй.

Җәй көне минем маршрут бик илтифатсыз кешеләргә генә билгеле түгелдер. Барыннан бигрәк, Фәсиховка таныш булган ул. Һәм бер көнне шул маршрут белән ул йөрергә чыккан да миннән ярты сәгать чамасы алгарак чапкан. Басуларда мин аның матайда пырылдап очканын күреп куям, тик әһәмият бирмим.

Куштирәк җәйләвендәге кызлар мине ямансу каршылый. Күзләрендә әйтергә ярамаган серләре тыелып тора. Монысын бик тә юка тоемлау белән генә сизәм, илла нинди дә булса мәгънә чыгарырлык дәрәҗәдә түгел. Гадәттәге сүзләр артык җитди һәм хәтта куркү катыш әйтелделәр шикелле. Икенче җәйләүдә шундый ук хәл. Тик анысында күзне Зөлхиҗә ача төште:

— Ильяс, теге котырган нинди гәзит күтәреп йөри ул?

Гаҗәпләнүемнең чиге юк:

— Нинди гәзит?

— Нинди дип инде...

— Кем котырган?

— Бездә моннан да яманы юк, шул инде, Фәсихов дигән хәсис.

— Нишләгән?

— Әллә нинди гәзит җилфердәтеп йөри, укыплар күрсәтә. Сине припискачы дип, закон бозучы дип, карак дип мыскыллаганнар.

Һуш җыя алмыйча интеккәнмендер, ахрысы, Зөлхиҗә читлекнең бу ягына ук чыгып, терсәгемнән тотты:

— Бар, Ильяс, бар шуның янына, тартып ал гәзитен дә ябылмас авызына тутыр — өне тыгылсын...

Нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Ләкин ни икәнен тәгаен белә алмыйча, гадәти маршрутны бүлеп, кире идарә йортына, үз бүлмәмә кайтырга ашыктым. Ә басулар буйлата Фәсихов матае пырылдый калды һәм кулында гәзит — җилпенә, оча егет! Менә кайчан икән аның канатланыр чаклары!

Газета. Күзләремә ышанмыйм. Хак дөресен әйткән Зөлхиҗә...

Районга шалтыратам. Шундый-шундый хәл, нишләргә?

Алар да укыган, алар да уйлый. Нәтиҗәгә ирешә алмыйча, трубканы сак куям да... шул арада үземә звонок. Иптәш Рамазанов. Борчылмаска боера. Үзем дә шулай тиешлеген чамалыйм. Ләкин әнә таныш матай инде урамнар буйлап, йорттан-йортка дигәндәй оча-куна тырылдый, таныш кәгазь — Фәсиховның чуар байрагы җилферди генә ләбаса иртәнге ак җилдә! Ә син борчылма, тынычлан — шундый боерык алдың. Үтәмәскә хакың юк.

Минем мондагы бөтен тормышым — саннар рәвешенә кергән күрсәткечләрдә. Дүрт елга сибелгән биш йөзләп терлекчелектә үтәлеп килә. Кыр үз сүзен менә шушы көннәрдә, шушы минутларда әйтә тора. Кырга, тиз арада — кырга! Шуны, бары тик үз хезмәтеңнең кайтавазын тыңларга басуга чап, тизрәк! Колакларыңда шул бәхетең җил сыман чыңласын, алама өннәргә җай калдырмасын! Тиз, тизрәк!

Әнис абый, ул елны сез үзегез дә күрдегез бит: басулар безне рәнҗетмәде — төрле хатлар, сүзләр, яман кешеләргә колак салмастан, безнең хаклыгыбыз хакында шаулады.

Колхозга (эш кешеләре тырышкан бит, алар шик астына эләкмәгән) бүләк: КПСС Үзәк Комитетының, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның Мактау грамотасы. Шул күрсәткечләргә ирешүне оештырган өчен колхоз председателенә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм... менә соңрак шуңа өстәп, исәп-хисап эшендәге кимчелекләргә юл куйган өчен, район җитәкчелегеннән каты шелтә. Монысыннан, әлбәттә, баш бухгалтер Сәлимгәрәй Байсламов үзе дә мәхрүм ителмәде.

Шулай да кем өчендер бу бик аз тоелгандырмы, яңа сигналлар булгандырмы, бездәге хәлләрне яңабаштан тикшерү өчен республика җитәкчелеге оештырган яңа комиссия килеп төште.

Калганын үзегез кайтып күрерсез дип беләм.

Сәлам белән:

Ильяс Җантурин.

10 май, 1977 ел.

Җиреклекүл.

## Ачылганны кабат ачу

*18 май, 1977 ел.*

Авылдан киттем дип йөрисең, ә чынында син аннан беркайчан да китә алмаячаксың, ул — синең үзеңдә, уйларыңда, җаныңда, бөтен тормышыңда. Гомергә узмый торган бергәлек — телефон аша, хатлар, сәяхәтләр, сәфәрләр аша, эфир аша...

«Үткән тәүлекләрдә урыны белән яңгыр яуды, салкынча һава булды. Бүген — 18 июньдә аязучан болыт. Урыны белән яңгыр булуы мөмкин. Көньяктан уртача, вакыты белән көчле җил. Яшен булуы мөмкин...»

Әлбәттә, булмавы да бик ихтимал.

Дөреслекне һәркем үзенчә күрә, әйтерсең ул — берничә. Ләкин дөреслек бер генә. Син шуны эзләп тап. Ә гаделлек? Син анысын бәхет белән фаҗига арасыннан эзлә һәм икесен дә килештер.

Уҗым буынга үрмәли, бодай кыяк суза, ә кемдер гаделлек, дөреслек эзли, синнән ярдәм көтә. Кайда ул хакыйкать, кайда, кем ягында гаделлек?

Самолеттан төшкәч һәм аннары Сөнне чыккач та, туган җир туфрагына басып, кулларны җилкәдә йозаклаган хәлдә, сусалган һаваны күкрәкләргә тулганчы сулап, күзләр яшеллек, якынлык һәм җил ләззәтеннән яшьләнгәнче карап торгач, ары атлыйсың.

Рәсми визит район үзәгеннән башлана.

Анда бүген нindидер җыелыш.

Ике катлы таш йорт алдында машиналарның саны-исәбе юк. Шоферлар бер төбәккә җыелганнар да, әлбәттә, һәркайсының сәләтенчә, тел чарлыйлар. Тупыллар ышыгында аларның үз пленумнары. Машиналар көтүенә безнең автомобильнең өстәлүе, ә үзебезнең алар җыенына кушылуыбыз бер дә гаҗәп тоелмады һәм сүзләре бүленмәде дә. Хәл-әхвәлләре мина таныш булмаганлыктан, сүз мәгънәләре җилгә генә оча тордылар. Әмма кайберләре хәтердә кызыклы мәзәк сымаграк булып калды.

Өлкән яшьтәге бер шофер үз эргәсендәге яшь егет җилкәсенә кулын куйды:

— Син, Фаяз энекәш, әйт әле дөресен генә: колхоз председателе булып эшли алыр идеңме? — Егет ни дияргә белмичәрәк торганга, аны һушына китерергә теләгәндәй, шапылдатып суккалап куйды.

— Икенче төрле әйтик, ул чакта рульдә синең председателең утырып йөрер иде. Ну, була аласыңмы председатель?

Фаяз дигәне кулбашларын уйнаткалап алганнан соң кепкасын уа-уа булса да, җавап бирде:

— Бүтән якларын булдырып та булыр иде. Бер нәрсә комачау итә.
— Нәрсә?
— Дөресен әйтсәк, эшли алмас идем, абзый.
— Нишләп?
— Нишләбе шул: яртыны салганнан соң доклад сөйли алмыйм.

Шофер халкы кояшлы көн сыман итеп елмаеп куя. Кунаклар сыйлаганнан соң халык алдына чыга алуның җиңел эш түгеллеген алар, чынлап та, беләләр бугай. Ә мин үзем, бер мәзәк хәзергә җитеп торыр дип, тагын да арырак киттем.

Рамазановның кабул итү бүлмәсендә озак утырырга туры килмәде. Халык шау-гөр килеп тәнәфескә чыкты да мин аны тиз таптым. Кабинетына кереп, бераз хәл алдык. Аннары — пленумның икенче өлеше. Иптәш Рамазанов доклады — минем өчен нәкъ кирәклесе калган иде. Сүз кешеләр, кадрлар хакында. Бәлки мине монда чакырып кайтарган кешеләр телгә алыныр? Кызыклы хәбәрләр ишетелер?

Дәфтәр битен ачып, беренче хәрефләрне, көн санын язып куйдым. Ләкин көндәлеккә шул саннардан башка бүтән берни дә өстәлмәде диярлек. Яшь колхозчыларның икмәк, ит, сөт өчен көрәштә ничек катнашулары, нинди һөнәр үзләштерүләре, үсү һәм яшәү мөмкинлекләре шактый ук табигый төстә сурәтләнгәнгә күрә, аларны кәгазьгә теркәүнең хаҗәте юк иде. Өч кенә сан язылган: 250, 300, 380. Болар — яшь тракторчының уртача айлык хезмәт хаклары. Шул хәлдә дә әле кайбер яшь-җилкенчәк моның яртысын гына алыр өчен калага тая... Ник дигәндә, алар әле күп нәрсәне белми һәм шуңа күрә беләселәре, киңрәк дөнья белән танышасылары килә. Ә Рамазанов күпне белә, һәм аңлатырга тырыша. Ләкин үз белгәннәренең ул монда чиреген дә сөйләп өлгерми... Кызыгы шунда, мин аның әле сөйләми торган, мин югында кайчан да булса инде сөйләгән, яки кайчан да булса сөйләячәк докладын тыңлап утырам кебек. Бу минутларда минем күз алдында Рамазанов ике рәвешкә аерыла: соры кительле яшь Рамазанов һәм хәзер кара костюмлы олпат Рамазанов. Алтмышка якынайган кеше өчен төсе дә ярарлык, куелыгы да әле житәрлек булган кара-кучкыл чәчләр. Нигәдер карарак сыман тоелган аксыл чырай. Ә-ә, табигать үзе кирәк тапкан күз сөрмәләре хикмәте икән — зәңгәр-яшькелт күзләр шуның аркасында кара сыман булып күренә. Хәзер ул калынаебрак киткән. Ә мин белгән елларда...

Хәер, яшьлектә без барыбыз да нәзек һәм төз булабыз бит — корсак һич тә комачау итми. Ул елларда — бигрәк тә...

Бер кулга китап-дәфтәр (укырга тырышу галәмәте), икенчесенә баян тотып йөргән (район культура йортында художество житәкчесе буларак, акча эшләргә тырышу, җан саклау галәмәте), кешечә яшии башларга гына әзерләнгән яшел чак иде бу минем. Яшеллеге дә базда үскән бәрәңге сабагыныкы төслерәк булгандыр. Ә Рамазанов ябык булса да, ул чакта ук мөһим кеше — райкомның пропаганда бүлеге мөдире иде. Эше буенча гына түгел, сәнгатьне яратканга күрә, ул безнең янга еш килә, карап, тыңлап утыра һәм хәтта тиңнәрчә сөйләшеп утырган чаклары еш була. Ул вакытта безнең концертларга, спектакльләргә райбашкарма комитеты председателе урынбасары булган Галибәк Хәмәтдинов дигән кеше дә йөрергә һәм анысы башлыча «житәкчелек

итәргә» ярата иде. Ике кеше, ике җитәкче — икесен дә яхшы белергә туры килде. Хәзер дә беләбез, истә тотабыз...

Сугышның башыннан алып азагына хәтле чик сакчылары гаскәрендә катнашкан Рамазанов һәм бронь ярдәмендә тыныч кына мая, әллә маймы җыйган Хәмәтдинов. Төсләре, кыяфәтләре дә капма-каршы: хәрби форма, китель, галифе, итекләр; чем-кара костюм, галстук, ялтыравыклы туфли... Шуңа өченче кыяфәтне дә өстәргә була икән әле — анысы мин үзем. Ертык чалбарны да ыргытырга мөмкинлеге булмаган һәвәскәр музыкант, берсенә үз итеп, икенчесенә капиталистка караган кебек карыйм. Ихтимал, бу карашлар аларның үзләренә дә сизелгәндер. Минме инде дипломат, минме инде күңелдәгеи яшерә алучы! Күп тә үтмичә дөпелдәп бәрелдем мин үземнең йомшак маңгаем белән Хәмәтдиновның какъ амбициясенә.

Зур гына концерт оештырган идек. Түләүле. Иң югары башлыкларга — чакыру кәгазьләре. Райбашкарма комитеты председателе урынбасары булуына карамастан, җаныбызга чит булуы аркасындамы, әллә икенче дәрәҗәдәге начальникларга бирү мәҗбүри түгел дип исәпләгәнгәме, Хәмәтдиновка чакыру, әлбәттә, юк. Концерт башланыр алдыннан билет тикшерү гадәте бар һәм күп чакта ул эшне үземә башкарырга туры килә. Артымнан милиционер ияреп йөри, фамилиясе дә хәтердә калган — Галимуллин. Начальство иң алгы рәттә утырган. Шул ук рәттә Рамазанов. Тикшерүне икенче рәттән башлыйм. Дивар яныннан әкренләп уртага якынлашам. Тыныч кына, мәгърур гына Хәмәтдинов утыра, үзеннән билет сорарлар дип башына да китерми, әлбәттә. Ә рәттән аңа чират:

— Сезнең билетыгыз, Хәмәтдинов абый?

— Нә-ә-әр-сә?

— Билетыгыз, дим, бармы?

— Нинди билет кирәк сиңа?

— Бүтәннәр күрсәтә бит.

— Мин сиңа билет күрсәтергә тиешме?

— Ә сезнеңчә ничек? Райбашкарма совет законын бозарга тиешмени?

— Нинди закон, нинди билет турында сөйлисез сез, әллә...

— Сезгә билет алырга туры килер, — дим, аның аптырап телсез калуыннан файдаланып. — Иптәш Галимуллин, монда билетсызлар бар, исегездә тотарсыз.

Милиционерга шулай кычкырып ук әйткәч кенә ары атладым. Кемнәрдер кычкырып көлә, кемнәрдер билетсызны битәрли, кемнәрдер — шундый олы кешедән билет сорарга җөрьәт иткән әдәпсез малайны. Ярый, алар бәхәсләшә торсын, ә без концертны башлыйк. Һәм без аны күңелле генә аткардык та. Гөрли-гөрли кул чаба тордылар. Ләкин сәхнәдә килеш шәйлим, берәү кул чапмый, селкенеп тә карамый бер кеше. Һәм ул мине иртәгә иртүк кабинетына чакырып алачак. Билет хакында — ләм-мим. «Ник сәхнәдә лампагыз берәү генә, ник ул корымлана, ник соңга таба бии башлады?..» «Сәхнәдә бөтен нәрсә шулай бии инде ул», дим һәм бу шаяртуым аны ярсыта гына. Ул инде шуннан соң әдәпле булып үйный алмыйча, үзенең чын халәтенә кереп, мине алама атын битәрләгән мужик мисалында тиргәргә керешә. Шул рәвешле мин аның үзенә үзенең чын йөзен күрсәткәч, хәзергә шул житеп тә тора. Инде тынычланырга, баш ияргә вакыт. «Гаеп бездә, төзәлербез». Шул көннән соң башка начальниклар рәтеннән аңа да чакыру билетлары җибәрә башладык. Мәгәр файдасы барыбер тимәде шул...

Рамазанов бүтәнчәрәк эшли: без җәй көне агитбригада белән концерт биреп йөргән авылларда ул кыш көннәрендә дә һәр вакыт була. Ә язгы чәчү яисә урак өстендә район үзәгенә кунакка гына кайта.

Үзенең инде әллә кайчан сөйләгәне буенча хәтердә калган кышкы бер көн — сугыштан соңгы кышкы суык көн. Язгы чәчүгә әзерлекне тикшерүдән бигрәк, аны оештыру өчен авылга җибәрелгән Рамазанов. Көн буе колхоз һәм бригадирлар белән бәхәс-тарткалаш. Ә кич — ачлык белән. Ялгыз әби нәрсәдер әмәлләгән — мич алдыннан ул өстәлгә тәлинкә чыгарып утырта. Көнозын бер стакан судан гайре берни капмаган вәкил, көч яңартырга чамалап, кашыкка тотынса... кашык тулы йон. Әби йон теткәннән калган онны эрәм итмәс өчен, анда да кунак килсә дип саклаган ризык икән... Шушыннан да әйбәт сыйны каян алсын ул?

Изелмичә калган ике-өч бөртек бәрәңге кисәген зур тырышлык белән тапканнан соң, Рамазанов йокыга ята. Урын-җир — какъ сәке, өстә шинель, аста шинель... нәкъ солдаттагының дәвамы. Аерма тик шунда — тамак тук түгел. Ләкин нишлисең, яшәмәк кирәк. Һәм яши Рамазанов. Колхоз чәчүгә мөмкин булганнан әйбәтрәк әзерләнә. Тырышлык иген дә бирер әле бәлки. Ә аңынчы аны районга чакырып кайтаралар.

Рамазанов үзе җитәкләгән бүлеккә кайтып кергәч тә андагы эшләр белән таныша, кимчелекләр таба: стена газеталары хәтсездән бирле чыкмаган икән. Шул җәһәттән тәнкыйтьли башлагач, иптәшләре аңа сәер карап тора:

— Гәзит чыгар ул, булыр, ә менә син үзең... Нишләп әле болай ук ябыктың?

— Сизеләмени?

— Тире дә сөяк.

Шул сүзне әйтә дә урынбасары каядыр чыгып китә. Соңыннан аңлашылганча, ул беренче секретарьга кереп, хәлне аңлаткан һәм райсоюз аркылы ярты пот борчак табып килгән. Рамазанов шуның белән язгы чәчүгә хәтле гаиләсен дә исән саклаган һәм үзе дә бераз тернәкләнгән!

Чәчү алдыннан — зональный җыелыш. Монысы да шул еллар сәламе. Икенче район үзәгенә кырык чакрым. Ярты юлда машина ватыла да, Рамазанов кыр уртасында кала. Хәмәтдинов куып җитә. Чиксез һәм буш аклыкта (анысы да алалы-колалы) ике шәхес очраша.

— Иптәш Хәмәтдинов, миңа сезнең машинага күчәргә туры килә инде. Бүтән җай юк, бераз кысылыйк та...

— Минем машинада урын юк бит, иптәш...

Элекке пограничникны алдамакчы шулай тыл күсесе. Урын җитәрлек машинада, күңеле генә тар.

— Сыя бит тагын бер кеше.

— Минем рессор ышанычлы түгел, ярамый.

Бәхәсләшүнең урынсыз икәнен аңлатып, Хәмәтдинов алгы ишекне ача да, җайлап кына, ашыкмыйча гына үз урынына, законлы урындыкка утырып алгач, ишекне шап итеп ябып та куя. Күгәрчендәй йомшак гөрләп, автомобиль ары җилдерә.

Рамазанов өлеше — саф һава, кыр чиксезлеге. Ул егерме чакрымны җәяү уза — солдат тынычта да солдат! Итекләре, табан дигәне чак әләгеп торыр дәрәҗәгә килсә дә, җыелышның икенче өлешенә барыбер өлгерә ул. Һәм әле чыгыш та ясый...: Залдан аңа карап утырганда ни уйлады икән Хәмәтдинов? Оялдымы икән? Ләкин оялса, соңыннан гафу үтенгән булыр иде. Үкенә белгән кеше юлдашын кыр уртасында ташлап китә аламы? Ә трибунадан аны күргәч, Рамазанов ни уйлады икән? «Тыңла, Хәмәтдинов, тыңла, шушының өчен ашыктың бит — мине тыңламый калмас өчен! Без сине җәяү дә куып уздык, тырышып булса да. Кеше тормыштан артта калырга тиеш түгел, ә артта калганнарны кыйныйлар. Ихтимал, синең чират җитеп тә килә торгандыр инде...» Күңеленнән генә булса да әйтте микән ул аңа бу сүзләрне?

Бүгенге Рамазанов та трибунада, тик түшендә — Социалистик Хезмәт Герое билгесе — Алтын Йолдыз яна... Ә Хәмәтдинов? Күренми.

Докладның ахыргы өлешендә минем дикъкатне менә нинди сүзләр җәлеп итте: партиягә кайбер кешеләрне ялгыш, өйрәнмичә кабул итү очраклары булгалый икән һәм Хәмәтдинов фамилиясе әйтелер дип көтсәм... ләкин бөтенләй ят фамилияләр ишетәм:

— Гыйлемханов Өлфәт Саттарович... дигән кеше. Югары белемле укытучы иде. Район үзәгендәге мәктәптә директор булып эшләде, хәтерлисездер, иптәшләр. Мондагы зур мәктәптә эшли алмагач, кечкенәрәк мәктәпкә җибәрелгән иде, анда да шау-шу куптарды да үзе калага качты. Калада эшче яшьләр мәктәбе директоры йөген дә тарта алмаган. Егәр җитми, сәбәп шул гына. Ә гаепне бүтәннәрдән эзли — үзен партиягә алган оешмага төрле ялалар яга. Югары оешмаларга җибәргән бер хатында менә ниләр яза ул:

«Иптәш Хәмәтдинов эштән законсыз чыгарылып кына калмый, әгәр ул машинада булса, аны юкка ук чыгарыр өчен теләсә кайсы җирдә авария ясарга күрсәтмә бирелә. Районда колхоз председательләре колхоз исәбенә автомобильләр алалар да, Рамазановка кирәкле кешеләргә саталар. Зур взяткалар алалар».

Кайчан башланган, игълан ителмәгән көрәш хәзер дә тынычланмый. Бу шундый аңлаешлы, ләкин искитмәле гаҗәп! Үз колагым белән ишетмәсәм, ышанмас идем.

Хаттан аерым җөмләләр укыгач, Рамазанов дәвам итте:

— Бәхетебезгә каршы, Хәмәтдинов исән, тыныч кына яши. Без аңа озын гомерләр телибез һәм өметебезне аклар дип тә ышанабыз. Шәхси кешеләргә колхозлар саткан автомобильләр дә табылмады. Үзегез беләсез, югарыдан килгән комиссияләр дә, үзебез оештырганнары да мондый хатларны яла дип тапты. Намуслы кешеләрдән конкрет гаеп таба алмагач, алар инде гомуми фразалар белән күләгә төшерергә азаплана башладылар. Хатларның берсендә менә нәрсә яза Гыйлемханов: «Мин үзебезнең районда төрле постлар биләгән, утызар, кырыгар ел партия сафында торган коммунистларга дөреслекне ачып салуларын үтенеп мөрәҗәгать иттем. Ләкин алар иптәш Рамазанов сүзләрен кабатлаудан уза алмыйлар. Үз фикерләре юк, үз тавышлары юк». Бу сүзләр — Гыйлемхановның үзен партиягә кабул иткән оешмага рәхмәт әйтү формасы дип аңлыйк һәм турысын әйтик — шәп форма түгел. Шунысын да өстик: бу кеше фикердәшләр таба алмавына да урынсызрак зарлана, бар аның фикердәшләре — Җиреклекүлдә Сәлимгәрәй Байсламов, Госман Фәсихов. Намуслы кешеләргә бәя бирү өчен ни әхлакый, ни политик, ни эшлеклелек сыйфатлары булмаган бу кешеләр таба алмаса да, ләкин бездә гаеп чынлап та бар: гаебебез — аларны моннан берничә ел элек партия сафына кабул итүебез.

Рамазанов фамилияләр атаганда мин дәфтәргә: «Бу кешеләр ничек берләшкәннәр, әллә туганнармы?» дигән сорау язып куйдым. Соңгы елларда партиягә алынган меңнәрчә яшьләрнең фидакарь хезмәтләре хакында сөйләгәндә, дәфтәр битләре ни өчендер чиста калды. Бер уйласаң, сәеррәк бит — яман фактлар тойгыга тизрәк үтеп керә, ә яхшылары... яхшылары безне гафу итсеннәр.

Күңелсез уйларны таратсын өчен тагын Рамазановның Алтын Йолдызына карыйм. Дәфтәргә барлык әшәкелекләрне берьюлы күмеп китүе ихтимал булган, бөтен район игенчеләренең Рамазанов теле белән әйтелгән максатын, вәгъдәсен язып куям: гектардан утыз биш центнер!

— Утыз биш!

Сабан язгы кырда уңыш җыры яза. Озак та үтми, ул язган җырны яшел кыр күтәреп ала — һәр башакның үз тавышы бар, һәр башак игеннең яшел моңына кушыла, аннары... аннары алтынсу тавышлар, бөтен илгә ишетелерлек яңгырый башлый. Шундый тавышларга да

каршы көрәшеп, ят сукранулар белән ничек бу дөньяга ямьсез авазлар таратырга мөмкин икән? Ник? Нинди максат белән? Нинди бәхетсез адәмнәрдер болар — яшел моңнарны тыяр өчен кычкырган кара тавышлы кешеләр! Аларның хәтерләре инде бөтенләй саңгырау һәм инде ерак елларда калган билчәннәр, ак мамыклар шаулавын ишетмәскә, күрмәскә әйләнгәннәр микәнни?

Арык еллар, сагышлы сабаклар бит хәзер дә вөҗданнарны пешерә, хәтерләрне сызлата... Кешеләр, язмышлар бәясе, вату-сындыру, юк, берсе дә туктата алмады — җиңү, бары тик җиңү! Иң гүзәл максат — җиңү! Җиңү — алтын җыр! Шуның хакына багышланган усаллыкларны хәтер югалтмаса да, аларны, ничек әйтсәң дә, аңлап була. Тиргибез, ләкин эчтән кичерәбез. Ә болары? Боларга ни.кирәк, нәрсә даулыйлар? Кемнәр алар? Туганнардыр, мөгаен, якын ук туганнардыр...

Өлфәт Гыйлемханов дигәне шәһәрдә. Анда ук барып булмас һәм бәлки әле кирәге дә чыкмас. Госман Фәсихов белән Сәлимгәрәй Байсламов Җиреклекүлдә. Ә Чуаркүлдә — Гыйбадулла Байсламов... Ихтимал, беренче хат авторы да шундадыр... Мин ачарга тиешле хакыйкатьнең шунда яшеренгән булуы, мине көтүе бик ихтимал.

— Утыз биш центнер!

Тулган ай сыман булып бөтен илгә күренеп торган бөтен икмәк. Аны кемдер бар иткән, ә кемнәрдер аларга бу вакытта комачау иткән, аяк чалган да, хәзер исә түгәрәк айны кыерчыкларга бүлгәләргә, өлешкә керергә, мөмкин булса, зуррак кисәген эләктерергә азаплана. Ә ул икмәкне игәндә, пешергәндә катнашу өчен бер дә гауга күтәрмәгәннәр...

— Утыз биш центнер!

Миңа Җиреклекүлгә барырга кирәк.

Киңәшмә беткәч, Рамазанов бүлмәсендә сөйләшеп утырдык. Бераздан Рамазанов, икенче бүлмәгә чыгып, ниндидер калын гына папка алып керде.

— Укый торыгыз. Бәлки шуннан соң тизрәк аңлашылыр кайбер нәрсәләр.

Аңа башкалар белән сөйләшергә комачау итмәс өчен, читтәрәк торган озын өстәл янына күчтем дә кәгазьләрне актарырга керештем. Кәгазьләр белән бергә — елларны.

Кәгазьдә бөтенләй әллә нинди сүзләр язылганга карамастан, беренче бит, ничек әйтсәң дә, мине җиде яшьтә этисез калдырган, җиде баланы берьюлы ятим иткән ел. Икенче бит — үземнән ике яшькә олырак апам Әгънияне унбер яшендә дөньядан алып киткән ел... Үләсе елның көзендә ул нигәдер ялгызлыктан курка башлады — мине гел үз янында тотмакчы иде. Минем исә аны аңларлык гамем юк, уенга чыгып таюны гына карыйм. Бигрәк тә кечкә таба — эштән кайтучы атларның берсенә — бүз аргамакка атланып очарга талпынам. Ә апам җибәрми, елый. Бер көнне мин аңа бер шешә көнбагыш алып кайтырга вәгъдә биреп ычкындым. Ник тәгаен шешә? Чалбар кесәләрендә андый вак әйберләр тоткарлана торган түгел — тишек тә тошык.

Көнбагышны чынлап җыйдым, шешәгә дә тутырдым, шулай ук кесәгә салуымны да хәтерлим. Тик... тик аргамагыма атландыммы, минем инде аттан узып күңел җилә, чик-кырыйсыз дигәндәй басу буйлата сабан туйдагы шикелле чапкан аттан алда акыл оча! Зиһен дигәненең әсәре дә калмый. Аттан җиргә төшкәч, җилкәләрдәге канатларның һаман исән икәнлеген тойган хәлдә өйгә кайтып кергәч... канатлар тиз ук салынып төшә төшүен. Ләкин инде бик тә соң. Әгъниягә антлар белән беркетелгән көнбагыш... кайда соң әле? Апам бит шуны зарыгып көткән. Кесәне капшаган булып карасам, анда җил исә. Юк шешә, юк көнбагыш. Һәм: «Алдакчы, алдакчы!» — дип, Әгъния апа елап, юк, елап кына түгел, үксеп тә җибәрә. Аңа кушылып, ул көннәр буе караган бала

еларга керешә. Ышандырырга, икесен берьюлы юатырга тырышып: «Кесәгә салганием, җыйганием, валлаһи-билләһи!» — дип, антлар әчеп интексәм дә, файдасы тиярлек түгел.

Апам, антларымны калдырып, өйгә ук кереп китте һәм, үзе ике ел буе биләүдән бирле карап үстергән кечкенә энебезне кочаклаган хәлдә, арыганчы елап ятты да... шул ятудан инде бүтән тора ук алмады... Дөнья катылыкларына өстәп, соңгы җәрәхәтне мин ясаган булып чыктым бугай... Алдану һәм ышанмау әчесенең никадәр дә көчле була алуын мин бит беләм...

Әйе, ул миңа ышанмады, мин аңа дөреслекне исбат итә алмадым— рәнжеттем, яхшы ният тәге килеш, күңелен җәрәхәтләдем һәм анысын гына түгел, үземнекен дә һәм гомерлеккә. Искә төште исә хәзер дә йөрәк сулкылдарга керешә. Менә хәзер тагын шул, шул яра, шул үкенеч сызлый.

Соңыннан минем өчен дөнья яктыра төшкән шикелле иде, хәтердә имин төсле булып калган иде. Ләкин ныклабрак карасаң, ул яңа фаҗигаләрнең башлануы булган икән. Шул елның көзендә... гаиләнең бердәнбер таянычы булган Илдархан абыебыз армиягә китте. Шул көздә район җитәкчеләре югары оешмалардан ярдәм сорый: «Терлекләр фуражсыз, кешеләр икмәксез калды — амбарлар чәчүлек орлыксыз калды, ярдәм итүегезне үтенәбез». Март аенда икенче хат: «Кешеләр, терлекләр ачлыктан авырый, язгы чәчүнең өзелү куркынычы бар, ярдәм итүегезне үтенәбез».

Ә без белмәгәнбез, сизмәгәнбез, онытканбыз.

Туган җиребезнең, ялан аяклы елларыбызның ул чактагы серен әйтерсең кабат ачтым...

Күңелдә өзек-өзек булып калган хатирәләр берсенә-берсе ялганырга, нинди дер мәгънәләр алып, бөтенләй яңача чыңларга кереште. Шул ук вакытта колакка бүгенге сүзләр дә килеп керә: «Утыз биш центнер, утыз биш центнер!» Ягымлы яктылыкны томаларга тырышкандай, элеккеләре ябырыла: «Бер гектар дигән җиргә бер центнер ярым чәчеп, шул хәтле үк уныш җыя идек». Монысын үз күзләрем белән күреп, зар елап яшәдем. Дөресрәге болай: дәүләт биргән алтын ашлыкны җиргә чәчеп, кырда көз көне билчән мамыгы җыя идек... Тырышлыклар, ышанычлар мамыклар белән бергә җилдә туза, оча тора. Һәм шул ук вакытта бүгенге трибунадан Рамазанов елмая: «Утыз биш центнер — безнең быелгы бурыч!»

Киләчәк җиңүләр бик якын, узган үкенечләр дә сагындыра. Гаҗәп, бер уйласаң, ә? Ник сагынырга ул елларны? Ләкин аларга кайтмыйча мин үземнең газиз апамны, Әгънияне ничек күрим? Ничек гафу үтеним?

Өч үлчәүдә берьюлы яшәргә тиеш адәм баласы: кичәгедә, бүгенгедә, иртәгәгедә. «Утыз биш центнер!» — «Ярдәм итегез, ярдәм!» — «Утыз биш...»

Өч үлчәүгә бүленеп ары киттем.

Җиреклекүлгә.

## Карга егылды карга

*20 май, 1977.*

Идарә йортында председатель бүлмәсенә утыз-утыз бишләр тирәсендәге берәү елмаеп керде дә күзләре белән зәңгәр яктылык сирпеп исәнләште.

— Партком секретаре Гатуф Бикимов.

Сүз арасында ачыкланганы: булачак агроном, читтән торып авыл хуҗалыгы институтын бетерә.

— Председателегез агроном, сез дә агроном...

— Игенчеләр бит без, агрономнар күп. Тик мин саф агроном гына түгел, ун класстан соң слесарь-монтажник булып эшләдем, аннары клуб мөдире булып... Ярым артист...

Әңгәмә шул «ярым артист» дигәндә өзелде һәм, шуңа күрә бугай, ул сүз хәтердә дә калды. Дөбердәп, председатель үзе керде.

— Җантурин Ильяс.

Авылдагы хәлләр хакында бераз сөйләшкәч, басуларга чыгып киттек. Анда бер генә төс патшалык итә: дөнья ямь-яшел сөенеч белән күмелгән. Тик инде яңгыр кирәк. Бүген төнлә сибәләгәне тузанны да баса алмаган әле. Җир яңгыр көтә.

Сүзне ничек дәвам итәргә белмирәк торган бер мәлдә, Ильясның миңа җибәргән хатын искә төшердем. Ә ул исә гаҗәпкә генә калды:

— Хат? Нинди хат ул?

— Менә.

Әйләндереп карады, укып бакты, ләкин гаҗәпләнүе һич кимемәде.

— Юк, минем язу түгел бу. Кызлар язуы лабаса.

Чынлап та, кызлар язуына охшатып, үземнең дә шикләнә язган вакытларым булмады түгел, булды. Ләкин «Ильяс Җантурин» дип ачык куелган имзаны аныкы түгел дип ничек уйлый алыйм? Шулай да хатны җентеклəбрәк укыгач, Ильяс:

— Барысы да дөрес язылган, үзем дә кул куя алыр идем, — диде. — Ләкин авторы — бүтән кеше.

— Кем?

Җантурин уңайсызланып елмайды гына. «Әйтәсе килми, үзе, мөгаен, белә...» Тагын бер табышмак.

Басулар аша җәйләүгә килдек. Бер савымчы белән Ильяс мине аерым таныштырды. Алдынгы савымчы Вәҗиһә. Чандыр гәүдәле, утыз тирәсендәге бәләкәйрәк ханым. Басынкы, хәтта оялчан карап торган коңгырт күзләр. Тышкы яктан караганда, бүтәннәрдән берни белән дә аерылып тормый, ләкин эшләре һәм уңышлы узган сынаулары белән ул Җиреклекүлдә генә түгел, бөтен районда танылган. Шуның бөтенесенә өстәргә мөмкиндер: өченче хатның авторы шушы кыз булырга тиештер. Югыйсә, Җантурин болай аерып таныштырмас иде. Һәм мин хәтердәге кайбер вакыйгаларны сайларга, Вәҗиһәне бөтен барлыгы белән аңларга тырышам.

Җәйге яшеллеккә кышкы төн, оясыннан эт тә борын сузмаслык карлы буран килеп керә. Кышкы караңгыда кемдер тәрәзә кага. Рамазанов уяна да тыңланып ята: кешеме, өермәме? Кеше. Рамазанов, өстенә тун салып, урамга чыга:

— Кем бар анда?

— Мин бу, Гозәер абый, Җиреклекүлдән.

— Онытмаган булсаң, исемең дә бардыр әле, ә? — Шул сүзләр белән Гозәер Җиһаннурович Рамазанов кунак кызга капка ача. — Нәрсә булды, ни бар?

— Бар шул, абый.

Рамазанов төнге кунакны өйгә дәшә, пальтосын салырга булыша, чөнки кызның куллары тыңламас дәрәҗәдә өшегән. Чәй җылытып биргәч кенә теле ачыла:

— Җиреклeдән мин, абый.

— Онытмаган булсаң, исемең дә...

— Онытырсың да... Шул. Вәҗиһә инде мин, Сәфиуллина.

— Шушы күз ачкысыз буранда, төнгә каршы юл чыгарга нәрсә мәҗбүр итте?

— Мине эштән чыгардылар, абый.

— Ник?
— Ник була димени, булсын дип эшләгән өчен.
— Бераз чамалыйм. Шуннан?
— Мин сыерларга бөтен рационны ашата барам, шуңа күрә сөт тә күбрәк бирәләр, ә бүтәннәр көн саен сыерларына дигән ризыкны әзләп-әзләп өйләренә ташый. Сөтләре аз чыга да, шуның өчен мин тагы начар. Әйбәтлек белән, дусларча аңлатып карадым — юләр дип көлделәр генә. Катырак сөйләшә башлагач хәтерләре калды, үпкәләделәр. Хәзер менә үземне мыскыл иттеләр: минем өйгә, абзарга фураж илтеп куйганнар да завферманы китереп күрсәттеләр. Телсез, аңсыз калдым. Фермада җыелыш кебек нәрсә укмаштырып, партоешма секретаре дигән Фәсиховны чакырдылар. Акыл өйрәтергә булган кызлар чатылдап кына тора, Фәсихов аларны җөпләп:
— Безнең советский сыерлар фермасында каракларга урын юк! — дип кычкыргач, бер бөтен төркем бертавыштан:
— Дөрес, дөрес! — дип кул чапты да шуның белән фермада минем өчен эш бетте.
Рамазанов бераз гына уйланып торгач («Чынлап эшләмәгән кеше болай йөрмәс!»), кызны карашы белән үк тынычландырып:
— Синең монда кунар урының бармы? — дип сорады.
— Бар, апа тиешле кешеләр.
— Шуларга бар да, тыныч кына йокла. Үзем кызыксынырмын.
Шул сүзгә дә сөенеп, (бусы да аның файдасына!) чыгып китте кыз. Онытсаң, игътибарсыз калдырсаң, иптәшләре кебек, «акылга» утырачак. Рамазанов моны белә. Шунлыктан Җантуринга икенче көнне үк эндәшә:
— Сез анда Вәҗиһәне эштән чыгаргансыз икән.
— Алама эш эшләгән диләр бит, акылга сыймаслык.
— Ә сиңа югалту кызганыч түгелме шундый савымчыны?
— Кызганыч.
— Әйбәт кешеләрне берәм-берәм югалта башласаң, кемнәр арасында калырсың? Кемнәр белән эшләрсең? Ялагайлар, караклар беләнме?
— Сезнеңчә, Гозәер Җиһаннурович, бөтен бер җыелыш карарына ышанмаскамыни?
— Син баштан, баштан башла. Әгәр ялган баштан башлана икән, ул билгеле шартларда парламент карары дәрәҗәсенә хәтле үсәргә мөмкин. — Ильяс уйлана калгач, Рамазанов инде боерык бирә, — «Диләр»гә ышанма, үзең тикшер, яме? Һәм миңа хәбәр ит.
Атна да узмагандыр, Җантурин Рамазановка хәбәр итә:
— Вәҗиһәне эшенә яңадан куйдык — нахак бәла якканнар.
— Молодец!
Ильяс бу «молодец»ны, беренче тапкыр ишеткәнгә күрә, хәтерендә аерым җирдә саклый. Ләкин минем өчен барыбер шунысы гаҗәбрәк, кешеләр турында кайгыртучанлык изгелек дәрәҗәсендә бәяләнә торган җирдә дә кемдер барыбер рәнҗетелә, кемдер гаделлекне исбат итешергә дип, читтән ярдәм сорый һәм син менә шуның өчен кайттың да. Ләкин кем, кем ул синнән ярдәм көткән кеше? Вәҗиһә? Ильясмы ярдәмгә мохтаҗ кеше? Юк, күрүемчә, һич тә алар түгел. Кемнәр соң алай булгач?
Ильяс моны чамалап та әйтә алмаганлыктан, белсә шул белер, авылның иң үткер күзле кешесе дип, Морадым картка мөрәҗәгать итәргә киңәш бирде дә, шул ук көнне мин карт янына ашыктым.
Аны электән бераз гына беләм: күп күрә дип даны таралган бу кеше—сыңар гына күзле, бер күзен тоташ каплап ак төшкән. Сәбәбе—хикмәтле, мәхәббәт аркасында, яшьрәк чакта... җилкенчәгрәк булу аркасында.
Җилкенчәк Морадымның бер заман күзләре авырып китә дә, ул, рай-

он үзәгенә барып, чирек литрлы аракы шешәсенә салдырып, тамчылы дару алып кайта. Хатыны Миңсорур жиңгәчәйдән шул даруны бал калагы белән авырткан күзенә көн саен салдыра торган була Морадым абзаң. Мәгәр бәндәгә болай гына житми. Күршедә гажәп тә чибәр вә мәхәббәтле бер жилбәзәк хатын гомер сөрә бит — аны күрсә, теләсә генә нинди тәүфыйклы ир дә кырын күзе белән генә булса да гөнаһ кылмыйча уза алмый. Хатын үзе дә бик угры булмаса да, бик үк тугры түгел, ахрысы, чөнки дип әйтик, хатын-кыз жыелып чыр-чу килешкән араларда: «Сирәк-мирәк тавыкларыгыз күрше әтәченә кергәләсә, тән рәхәтләнеп китә ул, бик тә рәхәт нәрсә ул!» — дип сөйләнгәнен үз колагым белән ишеткәнем бар иде. Күзләре авырткан хәерсез көннәренең берсендә Морадым дигән тилемсә үз хатынының түбән оч чишмәсенә суга киткәнен шәйли дә, тамчылы даруны маймылдай жәһәт эләктереп, күрше хатын ихатасына йомыла. Чибәр жилбәзәк йомшак куллары синең кытыршы маңгаеңнан сыйпаса, инде шуннан зуррак бәйрәм була димени! Гамәлдә шулай ул. Бал калагына тамчылы даруны салып тоттыргач, гүзәл хатын, хәйләле һәм мең вәгъдәле күзләре белән серле елмаеп-көлеп кенә, Морадым бәхетләнең, чынлап та, какъ маңгаеннан, хәтта ки битләреннән сыйпап куя лабаса! Гүзәлкәй, шул рәвешле, Морадым абзагызның күзен ачтыра да, бәхетле кытыклануларыннан дер-дер килгән күзгә бер тамчыны тамызып та куя һәм... шар-шор акырырга да керешә әле генә чиксез бәхетле булган Морадым дивана. Акыра гынамы соң, күзен тотып бакыра, үрле-кырлы сикерә, үз өенә таба чаба:

— Күзкәем, уфф, бетте, бетте күз, бетте баш! А-а-у-ухх! Хатын дим, син, өйдәме син?!

Ярдәмгә дигәч хатын кирәк бәндәгә...

Соңыннан ачыкланганча, суга киткән хатыны кайтып житә күрмәсен дип, күршегә керә алмый калудан куркыпмы, әллә, юкса, мәхәббәтенә артык та нык ашыгу-ашкынуданмы, күз даруы урынына ул хатынының аяк бармаклары бозылгач үки торган даруын эләктереп чапкан булган икән.

Яшерен-батырын түгел, дөп-дөресе шул: Морадым абзый мәхәббәт аркасында корбан иткән иде үзенең янып торган зәңгәр күзен. Үкенәме, үкенмиме, тәки төгәл генә бер сүз әйттерә алмадылар бу хакта: сөю хакына бер күз генә корбан итү күп түгелдер инде ул, дип, хәзер дә әллә шаярта, әллә чынлап әйтә. Белмәссең. Һәрхәлдә, Морадым карт бер генә күзлемен дип һич боекмады һәм хәзер дә боекмый, кимсенми, киресенчә, күп кешедән күбрәк күрә дигән даны йөри.

Менә шундый кеше янына килдем мин. Гадәтенчә, ул мине өйдән күтәрмә төбенә чыгып ук каршылады. Кем булуым, исәнлек-саулыгым белән кызыксынып алгач, мин дә, табигый, үземчә итагатьле булырга тырышып:

— Ничек, Морадым абзый, бу тирәләрдә өйдә генә ятасыңмы? — дип сораган идем, ул борын астындагы йоннарын тырпайта куйды:

— Һы, өйдә ятмай кайда ятаем, әллә тышта ятаеммы? Өйдә ике кат юрган ябынып та таманга килә бит әле.

Озак кына исемә килә алмый интектем. Үземнең тел чиштерә алу сәнгатемә ышанып житмәгәнлектән, өстәлгә самавар менеп баскач, портфельдәге запасны — Казаннан ук иярә кайткан ярты литр коньякны чыгарып утырттым һәм үкенмәдем. Ярты янында ярты сәгать тә утырмаганбыздыр, картның теле генә түгел, күңеле дә, хәтта жыр капчыгы да чишелеп китте:

Ботинкасы, ботинкасы,
Ботинкасы сакавай.
Иске любовь чурту матир,
Яңа любовь гатавай.

Һаман мәхәббәт турында җырлый ир кеше, әгәр башын җуймаса. Бик тә картаеп, «кыз» дия алмас дәрәҗәгә җиткәч тә, барыбер шул сүзне онытмыйча, «гыж, гыж» дип йөриячәк. Корткасы да үпкәләми тагы, котырта гына:

— Лубуф тагы сиңа, теле булмаса карга күтәреп китәр ие.

— Һы, тел ул безнең заманда самый важный эш коралы, баятасызсәнәксез яшәп була, иллә телсез булмый. Ә син, карга, имеш.

Шулай дип зәһәрсез генә ачуланып ала да тагын җырга күчә:

Китте карга, очты карга,
Карга егылды карга.
Шул карганы карар өчен
Карга җыелды карга.

«Я, ничегрәк?» дигәндәй, миңа да, корткасына да күз кысып алгач, ризыктан авыз итеп утырырга кушып, безне кыстарга керешә. Үз йомышымны мин чәй эчкәч, карт үз караватына менеп кунаклагач кына әйттем. Беренче хат эчтәлеген сөйләп биргәч, ул, шактый җитди кыяфәткә кереп, чигәләрен, муеннарын угалап торды.

— Һы, кем булыр икән андый яман хәлдәге бәндә? Бүгенгесе көндә? Элегрәк булса, мин сиңа сөйләп караган булыр идем.

— Соң, алайса, шунысын сөйлә. Элегрәк соң... булдымы хәл?

— Булмыйча кая китсен? Буласы килсә була инде ул, тотып тыя алмыйсың син аны.

— Менә шул тыя алмаслыкны белеп карыйк әле, ә?

— Сиңа кирәге юк аның: курыкма.

— Шулай да кызык бит.

— Анысын тыңлагач әйтерсең, ашыкма.

Барган атның башына сукма дигәндәй, бөтенләй киреләндермәс өчен, дилбегәне үз җаена куеп, тын калдым. Һәм ул, чыннан да: «Узган елгы хәл генә әле бу, иске дигәч тә алай», — дип, сөйләргә керешкәч, дәфтәрне үк чыгардым. Язуым сүзгә-сүз диярлек.

...Күзеңә чалынды микән, Әнис энем, безнең өйгә чапрыш кына ихатада берсенә-берсе терәлеп диярлек ике өй утыра. Берсе өр-яңа, алты почмаклы, калай түбәле өй. Икенчесе иске генә. Икесендә ике хатын тора. Искесендә — бианай, яңасында — өч баласы белән килене. Бианасы, хәләл өемнән күчмим дип, искесен сүттермичә шунда калды. Башта яңасына аяк та басмыйм дип җибәрсә дә, оныклары янына кермичә булдыра алмады алуын. Иллә йокларга барыбер үз куышына чыга ул. Көндезләрдә балалар күбесенчә үзләре аның янында гомер кичерә. Мәрхүм улы менә дигән йорт җиткерде, әнисе бәгъзе нәрсәләрне сизгән булып чыгадыр инде, улының шул байлыгына шилә фатиха бирмәде дә, улы исә өй җиткереп ел үтте дигәндә, шушы сараен гына түгел, менә дигән шәп дөньяны ук ташлап, үз теләге белән теге алама дөньяга китеп барды. Анысы әйтерсең тагы да шәбрәк. Ник алай ашыкпошык дисеңме? Үзебез дә шулайрак әйтәбез. Шаклар катты башлар. Әйе, кем, соңыннан аңладык бугай.

Күп чакта мин үзем — ындыр табагында каравылчы. Басуда да чыпчык та очырмыйм. Күзе берәү генә моның димә, аллага шөкер, минем күздән качып, үлән арасыннан елан да уза алмый. Госманның да бер хәрәкәте дә юктыр мин күрмәгән, мин белмәгән.

Шундый бер хикмәт хәтердә. Туңга сөрә бу, тракторист булып. Көндез куәтле яңгыр явып үтте. Җир йомшак, баткак. Кап-кара җир өсте. Тракторның утлары гына бара чекердәп, кыр буйлап. Сизәм, тракторы авыр тарта. Өстәвенә, алтөрәнгә еш кына салам җыелып җәфалый. Чамалыйм ки, Фәсихов дигән Госман алтөрәнне бер чистартып ала, ике, өч тә чистарта, иллә теңкәсе корыгач, бөтенләй үк алып ата. Икен-

че көнне моның төрәнен табып, җыеп куйдым — басуда күмелеп югалмасын өченгә. Алты гектар җирне алтөрәнсез, сай гына ермачлаган бу. Таң белән бардым янына да күрсәтәм шул очлы тимер кыяфәтендәге гөнаһсын:

— Синекеме бу?

— Басудагы һәр тимер өчен мин җаваплы дисәң, ялгышасың. — Госман тракторын сүндергәч, шулай дип тимерне үз урынына яңадан беркетә-беркетә, мин диванага акыл бирергә кереште. — Артык күп күрә торган күзгә — очлы тимер эләгә торган була, менә шушы төслерәк. Соңгы күзнең исән-имин булуы хәерлерәктер бит. Йомыбрак йөр син аны, йомыбрак!

Дөресе шул, бик тә кадерле бит күз — йомдым инде. Кул селектем дөньяның барлык гариплекләренә. Шул сәбәп белән ул җирне бригадир кабул иткән, хан кызында була торган хәтле дә гөнаһ әсәре тапмыйча. Мондый җир яз көне культивацияләнсә дә, иген бердәм шытса да, барыбер аны чүп күмә. Менә шунда инде залим кешене эзлиләр дә минем ярдәмнән башка гына табып та куялар. Кешесе — Фәсихов мөртәт. Былтыр алтынчы июльдә сөргән җиренә колхозның барча механизаторлары, кырыклап кеше җыелып, алдакчыны җавапка тарта. Кыңгыр эш тугыз айны көтмичә, сигез айдан ук калкып чыга. Иллә төнәгәндер, ант иткәндер димә, Әнис энем. Август аенда тагын шул гөнаһ — прицепщигын кайтарып җибәргән дә тагын алтөрәнсез йөргән. Шушысы да өстәлгәч, тракторист дигән исеменнән мәхрүм иттеләр. Көз вә кыш буе сәгать төзәтеп чыкты. Болай механизатордан ким акча эшләмәгәндер, артыграк булмаса. Ну, авылда механизаторның базары югарырак инде, ни әйтсәң дә. Икенче җәйдә ялынып диярлек сорап, яңа комбайн алды. Келтерәп йөргән машинага такмаклар гына кушып-өстәп йөрмәле иде. Иллә ул такмакларның адәм ышанмастайларын гына көйли торган бәндә шул.

Беренче көннәрдә әллә ни кыйрата алмаса да, соңынтын җырлый башлады бу. Арттальктан әкрен әкрен урталыкка, урталыктан беренчеләр рәтенә үрмәләде. Шундый да вакыт җитте ки, иң гаярь алдынгы маяк белән янәшәдәге биеклеккә менеп китте. Хәзер икәү сөзешә болар, Миңләхмәт дигән Исламетдинов белән. Күчмә әләм я моның комбайнында, я тегесенекендә җилферди. Болар артыннан житәм дип, Сәрбиназ атлы кыз бала кабалана. Һәр өчәвенең бункерына бер-бер артлы кызыл йолдызлар төшерелә. Болар инде — фәлән җиңүгә өлгәште дигән билгеләр. Колхоз йолдызлары, икенчеләй әйтсәк. Күпләр өчен хәзер өчесе дә кадерле, өчесе дә изге. Фәсиховка теге чакта алтөрән өчен бәйләнергә мәҗбүр иткән вакчыллыгымнан оялa ук башладым. Ә Миңләхмәт белән Сәрбиназны, көн дә бер җай табып, аркаларыннан сөеп китәм.

Миңләхмәтне беләүдән беләм мин. Мәктәптә чакта ук машина җене кагылган иде үзенә. Шундый көнен хәтерлим. Сумкасын тотып кайтышлый басуга кагылып, күрше абыйсы янына килде дә тракторны йөртеп карыйм әле дип чат ябышты. Бик тә ихлас сораганлыктан, бирделәр моңа тракторны. Күз алдыңа китер, улым. Бәп-бәләкәй куллар рульгә чытырдап ябышкан — аларны аеру мөмкин түгелдер, руль белән ул куллар берегеп үскәндер, бер үк корычтан коелгандыр шикелле. Артыннан тигез кара тасма сузылып кала — тип-тигез буразналар. Малай үз гомерендә беренче мәртәбә сузган буразналар. Исән-аман урап килгәч, күрше абыйсы аның аркасыннан какты, матур сүзләр дә тапты. Иллә малай үзенә дә аерым трактор сорагач, аптырап калды. Ул җәйне бик үтенеп сораса да, Миңлегә трактор бирә алмадылар, бик яшь әле син, диделәр. Көз көне укырга җибәрделәр. Армиядән кайткannан бирле менә бернichә ел инде иң атчайный, булдыклы маяк — Миңләхмәт. Дарым үзен йөрәксез дип мыскыллыйлар. Ничек дип, шул инде, йөрәген

тотып кара, үзең ышанырсың. Тумыштан юк йөрәк. Ышанмасаң ышанма, мин сине көчләп ышандырмыйм бит. Менә шулай, республикада өч кенә кеше алар, махсус исәптә торалар. Әйе. Ну, дарым што йөрәксез, үзе елның-елына сабан туе батыры. Бәхәсләшеп кара син аның белән, Фәсихов хәленә каласың килсә. Менә шундый егет ул безнең Миңләхмәт. Яшьрәкләр йөрәксез Мини дип йөртәләр үзен. Кызыксынырсың, бик шәп. Ярый. Ә Сәрбиназ кем дисеңме? Анысы да яшьләй тотынган механизатор. Ул да өч йолдызның берсе булып ашлык суктыра. Иллә машинасы кинәт абына моның — берьюлы ике детале диме сафтан чыга. Ул комбайнын сүтәргә керешә. Соңгы шөрепне борып алганда караса, инде караңгы төшкән. Кыз басуда бер ялгызы.

Комбайн ышыгыннан бераз читкәрәк чыгып, Сәрбиназ күккә карый, бөркәү астыннан муен сузып мин карыйм: һаваны кара болыт каплаган. Сәрбиназ өчен уйлыйм: көннәр бозылуга таба бара, ашыгырга кирәк, ашыгырга, ватык тимерләрне бүген үк төзәттерергә кирәк.

Иртәгесен сораштырып белүемчә, кыз шулай ашыккан да. Иллә мастерскойда җан иясе юк. Сварщикның өенә барып, мең вәгъдәләр бирә-бирә (яртысыз да котыла алмагандыр әле), шул ук төндә төзәттереп ала да таң белән — тагын басуга.

Миңләхмәт тә чыкта эз калдыра-калдыра килде. Ә Фәсихов... Менә анысы бик тә вакытында, салмак кына кыймылдап штурвалга тотынганда, тегеләрнең комбайннары артыннан дистәгә якын тезмә сузылып калган иде инде. Бу көннең хәлиткеч көн икәнен алар түгел, мин дә сизәм. Фәсихов ташбака мисалында калачак. Монысы күзгә, инде минем күрми торган күзгә дә аермачык булып ярылып ята. Тик ышансаң ышан, ышанмасаң ышанма, зиһенлерәк адәмнәр дә күрә алмаслык хикмәтләр дә юк түгел икән: кич җитәрәк тикшереп карасалар, Фәсиховның бодае боларныкынннан ким булу түгел, киресенчә, шактый ук артык та икән ләбаса! Менә шулай, акка кара белән язып куйганнар! Сезнең тормышта да шундыйрак экәмәтләр бар дигән хәбәрләр йөри башлады, сез ничек карый, ничек түзәсездер, Әнис энем, без исә бер мәлгә өнсез калдык. Җанып-пешеп эшләгәннәрнең бункерга сыйган ашлыгы сигез-тугыз центнер булса, Фәсиховныкы унике, хәтта ки унөчкә җиткән. Шул хәбәрне учка кысып, Миңләхмәткә чаптым. Машинасын туктаткач, тыным-көнем бетеп аңлаткан гына идем, сикереп тә төште бу, чабып та китте бу, бөркәү янына җиткәч, весовщикны селтәп тә атты. Менә сиңа йөрәксез. Дарым что. Мин барып җиткәндә, весовщик дигән Саттар көшел өстендә кыймылдарга да куркып ята иде. Ә Миңне аның өстенә барып менәрдәй, таптап кәтлит ясардай талпына:

— Сатлык җан! Син, син, син бутаган моны, и һәм юри бутаган, аракыга, илле грамм аракыга сатылган падлис, мин сиңа бушка да илле литрны куйган булыр идем нәфсеңне сиздерсәң, кабахәт танау.

Көшел өстендә ике кулына таянган Саттар калтыравын гына белә, без исә анысын да белмибез, тирә-якта кем бар, әммәсе күзләрен генә чет-чет йома. Ә Миңне шул арада Саттар абыйсын иңеченнән учлап, күтәреп алды да яңадан ашлыкка дыңкыды.

— Үтерәм, паразит, әгәр дә мәгәр дөресен генә әйтеп бирмәсәң, башыңны йолкып алам да әнә теге Өчнарат чокырына тикле тондырам. Әйтеп кал: ник яздың безнең бодайны шул Фәсихов дигән хәсискә? Әйт, хәзер үк. Яздыңмы? Әйтеп котыл — яздың бит? Яздың!

Куян да куян, Саттар да куян — аның да кулга эләккәне: кая сугышу диген, бер авыз сүз әйтә алмыйча калтырап, нишләтсәләр шуңа риза булып тик ята, күп булса, ауный. Якасыннан күтәреп торгызгач кына, анда да карышмыйча гына басып калды. Ник дисәң, өстәвенә, үзеннән аракы исе чынлап та аңкый икән әле. Эш вакытында, шушындый уттай урак өстендә!

Иллә Миңләхмәт аның йотылган телен тәки тартып чыгара алмады, һич югы, бер кәррә сүзен. Котырган аюдай килсә, шул ук ярсыну белән китеп тә барды. Фәсихов сыңарыдай, матайда тырылдап килгән председатель аның шундый яман чагына туры килде. Матайга мин дә (хәлләр буласын шәйлим бит) кунаклап, Ильяска чатырдап ябыштым.

Комбайнны куып җиттек. Беренче урынны әле дә бирми килгән иң алдынгы Миңләхмәт Исламетдиновны күрү шатлыклы булырга тиеш иде дә бит...

— Ничек эшләр? — диде председатель барып туктауга.

— Эшләр шундыйга җитте, иптәш председатель, прямы косасылар килә.

— Нәрсә сөйлисең, Мини, көмәнең бар мәллә? — дип, әйтерсең Фәсиховка булган ачуын моңа аударырга тырышты Ильяс. — Әллә һава җитмиме? Кырда?

— Җирәндергеч кешеләрегездән, иптәш председатель. Саф һавагыз да памагать итми.

— Төш әле монда, аңлатып кара.

Миңләхмәт җиргә төште.

— Югыйсә, минем баш тиз генә төшенми башлады, — дип үзенең сәбәпсез тупаслыгын төзәтергә азапланды бугай Ильяс бахыр.— Эш нәрсәдә?

— Эш — эшсезлектә, иптәш председатель. Нишләп комбайн тикле комбайнны бурларга ышанып тапшырасыз?

— Фәсиховны әйтсәң, ул үзе тәртип, гаделлек сакчысы. Тел тидерәсе булма.

Җантурин егетне юри котыртты гына, әлбәттә. Иллә монысының ачулы кинаяне дә аңларлык көче һәм вакыты калмаган. Ул тагын да ярсый төшеп:

— Дөрес, тел тидерәсе калмаган, йодрык кына памагать итсә итәр аңа. Ә син шуны яклап азапланасың,— дип акырды.

— Фәсихов минем иң якын әшнәм бит.

— Кирәгем исә чуртың булсын, карак икән, барыбер бур инде ул.

— Нишләгән?

— Ул минем центнерларны урлый, и мйнекен генә дә түгел, барлык комбайнерларныкын.

Хәбәр мине гаҗәпләндермәде, әлбәттә. Кырдан-кырга, авылдан-авылга матайда, Ильяс үзе бүләк иткән «Москвич»та чаба-чаба, бөтен эшне ярдәмчесенә тапшыруына ис китмәсә дә, урылган гектарларының шактый ук тиз артуы шикләндерә иде бит. Ярдәмче комбайнер нихәтле уңган булмасын, аның Миңләхмәт кебек атаклы маяк белән ярышырлык түгеллеге уйлап чыгара алмаслык табышмак түгел иде.

— Шулай, шикләндек ди?

Җантурин уйлана калган арада Миңләхмәт папирос кабызган һәм шуны каты-каты суырып, озын күмергә әйләндереп өлгергән, инде күмерне һаман суырырга азапланып та берни чыгара алмагач, аңа бик яман ачуланып, кат-кат төкереп, әйтерсең кемнәрнеңдер юньсезлеген, әшәкелеген бар көченә таптарга, изәргә керешә егет:

— Шик, шик! Нинди шик? Нинди шик булсын ди, бөтен дөньяга күренеп торган факты ич бу, факты!

— Соң, күрсәтеп, аңлатып кара.

— Весовщикны эчертә.

— Ә без аны каян белик?

Мини үпкәләде. Күл селтәп комбайнына менеп үк китмәкче иде дә, Ильяс аны тыя куйды:

— Соң, мин сиңа ышанам, Мини. Шулай — эчертә. Ну, шуннан?

— Ә ник эчертә? Күзләре матур булганы өчен дисеңме? Алай уйласаң, бик нык ялгышасың.

— Ярый, тикшерербез. Бүгеннән контроль куям. Иллә син сөйләнми тор. Югыйсә, шушы уттай эш өстендә син мине иң алдынгы комбайнерымнан колак кактыруың бар. Яла өчен хәзер үк судка бирәчәк ул син ачык авызны.

— Ну, котыңны алып бетергән икән.

— Сак булудан зыян юк, кем икәнен беләсең бит.

— Ну бетте, кабер, батты, ыһ дигәнне дә ишетмәссез.— Миңләхмәт елмая ук язды. — Шунысын абайла — үзең бүләк иткән «Москвич» белән кич саен шушы тирәдә выжылдый. Багажнигы дисәң, па-ма-ему, анысы буш ук булмый.

Контроль кую нәтиҗәсе көнендә үк көтелгәнчә булды — шул кичтә Фәсихов комбайны аша узган ашлык бермә-бер диярлек кимесә, икенче кичтә багажнигыннан шактый зур капчык тулы чистартылмаган арыш өстерәп чыгардылар.

— Хакыгыз юк, кешегә күрәләтә тентү кертергә хакыгыз юк! — дип кычкыра-кычкыра, Фәсихов үзе үк менә дигән шик кузгатты.

Ревком председателенә участковыйны чакырырга боерык бирелде. Ә Фәсихов капчыкны өйгә таба өстерәмәкче иткәч, Ильяс капчыкка аяк белән басты:

— Кузгаласы булма, башың ике булмаса.

Бу вакыт ул чамадан тыш кызган иде. Һәм буйсынмаса эшнең ни белән бетәсен Госман карак тиз чамалады булса кирәк. Ашлыкны калдырып, машинасына утырды да каядыр тагын пырылдап китеп барды. Соңыннан ачыкланганча, участковыйга үзе чапкан икән. Имеш, председатель, газетага язган өчен үч алу нияте белән тентү кертеп, закон боза. Участковый, барын да шунда ачыкларбыз дип, вакыйга урынына ашыккан. Килеп житкәч тә, ул озак бәхәсләшмәде — бер капчык кибәкле ашлыкны конфискацияләп акт төзеде дә икенче көнне районга китте. Шул ук көнне Фәсихов йортына тентү керде: каян алынганы билгесез булган бер мең өч йөз сумлык дефицит төзү материалы, «ЗИД-4,5 дигән маркалы мотор, колхозларга гына сатыла торган рамлы пычкы һәм башка сирәк әйберләрдән тыш; унсигез центнер чистартылмаган ашлык килеп чыкты.

— Бу хәтле ашлык нигә кирәк сиңа? — дип сорый участковый.

— Ашлык түгел — кибәк. Кош-кортка, малга. Кыш буена җитми дә ул.

— Әле яна ашлыкны колхозның бүлгәне юк. Чистартылмаган килеш гомумән бирми. Син моны каян алдың?

Фәсихов, мыгырдана-мыгырдана булса да, весовщик Саттар исемен атамыйча кала алмады. Имештер, аннан сатып алган. Участковый: «Ихтимал, Саттар өенә дә тентү керү зарурдыр», — дип фараз итсә дә... Ләкин... Ләкин тентүнең кирәге чыкмады. Иртәгесен Саттарның үз келәтендә асылынган хәлдә табылганлыгын хәбәр иттеләр.

...Фәсиховның кемлеге шул рәвешле бөтен тирә-якка фаш ителүгә карамастан, Ильяс җилкәсенә өйгән нахаклары күтәрә алмаслык йөк буларак һаман кала бирде. Шул авырлык безне йончыта, хәлдән тайдыра. Бер кешенең пычраклыгы икенче кешенең чисталыгын исбат итми шул... Күзгә чалынуга ук укшыта торган газетаны мең ыргытам да бер күтәреп алам. Карамаска тырышкан килеш, күзләрне авырттырыр дәрәҗәдә көчәндереп, чәчләрне үрә торгыза торган сүзләр укыйм. Укыйм гынамы, ятлыйм — һәр җөмләсен генә түгел, һәр сүзен, һәр хәрефен һәм өтерен Кайда нинди билге торганлыгын күз йомган хәлдә әйтә аламдыр хәзер.

«Колхоз председателе теләсә кая мал җибәрә. Ит комбинатына вак мал озатып, өч башны ике баш күрсәтеп, колхозга табышны артыграк ала».

Шулай, терлек эре булганда, дәүләттән илле процент акча артык түләнә бит. Бу җайдан файдаланмый калмагандыр дип уйлаган инде ул... Карак кайда ничек урлашу мөмкинлеген белә! Һәм ары менә:

«Колхоз председателе, биш мең центнерга якын икмәкне дәүләткә бирмичә, яшереп калган... Дәүләт планын үтәгәннән соң, исәптә булмаган малларны ашату өчен...»

Монысында да бәйләнер җай бар: ферма кешеләре, дәүләткә биреләсе отчетны вакытында өлгертсеннәр дип, терлекләрне егерменче декабрьда ук санаилар-исәплиләр һәм нәтиҗәләрне бухгалтериягә тапшыралар. Ә безнең ревком аларны ай беткәндә санаи. Атна-ун көн эчендә туган маллар отчетка керми кала. Сәлимгәрәй шуны Госман дустына әйтә дә, тегесе язып җибәрә... Закон бозылган булып чыга. Ун көн эчендә туган маллар февраль отчетына керсә дә... бәйләнергә барыбер мөмкин шул...

Тик ашлык белән булган хәлне Фәсихов бөтенләй һавадан йолкып алган. Ләкин теләсәң, үчләшсәң шунысына да бәйләнергә була: ашлыкны сугу белән берәттән, комбайннар аны теземнәргә дә салалар бит. Теземгә салганда (сугу белән чагыштырганда) эш хакы аз чыга. Шуңа күрә комбайнчылар ургыч тагарга теләмиләр, гел суктыру ягын каералар. Идарә аларның тезмгә салганда да кызыксынулары кимемәсен өчен шундый чара күрде: бер гектар урса, ун центнер сукканга исәпләнә. Билгеле инде, ведомостьлар белән саф ашлык күләмен тикшерсәң, күпмедер ашлык ким күренә... Аерма — биш мең центнер чамасы.

Корреспондент Сәлимгәрәйгә кергән дә:

— Дөресме шушы аерма? — дип сораган.

— Дөрес! — дип мөһер суккан баш бухгалтер һәм, әлбәттә, идарә карарын күрсәтергә, аңлатырга азапланмаган.

Колхозда биш йөз савым сыер бар иде. Шуларның йөз иллесе бозауларга имезелә дип, Сәлимгәрәй янә отчет әзерләгән. Ә чынлыкта барысы да савыла анын. Отчет шул килеш китсә, Фәсихов тагын язып җибәрер иде дә, тикшерү килсә, баш бухгалтердан:

— Дөресме шушы факт! — дип сорарлар иде һәм Сәлимгәрәй:

— Дөрес! — дип мөһер чәпәгән булыр иде.

Ләкин инде ышанычы какшаганга күрә, отчетның һәр графасын Ильяс нык тикшереп чыккан. Сәлимгәрәй: «Аһ, ялгышканмын икән!» — дип, бик тиз гафу үтенергә керешсә дә, председатель инде аңа ышана алачак түгел. Шуңа күрә хәлне идарәгә, шулай ук районга җиткергән ул. Хәер, монысы артык мәшәкать кенә иде. Барыбер, бөтенесен бергә тикшерү өчен безгә район җитәкчелеге оештырган махсус комиссия килеп төште. Иптәш Рамазанов безгә ышана, игенгә, сөткә ышана. Комиссия, әлбәттә, безнең эшкә түгел, газетага чыккан мәкаләгә бәя бирмәк өчен җибәрелгән ул.

Морадым абзыйның Җантуринга мөнәсәбәте тәмам ачык беленгәнлектән, томандарак калганны кайтарып сорадым:

— Үлчәүчене әйтәм, Саттарны. Фәсихов аркасында дип, кистереп үк әйтергә буламыни соң?

— Иманым камил — теге тынычрак дөньяга ул тентүдән куркып качты. Фәсиховның бик нык тырышканлыгы көн кебек ачык иде. Аннан кире шунысы да мәгълүм: элегрәк ул бик тә салырга маһир, бульниска барып, личит ителеп тә кайткан иде. Фәсихов, мөртәт, ирексезләп, куркытып, иманнан кире яздырган. Ни белән беткәнен әйттем. Бетте, Әнис улым, шуның белән, бүтән юк.

Ә мин, бу «бетте»ләрнең үзләреннән бигрәк, карт әле тагын сөйли алачак хәл-әхвәлләрнең чиксез икәненә ышанган кеше, урынымнан тиз кубарга җыенмыйм, берни көтмәгән кыяфәттә илтифатсыз утыра би-

рәм. Абзыйның бүтән эшкә кәефе дә, вакыты да юк. Хикәясен үз теләге белән дәвам итә ул.

Чын маяклар урып-суккан бодай исәбенә күкрәгенә Алтын Йолдыз тагарга иде Фәсиховның нияте, тотылып харап булды. Тотылмаса күрер идең син аны, ә? Тотылмаганнары да юк түгел дигән хәбәрләр дә ишеткәнем бар, бүтән җирләрдә ягъни. Сезнең арада да бардыр инде ул... Хикмәт, исән йөриләр. Бетте, Әнис улым, эһем. Һәр һөнәрнең үз җае... Бетте.

Фәсиховка дисеңме? Җык булсынмыни аңа. Комбайннан мәхрүм калып котылды. Чуртанны диңгезгә дигәндәй — хәзер сәгатьләр төзәтә, шуның белән бергә, төп һөнәренә керешә — үзе белгән барлык эш кешеләре өстеннән югарыга, барча түрәләргә вә газетларгә ялган хатлар яза. Бөтен авылны дер селкетеп яши бирә, ә весаушик, мәрхүм... әнә чапрыш ихатадагы ике йорт берьюлы хуҗасыз калды. Әнисе, хатыны, ике баласы — ятимнәр. Фәсихов автомобильдә җил куа бирә. Бетте инде, улым, бүтән юк, эһем.

Саттарның хатыны бервакыт идарә йорты каршында Фәсиховны туры китергәч, бөтен мир алдында хур итте итүен:

— Син генә үтердең иремне, син генә ятим калдырдың балаларымны! — дип каргады. — Машинаң-ниең белән җир йотсын, ярдан капланып үл, хәшәрәт! — дип тә каргады һәм күз яшьләре түкте. Ә Госман тагы чиста — халык алдында яла якты дип, ятимәне судка тартты. Тегенди-мондый җәза бирдерә алмаса да, теңкәсенә шактый тиде район үзәгенә чакырттыра-чакырттыра. Шулай ул күп нәрсәдә үзе кешеләрне гаепләүче, дөреслек якчысы, әүлия шикелле йөри. Колхоз җитәкчеләрен сүгеп язган хатларында имзасын «Дөреслек корбаны», яисә «Хакыйкать якчысы» дип куя икән, имансыз. Менә, шул бар булганы, бетте. Бетте, улым. Син якларлык кеше бар иде, весаушикны әйтәм, иллә бер генә елга соңга калгансың. Хәзер ярдәмең тимәстер, улым. Гәрчә бер кеше тагын бар, анысы да җайсызрак хәлдә. Иллә әйтү кыен — анысы лаек микән андый асубый хөрмәткә? Нindirәк кеше? Син, ни, шулай диярсең инде ул.

Әйбәт, шәп кеше иде. Соңгы елларга тикле әйбәт кенә эшләде. Элекке баш зоотехник Үрәзмәтне әйтүем. Анысының чире — хатыны. Шуны көйли-көйли әрәм булды бахыр. Ничек дип ни — артык та нык ярату аркасында. Патшалар да яшәргә оялмаслык йорт-кураны әйтеп тә тормастан, кием-салым җәһәтеннән дә патша кәләшләренә хас затлы дәрәҗәгә үрмәләде моның бичәсе. Калага барса, безгә исемнәре үк билгеле булмаган әллә нинди җанвар тиреләреннән ясалган якалар, туннар, бүрекләр һәм итекләр, туфли вә кәчтүмнәр — гел ташый кеше сөекле хатынына, гел җыя малны әрлән мисалында. Хатын чик белә торган түгел — һаман җитми, һаман сорый. Өстәвенә, бәйрәм ярата. Үзе духтыр, башкаларны эчмәскә үгетли, ә үзе, кич җиттеме, ир белән бергә чүмерә, тутыра дөньяның ачы суын затлы корсагына. Типтереп яши торгач, корсак дигәннән, боларның да кыңгыр эшләре калкып чыкмас диген. Шулай, килеп, төртеп чыкты — шөшле түгел, без. Шулай. Әүвәлдәнрәк китереп әйтим әле. Ирнең, самый главный зоотехник булган кешенең, арганизмасы алай ук шәп яшәрлек булмаган, күрәсең — бик тә чынлап чирли башлады. Ашаганы аш түгел, ризык яна да бетә, күпме ашаса да, тәнгә сихәте юк. Хатыны врач була торып, ирен шундый хәлгә төшерсен әле. Менә нинди тамаша бит.

Әмма кеше, чирләгән берсе, гел район үзәгенә барырга тырыша. Безнең авылдагы бу духтырга пешкән, кысылган төш белән генә киләләр. Ә баш зоотехник булган бу егетне исә калага ук алып киттеләр. Шулай булуга карамастан, хатын каушап төшми. Алай гынамы, угата ихласрак яшәргә керешә. Бер мәлне мин пожарныйга болай эш юклыктан гына кергән идем, телефон шалтырый. Ягъни, телефонның эше шул

бит инде — шалтырый бирсен. Иллә бер шалтыравында үзсүзлерәк шалтырады да, андый-мондый хәтәр нәрсә була күрмәсен дип тыңламакчы идем, исем китеп дигәндәй торам: бер дә алай ук яна торган нәрсә түгел икән. Калага бульниска киткән зоотехник Үрәзмәтнең... монаеп калган дип уйланырга тиешле Кәримә... Ихахай да михахай, ят ир белән гәпләшә. Искитмәле кайнар, баллы сүзләр озатышалар. Кеше ишетер дип куркудан ук узганнар лабаса! Үрәзмәтнең өйдә түгеллеге кердe телләренә. Ахырда ят ир ниндидер үзләре белгән жиргә, төгәлрәк әйтә төшсәк, Өчнарат чокыры янындагы урман полосасына чакыра Кәримәсен. Кәримә ялындыра:

— Белмим шул, вакыт юк бит.

— Син инде тагы бер кешене чиргә сабыштырма, саргайтма — әдәм бул.

— Бардыр әле миннән башка да.

— Валлаһи, билләһи, беркемем дә юк. Синнән башканы яратырга, әллә минем башка тай типкәнме?

— Типмәсә тибәр.

— Типтермәбез, алла бирсә, үзебез типтерербез, икенче төрле.

— Нигә өметләнәсең? Пунктта грамм спирт юк.

— Һы, тапты сүз. Спирт. Син үзең спирт, тәмам исерттең газиз башкаемны, диваналар иттең. Болай да айный алмыйм. Тамчы да кирәкми. Кирәк түгел, үзем табармын. Әйе, анысы минем өстә. Син кил генә. Булдымы? Киләсеңме? Син алай икеле-микеле сөйләшмә инде, теге юлы килешкән идек бит. Мин китәм, булдымы, китәм!

— Ярый, карарбыз әле, вакыты житсен.

Вакыты дигәннән, кичкә таба, бердәнбер күземне чекерәйтеп, юри күзәтеп тордым. Менә бит жәнлек шомасы — караңгы төшәр-төшмәстә, әнәдән-жептән чыккан матур киемнәрен киенеп, урман полосасына табатын менеп китте Кәримә дигән кәнтәй!

Үрәзмәт дигән ир калада һыңгырашып ята...

Мондый хыянәтне сез ничек бәяли торгансыз, ә минем жен ачуларым купты. Өсләренә барып чыгып, киемнәрен жыеп алып, әллә ялангач кайтарыргамы дигән уй да кузгалган иде дә, картлыгымнан оялдым. Яшьләрнекен белмәссең, бәлки үзләренчә хаклыдыр алар. Карасыннар инде, ә син күрә торган бердәнбер күзеңне йом да күрми торганын ачыбрак кара. Анысы дөресрәк мәгълүмат бирмәгәе. Аннары бит, Морадым туган, үзең дә бит мәхәббәт дигәндә бик үк тугрылардан түгел идең шикелле... югалган күзкәеңне яд ит тә, дога кыл да койрыгыңны кыс. Шулай дип, үземне тиз арада тынычландырдым. Хәзер кешеләрне сафлыкка өйрәтә башлаган, имеш, әүлия-суфи. Иллә дә Үрәзмәтне барыбер кызгандым. Чирле хәлдә тилмереп, еракта ятканга күрә. Шунысын әйтим хәзер, кызгануым урынлы ук булмаган. Хатыны үзенә тәки пар икән юньсезнең, мәгънәсез жан.

Ильяс белән якын ук дуслар иде алар — бәйрәмме, туймы-тегеме — табынны гел бергә кордылар. Бигрәк тә Үрәзмәт үзе якын итә иде аны, әллә түрә булганга. Гөнаһсына кермик. Кешене ярып карап булмый. Тегеләйме, болаймы, шунысы хак: Үрәзмәт Ильясны атна саен кунакка чакыра, тегесе жавап бирергә тырыша: шундый дуслык, көнләшеп туймаслык.

Иллә бер мәл жайсызрак хәл килеп чыкты бит: колхоз дәүләткә йон сату бурычын үти алмый азаплана. Бер илтә, ике илтә — тулмый төпсез кое. Аптырагач, әзерләүләр кантурына Ильяс үзе барган да шундагы кабул итүче колагына пышылдап үзенең авыр хәлен аңлата икән:

— Табып булмасмы, янәсе, сатып алырга йон?

— Табып булырга мөмкин — дус-ишкә.

— Дусың түгел, туганың булырга ризамын, тик тап кына.

Икенче көнне Үрәзмәткә саф акча тоттырып, әзерләүләр кантурына, кабул итүчегә җибәрә вә шул рәвешле законга хилаф эш аркылы колхозның бурычын да, йөкләмәсен дә үти. Бурыч үтәлүен үтәлә дә, тик җанны нәрсәдер һаман кимерә тора. Уйлый торгач, менә нинди фикергә килә Ильяс дигән Җантурин: йон күп кыркылды, план үтәргә генә түгел, бүтәннәргә ярдәм итәрлек тә рәт чыгарга тиеш иде, әгәр дә мәгәр коеның төбе тишелмәгән булса. Тишелде, тәки тишелде коеның төбе. Шундый ныклы фикергә килү аркасында, планны арттырып үтәмәк өчен дигән булып, барлы-юклы йонны кабат та җибәртмәкче була да Үрәзмәткә шул эшне тапшыра. Газизҗанов Рамил дигән рядовой зоотехникны күзәтергә куша. Һәм дә күзәтә тегесе: Үрәзмәт үлчи йонны, тиешле кәгазьләрен яза. Берни аңламаган яшь зоотехник күреп тора: үлчәгечтә бер сан иде, мәгәр накладнойда — икенче... Үлчәгечтә күбрәк сан иде, мәгәр кәгазьдә бәләкәйрәк... Әзерләүләр пунктында караклар җинаять өстендә тотылалар.

Шул көннәрдә Ильясның ничек тузынуын күрсәң! Үз йоныңны үзең сатып ал инде, ә! Ояты ни тора! Үрәзмәт үзенең якын дустына колхозның үз йонын, анда да закон боздырып, вөҗдан пычраттырып саткан бит әле! Эттән алып эткә салды председатель үзенең якын дустын — тегесе сүз дә әйтә алмый, тик тора. Фәсихов аркасында Миңле кулына эләккән Саттар мисалында — әреплә шми дә. Эштән чыгардылар. Чирле булуы сәбәпле, хәзер пенсия белән генә канәгатьләнеп ята.

И мин аңладым шул мәлдә: Кәримәсе моны алдаган чагында артык олы җинаять эшләмәгән икән лә. Рас инде үзеңә ышанган дусны сата аласың икән, рас үзең кешелеккә җинаять итә аласың икән, тиешле җәза килә дә килә инде ул. Дөньяда ниндидер күзгә күренми торган гаделлек, минем уйлап йөрүемчә, тәки бар бит ул. Эчке бер көч. Сез галим икәнсез, ачыгыз шул хикмәтле законны. Карак тотылмаса, җәзасыз калу ихтимал, иллә урынсыз катылык... шуның аркасында булган рәнҗеш хуҗасына барыбер кайта. Кайтмый калмый. Бүген булмаса, иртәгә. Мондый чакта хатынның кайтарма адресын юри язмый калдырсаң да, шәфкатьсезлек дигән кара белән язган ул хат барыбер сине эзләп таба. Бүген булмаса, иртәгә.

Ныклап уйласаң, Үрәзмәтне кызганырга мөмкиндер. Хәзер бигрәк тә: үзенә-үзе укол ясап кына дөньяга эләгеп тора. Шуның өстәвенәргә, эчкечелеккә сабышты. Анысы тагы бер җәза — вөҗдан сызлавына түзә алмый бәндә. Мин барыбер беткән кеше инде дип, кайчакта уколын ясамый калдыра дип тә сөйлиләр. Анысына да ышанам. Моңа хәтле әйбәт кеше булганлыктан, соңгы вакытларда гына ялгыш юлга тайпылганлыгын исәпкә алсаң, ихтимал, аңа мондый ук җәза тиеш түгелдер. Ни дисәң дә, хатын аркасындарак харап булган кеше бит. Әмма табигать, кешенең борыннан килгән табигате сәбәпләр белән исәпләшми, адбукатлар аңа кирәк түгел. Күпме генә акчага да мондый чакта синең хәлне беркем җиңеләйтә алмаячак.

Менә шулай, балам, үзең кара, үзең уйла.

Бетте, Әнис улым, бүтән юк.

## Бодай кыяк суза

*22 май, 1977.*

Гомеремнең мәгънәсез кара елларында авылда үземне рәнҗеткән, тәмәке һәм харам ризыктан саргаеп беткән тешләрен йөрәгемә батыра белгән җәнлекләрне акылга утырту, дөреслекне, хаклыгымны раслау,

хаксызларга тиешле җәзаны кайтару өчен мең планнар корып, мин Казанга юридик институтка керермен дип киткән идем. Ләкин кала шау-шуына күмелгәч, андагы масштаблар нисбәтендә бу максат гаҗәп тә бәләкәй булып калды. Шуны бик тә тиз арада тоеп, кайтарасы үчне аймылыш калдырып, үзем өчен кадерлерәк хыялларга таба киттем.

Чынлап та: кемнәргә үчләшергә, кемнәр каршында дәреслекне исбат итәргә тиеш идем соң мин? Һәм ни өчен тәгаен мин? Бәлки бу эшне миннән остарак, тынычрак һәм шуңа күрә дәресрәк утәүчеләр юк түгелдер?

Мин үчләшкән беренче адәм — Галибәк Хәмәтдинов. Культура йортында эшләгән чагымда соңгы бәрелеш... Юк, дөресрәге — аның үчләшүе иде. Минем тиешенчә хөрмәт күрсәтә белмәвем аркасында. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, районның «каймагы» җыелган залда аннан билет сораган өчен.

Лампалар ник корымлана дип тиргәве генә ярсуын басмаган булып чыкты. Җәмәгатьчелек каршында дәрәҗәсе какшау килеш калды, дип фараз итте, күрәсең. Директор укырга китеп баргач, бүтән кеше булмаганлыктан, культура йорты җитәкчелеген көчләп диярлек миңа йөкләгәннәр иде. Җәй айлары, укуга вакыт бирми торырга мөмкин дип, ризалаштым — көзгә хәтле ходай ни бирмәс... Әйе, үзем баянчы, үзем художество җитәкчесе, үзем директор. Чынлап эшләсәң, башың-колагың белән чумарлык. Һәм мин чумдым, тик исән чыгу өчен күкрәккә һаваны гына азрак тутырганмын, ахрысы.

Калага барып, «Тальян гармун» дигән пьеса кулга төшердем — өр-яңа әсәр. Композитор аңа күп кенә көйләр язган, барлы-юклы акчага танышлар ясап, алар аркылы композитордан ноталар сорап алдым. Ай дигәндә, агитбригада оештырып, спектакльне үзебездәге шартлар мөмкинлек биргәнчә өлгертеп, авыл сәхнәләрендә мөкәммәлләштереп, көзгә таба республика үзешчән сәнгать коллективлары смотрында беренче урынны алып кайткач, инде укуны юлга салу нияте белән культура йортында сирәгрәк күренә башлавымны (ул чакта анда көннәр буе буталуның хаҗәте дә юк, чөнки әле яңа программага тотынылмаган) каяндыр, ничектер сизеп, Галибәк галиҗәнаб шул көннәрнең бер иртәсендә мине ниндидер утырышка чакыра, имеш. Кулга кәгазь тоттырдылар: фәлән көнгә, фәлән сәгатькә. Мин культура йортында буталган бөтен тарихта беренче очрак бу, мондый игътибарны бүтән хәтерләмим. Көн тәртибе — культура йортында хезмәт һәм исәп тәртибе. Бухгалтериягә (ул бер генә кешедән тора) ревизия килгән. Гадәти эш дим, курка белмим әле. Хәер, курыксам, уйлана төшсәм дә, файдасы тиячәк түгел иде. Монысы бик тиз ачыкланды.

Башкарма комитет рәисе калада булганлыктан, утырышны аның урынбасары Галибәк Хәмәтдинов алып барды. Әйләнә-тирәдә мин танымаган җиде-сигез кеше утыра иде. Беренче сүзне ревизор алды. Смета бозу фактлары ачкан. Шуларның беренчесе — смотрда җингән өчен акчалата бүләкне күчерергә мин банктагы үзебезнең төп счетны, дәүләт акчаларын ала торган счет номерын әйткән булганмын икән — акча шәһәрдән шунда күчерелгән һәм без аны акчалата алып, кирәкле әйберләр (мебель һәм пәрдәләр) юнәтеп, закон бозганбыз. Бу хикмәтле счеттан акча бары тик күчерү юлы белән генә тотылырга мөмкин икән. Икенче гөнаһ: башка җирләрдән килгән иҗат коллективлары арендасы өчен түли торган акчаны кимрәк процент белән алганбыз. Ревизор ул чактагы ике мең сумлык беренче ялгыш өчен тиргәү белән котылырга мөмкин дип исәпләсә, өч йөз сумлык икенче хата бәясен түләтергә тәкъдим итте. Бухгалтердан түгел, миннән. Яратып кына салынган шикелле штраф инде бу. Ләкин ертык чалбардан әле күптән түгел генә котылган кеше өчен сизелмәслек тә түгел иде ул. Шулай да ачуланмаска

мөмкин иде. Ләкин сөйләүләр башлангач! Менә монысына түзә алмадым инде, гафу итсеннәр.

Ник дисәк, мин, беренчедән, урынбасар Галибәкнең үземнекен бер селтәнүдә бәреп еккан режиссерлык сәләтеннән көнләштем. Спектакльне менә, ичмасам, куйган иде ул! Безнең «Тальян гармун» монын янында пүчтәк кенә булып калды. Син, Әнис балам, һәвәскәр генә, ә менә Галибәк абыең Хәмәтдинов исә барлык профессионалларның да остазы була алыр. Ул актерларында шул кадәр «эреп беткән» ки, алары, минем белән моңарчы таныш та түгеллекләрен онытып, минем белән нинди генә мөнәсәбәткә кермәгәннәр дә, нинди генә эшләр башкарырга тырышып карамаганнар! Осталыкта болар безнең борынга менә дигәнчә шәп итеп чирттеләр!

Беренче герой — Карабаш МТСы директоры Хафизов дигән агай бик тырышып, үзен тормышны үгез кебек тартып баручы дип (ни өчен трактор кебек түгелдер, шунысы гына мәзәгрәк) мактаганнан соң, шуңа карамастан ихтирам юк, безне концертларга, спектакльләргә чакырмыйлар дип зарланды да, сәнгать түгәрәгенә бүләк итеп бирелгән ике мең сумны да түләтергә кирәк дип, аклы-каралы тавыш белән бик тупас акырды.

Бәхетемә каршы:

— Монысын суд хәл итәр, — дип, үзем дә шактый ук ямьсез кычкыргач, шуннан соң алар чак кына аптырап калган арада,— бүләккә бирелгән акчаны спектакльләрдә катнашкан кешеләргә таратып биргән булсам да, сез бер нишли алмас идегез, ә без, үзебездән кызганып, җиһазлар алдык, хатабыз үзебезне рәнҗетүдә, — дип өстәгәч, Хәмәтдинов хәтта гаҗәпләнде.

— Иптәш Бадигин, иптәш Бадигин, ипләп сөйләгез, кызмагыз! — дип, юаш кына итеп мине тәртипкә дә чакырырга тиеш тапты.

Юашланырга үзем дә әзер идем, ләкин аларның программасы дәвам итте. Районның сәламәтлек саклау бүлеге мөдире Букштейн дигән ханым (анысын бөтенләй беренче тапкыр күрүем) мине чыгырдан ук чыгарып аткач, тагын тыпырчына башладым. Энә өстендә утырам кебек. Ләкин аңларга тырышам. Ничек ди? Ул миңа культура йортында лекция үткәрү турында үз инициативасы белән берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән (мин аны күрмәүгә, ишетмәүгә карамастан, ул мине күргән дә, ишеткән дә, хәтта бәхәсләшкән икән әле), ә иптәш Бадигин аудитория бирмәгән, аның лекциясен планга да кертмәгән. Хатын-кызга каты бәрелү читен, сүзләре аның вөҗданында калсын, бәлки ул бер тыныч төндә уянып, үзен дә, Хәмәтдиновны да каһәрләр һәм артык та очсыз бәягә сатылуы өчен үзеннән-үзе җирәнер... Ә менә тагын бүтәннәр дә шушындый ук уңыш казана башлагач, ымлыклардан узып, тирәрәк сүзләр ыргытырга җөрьәт иттем. Шунысы гаҗәп, Галибәкнең: «Иптәш Бадигин, иптәш Бадигин!» дип кычкыруыннан башка җавап-отпор ишетелмәде. Үз язмышы өчен мондый да саксыз кешене күргәннәре булмаган, күрәсең. Гогольнең телсез сәхнәсендәге шикелле өнсез калдылар. Чөнки алар тормышка миннән бер атнага ераграк карый алалар иде... Бер атнадан соң син үзең дә күрәсең: сине директорлык вазифасыннан азат итәргә һәм өч йөз сум акча түләтергә дигән язу өстәлеңдә ята. Шул вакыт мин үчне матур һәм оста ала белгәне өчен Хәмәтдиновны котларга дип кергән идем, кылган эшеннән бик тә канәгать булып, могтәбәр кешегә куелган бюст мисалында утыра — селкенми дә.

— Смотрда беренчелекне алган өчен художество житәкчесен эшеннән алгансыз икән.

— Беренчелек? Бу адәм ышанмаслык батырлыкмы соң?

— Спектакль генә бар, батырлык юк, анысын сез эшләдегез.

— Спектакль куйдың. Син анда берәү генәмени? Пиесы язылган бит, аны тагын ничек куярга мөмкин?

Үзе утырышны искиткеч шәп куйса да, сәхнәдә спектакль куюның нәрсә икәнен белми иде, бичара. Шуңа күрә икенче хезмәтемне атап карыйм:

— Композитор янына барып, кайбер расходлар белән ноталар алып кайттым, аларны бер ярдәмчесез интегеп разбирать иттем, өйрәндем, ниһаять, сәхнә өчен музыкаль оформление ясап, баянда шуны үзем башкардым... бөтенесе өр-яңа музыка...

— Өр-яңа? Бөтенесе иске көй, халык көйләре. Ишеттек бит.

Бер уйласаң, композитор өчен дә, башкаручы өчен дә моннан артык мактауның булуы мөмкин түгелдер. Әмма Галибәкнең үзе өчен мактаулы булырлык нәрсә мин күрә алмадым. Бу кешедән котылуың үзе өч йөз мең тәңкәдән кыйммәтлерәк бәхет, ә син үпкәләмәкче булып йөрисең. Шулай да, шулай да... күңелдә бу кешене үз урынына, ат абзарына күчереп утырту теләге калган иде. Ләкин бүгенге көндә тагын гаҗәбрәк хис туды: аның белән көрәшкә керү түгел, хәтта күрәсе дә килми икән бит инде. Инде, бәс, шулай икән, соң минем кемгә әҗәт кайтарасым бар?

Кайчандыр бөтен хыялларым, киләчәк көннәремне үзенә җыйган яшьлегем мәгънәсен, баянымны тартып алган Шәйми? Ихтимал, минем ярдәм беләндер, теге вакытта ук анысы милиционерлыктан йөк ташучыга әйләнгән иде. Культура йорты директоры булып утырган көннәремнең берсендә ишек шакып, бүреген култык астына кыстырып, түбәнчелек белән баш иеп, ерак урманнан китергән бүрәнәсен кабул итүемне сорап торганы хәзер дә күз алдында. Танычгач та сикереп тордым. Артык мескенләнмәсен дип аркасыннан кактым да йөген кабул итәргә чыгып киттем. Кәгазенә кул куйганда, гаҗәп тә гаепле кыяфәт белән каушап торганы да хәтердән нишләптер чыкмый. Буш арбасына утырып, капкадан чыкканчы озата килдем, хәтта кул да болгап калдым. Ник бу хәтле нечкәрүемне хәзерге көнгә чаклы аңлап бетергәнем юк. Шунысын гына шәп тоям, бу кешегә дә минем бурычым инде юк... Дөнья, дөнья үзе бөтенесен белеп, бездән остарак, гаделрәк хәл итә.

Әйе, Шәйми дигән исем дә сызыла, ә кем кала? Акыртын гына хәтер капчыгы төбеннән Гыйбадулла Байсламов дигән кара сакаллы кеше шуышып чыга. Ул вакыттагы урман каравылчысы. Көчле, куәтле. Ләкин хәзер урын өстендә ята. Аяк өстендә йөрсә дә, белмим, аның белән дә булашыр идемме икән? Юк, булашмас идем.

Моннан күп еллар элек калага кемнәр беләндер мөнәсәбәт ачыкларга, алардан җавап алырга әзерләнер өчен дип киткән кеше, мин инде менә кемнәргәдер ярдәм итәргә йөрим. Бу, ахрысы, гаҗәп тә түгел, киресенчә, бик табигый. Бәлки әллә ни зур файда итә дә алмам, тик булышлык күрсәтергә тырышлык мәҗбүри кирәк. Минем бурыч шул. Тик минем ярдәмгә кемнең мохтаҗ булуы гына билгеле түгел.

Идарә йортында төрле җыелыш протоколлары карап утырганда, ишекне шакымый-нитми генә, дөбердәп, озын буйлы, кара пумала башлы бер җилбәзәк егет килеп керде дә, муенын кыйгайтып, каршыга басты.

— Син язучымы?

— Шулай дип сөйлиләр. Ә сез?

— Мин? Мин эт тә түгел.

— Һич югы, исемең бардыр.

— Исемем Мини-Әхмәт. Әтәй-инәй кушканы Миңләхмәт.

— Беләм. Тыңлыйм сине, Миңләхмәт.

— Тыңлыйм дип, әллә ни тыңлый алмассың — сүзем бер генә

— Булса соң. Барыбер әйтеп кара.

бөртек.

— Һөнәрем белән механизатор булсам да, төп шөгылем — көрәшче, разрядым бар.
— Авылда спорт түгәрәге бармыни?
— Үзем әмәлләдем шунда, өйрәнергә тырышабыз. Персидәтел каршы килми, әле калага җибәреп семинарда укытмакчы.
— Мин дә каршы килмим, — дигән булып елмаерга тырышам.
Ә Мини каушатырлык җитди.
— Син каршы әйтмә — эшлә генә, то-ес эшләмә дә. Калсын бөтенесе ничек булган килеш. Сиңа әйткәннәрдер инде, имештер, мине персидәтел кыйнаган дип. Ышанма шуңа и маташма булмаганны зурайтып. Кайберәүләр күек. Андый язучылар үзебездә дә бар, көн-төн язалар, гарык. — Егет муенын кискәндәй итеп ишарәләде. — Ә син язмаучы булып кара, шулай хәерлерәк булмасмы. Менә шул. Язсаң да, мине кыйналучы итеп күрсәтмә, и мин түгел дә ул кыйнала торган адәм. Мин үзебездә ел саен диярлек сабан туе батыры. Бер центнерлы Мини-Әхмәт. Аңлашылдымы?
— Нишләптер, йөрәксез Әхмәт дип тә йөртәләр бугай.
Ниһаять, әңгәмәдәшем шаркылдап көлде.
— Һа, ансы болай гына аның, йөрәкнең үз урынында түгеллегеннән. Шуннан соң утырып ук хәлне аңлатып бирде: аның йөрәге уң якта икән.
— Республикада өч кенә кеше без. Асубый исәптә.
— Кыен түгелме соң? Җайсыз түгелме диюем.
— Киресенчә, җайлы яклары күп. Кай адәмнәр усал сүз белән минем йөрәккә кадамакчы булса, анда — буш урын, йөрәк сау-сәламәт кала. Пытамушты ышанычлы, секретный урында.
— Ә мин хәзер беләм... юкка әйттең, ахрысы. Үкенмәссең микән?
— Шунда синең дә кемлегең сыналыр.
— Килештек. Ә шулай да... Чынлап тамы бернинди аерма юк?
— Инвалидлык бирмәкчеләр иде — алмадым, армиягә җибәрмәскә маташтылар, бирешмәдем, менә дигән хезмәт иттем илгә. Менә хәзер дә халык арасында ким-хур түгел.
— Шәп.
— Шәп шул. Нәрсә, әллә? Ну, без килештек — мин кыйналучы түгел. Булдымы?
— Булды.
— Мә бишне, ун булсын.
Кул кысышкач, кергәндәгечә үк башын бер алга, бер артка чөя-чөя атлап китте. Әлбәттә инде, бу кешене Ильяс кыйный алыр дип башка килерлек түгел. Һәм бу хакта онытып, яңадан кәгазьләр актарырга керештем.

*
* *

Укыйм: «Колхозда бер ел эчендә биш комиссия эшләде...»
Ак кәгазьне каралтып, чабата хәтле хәрефләр белән — изге мәктәп дәфтәре битенә! — шулай язылган.
Газета кыйтыгы: «Борчак, арыш һәм солы күптән инде урылып беткән, ә бодай урырга яңгыр комачаулый. Бер атна инде — яңгыр коя да коя».
Әллә хәтерлим, әллә укылган сүзләрдән сурәт ясарга тырышам...
Бодай сөрлеккән. Ләкин янгыр узгач, ул яңадан торып баса. Шундый хикмәтле сорт бу. Шәп кенә тизлек белән инде торып баскан бодайны комбайн аяктан ега. Бу очракта бигрәк тә Миңләхмәт чирак: тезмәләрне сугарга керешкәч, бөтен халык аның артыннан нярә. Ә Мини әйтерсең беркемне күрми, тизлек җиленә йөзен куйган да дөньясын

онытып бара да бара, әйтерсең ки бәхетенә, максатына таба ашыга. Ул белә: мондый бәхеттән дә зуррак бәхет юк, гомернең менә шушындый мизгелләренә кайчак аның бөтен мәгънәсе һәм яме сыйган була. Ул — батыр, сабан туы батыры, иген туе батыры, кыр дигән чиксезлекнең хуҗасы. Юк, ул бу хакта уйламый, бүтәннәр дә башына китерми. Ләкин бу уйлар һәркемгә җитә, һәркем аны тоя, һәркем аны кичерә, сүзсез генә, ә иң башта — Мини дигән бөек игенче!

Ниһаять, комбайн тукталды, һәм Мини басуның бөтен киңлеген берьюлы тутырып кычкырып җибәрде:

— Утыз биш! Утыз биш! Утыз бишәр центнер!

Артыннан җитешеп җыелганнарга:

— Тулып та куйды бункер, тулды бункер! — дип аңлатты.

Кешеләр бәлки Мини дигән Әхмәтне уңыш белән тәбрикләргә, юк, аны гына түгел, һәркем бер-берсен котларга, һавага чөяргә, баштагы эшләпә-кипкеләрне күккә ыргытырга, аунарга һәм рәхмәт әйтә белгән, игелек күрсәтә торган җирне, шушы туфракны кочарга, үбәргә тиеш булгандыр. Ләкин андый кыланышлар, андый ярсынулар булмады. Миңләхмәт штурвалдан бушаган куллары белән, әйтерсең җилне генә кочты да, аннары, озак та мавыкмыйча, янадан стартерга басты. Ә башкалар елмайган килеш үз шөгыльләрен дәвам иттеләр.

Иген үстерү дигән бөек мәгънә өчен... әйе, шуның өчен туган кешеләр тыныч яшиләр, тыныч бәхетләреннән аерылмас өчен, өнсез тантанада катнашу хокукы өчен дәгъвасыз көрәшәләр! Сүзсез хәрәкәтләр һәм адымнарда яуланган хокук, бәхет, олпат тынычлык аермачык күренә ул!

Ләкин икмәкне үстерә белү бәхете һәркемгә бирелмәгән, кайберәүләр андый тойгы барын хәтта белмиләр, аңларга да теләмиләр, алар өчен шул бәхет, шул абруйны бүлешкәндә өлешсез калмау көрәше кызыклырак һәм үзеңнең дөньяда яшәвеңне раслар өчен бердәнбер чара да шул. Иң зур кимчелек — дөньяда өлешсез калу. Һәм син көрәш, үз өлешеңне (бәлки башкаларныкын — барыбер!) яулап ал, бирмәскә тырышсалар, җәдәлләшеп, сугышып ал! Әгәр кеше арасында кеше буласың, бүтәннәр синең фикер-карашларың белән исәпләшерлек кеше буласың килсә, тормышта үз урыныңны биләп торасың килсә, әгәр инде үзең иген үстерергә бик үк хирес түгелсең икән, аны үстергән кешеләр белән бәхәскә кер. Әгәр синең бу көрәшеңнән тыныч игенче рухланмаса, гаделлекне яклаучы, аларны тәртипкә чакыручы (гөнаһсыз кеше булмый ул дөньяда, гаеп табылмас дип курыкма!), дөреслек сакчысы сыйфатында дөньяны шаулат! Үзеңне кайчакта шулай да саклап, раслап була дөньяда, бәлки шулай җайлырак һәм кирәгрәктер дә әле...

Бодай кыяк суза, буынга үрелә, табигать биргән хокукы буенча үсеп, кыр һәм яшел дәрья кыяфәтенә керә... һәм тормышта шул да — позиция.

Иген алтынсу төскә керә-керә, кешеләрнең күкрәкләренә сары йолдыз булып күтәрелә... Әгәр акыллы булсаң, игеннәрнең яшел музыкасын үзең яза белмәгән килеш, шул йолдызны эләктерсәң, бу да — тормыштагы позиция...

Ә кемдер ике позиция көрәшенә бәя бирә, ләкин дөреслекне белгән килеш, эндәшмичә файда таба — өченче позиция!

Позиция — өчәү генә, ә кешеләр күп, бар син бер карау белән аңлап, аерып кара. Шуларны аера, тоя торган барометр тап!

Ләкин мин бераз чамалыйм, инде гүя ки үз күзләрем белән күреп торам: нәкъ менә шушындый уңыш шатлыгы чыңлаган көннәрдә һәм шул ук киңлекләрдә ала-чуар байрак (икенче позиция!) җилферди. Әнә, кара һәм ышан: авылга колхоз председателе Ильяс Җантурин хакында мәкалә басылган газета килеп төшкән! Госман Фәсихов исә,

ул байракны болгый-болгый, өйдән-өйгә, урамнан-урамнарга, кырданкырларга, җәйләүдән-җәйләүләргә чаба:

— Күрдегезме, без капчыкта ятмый, күрдегезме, күрдегезме!

Кемдер аптырап тел шартлата, кемдер сокланып бот чаба, кемдер газетаны капшап карый, әйләндерә-әйләндерә дә кире хуҗасына бирә, кемдер исә тантана иткән Фәсиховның артыннан төкереп кала: «Бәдбәхет, кояш нурыннан мәхрүм булгыры!»

Тарткалаш, мәгънәсез кычкырышлардан котылу нияте белән идарә йортына кайтам, тик анда кәгазьләр сатулаша, кәгазьләр бәхәсләшә, кәгазьләр көрәшә, кәгазьләр сугыша, кәгазьләр кычкырыша.

Колакларга буйсынмаска тырышып, тынычрак кәгазьләр эзлим.

«Колхозда чылбырлы трактор — 25, тәгәрмәчле — 20, комбайн — 30, автомашина — 30, электр двигателе — 140...» Һәм, иренмәсәң, ары укы. Хәзерге колхоз — сугышка хәтле еллардагы бөтен бер МТС!

Тагын саннар очрашты: тагын чагыштыру, тагын аерма, тагын үткән гомер ямансу карый башлый. Әйе, фикергә тынгылык юк — бәхәс дәвам итә. Кәгазьләр кычкырыша, тарткалаша.

Беренче позиция — кыяклар чыңы, башаклар кыштырдавы...

Икенче позиция — «без сезнең кебек үк адәм балалары, сезгә күрсәтелгән кебек үк ихтирам һәм игътибар безгә дә даешь!»

«Ыклап уйласаң, кыр ул әрләннәре белән дә матур!» — өченче позиция. Дүртенчесе юк?

Ләкин позицияләр арасына республика прокуроры авазы килеп керә:

Беренче факт. Дәүләткә малларның санын киметеп, авырлыгын арттырып язу ысулы белән харам акча алу гаебе тикшерү барышында раслану тапмады. Баш бухгалтер Байсламов Сәлимгәрәйнең документларны яңадан тутыру, үзенә кирәкле саннар белән алыштыру очраклары исбат ителде.

Икенче факт. Комбайнчыларга эш хакы бирү хезмәткә түләү кагыйдәләренә туры килә дип табылды.

Өченче факт. Савым сыерларны киметеп, күрсәткечләрне ясалма зурайту гаебе расланмады.

Расланмады, расланмады, расланмады.

Бар икән бит дүртенче позиция!

Прокурор кул куйган урында бүтән кеше фамилиясе торса да, мин ул язмаларны кайчандыр бик кыска гына вакыт эчендә яшәп алган хыялым дөньясыннан үзем язып җибәргәндәй тойдым. Әйтерсең үз сүзләрем. Кайчандыр син алырга теләгән урын буш түгел, син әйтәсе сүзләрне барыбер әйтәләр, бәлки эле синекеннән яхшырак итеп... Бүтән фамилия, бүтән сүзләр. Ә син инде үзенә тиешлеләрен тап...

«Шушы елның ноябрь аенда амбар алдында Фәсихов Госман безне — ике савымчыны — Асылбаева Рәзиләне һәм мине, сез чистый бозыклар дип, язып булмый торган пычрак сүзләр белән мыскыл итте. Мондый сүзләр өчен чара күрелергә тиештер дип беләм.

Дөреслән имзам: Зөлхиҗә Гарифуллина.»

Укыйм да укыйм шушы кечкенә хатны — бөтен нәрсә ачык аңлашылып торган сүзләрне ни өчендер аңлаудан баш тартам, акыл карыша. Һәм... тукта, язу, кич утырып, өендә ялгызы гына бәлки яшьләрен сөртә-сөртә хатлар язган Зөлхиҗәне мин яңачарак күрәм түгелме? Бу язу миңа инде таныш түгелме соң?

Казанга килгән соңгы хатны алып, мондагы язу белән янәшә куеп карыйм: бер үк кул белән язылганнар!

Көтелмәгән ачыш мине йокыдан уяткандай булды. Хәзер инде Зөлхиҗәнең үзен күреп, нәрсәләрдер сорашырга кирәк бугай.

Зөлхиҗә, Вәҗиһә. Яшьтәшләр, бер үк авылда туып үскәннәр, бер үк мәктәптә укыганнар, бер үк төрле өйләрдә яшәгәннәр, хәтта төслә-

ре дә бер шикелле, мин аларның икесен хәтта бер кеше итеп тоям. Ләкин язмышлар! Язмышлар шул кадәр аерыла, башка сыймаслык. Ник? Кечкенә генә ялгышлык аркасындамы? Ә, гомумән, бармы шундый ялгышлык? Вәҗиһәнең дә ир иләслеге аркасында җайсызрак хәлләрдә калганы бар, ләкин аңа кемнәрдер ярдәм итә алган.

Җиреклекүл, урам. Урамнан Вәҗиһә дүрт яшьлек малаен җитәкләп өенә кайта. Алар бу көннәрдә олы бер өйдә үзләре генә торалар. Мини-тиле адәм аңламас көнләшүләре аркасында, аларны ташлап, әниләре янына киткән. Төп йортка. Шул өйдә бүген Мини яңа туй ясамакчы... Вәҗиһә дөньяны онытып, мөгаен, әнә шул хакта уйланып, нәрсәнедер аңларга тырышып, ләкин бернәрсә дә аңлый алмыйча гаҗәпләнеп, улының бик тә гади сорауларына да рәтле җавап бирә белмичә атлый. Атлый. Ә урамның икенче очыннан, тузан туздырып, атлы тарантас чаба. Әкрен генә атлап килгән хатын белән малайга якынлаша. Инде узды дигәндә генә... Һап! Баланың җилкәсеннән эләктерә дә очып та кача, карчыга гүяки чебеш типте.

Хатын аһ дияргә генә өлгерде дә, каккан казыктай катып та калды. Шушы хәл килеп чыккан урамның икенче ягыннан Рамазанов килмәгән булса, үз эше артыннан барган Рамазанов адымнарын кинәт тизләтеп бу якка чыкмаса, белмим, Вәҗиһә кайчан һушына килә алган булыр иде әле. Ләкин Рамазановның тыныч елмаюы аны тормышка тиз кайтарды, тиз уятты. Күзләрне ачып карасаң, ышанырга кирәк икән: иреннән генә түгел, инде баласыннан да колак каккан хатын — Вәҗиһә үзе, ә баланы эләктереп качкан тиле кош — аның ире, Миңләхмәт. Бергә тора башлаганнан бирле бер генә көн дә көнләшми калмаган тиле Мини!

Рамазанов исенә килә алмый торган Вәҗиһәгә үзе кул сузды:

— Исәнме, Вәҗиһә, ник болай югалып калдың әле?

— Ә-ә, Рамазанов абый, әйе. — Хатын күзләрен угалады, якаларын, яулыкларын рәтләгәндәй итте. Һәм мәгънәсен үзе дә аңламастан: — Әнә бит, ирем, — дип куйды.

— Иреңнең исеме ничек?

— Шул инде — Миңләхмәт. Авылча — Мини-Әхмәт.

— Теге, сабан туйда батыр кала торганмы?

— Шул үзе.

— Тагын бер батырлык эшләде.

— Хатын аеру батырлык булса...

— Ә сез ни сәбәп белән аерылыштыгыз?

— Сәбәп шул инде: авылда көнләшмәгән кешесе калмады. Соңгы вакытта теге Фәсихов бутала торгач, шуның үчен миннән алды — чыкты-китте ташлап. Хәзер әнә өйләнә, туйлары буласы.

Туй буласы дигән тиле көнендә дә малайсыз яши алмый икән, алай ук алама бәндә түгелдер, дип уйлый Рамазанов һәм хатынны ничек кирәк алай тынычландыргач та, идарә йортына барып, шунда Миңләхмәтне чакырта. Егетнең, дөресрәге, икенче кабат туйларга җыенган карт кияүнең каушап ишек төбендә торуын, Рамазановның исә аның янына үзе килеп, аркасына кул куеп бераз торуын, аннары сүз эзләп шул тирәдә йөренүен күз алдына китерү кыен түгелдер. Ниһаять, сүзнең туп-турысы:

— Ник баланы эләктереп чаптың?

— Үз малаем, имею права.

— Ә Вәҗиһә? Ул әйтә минеке, ди. Аның өлеше дә бар булып чыга түгелме соң?

— Булдыра алса, ул да урласын.

Егет, шундый сүзләрне бик тә житди сөйләгәнгә күрә, көләсене китерә. Ләкин түзәргә кирәк.

— Бер-берегездән урлый, тарткалый торгач, ул баладан нәрсә калыр икән соң? Чукый-чукый тәмам миндәтәсез бит сез аны.

— Бүтәнчә нишләп була? Үзе бит, юньсез хатын...

— Нишләгән үзе?

— Бер нәфсесенә баш булалмыйча...

— Дурак син!

Хатынының кем икәнен яхшы белгән һәм соңгы вакыйгалар белән инде танышып өлгергән Рамазанов егетне аңга китерү өчен аның үзенчә тупас эндәшкәч, Миңләхмәт, чынлап та, нәрсәнедер аңларга тырышкан кыяфәт белән күзләрен түгәрәкләндерә. Рамазанов исә кискенлекне киметмәү түгел, арттыра гына төшә:

— Хәзер өйләнәм дигән хатын... анысы кем?

— Кем дип... Ике аяклы, ике куллы.

— Ләкин күзләре юктыр.

— Нишләп булмасын?

— Күзләре булса, синең кемне яратканыңны күрер иде ул һәм күрә-ләтә син юньсезгә кияүгә чыкмас иде.

— Юньсез булып, без дә әллә нишләмәгәндер.

— Яратмыйсың бит анысын, бусы кадерле, балаң анасы. Дөрес түгел дисеңме шушыны?

— Дөрес булса нишли алам? Пычрак ыштан, карыш каткан якаларны гомер буе шул картаеп беткән әниемнән юдыра. алмыйм бит инде.

— Туйга аракы алдыңмы?

— Бераз бар.

— Хәзер бер яртыны әләктер дә — төп йортыңа, үз өеңә диюем — мине кунакка чакыр.

Мини-Әхмәт кычкырып көлә генә:

— Сүләмә лә юкны, зур кешемен дигәч тә. Сезнең көч җитмәс эшләр дә бар бу дөньяда. Белеп тор.

— Нәрсә, яртыны кызганасыңмы әллә? Оялмасаң, үзем алам, мин бит бу авылда кунак, шуңа күрә...

— Ярый, шаяртмасаң булыр. Сезнең өчен бер ярты тапмаска теге.

Мини-Әхмәт яртыны култык кесәсенә кыстырып кабат идарә йортына килүгә, машинага чыгып та утыралар. Рамазанов шофер егеткә кая юл тотарга икәнен әйткәч, Мини кыбырсына башласа да, Рамазановның бер сүзе җитә:

— Хуҗа — кунакның ишәге. Хуҗа була бел.

Ир белән хатын олы кунакны сыйлаган арада кайбер мәшәкатьләрне бергә, киңәшеп үткәрергә мәҗбүр булганлыктан, тел яшермәс дәрәҗәгә кутәрелсәләр, шул ук кичтә малайлары үз аягы белән кайтып кергәч исә, бер-берсенә сүзсез генә булса да елмая ук башлыйлар һәм, иң мөһиме, тормышны яңадан башлап җибәрәләр. Савыт-саба бөтенләй үк шалтырамый тормаса да, инде бу араларда көйле генә гомер кичерәләр. Бу кадәресен инде мин дә беләм, шуңа күрәдер инде, бая Мини минем янга кергәч, «Тату гына яшисезме?» дип, хәл белешергә дә онытылган. Хәер, бу хакта сорашу үзе үк мыскыллау төслерәк ишетелер иде кебек. Шунысы хак, алар — бәхетлеләр. Вәҗиһә бәхетле. Вәҗиһәгә Рамазанов бик җиңел генә ярдәм итә алган. Ә менә Зөлхиҗәгә... Зөлхиҗәгә беркем дә ярдәм итә алмый. Ә бит болай карасаң, ул да Вәҗиһә кебек үк бәхетле булырга тиеш иде. Күзгә күренми, анга килеп җитми торган бик тә кечкенә, ниндидер каһәрле нәрсә ана бөтенләй икенче тормыш китергән. Хәтта Рамазанов та, көн саен бергә күрешеп яшәгән Ильяс та аңа ярдәм итә алмаган. Инде килеп мин дә — кемгәдер ярдәм итәр өчен махсус кайткан кеше — кемнедер, нәрсәнедер кулдан ычкындырам, таба алмыйм. Ә ярдәм итәргә, гомумән, хакыбыз бармы? Каты кул белән ялгыш кагылып, үзең күрми торган

дәрәҗәдәге нечкә тойгы челтәрләрен коеп төшермәм дип әйтә аласыңмы? Ниндирәк сорау белән кем янына барырга? Ә бармаслык булгач, ник кайтырга иде? Ялгыш булды бугай кайту, ялгыш...

Уйлый торгач, тагын да ныграк бутала гына төшәм.

Мин кайтканнан бирле генә түгел, игеннәр чәчелгәннән бирле, яңгыр яуганы юк. Күңел нидер эзләгән, көткән шикелле, басулар дымга сусый. Коргаксыган дөнья яңгыр көтә. Чак кына болытлар куера төшсә, Рамазанов колхозларга шалтыратырга керешә:

— Яумадымы яңгыр?

Телефон чыбыгының икенче очындагы кеше көрсенә генә:

— Юк шул.

Рамазанов кабинет буйлап йөренә.

Кабинетта ике барометр — икесе ике төрле күрсәтә: берсе явымга якын, икенчесе — ераграк.

Ак барометр, кара барометр.

— Икесенең берсе ватык, ахрысы? — дим.

— Юк, төзек.

— Кайсы әйбәтрәк?

Рамазанов ак барометрны күрсәтә:

— Монысы.

— Нишләп?

— Чөнки анысының угы яңгырга таба күбрәк авышкан, шатлыкны якынайта.

Явым теңкәгә тигән чакта кер син аның бүлмәсенә дә кара: бүлмәдә ике барометр, берсе аязга якын, икенчесе — ераграк.

— Кайсы шәбрәк?

Рамазанов абыең бу юлы кара барометрны мактар. Ник?

— Кара барометр булса да, ул яктыга юрый, шатлыкны, бәйрәмнәрне якынайта.

Мин Җиреклекүлдә шушы минутларда Рамазановның ак барометрга текәлгәнен тоям. Ә минем янда бернинди барометр юк — күзне кая текәргә белмәссең.

Тышта, идарә күтәрмәсендә ирләр тәмәке тарта, дөнья хәлләре турында гәп корып утыра. Шулар янына чыгам. Зиһенне томалаган коры рәшә таралмасмы, кайбер сорауларга җавап табылмасмы дип, күтәрмә култыксасына сөялеп, мыштым гына тыңлыйм. Мавыгу сәбәпле, алар мине, чит кешене, күрмәделәр дә шикелле, талгын мәҗлесне булган көенә дәвам иттеләр.

Әңгәмәдә мин белмәгән җиде-сигез кеше һәм миңа яхшы таныш Мини-Әхмәт (әле китеп өлгермәгән икән) катнаша. Танышка күрәме, күбрәк аларның сүзләре колакка кергән икән.

Морадым, сул күзен каплап, миңамы, бүтәнгәме уң күзе белән карап торды да аннары, сүз юктан гына бугай, телгә биреләсе итте:

— Шулайрак... кем дип әйтим... Миңләхмәт улым. Син ишеттеңме икән, безнең теге якта, Әшмән урманында күңелсезрәк нәмәрсә килеп чыккан ди бит әле.

Әшмән дигәч, билгеле инде, минем колаклар торып баса. Баш күтәреп карасам, Морадым тагын сул күзен йомып бакты һәм башын ия төшеп кенә үзенең вак сәйләннәрен күзгә күренми торган җепсәгә кидереп тезәргә керешә:

— Әйе, кем шулай, Әшмән урманында. Ниндидер бер кунак һуштан язып егылган ди.

— Шул хәтле эчмәсә, бирәндәй булып.

— Нинди эчкән? Кем әйтте сиңа? Тамчы да капмаган килеш. Шул. Базы буендагы пионерлар җәйләвенә табатын килгән бер автомобиль моны күреп туктаган дип сөйләделәр.

— Автомобиль ике күзле бит, күрүе дә растыр.

— Бутама, минем уң күзем синең ике күзең берьюлы күрә алмаганны күрә. Буталчыграк хәлләрдә мин шул күз белән карасам гына дөреслекне күрә алам. Шул, улым. Шул автомобильдән чыккан адәмнәр һушсыз яткан кеше янына килгәннәр дә моны уятып карыйлар икән, селкетеп, утыртып, аунатып карыйлар. Кая ул, уянмый бу кеше. Синең кебек шикләнеп, иснәп карыйлар, юк, чип-чиста. Нишләп уянмый да нишләп һушына килми дип, тәмам аптырагач, йөдәгәч, кесәсеннән дүкәмитләрен алып карасалар, кемдер берәү шатланып кычкырып та җибәргән: «Тизрәк, тизрәк автомобиль янына китерегез!» — ди икән. Шулай, күтәреп китерәләр кунакны, автомобильнең төтен вә газ чыга торган торбасы астына ук яткыралар моны китереп тә и керешмәсеннәрме моның борыннарына төтен, газ өрдерергә. Нишли дисез кунакны? Шул газ дигән төтенне бер-ике тапкыр йоткач та, башын кинәт күтәрә дә, тимергә ялгыш бәрелүгә дә карамастан, ялт торып баса мескен кеше.

— Ә һуштан, һуштан ник язган соң?

— Менә исәр, шуны да белмәскә — кислород күплектән бит инде. Ышанмасагыз, әнә үзеннән сорагыз, — дип, Морадым төлке миңа уң күзен төкәде.— Шулай бит, Әнис улым? Булды бит шул хәл?

Карт сөйләгән әлеге мәзәкнең билгеле бер газетадан күчебрәк сипләнгәнен сизмәсәм дә, югалып калмадым шикелле. Әйтерсең ки сәхнәдә мин — торам да баш иям, имештер, алкышлар кабул итәм. Кул чабулар булмаса да, елмаю, тыныч көлүләрен җыеп алдым. Шул торудан торып, фатирга таба юл тоттым. Күп дигәндә ике-өч метр уздыммы-юкмы, артымнан автомашина килүен шәйләп, юл читенәрәк тайпылсам, машина миңа бәрелер дәрәҗәдә якынаеп, карчыга мисалында бөтерелеп узды да, шунда чыелдап тукталды һәм аннан чыккан ят кеше берьюлы ике кулын сузды:

— Сәлам, якташ, исән генәме? Әйдә, утырыйк әле шушы машинага.

Берни аңламый тик торам: квартирым бик якын ич, җәяү дә җәһәт житәрлек. Ә ят кеше ихлас ук кыстый:

— Я инде, якташ, ялындырма, утыр тизрәк.

— Ник әле утырырга тиеш?

— Сиңа әйтәсе сүзләр бар. Урам уртасында җайсыз лабаса.

— Соң әйтегез, шушында гына.

— Кайткач, өйдә рәхәтләнеп сөйләшербез. Әйдә инде. Яртыны да табарбыз. Буламы шулай?

— Кем соң сез? Ник мин сезнең белән аракы эчәргә тиеш?

— Менә инде, танышып та була бит аны, курыкма, мин кала жулигы түгел.

— Ә кем сез?

— Әйтәм бит, танышырбыз да, дуслашырбыз да, китик кенә...

Без шушы рәвешле сатулашкан арада йөгерә-атлый Миңләхмәт килеп житте дә, житә-житүгә кызган мунча ташыдай кайнарлык бөркеп, күз иярмәс бер җәһәт селтәнү белән әлеге бәйләнчекне бер читкә җилтерәтеп тә атты һәм, шул ук тизлеген һич киметмәстән, иңбашыма кулын куйды:

— Маладис, абый, утырмадың.

Үз юлыбыз белән бераз баргач, мин аннан әлеге кешенең кемлеген сораган идем, Мини кул селтәде дә:

— Әшәке нәмәгә кагылма, пычрагы йогар, — дип кенә куйды.

Шулай да гостиницага кайтып, анда кәрт уйный-уйный сөйләшкәндә, сүз ул кешегә яңадан әйләнеп кайтты.

— Мин дурак быел кыш аңа чак кына кагылган идем, исе әле булса күңелне болгата, — дип аңлатты Мини. — Үкенеп бетмәслек. Үзең уйла, я, минме инде юк-барны бүлешеп, низаг куптарып яшәр кеше? Ә менә ул китереп кертте мине үзе изгән пычракка — шаһит буларак

кына түгел, пострадавший буларак исемем калага тикле житте дә, ярты елда жиде комиссия килеп, жинаятьтә тотылган карак диярсең, миннән сорау, дапрус алалар. Ашымның тәме китте, эшемнең яме бетте. Менә нинди адәм ул.

«Адәм» дигәннең, әлбәттә, исемен атарга чиркана иде Мини һәм, шунлыктан, мин ярдәмгә килдем:

— Исеме — Госман... Фәсихов.

— Өстенә бастың, сыер икәнсең. Шул үзе. Сәгатьче, киномеханик, ә совместительство буенча — анонимщик. Алты да сигез... Атбуй. — Бөтен ачуын, бөтен көч-куәтен туплап, Мини кәртен өстәлгә чәпәде.— Аның белән эшең төшәргә алла күрсәтмәсен, бәхетле яшә.

Көчле-куәтле кеше белән утыра торгач, күңел шактый ук күтәрелеп китте. Күптән түгел үзем укыган язмалар һәм кешеләр сүзен хәтерләп, Морадым карт ысулы белән бер күзне йомдым да Мини өчен бераз җайсызрак булган хатирәне яңарттым:

— Син, Миңләхмәт, дөресен генә әйт әле миңа, көндәлеккә бер дә юкка язмагансыңдыр. Ничек шуның дөресе: кыйнадымы сине Жантурин, юкмы? — Егет чак кына елмаеп, икеләнеп торганда, ашыгыч рәвештә хәлне жиңеләйтмәк өчен: — Беркемгә дә сөйләмәскә ант итәм,— дип куйдым. — Егет сүзе.

— Һа, егет! Ант итмәсәң дә курыкмыйм, сиңа ярый ул.

— Рәхмәт, — дип инде мин елмаям. — Бер-ике кабат кына тамызды бит, ә?

— Булгач булды инде. Ну, язылганча ук та түгел — исерек килеш идарәдә буталган өчен тәрткәләп кенә чыгарган ул мине.

— Шулай гына? Ә үзең атна буе эшкә чыга алмагансың.

— Председательгә үч итеп, тагын бер яртыны каккач, нидер тагы өстәлгән инде, аларын хәтерләмим дә рәтләп. Соңыннан гына әкертенләп, берәм-берәм хәтергә төште.

Бер кызып киткәч, кәрт шапылдавы шактый озакка сузылды. Ким дигәндә сәгать уннар тирәсе булгандыр, Мини бер-бер артлы дүртме, бишме тапкыр дурак калды. Соңгы уенда берьюлы дүрт алтылык чәпәлгәч, телдән үк язды ул. Бала-чаганыкы кебек иреннәре дә мелт-мелт килеп торды, күзләре челт-челт йомылдылар. Шулай да киткән чакта:

— Мә бишне, ун булсын,— дип, ясалмарак булса да җорлык күрсәтә алды.

Ниндидер замыкание аркасында тоташмый интектергән телевизор белән булашканда, аның какъ тактасына йодрык белән юри генә бәргәлисе иткән идем, телевизорым бозык адәмнәрчә күз уйнатуыннан шып тукталды һәм күңелдә тагын Ильясның Мини-Әхмәт өлешенә тигән йодрыгы елкылдап узгач, шуның артыннан ук: «Башны телевизор кебек эшләтеп җибәрергә кайчак йодрык та ярдәм итә ләбаса», — дигән уй ялтырап үтте. Ышанып әйтәм, әгәр дә мәгәр ишетсә, моны Мини үзе дә җөпләп алыр иде.

Идән астында комаклар йөгерешеп кайбер вакыйгаларны хәтергә төшерә торуга карамастан, йокы ярыйсы ук тәмле булды, дөресрәге, тәмле буласы иде. Ләкин монысын Мини-юләр үзе боза куйды. Төнге сәгать икеме, өчме булгандыр, тәрәзә кага.

— Нәрсә бар? — дим, берәр хәерсез хәл чыккандыр дип уйлап.

Инде яктырып диярлек беткән тәрәзәдән Мининең чырайсыз кыяфәте карый:

— Әллә ни юк болай.

— Алайса, нишләп таңны куркытып йөрисең?

— Йоклап булмый, малай, төн буе борсаланып чыктым.

— Берни аңламыйм, ни сөйлисең син?

— Шул инде, баягы уен турысынарда.

— Нәрсә? Кәрт уйнаганны әйтәсеңме?
— Ну инде, өстенә бастың.
Нәрсәдер сөйләргә җыенуын сизгәч, тәрәзәне ачтым һәм ялгышмадым. Мини көттермичә үк хикәя башлады:
— Карале, кем, Әнис туган, теге уенда, соңгысын әйтәм... Вот, шул тапкырында... Әгәр дә мәгәр мин чирби кәрүлен бирсәм, син дурак каласы идең бит.

## Җәйләү, үгез һәм... Агыйдел

I

*23 май, 1977.*

Идән асты халкы инде тынычлануга карамастан, өйгә җәйге яктылык кереп тулгангамы, Мини сүзләре колакта һаман буталып торгангамы, йокының калган өлеше рәтле була алмады. Мини әйткәндәй, сәгатьләр буе борсаланып кына ятарга туры килде, стеналар сөйләшеп бимазалады. Кыйналган кебек идем. Мини шикелле, дәфтәргә дә шул хакта язып куярмын, ахрысы...

Юынгач һәм аннары якын-тирәне җәяү әйләнеп кайтканнан соң, хуҗабикә әзерләгән чәйне каты итеп эчкәч кенә, дөньяның якты, көннең чалт аяз булуы, шактый ук куәтле эсселек вәгъдә итүе күренде. Күңел көйләнә төшеп, өстәлдә кыштан бирле яткан газета-журналларны караштырган мәлдә телефон шалтырагач, күзгә күренмәгән кешеләр белән дә шаярырлык хәлгә килгән идем, әмма сүзгә катнашырга ук җай табылмады. Тыңлап кына тордым. Кошчылык фермасын сорыйлар.
— Әй, Нәфисәме бу?
— Бә-әй, туганнан бирле Нәфисә булгач, бүген генә ничек үзгәрим тагы?
— Нәфисә булсаң менә шул: мин Сәрваров абыең булам. Биш тавыкка распоряжение алдым. Шул тавыкларны йолкып, чистартып куй әле.
— Менә тагы, тере тавыкларны ничек итеп йолкыйм, чистартыйм ди.
— Соң, суегыз.
— Шулай диген аны. Шулай диген, мал суярга да хатын-кызлар кулына калдык диген.
— Әй, Нәфисә, чөрләгән тавык, шаяртма, кешесен тап, суйдыр.
— Бә-әй, мин тапкач та мал суярлык буламыни ул кеше? Тугач та?
— Ирләргә үләт булдымы әллә анда?
— Кырылып беттеләр, берәү дә юк.
— Су җылытып куегыз, яме. Бишәү булыр, тотып куегыз, яме.
— Я, я.

Кыңгыр эшләргә колак сагая төшкәнгә, биш тавык дигәннәре кызык тоелып, мин бу санны, Фәсихов сыңарыдай, ничектер хәтергә салып куйдым шикелле. Ләкин чама белән бер сәгатьтән соң ярты әрҗә минераль су күтәреп, уртача буйлы гына, түгәрәк гәүдәле нык бер кеше килеп кергәч һәм исәнлек-саулык сорашканнан соң: «Бу шушында торып торыр әле», — дип чыгып киткәч, тавыклар башына җитәчәк газраилнең шушы кеше икәнен, кыңгыр эшнең үземә дә тоташып килүен чамалап: «Фәсихов блокнотына үзең дә эләгәсен бит!» — дип уйлап куйдым. Ярый әле, чүп-чар уйдан арындырып Ильяс шалтыратты, минем теләсә кая барырга әзер икәнемне белгәч.

басулар карап йөрергә тәкъдим итте. Нәрсәләр күрдең, ниләр хәтереңдә калды дигәндә, булган кадәресе — дәфтәрдә.

Кушнарат чокыры, Ябалак тавы, Куштирәк куагы дигән җирләр — авылның көтүлекләре. Җәйләүләр, савымчы кызлар һәм хатыннар, көтүчеләр, алар ял иткән вагон-йортлар, җәйләүгә чыккач сөтнең артачагына бәйләнгән өметләр, вәгъдәләр, җәйләүгә әле генә җыеп кертелгән сыерлар, үгезләр...

Үгез дигәннән, безне тимер чыбыктан ясалган челтәр койма аша күреп, берсе яман да каты үкерә, өстебезгә ташланырга, сөзәргә, изәргә тырышып, җир тырнарга керешге. Җәйләү эчендә күпме хатын-кыз, берсенә дә тукталмый, ә безне, чыга алса, мөгезләренә элеп күккә очырасы. Гадәте шундый алама икән, ир җенесеннән булган барлык халыкка җене котыра, сыерларын көнли. Бу юлы бездән шикләнә. Бер көтү сыер — берсен дә бирәсе түгел, һаман җитми! Бөтен кыяфәт-кылынышлары белән: «Минем кебек адәмнәр дә юк түгел, бар дөньядагы барча хатыннарны үзенеке дип исәпләүчеләр очраштыргалый ул, әйтик, менә шушы тирәгә, Ябалак тавындагы урман полосасына Үрәзмәтнең тормыш иптәше булган Кәримәне кичке эңгердә кунакка дәшкән кеше... Кичке эңгердә аның янына, басу юлыннан үргә менеп баручы яшь хатын... «Шундый мәгънәләр белән үкерә бу үгез, валлаһи, билләһи. Тфү, нинди фикер! Ак тәүбә, кара тәүбә».

Җәйләүдә — механикалаштырылган савым! Автомат-саугыч арасына сыер, завод проходноендагы шикелле, әйләнмәле капкадан керә. Алдындагы ашаткычтан кабымлык алгалый торганда, аның сөте саугычка һәм аннары үлчәгечкә, чиләккә, аннары савымчы кулы аша шундый ук ак савытларга — флягаларга күчә. Авыл кызлары һәм хатыннарының гөнаһсыз тойгылары сыман ургылган ап-ак сөткә карап, тын калам. Үгезне күрмим дә, ишетмим дә. Бу як кырыйдан өченче кеше — Вәҗиһә. Хәрәкәтләре — япь-яшь кызларныкыча тыелгысыз. Мини-Әхмәтнең бу хатынны көнләве гаҗәп түгелдер шул. Ә ул унсигез-егерме яшьләрендә нинди булгандыр! Җитмәсә, даны, дәрәҗәсе! Вәҗиһә егерме бер яшьтән автономияле республика күләмендәге депутат. Мини-Әхмәте аркасында шул чакта ул бигрәк тә җайсыз хәлләрдә калган. Сайлаучылар арасында үзеннән башка йөрүеннән башлап, сессиягә баруларына хәтле каршы булган Мини, һич күнегә алмаган.

Сессиягә барырга вакыт. Беренче тапкыр. Тәртип шундый: шәһәргә китәр алдыннан депутатлар район үзәгенә җыелалар. Ә Вәҗиһә — юк... Телефоннан дәшеп карыйлар, Вәҗиһә — юк. Нишләмәк кирәк, аның янына Рамазанов үзе килә. Ишекне киң итеп ачып керә дә, елмаерга тырышып:

— Вәҗиһә, сеңелем, ни булды сиңа? — дип сорый.

Вәҗиһәнең елмаерга җае юк, алсу чырае минут эчендә ак сөт төсенә керә:

— Берни дә булмады, Рамазанов абый.

Берсекөнгә сессия ачыла, хәбәр итмәделәрмени шуны?

— Мин анда бара алмыйм инде, Рамазанов абый.

— Эш нәрсәдә?

— Сыерларны кешегә калдырасы килми, көйгә китерә алмыйча диңкеп бетәм соңыннан.

Ачуланып, көйләп, ялынып карый Рамазанов — ябышып каткан урыныннан кымшанмый да кыз. Моннан соң яраткан сыерларыннан бөтенләй аерылырга туры киләчәген әйткәч, бераз йомшый төшсә дә, тик анда да алтын балык кына үти алырлык шарт куя:

— Самолет чакырсагыз барам.

Бу тилелеккә кызны Мини-дивана котыртканлыгы ул чакта чамалап та беленми әле, кызның акылына зыян килмәгәнме, дип кенә шикләнәләр. Ләкин ул үз акылында! Аэродромы ук булмаган районга АН-2 дигән бәләкәйрәк самолет булса да төшертеп утырт та, аннары пар канатлы аэропланда иптәш Рамазановның үзе белән рәттән утырып бар әле син! Ул кем оча шулай республика башкаласына? Рамазанов белән беррәттән, республика башкаласына Мини-Әхмәтнең сөйгән яры оча! Болай ук эшли алмаслар, мондый капризны үтәмәсләр һәм шуңа күрә хатыны үз янында калыр дип өметләнгән Мини-тиленең аксылсыз ышанычы акланмады — китте хатыны, күзләрен тутырып, тәмам боегып, канатлары сынган коштай карап калды яшь баһадир күзләрен яшьләндереп... «Алып киттегез хатынны, йөрәк читлегеннән йолкып алдыгыз, күкрәкне ватып, җимереп. Ләкин шушының белән эш бетте, Минидән котылдык димәгез, бик каты ялгышкан булырсыз Мини дигән кешегез үзе дә төшеп калганнардан түгел ул!»

Алдынгы савымчыларның акчасы күп — калага баргач, Вәҗиһә, кеше арасында кешечә булсын дип, аякларына ялтыравыклы итальянский туфли, өстенә сары замш итәк, шул ук төстәге батник белән бельгийский кофта, ә аннары... норка тун! Тукта, чү! Кем бу?

Рамазанов бүлмәсендә ниндидер ят кыз күренде! Гозәер абыең үзе үк телдән калды: нәкъ менә кинофильмнарда гына күрергә мөмкин булган патша кәләше! Ләкин ул бераз гына таныш шикелле, кемгәдер, бик якын бер кешегә бераз гына охшаган да шикелле. Әйе, охшаган һәм алай гына да түгел, Җиреклекүлдән Вәҗиһә дигән кызны хәтерләтә ул. Күзеңне ачыбрак карап, тойгыларыңны батыррак итә алсаң, тәгаен дә әйтә алырсың: Вәҗиһә бу, синең якташың, сыер савучы маяк!

Мини-Әхмәт нишләр, Мини дигән Әхмәт! Хәзер бит бу гүзәлгә үзе кебек чибәр егет, патша малае кирәк һәм, әлегәчә дәвам итсә, тракторчы хатыны буласым килми, Каф тау артындагы әкияти илнең патша улына ярәшегез мине дип, яңа шарт та куячак ул! Көт тә тор, куячак!

Бәхеткә каршы, бу вакытта мондый эшкә аны котыртучы юк — үз башына килми, чөнки күңелендә авыл оялчанлыгы яшәп ята. Вәҗиһә тыныч кына барып, тыйнак кына утыра сессия утырышларында. Шулай да тәнәфес араларында толымнарын артка кабартып салган артык та җитди кызга карап сокланмаган кеше булдымы икән. Йөри бит, әй, йөри савымчы-аристократка! Кем уйлаган аның шушындый да кызыктыргыч була алганын! Кем? Мини-Әхмәт? Ялгышмаган, белгән!

Шәһәр кызларыннан күрмәкче тәмәке тартырга гына керешмәсен, дип шөбһәләнә Гозәер абыйсы.

Тәнәфес.

Халык, урамга чыгып, шундагы зур мәйданда театр фойесындагы рәвешле ирек ача. Шунда кайдадыр Рамазанов, кайдадыр Вәҗиһә атлы принцесса.

Сессия барган бина алдында бәйрәмнәр өчен куелган трибуна бар. Шул трибунада, бүрек колакларын җилфердәтеп, ниндидер авыл эзмәвере басып тора. Карый, күзәтә һәм кинәт кычкырып та җибәрә:

— Иптәш Рамазанов, иптәш Рамазанов!

Иптәш Рамазановның үзенә таба борылганын күргәч, баягыдан да яманрак акыра егет:

— Минем хатын, кайда минем хатын? Хатын! Вәҗиһә!

Мини!

Депутатлар аста, ул — югарыда. Аңардан да биек (һәм озын дип

тә өстик!) кеше юктыр — буйсынмыйча кара, тагын әллә нинди әкәмәтләр куптарып хур итәчәк. Шуңа күрә иптәш Рамазанов:

— Хәзер табам,— дип, үзе дә (астан булса да) шактый ук куәтле итеп аваз салырга мәҗбүр ителә. Мини йөгереп төшкәч, бу таба килүенә үк хатын, әлбәттә, табыла. Ләкин хатынына карагач, Мини телсез кала.

— Бә-әй, күрешмисеңмени? Миңләхмәт? — дип, аңа әллә нинди ят, ләкин сөекле хатын аптырап карый.

Телгә килсә дә тынычланырга чамасы юк ирнең:

— Минем хатын... хатын... Кайда соң минем хатын?! Ник алыштырдыгыз! Миңа үз хатыным да бик җиткән, кешенеке хаҗәт түгел! — янәсе. Авылча итәгатьсез акырган тилемсә ирне Вәҗиһә бик тиз хәтеренә төшкән тупаслык белән генә тынычландыра ала:

— Акырма, тилебәрән орлыгы соскан нәмәрсә, тагын сиңа нинди хатын кирәк?

Әрепләшүдән коткарыр өчен звонок шалтырый — тәнәфес тәмам. Рамазанов култыклап алып киткән чибәр хатынны тәки үзенеке дия алмыйча, тагын канатсыз коштай, үз канат астына чыгарган үрдәк бәбкәләре суга кереп чумгач аптыраган тавык мисалында сәлперәеп, боегып тик кала Мини. Күзләрендә тагын яшь юк иде микән әле? Бар иде бугай, әйе, яшьләнгән иде салпы колаклы баһадирның кечкенә, елтыр күзләре.

Сессия тәмам булган көнне гостиницада очрашкач кына Мини беләи беррәттән Рамазанов иптәш үзе дә Вәҗиһәнең патша кәләше түгеллеген, элеккечә гади тракторист хатыны икәнлеген күреп ышана ала. Бәхәссез галәмәтләр күз алдында: Вәҗиһәнең бүлмәсе тулы байлык, авылга кайтачак ике капчык күчтәнәч — клиндерләр, батоннар, консервалар, пальтолар, костюмнар, тагын әллә нәрсәләр. Шулар арасында — затлы тун... Шыплап тутырылган киндер капчыкның берсен аркасына Мини салса, икенчесен хатын үзе күтәрергә тиеш. Принцессага андый авыр нәрсә күтәртеп булмый лабаса, иптәш Рамазанов, машинага хәтле син күтәреп чык, ә мадоннага синең кабыргалары беленеп торган арык портфелең җитеп арткан. Менә шундыйшундый хәлләр...

Хәзер ул сәер кыланмышлар арттa калган калуын да, ләкин берсе дә онытылмаган һәм Вәҗиһә дә һаман мадонна, һаман япь-яшь. Чая тавышы яланны яра:

— Әй, председатель, нишләп алай, минем унсигез яшьлек чагымдай оялып торасың? Нишләп узмыйсың безнең янга?

— Үгез бит әнә, күрәсең, җир тырный.

— Безнең егетләр аннан да яманрак. Хәлебезне шуннан аңларсыз.

— Зөлхиҗәгә әйт әле шунда, берничә секундка безнең янга килсен әле.

— Зөлхиҗә, әй, кил әле бу таба. Әнә егетләр килгән синең янга.

Зөлхиҗә үлчәгеч чиләк күтәргән килеш якынлашкач, Ильяс аңа мине күрсәтеп:

— Бу абыеңны таныйсыңмы? — дип сорады.

— Сурәтен күргәнем бар.

Арган елмаю. Вәҗиһә чаялыгы белән бөтенләй капма-каршы. Булса да булыр икән шушы хәтле аерма. Берсе язмыш иркәсе, икенчесе...

— Ул синең белән сөйләшмәкче була, Зөлхиҗә.

Зөлхиҗә, сөтне марля капланган ак савытка сала-сала, салкын гына итеп җавап бирде:

— Сөйләшеп ни мәгънә инде? Үзегез генә сөйләшерсез лә.

Кыз китеп тә бармакчы иде, ләкин Ильяс вакытында өлгерде:

— Я инде, тукта, ул хәтле тагы.

Инде үзем катнашырга тиеш булдым:

— Сүз әллә ни күп тә түгел. Менә шушы хатны гына күрсәтмәкче идем.

Үземә шәһәргә җибәрелгән өченче хатны күрсәткән генә идем, комачның нәкъ үзедәй кызарып, кыз битләрен каплады.

— Сезнең хат...

— Бик алама язылгандыр инде... мыскыл итәсездер.

— Юк, искиткеч шәп язылган... Монда килүем дә бары тик шул хат аркасында. Тик бераз аңлашылып кына бетми: ник аны сез язасы иттегез һәм кеше исеменнән? Анонимка булып чыга түгелме соң?

— Менә тагы, алар яза лабаса — безгә карап торырга дигәнмени гел? — Зөлхиҗә Ильяска үпкәләгән кешедәй карап куйды. — Ә аның үзеннән булмый, надан.

Уңайсызланып елмаюына караганда, бу сүзләрнең искиткеч зур мактау икәнен Ильяс аңлагандыр, әлбәттә. «Без» һәм «алар». Бер якта — Зөлхиҗә үзе, Вәҗиһә, Миңләхмәт, Ильяс, Рамазанов, ә икенче якта... Тик бүтән сүз кирәкмидер инде, Зөлхиҗәнең тиз арада үз эшенә, сыерлары янына китеп баруы — шуның билгеседер. Күңелгә кыяфәте-мәгънәсе ачык ук булмаган ниндидер тойгы салып, сүзсез генә китәргә кала. Һәм без китәбез.

Басулар, тугайлар буйлата йөрибез.

Җил белән бергә яшеллек рәхәтен кочакларыбызга алагаем тутыргач, туйганчы үпкәләргә сулагач, яңадан авылга кереп, машина-трактор паркын, ындыр табагын һәм андагы яңа ашлык чистарткычларның гыйфрит сыман күккә баш терәп утыруларын, абзар-кураларны, һәр авылда яңа салынып яткан культура йортларын карап, киңлек хисенә муллык, байлык тойгысын өстәдек. Ә кояш өйләдән авышкач исә, Ильяс Агыйдел буендагы авылга, аннары елганың ярына, болынга ук китереп куйды. Монда безне бая гостиницага су китергән кеше — Сәрваров Ирек һәм Гатуф Бикимов көтеп торалар иде. Дөрләп янган учак янында.

Тагандагы шактый зур казанга күз төшкәч, иртән «суйганчы ук» чистарту хакындагы бәхәскә эләккән тавыкбикәләрнең монда килеп капканын аңладым һәм әллә ниндирәк,оялуга охшаш хис белән читкәрәк тайпылдым. Идел буенда, яшел болында — биек тау астында бергәләп какы өзәргә керешүебез хәерлерәктер.

Сүзләр арасына теге учактан күтәрелгән төтен белән кушылып, өзелер-өзелмәс нечкә бер шик үреләː сиңа гына түгел, Фәсиховка да «азык» булмасмы бу биш тавык, һәм, өстәргә кирәк ки, биш савыт?

Инде колхозчыларның гомуми җыелышын ук күз алдына китерик, ревизия комиссиясенеңː «Казаннан килгән кунакны сыйлау өчен тотылган биш тавык һәм биш савытны... фәлән сум исәбеннән раслыйбызмы, иптәшләр?» — дигәндәйрәк сүзләрен дә ишетәм кебек. Җыелышта иң арткы урыннарның берсендә утырган Фәсихов үзе күтәреләː «Юк, иптәшләр, расламаска кирәк, һәр килгән кунак аркасында закон боздыру куркәм эш түгел ул. Безнең сметаның бер генә статьясында да кунак сыйлау өчен бер генә тиен акча да каралмаган. Кем бәйрәм итсә, шунын үзеннән күтәртергә кирәк».

Фәсиховны Сәлимгәрәй яклап чыгачак та, менә китәчәк яңа чәрбе! Һәм бит алар хаклы булачак! Ләкин икенче яклап карасаң, инде шушы елларда да шушы хәтле вакчыллану үзе сыямы әхлакка һәм тимиме колхозның горурлыгына? Ә эрерәктән китсәң, байлык туздыруга да юл ачыла түгелме? Әйе, кечкенә саннар турында бәхәсләшү — мескенлек, ләкин бәхәс купса, бер сүз белән аны хәл итәрмен дә димә.

Житте, кунак, үзең дә чама бел, вакчыллыкка буйсынып, юмартлыкны рәнҗетмә, табынга рәхим ит. Җитмәсә, тост та синең килүең хөрмәтенә һәм сиңа корычтай сәламәтлек теләп игълан ителә. Рәхим ит һәм үзең дә җавап әзерлә. Шулай. Киң күңелле хуҗалар сине тиз генә җибәрергә чамаламыйлар. Кояш баеп, яктылык кими барса да, күләгәле яман уйлар кача, хатирәләр сине шәраб белән бергәләп кабат яшәртә, онытылган җырлар яңарырга азаплана.

Агыйделнең аръягындагы шушындый ук яшел тау һәм ышык үзән хыял сыман куе күк төскә керә. Бер матурлык икенчесен тартып китерә: шул яктагы ярга барлык утларын берьюлы балкытып, үзйөреш-ле баржа тукталды. Мондый матурлыкны ят кешеләрнең дә тиз генә узып китә алмавы бик тә аңлашыла. Аръяктагы пароход утлары, бу яктагы безнең учаклар белән үз телләрендә аңлашып, яшьлекнең үзеннән килгән сәламнәрдәй, җыр шикелле булып ишетелә башлый. Аңа кушыласы килә, чишмәгә кушылган чишмәдәй чылтырыйсы килә. Тик безнең чамага туры килми шул инде мондый ихласлык, мондый сафлык. Әнә, хәтта яшьрәкләр дә хатирәләрдән һәм аръяктан ишетелгән моңнарга кушылып, аның сихергә якын көчен кимегә генә төшә. Әйе, җырлый безнең мәҗлестәшебез, җырлый безнең ярым артистыбыз Гатуф Бикимов. Тыңлый торгач нәкъ менә шул ярым артистлыгының комачау иткәнлеге, табигыйлектән тайпылган тавышның сәнгатькә якынлашмавы гына түгел, тагын да ераклаша төшүе ишетелеп тора шул, артистлыктан бигрәк, шешәдәге җен ихтыяры аркасында туган кыюлык һәм көй иканлеге ап-ачык. Теге еллардагы моң... Кая инде аны кабат ишетү!

Шулай да боегу егет эше түгел, бүгенге көненнең матурлыгын ычкындырма, күрә бел, җиргә төш. Үзең өчен ят булган аръякка чыгып китә күрмә — анда сине көтмиләр һәм чыгарга җай да юк — мәҗлеснең тәнәфесе башланса да, сине үзе белән Ильяс чакыра.

Агыйделнең бирге яры буйлап китәсез. Сүз табылганчы ук Бикимов куып җитә дә, Ильясны култыклый һәм ярты сәгать буе аңа матур сүзләр бөрки. Бергә булгач, сүз мәгънәләре сиңа да сирпелми калмый, ишетәсең, тыңлыйсың. Аларның сөземтәсе шул: Ильяс кебек чын оештыручы белән эшләү Гатуф өчен бик зур фарт килү билгесе икән. Аның белән бергә эшләү дәвере — Бикимов өчен олы мәктәп булачак.

Бәлки ихлас әйтә торгандыр, чынлап та, сабакны күп алыр әле бәлки, тик... кайбер дөрес сүзләрне әйтү дә кайчак сентименталь көчсезлеккә әйләнә бәлә бит. Кызганычка каршы, юравым шул кичтә үк юш та килә язды шикелле.

*
* *

Җырлый-җырлый, тукталып йолдызлар саный-саный, Җиреклекүлгә кайткач та бер үземне генә калдырырга теләмичә, хуҗалар мине гостиницага кадәр үк озата килделәр дә, мәҗлес яңадан дәвам итте. Бикимов баян алып кергәч, үзе уйнап күрсәткәннән соң миңа бирде. Музыкадан минем хәзер дә читләшеп үк бетмәвемне, хәтта Сәрваров профессиональлык дәрәҗәсен саклавымны хуҗаларча арттырып әйтсә дә, минем инде масаерлык рәт юк — бу җәһәттән бөтен нәрсә хәл ителгән, мактаулардан һушсыз калырлык түгел. Тик бер нәрсәгә игътибар итмичә кала алмадым: музыкант буларак минем инде искергән килеш тә бүгенгесе көндә үзен баянчы дип йөргән Бикимовтан шактый әйбәтрәк уйнавым баян хуҗасының кәефенә (менә йөр син аны җитди кеше дип!) һич тә туры килмәде. Исереклеге комачау иткәнлектән, хисләрен яшерә алмыйча, миннән, әле генә чык-

сез кадерле булган кунактан, гаеп эзләп («язучының ни эше бар — уйнап тик утыра инде ул һ. б. һ. б.») азапланды һәм, билгеле инде, монысы минем башта кич буе җыелган хәмернең ким дигәндә уннан тугыз өлешен җилгә очырды. Шунда мин баянны Сәрваровка биреп, бераз гына ял итәргә диванга утырдым да хәтер мине «әһ» дигән арада туган авылга кайтарып ташлады һәм үземне генә түгел, ялгыз булмасын дип, иптәшкә Хәбир атлы дустымны да яныма китереп бастырды.

Ул чакта мин баян дигән кодрәткә бөтен яшьлегем, бөтен киләчәгемне сыйдырган тилемсә малай бит. Мавыгуларым үземнән артып, тирә-юньгә тарала, күршедә генә яшәгән Хәбиргә дә йокы бирми икән. Җайлы вакыт килдеме, тыңлап тора-тора да: «Әнис, өйрәт әле мине дә шушылай уйнарга!» — дип, соры күзләрен түгәрәкләндереп ялвара. Мондый да ихлас үтенечне ничек инде җиргә ташлыйсың. Сөйләшәбез, килешәбез дә, өйрәнгәнче дип, аңа кечкенә тальян сатып алабыз. Буш вакыт булдымы, ул тальянын күтәрә дә безгә ашыга, янсә мин аларга керәм. Гади генә бер көй уйнап күрсәтәм: «Карап тор, бармакларның кайчан кайсы телгә басканын хәтереңә сеңдерергә тырыш».

Шулай кабат-кабат, күп мәртәбә уйнап карый, юк, көй чыкмый. Кабат күрсәтәм, тагын уйнап карый. Искитмәле гади көй булып та буйсынмый бит, үтерәсеңмени аны! Ләкин без дә бирешергә ашыга торганнардан түгел. Мин аның янына ук килеп утырам да, аның бармакларына үз бармакларымны бәйләп, тагын уйнарга керешәм... Көй әкрен-әкрен буйсына башлый — тавышлар берсе-берсенә ялганып, мәгънәләрәк ишетелә башлый. Бу вакытта үзе уйнаган шикелле итеп, чын күңелдән елмая, шатлана Хәбир. Ин-унбиш атна шулай азаплана торгач, иң хәйләсез, иң туры дигән өч-дүрт көйне тәки ота да алды ул. Хәбирләрнең өй турыннан узган чакларда мин үзем бүләк иткән көйләрне еш ишетеп шатлана идем. Ләкин кешеләр алдына, урамга чыгып, яки мәҗлесләрдә, клубларда уйнарлык хәлгә ул тәки килә алмады. Ни генә әйтсәң дә, кич җиттеме, авыл өстенә бу якларда бердәнбер булган сәер тавыш, минем кулдагы баян тавышлары сибелә...

Көй тирәсенә үзебезнең яшьтәшләр дә, зурлар да җыела һәм, әлбәттә, көй бормаларын турыданрак уза торган тавышы белән булса да, Хәбир дә кушыла. Җырлый. Ләкин мин җырлый гына дип белсәм дә, ул уйлаган да икән. Башында нинди уйлар, күңелендә нинди тойгылар көйрәгәнен мин баянымны Шәйми дигән ялган милиционер тартып алып киткәч кенә төшендем. Анда да бик тиз түгел...

Менә шуннан соң инде авылда Хәбир уйнаган гармун тавышлары музыкаль дөньябызда бердәнбер хуҗа булып калды. Хәзер якын-тирәдә ул гармунчы, хәзер инде үз тирәсенә кешеләрне ул җыярга тырыша, һәм хәтта ул инде мине көнләштерергә үк азаплана. Тик мин үземдә андый тойгының әсәрен дә сизмәгәнлектән, ул бүтәнчәрәк юл сайлый: матур-матур көннәрдә кулына айдан кыеп алгандай тәмле кыерчык ипи тотып, безнең тәрәзәгә карый-карый, көлә-көлә, рәхәтләнеп чәйни-чәйни, урам уза. Менә, ичмасам, бу вакытта ул ирешә үзенең бөек максатына! Менә бу вакытларда мин көнләшәм! Йөрәкнең, юк, йөрәкнең генәме, ашказанының кай төшләредер җыерылганчы көнләшәм. Тик башымны кискәгә куйганда да курыкмый әйтерлек дәрәҗәдә дөресен әйтәм: мондый чакта да аны кемгә дә булса әләкләргә, үч алырга кирәк дигән уйның башыма кереп караганы булмады һәм мәңге кирәчәк тә түгел. Ә ул, ул!..

Минем кулдагы баяннан таралган тавышлар бәрелүдән, һай, сулкылдаган да икән аның бәләкәч йөрәк ите! Минем күңелдән ургылган максатсыз көйләр минем теләкләрдән, минем рөхсәттән башка

ин якын дустымны интектерә торган булган. Әх, баштарак сизгән булсам! Әгәр сизгән, чамалап кына тойган булсам да, мин аны тынычландырырга, һич югы, артык ук үртәмәскә, һич югы, шуның җаен эзләргә тырышкан булыр идем. Я инде, мин гаепле идемме табигать нәрсәнедер миңа күбрәк биргәнгә? Әнә бит, аның каравы, тәкъдир аңа икенче нәрсәне жәлләмичә биргән — аталы-аналы бай гаилә улына ул ипи биргән! Һәркемнең үз өлеше. Ә нишләп ул минем сагышлы, җәрәхәтле бәхетемне күпсенә? Җитмәсә, максатына да ирешә: авыл өстендә шул чакларга хас булган зәгыйфь көйләр, тычканнар вә күселәр музыкасы чыелдап сирпелә... Ипи исе аңкыган тәрәзәләрен киереп ачкан Хәбир дус гармун уйный... Әйтерсең ки шул көйләр бүген дә дәвам итә — Гатуф атлы Бикимов иске хатирәләргә охшаган көйләрен бер-берсенә ялгап утыра...

Еракта калган дустым минем. Ни дип каныкты, ни дип үчләште икән ул миңа? Һәм ник шундый хәлләр гомер буе дәвам итә — музыкада, әдәбиятта, тормышта?! Табигатьтән кемгәдер моң бирелмәгәнгә бүтән кеше гаепле микәнни? Нәрсәдә иде соң минем гаеп? Минем бит үземә беркемнән бернәрсәне дә артыграк бирегез дип бернинди кодрәткә ялынганым булмады. Үземә караганда чагыштыргысыз зуррак эш башкарган кешеләрне таларга, мыскылларга да җыенганым юк. Ә ул — Гатуф Бикимов, ә ул — Хәбир Гыйльманов — ник рәнҗи һәм ник башкаларны рәнҗетә? Һәм ерак яшьлектә калган Хәбир белән хәзер каршымда утыручы Гатуф ник икесе бер кеше булып күренә? Ул хәтта менә мәҗлесне боза. Хәер, миңа түгел, бу юлы Ильяска бәйләнә икән.

— Дөресен әйтсәк, син мине яратып бетермисең бит, Ильяс.

Сүзе кинәтрәк ишетелгәнгә, Ильяс шаярып котылмакчы:

— Ә син яратырлык нәрсә эшләдең соң әле?

— Яратсыннар дип, чәч белә җир себерергә керешиммени?

— Себермә, тик үзеңә тапшырылган вазифаларны намус белән үтә.

— Беләм нәрсәгә ишарә иткәнеңне. Мин бу авылга килгәч тә булган әйткәләшне оныта алмыйсың.

Гатуф бу сүзләрне кәефе тәмам кырылып әйткәнлектән, мәҗлес үзенең бәйрәмчәлеген тиз үк җуя язды. Кайчандыр булган әйткәләшнең нәрсә икәнлеген икенче көнне Ильястан сорап белдем. Авылга эшкә килүенең икенче көнендә Бикимов завхозга барган да акча түләмәү шарты белән үзенә ит сораган. Уңышсызлыкка очрагач, Ильяска килгән: «Колхоз председателе белән парторг итне распоряжение белән алырга тиеш түгелдер бит инде?» — янәсе. Күз дә йоммыйча шулай ди икән кешеләрне дөрес әхлакка өйрәтү өчен махсус акча алып эшләргә тиешле кеше.

Әлеге мәҗлестә шул бәхәс дәвам иткән иде. Бикимов кулына рюмкасын алды да, ике кул арасында шуны әвәли-әвәли, күңелендә йөргән әче нөктәсе белән бергә әйләндерергә керешге.

— Синең үзеңнең дә булгалады бит ялгышлыклар, Ильяс, бәхәсле моментлар. Машина ваттырдың да үз кесәңнән бер тиен дә чыгармадың. Булды бит шулай?

Сизелеп торганча, Җантуринның ачуы кузгалса да, миннән, чит кешедән, уңайсызлану аркасында, бөтен гәүдәсенә таралып өлгергән ачуын ул йодрыгына җыеп кысты. Йодрык, әгәр дә мин булмасам, һич югы, өстәлгә булса да шапылдап төшәсе иде. Хаклы, законлы булыр идеме бу чакта, түгелме, әйтә алмыйм, әмма Бикимовның асылда үзенә карата жалоба биреп утыруын сизгәнгә күрә, Җантурин эшне җитди рәвештә аңлатып бирергә мәҗбүр булды.

— Син килгәнче булган хәл. Урак вакытында, ындыр табагында, бөтен халыкның күз алдында булды ул. Ашыгычлык аркасында, ма-

шинаның арты белән бетон баганага бәрелдем. Начар юлда йөрмәгәч, эш өчен чапканда килеп чыккан бәла булгач, минем өскә ташламадылар. Үзем дә шул караштa торганга күрә, алар ихтыярына буйсындым. Бердән, шулай. Ә икенчедән, кем иске усаллыкны яңартса, шуның күзен чокып чыгар, дигән халык мәкале. Ник әле син аны нәкъ менә хәзер кузгатасың? Фельетонга заказ бирәсеңме?

— Гаделлекне яратканга күрә. Үзең түләмәдең, ә миннән түләттең! Икебезнең дә бер үк «Москвич»лар иде. Ә мин кесәмнән дүрт йөз сум чыгарып салдым.

— Хәмерле баш белән машинага утырмаска кирәген аңлаттылар — сабак бирделәр. Син моның өчен рәхмәт әйтергә тиеш идең.

— Ә үзең гел читтә, гел бүтәннәр кулы белән ут тотасың. Өченче көн идарә утырышында зоотехник Рамил Газизҗановны кушып тиргәттең: имеш, мин туган авылда калган дөньямны оныта алмыйм, килмешәк хәлендә яшим, имеш, шуңа күрә монда рәтләп эшләмим, имеш, җәйләүдә таналар киреләнеп саудырмаганга мин гаепле, һичнидән курыкмыйча, шуларның бөтенесе өчен мине тирги Рамил. Ә ник ул хәтле кыюланып киткән әле ул? Аңлаттылар моны акыллы кешеләр: әгәр аю хәтле яклаучысы булса, куян да бүрене тәнкыйтьли ала.

— Әле син санаган эшләргә күзәтчелек итү, шуларны оештыру сиңа тапшырылмаган идемени? Фактта син бу эшләрне провалить иткән өчен халыктан мактау көттеңме?

— Ник аерым гына, үзең генә тәнкыйтьләмисең? Ник бөтен халыкка тапшырасың да бүтәннәр авызы белән тиргәтәсең? Син бит минекен генә түгел, партком секретареның абруен таптатасың.

— Син ул исемне ник җиргә ташлыйсың? Күтәреп ал, таптатма. Анысы да сиңа тапшырылган — сакла!

— Сакларсың синең белән... — дип, шактый ук каты кычкырган иде Бикимов, Ильяс кинәт шым калды.

Күзләр сугышы. Җайсыз көрәшнең хокуксыз шаһиты буларак, мин шулай да Ильяс ягында идем. Шуңа күрә икесе дә бер-берсенә мыскыллы караш белән кадалышкан мәлләрендә:

— Тыңламый бит, өстәл сукканны көтә ул, — дип, мөнәсәбәт белдерергә җөрьәт иттем. Җантурин: «Шулай ярыймыни», — дигәндәй сораулы карагач, — миннән рөхсәт, — дип тә куйдым.

— Ишеттеңме, Бикимов, бар, тиз генә урамга чык, суынып кер.

Бикимов мыскыллы карашын киметергә дә җыенмыйча, селкенергә дә иренеп утырганда, Ильясның таш йодрыгы какъ өстәлгә шартлап килеп төште дә, андагы вак-төяк әйберләрне ярты метр биеклеккә очырды һәм Бикимовны да аягүрә бастырды. — Бар! — Шул сүз белән Җантурин үзе дә сикереп торды.

Гатуфның якасына ук тотынырга әзер шикелле иде ул. Бикимов, күпмедер арада ярдәм сорагандай Сәрваровка текәлгәч һәм тегесе ниндидер мәгънә белән ымлагач, йомшарырга тиеш тапты:

— Син нәрсә ул хәтле, син нәрсә...

— Бар, хәзер үк! Җилләтеп кер арган миеңне!

Әгәр дә Сәрваров тиз генә Гатуфны култыклап, көчләп үк диярлек алып чыгып китмәсә, эшнең ни белән бетәсен чамалау җайлы түгел иде. Ярый әле, чыгып киттеләр. Без икәү бүлмәләр буйлап йөрийөри тынычланырга тырышкан арада, Сәрваров урап та керде. Бераз гына, чынлап та, сулыш алып өлгергән Җантурин:

— Нишли? — дип кырыс тавыш белән сорады.

— Бикимов китте.

Мин: «Димәк, үзен хаклы саный», — дип уйлап өлгергәч тә, Җантурин:

— Кешенең үзен ихтирам итмәгәнен күрсәм, җенеп котыра, — дип, безне яңадан өстәл катына чакырды.

Ләкин әүвәлге уйнау-көлүләр җилсез-давылсыз да каядыр очкан, күңелдә кемгәдер, ни өчендер рәнҗү хисе урнаша башлаган иде. Саран һәм ясалмарак елмаюлар алмашканнан соң тиз үк аерылышырга туры килде.



*
* *

Иртән ишекне беренче булып Бикимов ачты. Тыштагы кояш яктысын алып кергән зәңгәр карашы белән тартынулы елмаеп исәнләште дә, кичәге өчен гафу үтенде. Бернинди ясалмалыксыз, чын күңелдән. Кичәге сүзләр дә чын иде. Үзен таныштырган чактагы «ярым артист» дигәненең генә дөреслеге чамалы икән — бөтенләй уйнамый Бикимов һәм шуның белән ул кызганыч та. Ә болай, һич югы, кичәге шикелле бәләкәй нөктәләрне сиздерми кала алырлык кына, андый ук ваклыклардан намусны сакларлык кына булса да артист булу һәркемгә зарури бит. Карашыннан, бөтен кыланышларыннан — һәм кичәгеләреннән, һәм бүгенгеләреннән — үтәли күренеп тора: холкың белән шактый нечкә, миһербанлы кеше син, әмма көнкүрештә үзеңне ничек тотарга икәнен әле белеп бетермисең — конституцияң эшләнмәгән, уйланылмаган һәм шуңа күрә тәртип юнәлешең бормалы-сырмалы. Әгәр шуны тиз арада ачыклый, мәгънәле итә алмасаң, буталчык бәрелешләрдән тәмам туйгач, Фәсиховлар төркеменә күчүең бик тә ихтимал. Мәгънәсез катылыклардан һәм олы дәгъвалы ваклыклардан башлана фәсиховщина... «Син дә алар төркеменә күчәрсең микәнни, иптәш Бикимов?!»

Мин үзем дә мактанырлык дипломат түгел, ни уйлавымны бәлки Бикимов сизгәндер дә. Зыян юк. Бәлки сиздерү бу юлы кирәгрәктер. Өметсез кеше түгеллеген истә тотып, ихтирамсызлыгы өчен ачуланмавымны мин дә елмаеп аңлатырга тырыштым. Ул баянны күтәргән килеш ишек төбендә тукталгач, кулларны шактый ук каты кысыштык. Мәгәр гостиницаның җыештыручысы һәм хуҗасы булган апа кереп бүлмәне тәртипкә китергәндә, төнге чәрбенең яңа бер шаһите тынычлыкның тиз генә урнашмаячагына, онытылып ук бетмәячәгенә ишарәләде шикелле: апа идәннән сәгать пыяласы һәм сәгать угы күтәреп алды.

— Сәгатегез ватылган, ахрысы, — дип, ул аларны миңа сузгач, әллә, чынлап та, шулай дип сәгатемне тикшерсәм, аның бөтен җире төзек иде.

Ия чыгарына ышанганлыктан трофейларны китап шкафының аскырак киштәсенә куйдым.

Шул мизгелдә телефон шалтырады. Гостиница хуҗабикәсен, Гөлсабира апаны, Зөлхиҗә сорый: үзенең улын Гөлсабира ападан бер генә көн карап тормассыңмы дип үтенә. Җәйләүдән бүген төнлә кайта алмыйлар икән.

— Гостиница иркен бит, ал да кил шушында,— дим, гөнаһ шомлыгына каршы.

— Ярый, алайса, икәүләп йокларсыз,— ди дә Гөлсабирә апа, Зөлхиҗәгә улын барып алырга вәгъдә бирә...

Аннары иртәнге чәй. Чәйдән соң Ильяс белән Сәрваров кергәч, күзләре баягы «трофейларга» төшеп, алар да уңайсызланып елмаешалар. Кичә йодрык өстәлгә төшкәч, нәрсәдер нечкә тавыш белән чыйкылдаган иде шул — сәгать сай кырлы вазага яки өстәлнең үзенә бәрелгән булырга тиеш.

Ильяс кесәсенә кәгазь белән төреп салынган ватык сәгатен чыгарды да аны тиз арада рәтләп куйды. Ә ныклап төзәтергә дисә, Фәсихов

дигән Госманга мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк. Шушы фикерне Ильяска әйткән идем, чын күңелдән көлде ул:

— Юк, авылда сәгать аларныкыча йөрмәячәк, һичкайчан да.

Тагын басулар әйләнеп, идарәдә күпмедер сөйләшкәннән соң тагын гостиницага кайтсам, шундагы бакчада бер малай тавыклар куып азаплана иде. Кыз балага охшашлырак бу матур малай белән көн буе бергә булачагыбызны уйлаганда, мин аны үземә тиз иялäштерергә тиеш.

— Менә молодец,— дим аның, чынлап та, куәтләргә мөмкин булган хезмәтен танып,— түтәлләрне туздырып йөрмәсеннәр. Исәнме, я, күрешик инде. Исемең ничек әле синең?

— Әнис.

— Әнис? Юк, син түгел бит Әнис, мин — Әнис.

— Мин — Әнис.

— Син минем исемемне рөхсәтсез алгансың, үземә кире кайтар.

Әлбәттә, сүзләремнең шаярып әйтелгәнлеген бөтен торышым белән сиздерергә тырышам мин. Шулай да бала бәхәснең чын булуына шикләнмичә, исемнең кемнән кемнең алуын ахыргача ачыкламакчы:

— Мин исемне синнән алмадым, аны миңа әни бирде.

— Булды, аңлашылды. Дус булсак, икебезгә бер исем җитәр. Җитәр бит?

— Әни әйтсә, җитәр.

— Килештек.

Бәхәснең файдасы тигәндер инде, малай миңа тиз иялäште. Моның өчен яныбызда Гөлсабира апа булуы да ярдәм иткәндер, билгеле. Төшкелекне өчәүләп ашагач, кармак рәтләдек тә икәүләп балыкка киттек. Елга буенда уйный-уйный, комлыкта, яшел ярларда йөгерешә-йөгерешә аргач һәм кичен аны үз янымдагы караватка яткыргач, ул, башы мендәргә тиюгә, йокыга китте. Минем үз улым бу вакытта ерак бер ят илдә спортчы-кылыччылар ярышыннан соң шушы рәвешле арып кайткандыр, аны да тынычландырырга һәм бәлки юатырга кирәктер. Ә мин менә туган җиремдә бөтенләй ят кеше малае белән бәхетле булып йөрим...

Уйланып яткан җирдән үзем дә йоклап киткәнмен. Телефон шалтыраганнан уянып китсәм, өй эче кап-караңгы. Телефон тынар да яңадан йоклап китәрмен дип кузгалмый ятсам да, ул чылтырый. Аптырагач трубканы алам да, тагын төш бугай, дип исемә килә алмыйча торам. Әйе, Җантурин шалтырата: Зөлхиҗә, үзенең улын эзли-эзли хәлдән тайган, шашкан кеше сыман елга буйларын әйләнгән, хәзер өй борынча кереп йөри, ди!

— Малай миндә бит, миндә!

— Шулайрак әйткән идең шул. Ә Зөлхиҗә белмәгән — улым суга баткандыр, я үтергәннәрдер дип чәчләрен йолка!

— Хәзер, без шунда чаптык!

Малайны уятам да, житәкләшкән хәлдә, хәзер үзебез дә тилергәндәй каушап йөгерәбез. Тын-көн бетеп, өйләренә җиткәндә, анда инде халык җыелган да, кайсыдыр миңа малайны рөхсәтсез алып киткән өчен бәйләнергә үк керешмәкче. Зөлхиҗә мине танығач та, малаен кочаклаган хәлдә, үкси-үкси тагын бөтен көченә кычкырып җибәрде:

— Юк, ул түгел, улымны урлаучы ул түгел! — дип, мине якларга керешә.

Ә мин каушый-каушый иртәнге телефон турында әйткән идем, Зөлхиҗә моның нәрсә икәнен дә белми, аңламый да:

— Юк, абый, мин сезгә шалтыратмадым, Гөлсабира апага да. Ник үз улымны кешегә тагыйм ди мин?

Шулай, ышан, Гөлсабира апа белән иртән сөйләшкән кеше Зөлхи-

җә булмаган, ул булып кемдер бүтән кеше сөйләшкән... Кем? Нинди максат белән? Шушы җәйге таңны, саф дөнья ямен, тәмен бозарга нинди адәмнәрнең вөҗданы җитә? Бар бит, шундый адәмнәр дә шушы гүзәл дөньяда! Ләкин, гостиница идәне астындагы кимерүчеләр кебек, аларның исемнәре генә юк... Кемнәр, кемнәр?

Чамаларга мөмкин шикелле...

... Болай хушлашу миңа да, мөгаен, хуҗалар өчен дә матур ук була алмас, нәрсәдер җитми калыр сыман тоелганлыктан, район үзәгендә, сабан туйда очрашырга сүз куештык. Агыйделнең Иске Аю диган пристаненнан бер авыл куеп, шул тирәдә елгадан бераз гына эчкәре урнашкан Җиреклекүлдән үзебезгә, Базы буена таба, Буранлы авылы аша Этиле авылына хәтле диярлек, мине Җантурин озата килде.

Ә дөнья — искиткеч иркен, ямь-яшел, яшь-яшь. Игеннәр, игеннәр, игеннәр. Тик яңгыр юклыгын хуҗалар гына түгел, инде кунаклар да сизә. Барыбыздан бигрәк — басулар үзләре. Ләкин әле боекмаганнар игеннәр — кыякларын сузып, кояшка яшел шатлык сирпиләр, тормыш өчен рәхмәт әйтәләр, ахрысы. Алар бездән, кешеләрдән, мәгънәлерәк бугай. Без яшәүнең үзеннән шатлыкны сирәк алабыз, максат артыннан көн-төн иярә-иярә, мәшәкатьләр чигә-чигә, көннәр узганын сизмибез, аларның янармас матурлыгын күрми, тоймый узабыз — таңнарны ашыктырабыз, көннәрне, кичләрне куабыз, төннәр килсә, тизрәк йокыга, йокыга авабыз. Уйланырга, бәхетне тоярга, кичерергә җитми вакыт. Ә ныклап уйлансаң, вакыттан күп нәрсә юк, аны бары тик бер генә нәрсә — мәгънәсезлек кенә йота бара. Җитмәгәне — акыл һәм холык... Бер-беребезне үртәргә, рәнҗетергә дигәндә вакытны мул табабыз лабаса!

Басу капкасы янында тукталдык. Шунда бу авыл колхозы председателе машинасы тора иде. Эчтәрәк, урман полосасы тирәсендә, гербицид сибүче механизаторлар белән кызып-кызып әрепләшкән кеше председатель Вәлитов үзе булырга тиеш.

Аны бик кырыс кеше дигәннәре тиз арада рас килде. Күрше колхоз председателен үз җирендә күрсә дә (мине исәпкә алмаска да мөмкин, әлбәттә), ул тиз генә безнең янга ашыкмады. Гербицид сибәргә үзе рөхсәт иткән төштә гербицидны, ихтимал, саксызрак сипкән егетләрне кыздыра торуы аның өчен мөһимрәк иде. Ә без көтә дә алабыз һәм көттек тә. Һәм ул, ниһаять, килде. Ләкин безнең янга түгел, үз машинасы янына. Аңа үзебез барып кул сузгач та, ул безнең кулларыбызны игътибарсыз гына кабул итте. Җантурин белән атна буе дусларча сөйләшеп йөргәннән, шундыйга күнеккәннән соң Вәлитовка тап булу таш диварга бәрелгәннән һич ким тоелмагандыр. Ярый, кинәт күрелгән аерма дөньяны, холыкларны тану һәм яхшының кадерен шәбрәк белү өчен әйбәт чара бит. Җантуринга кул бирдем дә очрашулар, матур әңгәмәләр өчен (кичәгесен сыза төшкәндә, билгеле) рәхмәтләр әйтеп, кулын кыстым.

## Аръякта — малай чагың...

*26 май, 1977.*

Этиле авылына мин Базының теге ягыннан, үзебезнең авылдан карарга күнеккән. Зәңгәр өметләр ябынган өянкеләр һәм өйләр сине гомер буе шул таба дәшәләр, нинди очрашу, көрәшүләр, көтелмәгән яңалыклар, ачышлар вәгъдә итәләр. Без, ул чактагы бәлә-

кәйләр, җәйге кичләрдә зурларга ияреп, бу авылга еш килә торган идек. Олылар клубта спектакльме, концертмы, караса, без, бала-чага, этешә-төртешә үз бәйрәмебезне ясыйбыз — гадәттәгедән иртәрәк өлгерә торган Этиле кызлары белән шаярганда, алар безгә ярыйсы ук мәгънәле кагыла, күрәшкән булып, дөньяда кочаклашу дигән хәл барлыгын җисемле аңлата иде. Сигез-тугыз яшьлек малай, ә шуларны хәтеренә салган бит!..

Зурлар клубтан чыгып каядыр таралышкач та без моның да мәгънәсен чамалыйбыз һәм, әллә инде шуңа бераз курка төшү дә өстәлү аркасында, үзебез генә өйгә ашыкмыйча, атлар куелган йортка кайтабыз да печәнле арбага менеп ятабыз. Ат төн буе кетер-кетер печән ашый, лапас түбәсенә шыбыр-шыбыр яңгыр сибелә, ә син малайлык ләззәтеннән оеп, рәхәтләнеп ятасың.

Этиле малайлары безнең белән ни өчендер сугышырга ярталар. Базы суы Агыйдел хәтле җәелгән ул елларда елганың бер ягында без, икенче ягында — алар. Рогаткалардан атышабыз, елга аша берберебезгә тидерергә тырышабыз. Ләкин елга киң, ташлар чыгып җитми, ә чагыштырсаң, аларныкы шәбрәк оча. Таш атышу еш кына очрашып тәпәләшүгә тоташа. Башлаучысы бер, күп дигәндә ике малай, әмма да соңынтын аларга зурраклар, әтәч булып җиткән егетләр кушыла, хәтта олы ирләр. Шунысын да хәтерлим, бер мәлне безнең бөтен авыл халкы атлар атланып Этиле «дошманнарны» авылларына чаклы куып илттеләр. Тәпи баскан сабыйдан башлап, тешләре коелган картларга кадәр «шугышты». Сәбәбен сорагыз: әйтә алучы таба алмаячаксыз. Хәтерләүчеләр булса, хәзер дә табылмас андый кеше. Дөресен әйткәндә, сәбәпне эзләүче дә юк, анысы кирәк тә түгел. Хәзер ничек икән? Бәлки хәзер дә шулай дәвам итәдер? Малайлар арасында булмаса, зурлар арасында?

Шундый очрак истә: Базы аръягыннан «дошманнар» бирге якка чыгып, безне тукмарга вәгъдәләр бирә-бирә акырышалар. Үз чиратыбызда без дә яныйбыз: «Чыгып карагыз, башыгыз ике булса», янәсе. Бәхәсләшә торгач: «Әллә курка дип беләсезме, курка торганнар безме әллә!» дип, күкрәк кага-кага чишенделәр дә күлмәк-чалбарларын муеннарына бәйләп, йөзә дә башладылар. Без балчык, ком, таш ыргытабыз — чынлап та, курыкмый болар, килүләре килү. «Безнең якка аяк бассагыз, муеныгызны каз муены шикелле итеп борып кына ташлыйбыз!» дигән өркетүләребезгә каршы берсе — олырагы: «Суксагыз бер сугарсыз, аннан соң үзегездән кәтлит ясыйбыз!» дип акыра-акыра, башка «дошманнарны» ияртә-ияртә, чынлап та, чыгып житте бит. Чыкты, яр читенә басты, куллары-башлары яман да ямьсез бутый-бутый, баягыдан да хәтәр акырды, акырды да... тамагы ачытып булса кирәк, яшелле-зәңгәрле авазлар гына чәчри торганга әйләнгәч, шып тукталды. Без дә капка кадәр ачылган авызларыбызны ябарга кирәк икәнлеген дә уйлый алмастан, кагылган баганалардай тик торабыз. Мең вәгъдәләрнең берсен генә үтәп, берәрсенә бармак белән генә булса да чиртә алсак икән. Әллә без кагылмаганга инде, «дошманнар» үзләре дә нишләргә белмичә телсез калдылар. Араларында, чынлап та, телсез бер малай — Әпә бар иде. Төскә чибәр, гел әйбәт, чиста киенеп йөри. Шул гына минем янга ук килеп, анда да авырттырмыйча гына, беләккә бәләкәй бер таш тидерде тидерүен. Бик якыннан гына. Ләкин мин җавап кайтармагач, сугыш чыкмады һәм шулай аптырашып озак кына торгач, әле берничә минут элек кенә булган шапырынулар һәр ике якка да кызык тоелып, башта күзләр белән, аннары иреннәр белән елмаеп, аннары исә шаркылдап ук көлешергә тотындык. Көлешү аркылы килгән килешү шатлыгыннан канатланып, безнең авылга менеп киттек.

Этилегә ерактан карасам да, мин әнә шул малайларны андадыр

дигән өмет белән карыйм, шул чакларны табарыма ышанам. Хәзер дә, һич югы, берсе белән көрешергә, килешергә дип барам... Малай чакның мәгънәсез бәрелешләре инде сагындырган, шул кадәр сагындырган! Әмма зурларның шул чактагыча, малайларча мәгънәсезлекләре генә күңелне иркәләми һәм хатирәләргә әйләнгәч тә һич тә иркәләмәс шикелле.

Вәлитов танышканда миңа үзенең фамилиясен әйтсә дә, ул аны авыз ачмый гына әйткәнлектән, ишетми калган идем. Гербицид аркасында кәефе киткәнгә шулайдыр, ачылыр әле чырае да, авызы да дип өметләнсәм, юккарак хыялланган булып чыктым,— ул гомумән авыз ачмыйча сөйләшә белә икән. Бер-берсеннән аерылырга теләмәгән иреннәр аша ычкынган сүзләргә мин әле күнекмәгәнлектән, аларның кайберләрен генә, анда да уйлап торгачрак, чамалабрак аңлый идем.

Идарәгә кердек. Алгы кысан бүлмәдә кызгылт чырайлы кыз бала утыра. Секретарь кыз. Председатель бүлмәсе дә шуннан иркенрәк түгел. Сул яклап кечкенә өстәл, дүрт-биш урындык тезеп куелган. Уңдарак, түр почмакта шундый ук бәләкәй өстәлдә председатель үзе утыра икән. Җиреклекүлдәге иркенлеккә күнеккәнгә бугай, аптырабрак калдым.

Вәлитов үзе утырды да... инде миңа урын тәкъдим итәр дип көтсәм, көтә-көтә каранып та алсам, юкка өметләнгәнемне шәйлим — аның өстәле янына бүтән урындык куелмаган. Ни эзләвемне чамалагандыр, ниһаять, миңа ул үзеннән шактый ерак өстәл тирәсендәге урындыкларны күрсәтте:

— Сезгә урын теге өстәл янында булыр.

Ике арада шунда ук зур гына ераклык хасил булды һәм ул кыскарыр сыман да тоелмады. Бу тирәләрдә ни өчен йөрүемне истә тотып, хәл-әхвәл сораштырырга тырышу да файдасыз булып чыкты. Сөйләшеп китә алмадык. Җиреклекүлдә башланган дәфтәрләргә шушы ике-өч сүздән башкасы өстәлмәде. Кемнәрдер кереп, ниндидер күрсәтмәләр алып чыккач, гостиницага киттек.

Менә монда баягы кысанлык инде юк — искитмәле зур агач йорт. Идәннәр һәм диварлар төрле-төрле келәмнәр белән капланган. Кем әйткәндәй, патша яшәрлек затлы тормыш.

Көндезге аштан соң баягы машинада шушы колхозга караган Буранлы авылына юл тоттык. Без бәләкәй чакларда үзебезнең авылдан караганда серле булып күренә торган күк аргамак янына. Мин аны күптән инде күргәнем юк, хәтта ерактан да ничектер күз төшми башлаган икән. Хәзер шуны гаҗәпләнеп уйлап куйдым. Ләкин менә искә төште һәм мин аны тиз арада яңадан күрәчәкмен — еллар буе үзенә ашкындырып, ә аннары чиксез еракларга алып китәчәк бүз аргамак белән очрашачакмын. Ләкин килеп җитсәк, аргамак дигәнемнең бары тик күп кенә өянкеләрдән укмашкан сурәт икәнлеген хәтерлим... ул өянкеләрнең дә инде күптән киселгән булуын күрәм дә... әйтеп аңлата алмаслык тирән сагышка чумам. Башта алар корыган булганнар икән...

Булмаган аргамакның югалуын исәпкә алмастан, председатель кечкенә авылда зур итеп төзелә торган клубны күрсәтте: миңа язарга материал бирмәкче, мөгаен. Әмма мин хыялымда гаярь аргамак хасил итеп, еллар буе кечкенә җанымны каядыр ашкындырып, җилкендереп, ерак юлларга һәм елларга дәшкән өянкеләр юклыгыннан һушсыз калганмын... Ансыз мине бу минутларда бүтән һичнәрсә кызыксындырмавын аңлый, сизә белгән кеше Вәлитовмы инде!

Яңадан Этилегә кайтып, елга аръягына, үзебезнең яккарак чыктык. Аннан да югалган аргамагымны эзлим — каядыр утлауда гына йөрмәгәнме дә, яңадан үз урынына кайтып басмаганмы, янәсе. Өян-

келәр урынында күгелҗем кара болытлар кабарып ургылуын гына күрергә мөмкин иде. Нишлисең, бүгенгесе көндә шунысы җитеп торадыр.

Базы ярында механизаторлар җыйналган. Бүген сипкечләрне рәтли алмаганга күрә гербицид чәчү оешмаган. Кичтән әзерләп куярга һәм иртәнге биштән сибә башларга вәгъдә бирештеләр. Шактый үк кайнар речьләр булды: кирәк мәлендә, бер атна эчендә чәчмәсәң, иген орлыкланмый — кибәк җыюың бик мөмкин. Җилдә чәчсәң, агачларга чәчрәп, аларны көйдерә, юк итә... Буранлы тарафында өянкеләр югалгандай... Монда да, бу кешеләр арасында да мин эзләгән малайларга охшаганнары, миңа хат язу ихтималы булырдайлары күренми иде. Буз аргамак артыннан алар да каядыр китеп барган, ахрысы.

Ә шул арада Буранлы тирәсен каплаган өермәле кара болытлар инде Этиле өстенә ябырыла. Шуны күреп, Вәлитов машинасына утырырга ашыкты. Гостиницага кайтышлый давыл бөтен авылны берьюлы бөтереп алды һәм яварга да кереште. Чиләкләп койды дию кимету булыр, җил белән су «Волга»ны туктарга мәҗбүр итте. Урам елга рәвешенә кереп шаулады һәм гөрләвекләрен шул хәлдә калдырып, күп дигәндә ярты сәгать эчендә тынычланды да. Чуаркүл ягыннан кояш балкып күренде һәм... ышаныгыз, шушы мәлдә Вәлитов елмайды!

Шулай да, давыл афәт калдырып китмәдеме дип, басуларны карарга ары чаптык. Гарасат зыянсыз диярлек узган. Чуаркүлдә бер өйнең шифер түбәсен йолкып аткан атуын, тупылларның олы-олы ботакларын сындырып урам уртасына ыргыткан — көч-хәл белән генә үттек. Әмма Вәлитов битендәге елмаюны сүндererлек түгел иде бу хикмәтләр.

— Табигать шулай килешмәгән яисә артык булган әйберләрне юк итә инде ул, табигый отбор, — дигән фәлсәфи нәтиҗәгә килде Вәлитов һәм... тагын елмайды.

Йомгаклап әйткәндә, Этиле авылында узганнарга бәйләнешле өметләр акланмау, беренче хат иясе табылмау сәбәплеме, шушы елмаюлардан да яктырак хәлләрне тәки күрә дә, шәйли дә алмадым. Өмет өзеп инде китәргә җыена идем.

Гостиницада радиоалгычтан музыка сайлап азапланганда, коридордагы бердәнбер телефон шалтырап сискәндерде. Миңа кемнең дә шалтырату ихтималы булмаганлыктан, коридорга чыгып трубканы алмадым. Икенче бүлмәдән хуҗабикә апа кергәч кенә шалтыратуның үземә икәне аңлашылды.

— Анда... сезне сагынганнар, — диде апа, ничектер үз шаяртуыннан үзе оялыбрак.

— Кемнәр? — дип сорыйм, чынлап та, никтер шул ялганга ышанасы килеп.

— Нәзилә.

— Нәзилә? Нинди Нәзилә?

— Ул үзе танышбыз ди тагы. Нишләп алай әйтә икән? Менә инде, бер дә килешмәгәнне.

Хәтерләргә тырышып карыйм, юк, зиһен мондый исемне өстерәп чыгара алмый. Дөресрәге, шушындыйрак исемне ишеткәнем бар бугай, әмма бер генә конкрет кешене дә ул исем белән янәшә куя алмыйм.

— Я оныткансыздыр, бер дә алай ялганлый торган гадәте сизелми иде, укытучы кеше бит ул.

Оныткан булуың да бәхәссез үк түгелдер. Бәлки үзен күргәч хәтергә төшәр. Төшмәсә тагы ни зыян?

— Ә нәрсә сөйли соң ул Нәзилә?

— Сөйләми лә. Кунагыгыз кайчан китә дип сорый. Мин бүген китми бугай әле дидем. Шулайдыр бит?

Шулаен шулай да, тик шактый ук мәзәк бит: мине күрәсе килсә, сүзе, йомышы булса, телефонга үземне чакыртырга тиештер, ә ул чакырмый да, үзе дә килми, бары тик сорый гына. Эш юктан гына шаярта торгандыр.

Ләкин бу звонок бераз гына серле булуы белән миндә кызыксыну тойгысын кузгатты, чөнки ул ниндидер гайре табигый нәрсә вәгъдә итә иде шикелле. Ахрысы, узганнардан бер әкиятнең таныш кеше кыяфәтендә кайтачагына өметләнә күңел. Йөрәк татлы сулкылдап куя, кабатланмас яшь матурлык кайнар агым булып чымырдый һәм бик тиз шулай узып та китә. Могҗиза булмаячак, син инде бу урамнарда ялан аяк йөри алмаячаксың һәм... тагын звонок. Бу юлы трубканы алырга инде үзем чыгам. Ләкин... ләкин анда чамасыз тупас, калын ирләр тавышы ферманы сорап кычкыра.

Баягысын да очраклы звонокка исәпләп, тыныч кына колхоз идарәсенә таба киттем. Кайбер кешеләр белән вак-төяк сүзләр. Ләкин күңел эзләгән бер генә ым ник кенә ишетелсен икән. Төссезлектән качу нияте беләндер, ахрысы, урамда йөрим. Барам, барам... Бер мәлне һушыма килгәндәй карасам, авылны чыгып, Базы дуена якынлашам икән. Ник киләм мин монда? Базының да, елга булып елганын да төсен, көчен дә җуя, картая баруын мең дә бер кабат күрер өченме? Шуннан җиңеллек табылыр дигән өмет бармы?

Тарая, тарая Базы дигән елга. Ул тарайган саен, анда без су кергән вакытлар белән бүгенге көн арасы киңәя, ерагая.

Менә мин елганың үзем өчен мәңге аръяк булып каласы төшеннән үзебезнең якка карыйм. Җәяүләп кенә чыкмалы — тезләреңә кадәр генә балакларыңны сызган да чык та җит бала чагыңа. Шул еллардагы суларда йөз... Ләкин борынгылар бер елгада ике тапкыр су кереп булмый дигәннәр шул. Кайчандыр безне иркәләгән сулар агып беткән, дәрья кипкән. Бары сагышлар гына елдан-ел арта, тирәнәя, киңәя, ярсулырак була бара, бары тик сагышлар гына.

Кайчандыр Базының биленә сары каештай уралган буаның калкурак бер почмагында, яр өстендә шаулаган элекке зур куактан калган бердәнбер тупыл лебердәп утыра. Зәгыйфь кенә, өметсез генә.

— Таныйм, хәтерлим мин сине, син — минеке! Тамырларың җир өстенә чыккан, шулай да яшел әле син. Тик җәй башында ук саргылт чалымнар күренә төсеңдә. Син дә элекке елларыңны сагынасыңдыр:

Исә җилләр, исә җилләр,
Исә җилләр файдасыз,
Төнлә төшләремдә күрәм,
Көндез әллә кайда сез,

— дип талпынасың-талпынасыңдыр да әле кайчан гына бергә шаулаган куакташ тупылларыңны янында күрмичә, яңадан тынасыңдыр. Җилләргә баш иясеңдер. Яшьтәшләрең ташлап киткән сине, алар сиңа бөтен барлыкларын, барча теләк-өметләрен калдырып киткәннәр. Ә син? Син үзең өчен дә рәхәтләнеп, киңәнеп шаулый алмыйсың. Яфракларың инде вак-вак кына калгангадыр, шау-шуларың ярсусыз, тын гына, тып-тын. Исә җилләр, исә җилләр... файдасыз шул. Файдасыз шул, тупылгынам. Җилләр синең соңгы яшеллекләреңне читкә сипкәләргә тырышалар.

Синең яныңа килеп, мин дә сулары кипкән ярга аякларымны салындырып утырам... да үзебезнең якка карыйм. Анда да ямьсез, тәртипсез булып өелеп калган ниндидер өемнәр, чуп-чар һәм мәсәрәчәк сулы вак-төяк күләвекләр. Ялан аяклы малайлар анда йөрергә дә җөрьәт итмиләр — күренми, күренмиләр.

Ә безнең малай чаклар йөргән юлларны сөргәннәр. Ничә кабат икән инде? Безнең сукмаклар югалган. Безнең өчен сайраган кошлар тынганнар. Сайраганда да без аңламас көйләргә җырлыйлардыр алар.

Яратмыйча гына, бары тик яратырга гына хыялланып бу җирләрдән узган кызлар... Ничек, ничек сезне әбиләр итеп күз алдына китерә алыйм? Әй, сез, йөзләре җыерчыклы кызлар! Сез идегезме ул? Сез идегезме?..

Ул чакларда без мәхәббәтне алдан, киләчәктән көттек, ул чакларда мәхәббәтне без уйнадык кына, ишетәсезме, җыерчыклы йөзләр! Без шаярдык кына, ә сез? Сез дә шулайдыр бит? Тик соңыннан чын дигәнебездән башта уен тоелганы чынрак булып чыкмадымы?

Хәзер ул чактагы уен-көлке, хәтта хыянәт тә уй җитмәслек ерак аралар артында калган. Узганбыз да киткәнбез чабыша-чабыша.

Ник сөймәдем, ник чынлап яратмадым икән сезне шунда дим дә... чын яшьләрем, сезне күрсәтмәс өчен, күзне томалый. Дөнья импрессионист рәссамнар ясаган сурәт шикелле тонык, аныксыз һәм нәкъ тормыштагыча, яңгыр чылаткан тәрәзә аша караган сыман чын. Әллә ул рәссамнар да дөньяга яшь аркылы карыйлар микән? Сулы тәрәзәләрне йодрык белән сөртсәң, чыланган кул, бармаклар белән сезнең күзләрне, йөзләрегезне сыйпасаң, еллар зәхмәтен сөртеп-сыпырып ташлап булмас микән? Әйдә, сынап карыйк — килеп чыксын берегез, килегез, кайтыгыз югалган елларыгыздан! Юри генә, әй, юри генә булса да кайтыгыз!

Тагын уйнар-шаярыр идек микән, көләр идекме, әллә елар идекме?

Танышмыйча, ят кешегә сүз катарга яхшысынмыйча, узып кына китәр идек!

Без — без түгел.

Сез — инде сез түгел.

Тойгыларның мәңгелек ызгышына шулай нокта куеп, яңадан гостиницага кайтсам, сәер звонок тагын кабатланган икән. Хуҗабикә апа бик җитди кыяфәттә хәбәр итте:

— Нәзилә сезне кунакка чакыра, бик үтенеп. Әйтәсе сүзләрем бар, ди.

Тагын табышмак.

— Таныш түгел кешегә ничек кунакка барыйм?

— Барсаң тагы. Куркыныч кеше түгел лә.

Чырайга курку галәмәте үк чыкты микәнни? Яхшы түгел, һич тә ярый торган нәрсә түгел монысы. Әйтерсең контрабандистлар белән эш итә кеше. Таныш булмаса, танышу үзе дә кыен эш түгел ләбаса. Җитмәсә, максатың шул — мөмкин кадәр күбрәк кешеләр күрү, сөйләшү, дөньяны, тормышны тирәнрәк төшенү һәм... тагын звонок.

«Хәзер» дигән сүзен әйткәч үк, ханым трубканы миңа сузды.

— Әйе, — дим бернинди тойгысыз һәм уйсыз бер хәлдә.

Ә трубкада — шактый ук ягымлы, яңгыравык һәм бераз гына тыенкы тавыш.

— Исәнмесез, хөрмәтле якташыбыз. — Мин ни дә әйтә алмыйча торган арада дәвам итте. — Сез Әнис бит?

— Әйе.

— Кайтуыгыз белән котлыйм.

— Рәхмәт, исәнмесез.

— Мин сезне бик сагынган бер кеше исеменнән сөйлим, аның үтенечен тыңлап.

Әкияттәге төслерәк: агач, агач башында оя, оя эчендә үрдәк, үрдәк эчендә йомырка, йомырка эчендә ачкыч...

— Ул кем соң? Нишләп үзе сөйләшми?

— Артык оялчан ул, уңайсызлана.

— Менә кызык.
— Ул синең яшьлек юлдашың, син үзең эзли торган яшьлегең.
Бу сүзләрдән соң мин уңайсызланам... Алай дию ансат котылу — мин хәзер бөтенләй сүтелеп төштем, беттем, бер минутта юкка чыктым. Хәзер ул гына, телефон чыбыгының икенче башындагы тавыш кына бар:
— Мин сезгә шул кешене күрсәтергә вәгъдә бирәм. Сезгә калага күптән түгел хат язган кешене дә. Сез мине тыңлыйсызмы? Тыңлагыз, зинһар, сез... сез хатны алгансыздыр бит?
— Хатны? Әйе, алдым мин ул хатны.
— Мин сезгә әнә шул хатның авторын да күрсәтә алам. Дөресрәге, ул кеше сезне үзе күрергә тели. Сез кире какмагыз инде — алар өчен мин үтенеп сорыйм.
— Ничек табарга соң сезне? — дим мин кинәт, соңыннан үземне уйсыз ризалашканга тиргәр өчен.
— Безне табу бер дә кыен түгел, сезне монда озатып куярлар. Трубканы Халидәгә бирегезче.
— Халидәгә?
Халидә дигәне — хуҗабикәбез икән. Нидер сөйләшеп алгач та трубканы куеп:
— Сәгать кичке бишкә сезне чәйгә чакырдылар, — диде дә, — үзем алып керермен, — дип елмайды. — Ерак түгел ул.
Үзем рәтле сүз әйтмәсәм дә, шул рәвешле вәгъдә бирелгән, сүз куешылган булып чыкты, чигенергә (бәлки монысы кирәк тә булмагандыр) җай-әмәл инде юк. Вакыты житкәч тә киттек. Гостиницадан ике-өч кенә өй аша мәктәп күршесендәге бер өй капкасыннан уздык. Каршыбызга эт ырылдап чыкса да, җиңелчә генә куркыта алды — бәйле иде. «Хәзерге тормыш элеккечә түгел шул» дип, эт хакында уйны төгәлләгәнче үк, өйалдыннан гаҗәп тә якты елмаеп, ят ханым чыкты. Капкага таба килә-килешли:
— Ә-ә, әйдәгез, рәхим итегез! — дип һичбер тартынусыз елмайды, юан диярлек дәрәҗәдәге калын гәүдәле чибәр хатын. — Әнис булып торсын да ул, безне күрми дә китсен! Шулай була димени! — Әйтерсең без күптәнге танышлар!
Танышларча гына да түгел, хәтта дусларча ук кул сузды ул. Таныш? Тукта, ике-өч кенә көн элек мин аны Җиреклекүлдә идарә йорты алдында күрдем түгелме соң? Әйе, без анда сөйләшеп торганда, ул ике тапкыр узып киткән иде. Танышлыкның бөтен булганы шул гына һәм якынлык уйнарга тырышуы да Халидә дустың гаҗәпләнмәс өчен генә булырга тиеш. Нигә дигәндә, Халидә тиз арада саубуллашып киткәч тә Нәзилә бая телефонда сөйләшкәнчәрәк, тартынып сөйләшә башлады.
— Ирем әле килеп җитмәгән. Шуңа күрә өйгә чакырып тормыйм инде, гафу итәрсез. Без чыгыйк мәктәп ягына. Анда интернатның бик тыныч бүлмәсе бар — шунда кызлар белән чәй эчә торырбыз. Мин сезгә ул кызларны күрсәтәм, күрсәтми калмыйм.
Мәктәп ягына да уздык. Агач арасыннан бик тә кечкенә күренгән өй эчке яктан шактый ук иркен икән. Иркен һәм матур. Стеналар төрле рәсемнәр, кинофильмнардан киселгән кадрлар белән бизәлгән.
— Монда безнең укучы кызлар яши. Хәзер алар чөгендер җиреэшкәртүдә, җәйләүдә торалар. Безне беркем дә ашыктырмас, хуҗа булып урнашыгыз.
Ләкин, хикмәт, бу тыныч матур бүлмәдә без Нәзилә белән икәү генә идек.
— Ә кайда соң сез күрсәтәсе кешеләр?
— Килерләр, килерләр алар, чак кына сабыр итегез. Иркенләп сөйләшеп утырырбыз, чәй эчәрбез, вакыт җитәр дип уйлыйм.

Шулай сөйләнгәләп алды да кухня кебек җирдә кайнаша башлады Нәзилә. Мин стенадагы рәсемнәрне карый тордым. Барлык рәсемнәрнең, картиналарның темасы бер — яшьлек, мәхәббәт, аерылу, кавышу, югалту, җилкәләргә ямансу яктылык булып төшә торган хатирәләр һәм кухня кебек җирдән бу як өстәлгә ризыклар китерүче ярым таныш ханым Нәзилә. Хикмәт, нинди зур, аулак өйдә без һаман икәүдән-икәү. Киләсе кешеләр булганга күрә генә гаҗәпләнмисең, тартынмыйсың, көтәсең һәм, үзеңнән яшермичә әйткәндә, менә шушы сәер минутларның берсендә ишектән елмаеп... елмаеп... Әйе, ишектән һәм яшьлектән елмаеп ерак калган Фәһимә исемле кыз... я булмаса Лена атлы чибәр килеп керер дип көтәсең. Фәһимә? Лена? Ничек, нишләп килсен икән алар бу авылга? Юк, бераз ялгышам — ничек килгәннәр икән?! Нәзилә яшьлек дусларың диде бит. Алардан башка тагы нинди дусларым бар? Алардан якынрак? Шулай, Нәзилә вәгъдә бирде, ләкин бу — булмас хәл. Булмаслыгын үзең дә белеп торасың һәм белгән килеш көтәсең.

Шактый ук матур өстәл әзер иде инде. Хәтта эчемлекләр дә куелды. Фәһимә белән Лена кайсын эчәр икән? Юк, алар эчмәсләр, рыясызлык өчен генә чәкештерәп куярлар да елмаерлар... Фәһимә үзенең мәңге сагышлы елмаюы белән елмаер, ә Лена саф җиз тавышы белән челтердәр дә:

— Нәрсә, әллә сагыну оялырлык эшме? — дип сорар.

Ә Фәһимә берни дә әйтмәс.

Нишләптер, авылга кайтканның икенче көнендә үк төштә ул минем янга килде. Шунда мин аннан: «Безнең бергә була алуыбыз мөмкин икәнлеге инде ачыклангач, хәзер үкенмисеңме?» — дип сорагач, ул еларга җитешеп: «Сорашма, сорашма алай!» — дип ялварды.

Инде шунысы гаҗәп: менә хәзер шушы бүлмәдә алар, Лена белән Фәһимә, бер өстәл янында ничек утыра алырлар икән? Бу Нәзилә дигән яңа танышым аларга монда кем буласын әллә әйтмәдеме икән? Ачык кына итеп миңа да аңлатмады бит әнә. Ишекле-түрле йөренүен, өстәлгә һаман нидер китерүен белә.

Өстәл янына соңгы кабат килде дә тантаналы төстә мине шунда чакырды:

— Рәхим ит, Әнис. — Инде «син»гә дә күчеп алган! Кай арада?

— Ә тегеләр? — Фәһимә белән Лена исемен атаудан үземне көчкә тыеп калдым.

— Ә-ә, алар... Алар бераз гына соңга калырбыз диделәр. Үзегезнең дә сүзләрегез бардыр, серләшеп бетерегез, диделәр.

— Кызык, бик тә.

Өстәлдә — дүрт бокал, чынлап та, киләчәкләр, димәк.

— Я, Әнис, эчемлекне үз кулыңа ал инде — егет бул. Тыңлата алсаң, бәлки эчеп тә карарбыз.

Миннән егетлек көтелә? Рәхим ит — дүрт бокалның икесенә ак аракы, икесенә коры шәраб салам. Лена белән Фәһимәгә затлырак әйбер, ә безгә тупасрагы да ярар. Һәм, сәбәбен үзем дә тоймастан, тагын: «Нишләп соңладылар соң?» — дип уфтанып куям. Нәзилә — сабыр:

— Алар — монда.

— Монда?

— Алай ук каушама.

— Кайда соң, ник кермиләр?

— Менә шушы бокалны бетергәнче эчкәч, күрсәтәм.

Хуҗабикә сыйлый белә! Мондый да шәп тостны беренче кабат ишетүемдер. Ялган һәм искиткеч тылсымлы ялган! Мин аны шушы бокалдагы эчемлек сыман күреп кабул итәм. Бу көннәрдә кунак булу инде авыр эшкә әйләнсә дә, баш тартыр җай юк. Нәзилә үзе дә (кыю-

лык өчен бугай) бетереп эчте. Хатыннардан калышу ирләргә оят. Булды, киттек. Аннары бераз ризык капкалагач, инде Нәзиләгә сынагандай, тикшергәндәй итеп карагандмындыр, ахрысы. Мин аның алланып киткән йөзенә һәм шактый ук калын гәүдәсенә карыйм. Шактый ук юан диясе дә килә. Шул вакыт, уйларымны каян сизгән диген, Нәзилә мине:

— Унсигез яшьтә чакта... хәтерлисендер, мин бит энә йоткан эт кебек зифа идем, — дип шаккатырды.

— Сез хәзер дә зифа, — дим ирләрчә алдашып.

— Элекке чакны оныткач ни... Ярый инде.

— Минем сез әйткән кунакларны күрәсем килә.

— Шулаймы, кара син.

— Кая?

— Минем йөземә.

Гажәпләнүнең, йөдәүнең чамасыннан ашып, аның шактый ук таза йөзенә карыйм. Фәһимәнекенә һич тә охшамаган, тик эз генә, бик тә эз генә Лена аклыгын хәтерләткән чырай, калын гына, тулы айдай чырай, кечкенәрәк соры күз, ныклап карагач күренмичә калмаслык дәрәҗәдә генә җыерчыклана башлаган маңгай, маңгайда игътибар белән караганда шактый ачык күренгән җөй... Юк, монда Фәһимә дә, Лена да юк — алар бу кыяфәткә керә алмыйлар. Бу — икенче төрле чибәр. Шулай да өмет өзелеп үк бетмәгәнгә, шаяртуны кабул итәм:

— Бу нинди җөйләр?

Нәзилә тиз генә маңгаен каплады:

— Ә-ә, безнең машинабыз бар бит.

— Соң?

— Ирем... салганрак баш белән баганаларга барып менгән саен минем бер-бер төштә җәрәхәт кала, аннан кире шушындый җөйгә әйләнә.

— Кызык. Кунаклар килмәде.

— Әллә син мине чынлап та танымыйсың инде?

— Син миңа хат авторын күрсәтергә дә вәгъдә иттең.

— Анысын да күреп торасың.

— Күрмим.

— Ул кеше — мин.

Рәхим ит, Әнис туган, беренче хат авторы күз алдында. Ләкин һаман ышанасы килмичә сорыйм:

— Ә мине сагынучым кем? Яшьлегем, мәхәббәтем кем?

— Анысын да күрәсең.

— Анысы да син түгелдер ич?

— Нишләп мин булмаска тиеш ди?

— Син?

— Мин!

Алдануыма тәмам инанып, урынымнан сикереп үк тордым. Ни әйтсәм дә усал сүз әйтеләчәк иде. Мин инде аны тирги-тирги чыгып та китәсе идем. Ләкин бер минутта Нәзилә минем кулдан эләктереп алды:

— Шул чаклы ук оныттыңмы? Шул чаклы!

— Кемне оныттым, нәрсәне? Мин бит сезне беренче мәртәбә күрәм — үз гомеремдә беренче мәртәбә!

— Ялгышасың! Хәтереңә төшер. Нинди хәтер ул мәхәббәтен дә онытырлык. Үзең бит мине эзлисең!

Бусы инде шантажны ук хәтерләтә иде. Ләкин бер нәрсә — аның миннән ни көтүе генә билгесез. Ни кирәк аңа миннән? Миннән нинди файда көтәргә мөмкин?

— Син мине озата барган идең.

— Озата? Кая, кайдан?

— Этилегә. Районда эшләсәм дә, мин өйгә еш кайта идем.

«Мине үз гомеремдә бер генә кызны озаткан дип уйлый микәнни ул? Озаткан бер кеше күңелдә калырга, онытылмаска тиеш булды микән?»

— Бер кайтуымда сез безнең авылга килгән идегез. Спектакль күрсәттегез, концерт куйдыгыз. Без шул кичтә таныштык. Сез сәхнәдә уйнаган кыяфәт-киемегез белән урамда да йөрдегез — герой егетне уйнаган идегез.

Тагын «сез!» Димәк, мин аңа шул кыяфәт белән ошаганмын да, ул мине герой буларак кабул иткән. Ихтирам да шул онытылган геройга! Һәм акрын-акрын хәтер кирегә әйләнә, әйләнә-әйләнә дә, шунда нәфис кенә, нечкә генә (энә йоткан эт шикелле зифа!) кызны китереп чыгара. Тездән өстәрәк булган, бераз оялчан юка ситса күлмәк вак-вак болын чәчәкләре белән бизәлгән. Чынлап та, шул кичтә матур күренүе үзенә икенче тапкыр да чакырып ымсындырган һәм яңа бәхетләр өмете кузгатып бөтерелгән иде ул чибәр кыз. Шул кичтә без аның белән мәхәббәттә дә аңлаштык микән? Булгандыр, анысы да булгандыр — сәхнәдәге кызыктыргыч ят тормышның кичке күрешүләрдә дәвам итүе мөмкин булгандыр ул чакта.

Менә нәрсә генә гаҗәбрәк: ничәдер көннән соң без аның белән район үзәге урамында тагын очраштык та, сүз дә куешмыйча ук, мин аны, чынлап та, туган авылына хәтле озата килдем бугай. Әйе, килдем, килдем. Ләкин инде герой егет түгел, үз кыяфәтемдә идем: шактый таушалган туры чалбар һәм күк гимнастерка. Ул елларда мондый кием ят түгел, әмма инде тылсымын җуя язган, һәрхәлдә, шәп костюмны алыштыра торган түгел иде. Геройга гашыйк кыз йөрәгенең кинәт үзен алдангандай тоюын, нинди хисләр яралып өлгерүен, мин аның бер күз сирпүеннән, боегып калуыннан, әлбәттә, шунда ук сиздем. Хәтта яшерергә теләсә дә. Бәлки ул яшерергә дә тырышмагандыр әле. Шунысы хак, мин аның үземә талпынуын тоймау гына түгел, читкә тартылуын ук аңлап атладым. Шушы ук омтылыш-тартылышлар хәтта кочаклашкан, хәтта үбешкән чакта да аермачык булып күңелгә шом сыман бер авырлык салды һәм яңадан очрашу хакында сүз куешу уе башка ук килмәсә дә, бер атна чамасы вакыттан соң эшләгән җиренә шалтыраткан идем. Нәзилә каядыр чыкты, диделәр. Безне очраштырган спектакльдә минем көндәшемне уйнаган дус малайга шушы сәер хәлне сөйләгән идем, ул: «Сәю сиңа не картошка, не выбросишь из окошка... тагын, тагын шалтырат», — дигәч, шалтыратсам да үзгәреш килеп чыкмады. Нәзилә тагын каядыр киткән... Сизә, сизә минем яшь һәм горур йөрәгем: Нәзилә гөнаһ кылган мәче шикелле күзен ялтыратып янда гына утыра, шунда гына. Сиземләү мине бик сирәк алдый ул.

— Мин шалтыратканда, син, чынлап та, шунда утыра идең бит? — дип сорыйм, чирек гасырны сикереп чыгып.

— Шулай шул, — дип елмая юан диярлек үк тулы ханым, җөйле маңгаен җыера төшеп.

Ә күзләре һаман ялтырый...

— Син бик дөрес эшләгәнсең, молодец! — дим чын күңелдән.

— Нишләп?

— Мине яратмыйча.

— Менә хәзер үзем эзләп таптым.

— Мәңгелек диалектика: без яратканда, безне яратмыйлар, без яратмый башласак, ярата башлыйлар.

— Алай ук түгелдер лә. Синдә чак кына ерткычлык җитмәде — шул гына.

— Ә синең өчен ерткычлар герой... ихтимал, синең өчен генә дә түгелдер. Сезнең өчен безнең кебекләр — җебегәннәр. Шәхси машинабызда йөртеп, маңгайларыгызда җөй дә калдыра алмыйбыз...

— Алай да түгелдер лә ул...

Фикерен төгәлләргә сүз таба алмагандай, Нәзилә эчемлегә ике билгесез затка аталган ике бокалның берсен минем алга куеп, икенчесен үзе тотты:

— Кемнең онытуына, кемнең онытмавына караганда, кемнең ярата белүен, кемнең белмәвен әйтү дә кыен әле. Андый озатуларның мәңнән бере генә миңа багышлангандыр ул. Хәтерегезгә төшердегез бит, шунысы өчен дә рәхмәт. Ни булса шул. Бөтен тилелеге белән кабул итик тә, җайсыз елларда да матур булып калган тойгылар өчен эчик. Булдымы?

— Булды.

Инде саубуллашырга вакыт җиткәнен тоям, тик бер нәрсәне ачыклый алмыйм, менә шушы сүзләрне генә сөйләшү өчен чакырмагандыр бит ул. Көчкә генә сакланырлык бәләкәй хатирә хакына да түгелдер. Нидер бардыр һәм мин бераз гына сабыр итәргә тиештер. Ә-ә, хат бит әле. Шул хакта сөйләшәсе бар лабаса!

Шул хакта сүз котеп, инде моңая башлавым сизелгәндер, бәлки, төп йомышын әйтергә кыенсынгангадыр, ул гайре табигый рәвештә кунагының кәефен күтәрергә чамалап, елмая, көлә, шаяра башлады. Ә чынлап кәефләнү өчен егерме биш елны онытырга кирәк иде. Ләкин ничек? Минем күз алдымда чәчкәле ак күлмәк кигән зифа кыз тора — энә йоткан эттәй зифа! Ләкин шул чибәрне этә-төртә, шактый ук калын (чак юан дип ычкындырмадым тагы!), әйе, бераз калыная төшкән ханым алыштырмакчы. Юк шул, бу көлү, бу шаярулар — кызганыч кына, бары тик шул гына. Без инде әүвәлге гөнаһсыз елмаюларны кабатлый алмыйбыз, гәрчә чынбарлыкта кабатлау гына түгел, хәтта арттырып, уздырып җибәрү мөмкинлеге булса да. Сикереп чык ярты гасырны да... Һоп!

Дөресен әйткәндә, яшь чакта да сикерүләр белән бик аерылып тормыйдыр идек инде. Хәзер бигрәк тә. Бу калын битлекне йолкып ату мөмкинлеге, чәчкәле ак күлмәкле, тал чыбыгыдай зифа кызны аннан әрчеп, ярып чыгару, коткару мөмкинлеге нык диярлек үк сизелми шул инде. Шактый калын май катламы эчендә мәңге чыкмас өчен ябылып, томаланып калган ул кыз...

Мин торып баскач та ханым бөтенесен тиз үк аңлап, ике кулы белән талантлы артистларча күзләрен каплады — баягы шаярулардан оялуы булырга тиеш иде монысы.

— Ничә елдан соң... Ярый, күңелле булды, онытмаганың өчен рәхмәт, — дим булдыра алганча итәгать сиздерергә тырышып.

— Зинһар!.. — Нәзиләнең кул ишарәләре мине кузгалмаска өнди иде.

Баскан килеш катып калдым.

Озакламый ул да торды. Коры күзләрен һәм бераз тирле битләрен сыйпаштыргач, тәрәлеп үк дигәндәй текәлеп калды. Бөтен чырае-кяяфәтендә: «Әллә синең җаның юкмы?» — дигән үкенечле сорау аның керфекләре төсле үк җитез бии иде... Тагын бер тапкыр кызгану хисе белән инде интектермәскә тиеш таптым:

— Мин сезнең калага язган хатыгызны алдым.

— Рәхмәт.

— Ни өчен?

— Ә-ә, мин болай... ялгыш кына.

Елмаюы ничектер кинәт Ленаны хәтерләткәнгә, мин аңа, чынлап та, ярдәм итәргә тырышырмын кебек:

— Сез коткарып калырга дигән кеше кем?

Нәзилә, сорау таш булып бәрелгәндәй, читкә тайпылды да минем җавап көтүемне күреп, кырыс кыяфәткә керде.
— Ул кеше — минем ирем...
— Исеме?
— Исеме... Исеме... — Әйтерсең иренең исемен әйтергә ояла. — Сез аның исемен белмисезмени?
— Каян белим?
— Ул болай исемле кеше... Госман, Фәсихов.
— Фәсихов? Шул... — Чак-чак «кляузник» дип ычкындырмадым.— Син шул кешене яклыйсыңмы?
— Ә сезнеңчә, нишләргә тиешмен? Бергә яшәгәч, аның намусы — минеке...
— Мин нишли алам? Минем кулда бит бернинди власть юк.
— Язып чыксагыз... шул җитә дә торыр иде. — Шактый ук кәефсезләнүем чырайга чыккандыр, күрәсең, ул каушап, кайнарлана ук башлады. — Яшьлек хөрмәтенә, яшьлекнең тиле сафлыгы хакына. Хәзер аның кеше күзенә күренерлеге калмады... аңлап кына бетерми. Аннан бигрәк — миңа... исәнләшергә дә теләмиләр, бөтен дөньяда бер ялгызым. Беребезгә беребез иптәш тә була алмыйбыз. Мин ул авылдан киттем үк — биредә яшим. Ә ул минем ник киткәнемне белмичә йөди, тиргәшә.
— Аңа нәрсә кирәк соң? Ул нәрсәгә ирешмәкче була?
— Белми, үзе дә белми ни кирәген. Тегендә сугыла, монда... Максаты түгел, яшәү рәвеше шул аның. Үзенең кеше икәнен шул рәвешле раслый ул.
— Шундый рәвеш... Син үзең сайлаган ерткыч...
— Әнис!
— Гафу ит.
— Ә син ярдәм итә алыр идең.
— Аны үзгәртү мөмкин түгелдер инде, бер фельетон гына ярдәм итмәс.
— Ә син мактап яз, гаделлек өчен көрәшүче кеше намусын якла...
Әйе, бу сүзләрне чын ихласлык белән әйтте ул: сөекле ерткычын җил-яңгыр тидермичә саклар иде. Үтенече — изгелек, яшьлек хакына... Шулай да мин вәгъдә бирә алмадым. Яшьлегемнең онытылган бер хатирәсе хакына түгел, хәтта... хәтта, әйтик, Лена, хәтта Фәһимә үзе сораса да килешә алмаган булыр идем. Хәер, Фәһимә уена мондый йомыш бөтенләй кермәс, хәтта минем аркылы килгән сабаклардан соң Лена да, мөгаен, мине болай җайсыз хәлгә куймас иде. Ә Нәзилә?
Бер минутта башымда ватык пыялалар челтердәп коелды, бер минутта: теге чакта да, Фәсиховны яклаган мәкалә авторы белән дә шушындый мәҗлес булмаган идеме? дигән сорау миемне көйдереп узды. Зөлхиҗә булып аның баласын алып китәргә гостиницага килеп җиткән тавыш та Нәзиләнеке булмаганмы?
Әйе, ул тавышны мин дә ишеттем бит, хәзерге шушы тавышка охшаган, шактый ук охшаган иде ул...
Тфу, шайтан, фаразлар белән генә кешене болай тиргәү акыллы эшме соң? Шикләнүемнең сәбәбе бер генә — Нәзиләгә минем хәтерем калды. Шуңа күрә бераз катырак та бәрелә яздым:
— Синең ирең — Җирекледә генә. Мотоциклы, машинасы бар. Хәзер дөбердәп килеп керсә?
Сорау җавапсыз кала. Җавапсызлык минем шикне арттыра гына, шуның аркасында саксызлык күрсәтеп:
— Һәм ул бу очрашуны белә! — дим.
Ләкин Нәзилә тупаслыгымнан пыр тузып ачулана, үпкәли, тирги башлар дип көтүем акланмый. Нәзилә тыныч:
— Белми.

Хушлашканда да, шул тынычлыгын саклап, мине ишеккә кадәр озата килде һәм чыгышлый:

— Урамга мәктәп ягыннан узыгыз, кеше күрмәсен, — дип кисәтте.

Күрмәс! Авылны белмимме әллә мин. Мең кеше күрәчәк һәм мене мең төрле гайбәт сөйләячәк. Үз күзләре белән күрмәгәннәре тагын да күбрәк беләчәк һәм... алар бик тә хаклы булачаклар. Ике җенес кешесе бер тын өйдә сәгатьләр буе утырсын да... Юк, булмый ул алай, булмый, бөтенләй гайре табигый эш аның монысы!

Үземне шактый ук пычранган хәлдә тойдым. Мондый алама кичереш өчен рәхмәт әйтү кыен — хәтта дөньядагы иң изге нәрсә, яшьлек хатирәләре исеменнән эшләнсә дә!

Ләкин моның өчен мин аны кичерә алыр идем, моның өчен генә минем аңа хәтер калмаган булыр иде.

*
* *

*2 июнь, 1977.*

Рәттән генә диярлек, ике ояда ике каз йомырка өстендә ай буе утырдылар. Бер ояда бәбкәләр ике-өч көн иртәрәк чыкты да: «Пип, пип, пип, пип», — пипылдарга да керештеләр. Түземлек, җитдилек өчен бүләк булып килгән балаларын ияртеп йөргән шушы каз бәхетенә, бәбкәләр матурлыгына кызыгып һәм артык сокланып, оядагы икенче каз сикереп төште дә, аналарның ике була алмавын уйлый белмәгәнгә күрә, шулар тирәсендә мавыгып йөри торгач, озак вакыт әрәм итте һәм чыгарга инде бер-ике көн генә калган үз йомыркалары суынып өлгергәнлектән, алар томаланды — бәбкәләре чыкмый калды. Гәрчә соңра бик зур түзем белән утырырга тырышса да, йомырка кабыгын яшь борыннар чукымыймы дип күпме генә тыңласа, ишетергә теләсә дә, кабык эче үлем шикелле тын иде. Ашыкты, күпмегә калгач, җиңелде, югалтты — бөтен җәен, бәхетен югалтты! Көннәр шушы рәхимсез хакыйкатьне бәхәсләшә алмаслык итеп аңлаткач, каз беренче ояда чыккан бибиләр төркеменә кушылмакчы булып, шул тирәдә күпме яхшатланса да, болары аны икенче ана сыйфатында кабул итмәделәр. «Ана — берәү җитә! Пип-пи-пи-пи!»

Ялгыз каз, оя-оя бәхетле казларга кызыгып, һаман каңгыра. Ә якын килсә, аталы-аналы пар казлар гына түгел, инде балалары ысылдап каршылый һәм шулай ук озаталар да. «Җиндек, җиндек!» дигәндәй, бер-берсеннән сөенче алалар.

Урамда казлар...

Ник алар күңелгә шушылай рөхсәтсез килеп керделәр соң?

Минем көндәлекләремә, хатирәләремә сезнең бәйләнешегез юк бит, көш, көш!

## Сабан туе

*4 июнь, 1977.*

Бәйрәмнәр, тантаналар ае булган майның барлык шатлыкларын корбан итеп, шуларның барысын икеләтә-өчләтә тапкырлап, зур өметләр туплап, игенче сабан туена килә. Бүген шул туй — тыелгысыз дәрт һәм теләкләрнең киңлекләргә ургылган чагы. Базы буендагы үзәндә, таулар үзләре стадион трибуналарына охшап торган биеклекләрдә чуар диңгез, халык диңгезе. Уртада — эстрада. Шуңа әүвәл район һәм иң алдынгы колхоз җитәкчеләре чыгып басты. Шунда —

Жантурин, күкрәге тулы орденнар, медальләр — полководец... туры мәгънәсендә шулай, чагыштыру гына дип уйламагыз. Рамазанов күкрәгендәге таныш йолдыз яктылыгын арттыра гына шикелле башкалар күкрәгендәге очкынлы-очкынлы тәңкәләр.

Сабан туйны ачкан чакта, Рамазанов район кешеләренең бәйрәмгә нинди бүләкләр, уңышлар алып килүләрен санап чыкты, эш батырларына, кайбер колхоз җитәкчеләренә сүз бирде. Шуларның берсе — Жантурин.

Композитор Бәхти Гайсин алып килгән концерт бригадасы һәм районның бөтенсоюз смотры лауреаты булган җыр һәм бию ансамбле чыгыш ясаганда, җилкәләрдә барлыкка килгән канатлар, аннары барлык сабан туй куанычлары: көрәш, йөгереш һәм... сабыр итик. Әнә, үз күзләрең белән кара: татарча көрәш аренасында иң зур бүләк булган телевизорны дистәләрчә кеше ияртккән, Мини дигән Әхмәт күтәреп чыгып китте. Вәҗиһәсе дә шул тирәдә бөтерелә...

Ләкин күзләрне бүтән тамаша икенче якка карата: аренада ат чабышы! Ике тәгәрмәчле арбалар, атлар... Тавышлар: «Безнең авылныкы! Безнең «Гигант!», «Бөркет!», «Акканат!» һәм башкалар... Бүләкләр, сөенечләр. Һәм... арбасыз атлар чабышы — малайлар!

Болары — бөтенләй бүтән исәп. Бу вакытта кайдадыр син үзең очасың, малайларның берсе — син. Тик шунысын гына ачыклыйсы кала — кайсы ул син? Кайсы? Егермедән артык ат, егермедән ким булмаган малай... Табып кара! Ләкин бик тә җиңел эш икән бу. Әнә — теге бүз аргамакта син бит, син!

Колакка каяндыр кыңгырау тавышлары ишетелә башлый. Үзен тагын да зурая, әрәмәләр, вакытлар, урманнар исәбенә киңәя һәм ул синең авылыңны, синең бала чагыңны, синең язмышыңны, танышларың, туганнарың язмышын да сыйдыра. Басулар буйлап ат көтүләре чаба башлый. Атлар, атлар, атлар! Алар безнең авылда бигрәк тә күп иде шул. Һәм бу үзе бәхет, һәм бу үзе фаҗига иде. Фаҗига? Әйе, мәңге онытылмый торган фаҗига.

Ул чакларда атларны ниндидер корткычлар агулаган дип сөйлиләр иде. Тәгаен генә ничек булгандыр, тик шунысы хак: безнең авылга бик күп чирле атлар китерделәр. Күзләренә салынга торган дару исеме белән аларны «Малинновый атлар» дип йөртәләр иде. Ә безнең телдә — малиновый атлар. Карап торсаң, шау таза атлар — каян сайлап китергәннәр диген, озын торыклы, жираф шикелле биек, шәп атлар. Минә без җилдерә идек тә аларда! Базыда су коендыра идек, атланып йөзә, йөздерә дә идек. Мин аларны нигәдер аеруча бер ашкыну белән яраттым.

Кыңгыраулар чыңлатып урманда, кырда йөрүләрен кичләр, төннәр буе тыңлап ятам. Безнең өйдән саз аркылы гына торган абзарларына көн саен йөз керәм, улаклардагы башакны, печәнне кетеркетер ашауларын көннәр буе тыңлыйм. Моның өчен миңа бүләк тә тия: конюх дигән абзый аларны җыеп абзарга кайтарганда, яки төнгелеккә урманга чыгарганда, иң яхшы атны, ак аргамакны миңа тоттыра һәм атландырып та җибәрә. Ә син... билгеле инде — канатсыз очасың. Чынлап уйласаң, канатлар да бар, әлбәттә.

Бер көнне эштән соң төшлеккә кайталар болар — урам тутырып, тузан кубарып. Мин үзебезнең өй янында. Җаным тагын урыныннан куба да мин атлар көтүенә каршы чабам. Чабам да бөтен көчемә ажгырган атлар көтүенә барып та чумам, чумам да үземнең иң яраткан бүз аргамагымның муенына асылынам да... бүтән нәрсә хәтерләмим.

Кичкә таба уянсам, өйдә бер үзем генә ятам икән. Кулларымны, битләремне карыйм — кан... Торып утырам, авырту сизелми, аякка басам — бар җирем төзек. Биттән генә кан һаман саркый. Күзгедән

карыйм — бармак сыерлык җәрәхәт. Бит — тишек. Бармакны ни өчендер яра эченә тыгып карыйм, тамчы да авыртмый! Урамга чыгып, малайларга да күрсәтәм шулай итеп, алар исә йөзләрен генә җыералар да бер сүз әйтмиләр.

Ике-өч көн авырган сыман йөргәч, бөтенләй ук савыктым. Бипә генә җөй калды гомерлек хатирә булып. Ышанмасагыз, үзегез карагыз, бу — сөекле ат хатирәсе булыр. Муенына юләрдәй ташланган өчен бер теш эзен генә калдырып киткән — таптамаган, измәгән, мәхәббәт бәясен генә түләткән!

Менә шундый атлар — акыллы атлар. Утарга җыеп, еш кына күзләренә бая әйткән даруны салалар — югыйсә, котыралар, имеш. Елына бер тапкыр арт аякларындагы номерларны утлы тимер кыздырып басып яңарталар — көек исләре хәтердә... Минем биттә ядкаре калган атның номеры — 213 иде. Менә шулай еллар буе үз матурлыклары — шәплекләре белән безнең гомерләрне бизәп киттеләр алар. Ә шул ук вакытта үзләренең, докторлар кисәткәнчә, котырып үләр вакытлары җитте. Икенче Елан тавы дип аталган җирдә күп итеп кабер казыдылар да... безнең сөекле атларыбызны шунда алып киттеләр. Карыйсыбыз килсә дә, без анда озак тора алмадык... Сәгатьләр буе ат кешнәвен, дөпелдәп ат егылуын, шак-шок сугулар гына үзебез кыйналганнан мең мәртәбә артык булып тәнне дә, җанны да сулкылдатып тордылар һәм хәзер дә шул авырту сүрелми. Буып, егып, кыйнап үтерделәр мескеннәрне. Ләкин берсе... качып котыла алган! Берсе муенына дилбегә уралгач та кешеләрне өстерәп барган да һәм, өстерәлгән кеше ычкынып калгач, ары чапкан. Базы аша узып, аръякка, безнең авылдан гел зәңгәр булып күренә торган хыяллы якка чапкан ул! Нинди ат! Ике йөз дә унөч номерлы бүз аргамак!

Аңа шул зәңгәр дөньяларда мәңге-мәңге чабып йөрисе дә бит, тик кешене генә түгел, атны да сагыну харап итә икән. Буп-буш калган абзарга кайткан бу — берүзе шунда шым гына тора...

Бу хәбәр авылга тиз таралса да, аны фаш итүче, икенче кабат муенына дилбегә салучы тиз табылмады, ләкин бер атна чамасы вакыттан соң андый кеше килеп чыкты бит. Каян? Минем хыялларым яшәп яткан, аргамагым качып йөргән шул ук зәңгәр дөньядан!

Гыйбадулла абзый бу — әле күптән түгел генә урман каравылчысы булып кергән, тик явызлыгы белән инде күптән атаклы булган адәм. Бөтен тирә-як белә: явызлыгы чит-ятларга гына түгел, үз балаларына да мирас итеп бирелгән, бигрәк тә улы Сәлимгәрәйнең күнелендә, тәнендә, бөтен кыяфәтендә калган. Ачыграк әйтсәк, болай. Гыйбадулланың матча ярыгында һәр вакыт пеше таллар тезелеп торыр. Балалар чак кына ярамаганны кылса, талларга — эш, чаж, чож. Сәлимгәрәй бер мәлне шкафтан ипи алганда ялгыш савыт-сабаны коеп төшергән икән дә, сөекле әтисе янда гына булганлыктан, имеш, тиз арада чыгып чапмакчы. Әмма бик ашыкма, ата кешенең куллары талны кайчан йолкырга икәнен шәп белә ул. Йолкып та ала талларның берсен, улына сәке читенә сузылып ятарга боерык та бирә. Сәлимгәрәй әүвәлге тәҗрибәләрен онытмаганлыктан, һаман чыгу юлын эзли, анда чаба, монда йөгерә. Ә әтисе өй бетереп куа. Өй бетереп шулай чабыша торгач, малай лакан янындагы чиләк өстенә егылып төшә һәм кычкырып та җибәрә. Тал чыбыгы бәлки андый ук яман эз калдырмаган булыр иде, ә тимер чиләкнең очлы коласы Сәлимгәрәй дигән малайның котын гомерлеккә ала шул — борын сөяге сынып, төзәлгәч тә эчкә баткан килеш кала. Кыйналып үсүе аркасында, буе да метр да илле сантиметрда тукталган аның. Кыска буйлы, редис борынлы, кечерәк күзле булганга, Сәлимгәрәй дөньяга «Самурай» дигән кушамат белән чыгып китә. Ата кеше үзе

исә җир селкетеп, халык куркытып, шуннан олы тәм табып яши бирә.

Менә шул кеше.

Кулбашында — мылтыгы. Бүз аргамакны йөгәнләп алды, менеп атланды да, урам буйлата чатыр-чотыр чабып та китте. Нияте ни — шайтан белсен. Хәер, тиз беленде моның барлык уй-гамәле — соңгы тапкыр бөтен көченә куган бу атны, тизлек рәхәтен канатлар итеп, туйганчы бер очып калган. Ә аннары әйләнеп килде бу безнең янга, буш абзар янына. Менә шунда без күрдек мәңге кабатланмас бердәнбер хәлне!

Абзарны узып, Елан тауларына таба чыкмакчы иде Гыйбадулла абзый, ләкин шунда бүз ат карышырга, киреләнергә, бер урында таптанырга, бөтерелергә кереште. Ул да аңлады, без дә төшендек — теге көнге фаҗига урынына барасы килми атның һәм сизенә бичара, Гыйбадулла ерткычның шунда үзен мәңгелеккә иптәшләре белән теге дөньяда кавыштырачагын тоя. Без дә тоябыз. Ат бер төбәктән узмый, Гыйбад тезгенне нихәтле каты тотса, борырга азапланса да, биреш-ми. Шулай азаплана торгач, җайдак яман да каты ярсыну белән тезгенне тарткан иде, аргамак ике аякка төп-төз басып, кешни-кешни биергә тотынды. Сикерә мескенең, ыргый һәм менә максатына да иреште ул: ат өстендә аркылы торып озак түзә алмыйча, салынкы йомшак капчыктай җиргә лапылдап төште аның палачы! Төште һәм сикереп тә торды, торды да мәгънәсез акыра-акыра мылтыгын эләктереп күз ачып өлгермәс бер мәлдә... атып та җибәрде. Аргамак баягыдан катырак кешнип, юк, кешнәми, ярсыннан чыдый алмыйча ыңгыраша, ярдәм, шәфкать көтә. Ләкин кая ул шәфкать! Менә ул: Гыйбад үзе! Хәлдән таеп башын җиргә терткән атның янына ук килде дә аның нәкъ колак төбенә тагын бер патронын бушатты...

Ат берничә көн буе шунда ак жирафка охшап ятса да, аннары аны авыл абзыйлары берничә ат белән өстерәтеп, Елан тавына илтеп күмсәләр дә, мин аның үлгәнлегенә барыбер ышана алмадым. Шушы хәтле дә матур, гөнаһсыз җан иясен үтерә алырлык кеше юк сыман иде.

Күпмедер вакыттан соң, иске-москы җыючы карт соравы буенча, без ул атларның сөякләрен авылга күтәреп кайтып, аларны чарылдап торган сыбызгыларга алыштырдык... Кыңгыраулар чыңын ачы сыбызгылар алыштырды. Ләкин, шулай булса да, мин бүз аргамакның исән түгеллегенә күңелне барыбер күндерә алмадым. Ул исән, тик инде үзен тотмаслар дип ышанмыйча, инде кайтмый гына, елганың теге ягында, зәңгәр илдә чабып йөри-йөри дә, әнә тегендә, Буранлы дигән авыл эргәсендә, офык белән күк очрашкан җирдә басып, тын кала. Өянкеләр укмашуыннан хасил булган сурәт кенә түгел бу — ә тере ат, бүз аргамак!

Мин аны гомер буе шул кыяфәттә күз алдына китердем.

Инде менә бүген, шушы сабан туйда атлар... малайлар... чабыштылар, кемнәрдер нидер кычкырды, акырыштылар, кайсы ат җиңгәнен тәгаен итеп тә әйттеләр. Ләкин мин аларны ишетмим, мин беләм: җиңгән ат — бүз аргамак!

Шулай булмаса, кичә туган бәби дә, иртәгә үләсе бабай да юкка гына килгәнмени бу сабан туена! Һәм мин юкка гына йөрдеммени әле Базы аръягындагы авылларда? Шул аргамакны да эзләп түгелмени?

Картаеп түшәккә егылган хәлдә булса да, аргамакка мылтык күтәргән Гыйбадулла картны, теләгем зур булса, мин инде берничә кабат күрә алган булыр идем. Ләкин үземне мәҗбүр итә алмыйча йөрдем. Менә хәзер исә, күрми калмагаем дип, курка куйдым шикелле... Һәм мин аны күрәчәкмен — бик тиздән.

Җантурин белән сөйләшеп, Чуаркүл аша кайтырга инде җыенып беткәч, машина ишеген ачарга торганда, Ильяс янына миңа таныш булмаган бер кеше килде. Алар кырыс кына бер-ике сүз алмашкач та, Җантурин миңа борылды:

— Үзең чакырсаң, әйбәтрәк булыр, — диде дә әлеге кешегә мине күрсәтте, — вакыт таба алса... барырбыз да. — Һәм аннары миңа ул кешене тәкъдим итте. — Бу — Сәлимгәрәй, безнең элекке баш бухгалтер. Хәзер үз авылларында Чуаркүлдә тора, шунда безне кунакка чакыра.

Җантуринның үзебез барасы килгән җиргә үзебезне кунакка чакыруларына ирешкәнлеген (сүз тыңлап, изгелек кылу шәбрәк бит!) мин тиз чамаладым да, Сәлимгәрәй хакында белгәннәрем, ишеткәннәремне һәм үзенә булган карашымны сиздермичә, ачык кына күрешергә тырыштым. Хәзер аның кем икәнен белмәгән булсам, әлбәттә, таный да алмаган булыр идем. Сәлимгәрәйнең күзләре генә элекке үткенлекне саклаган иде. Ә ят мыеклар өстеннән оялыбрак караган бәләкәй һәм билле борын инде юк — төп-төз, тәкәбберрәк борын алыштырган аны. Шулай да тавышын, хәрәкәтләрен таныдым. Һәм әтисен күрмәгән хәлдә дә аның үзе белән кайбер нәрсәләрне ачыкларга, кайбер нәрсәләргә мөнәсәбәтле фикерен аның үзеннән ишетергә дә кирәк булганлыгын, вөҗданны тынычландыру өчен хәтта зарур икәнлеген шул минутта ук төшендем. Ә болай үзе чакырып торгач, бигрәк тә җайлы килеп чыкты. Җантурин шактый хәйләкәр!..

Шул рәвешле, гөрләп торган сабан туйны калдырып киттек. Сәлимгәрәй үз машинасы белән алдан, без Җантурин белән — аның артыннан.

Үзем үк оештырган дигәндәй хәлне аңлый алмыйча юл буе йөдәдем: Сәлимгәрәйне мәңге күрми дә түзә алырлык Җантурин һәм Гыйбадулла Байсламовны дошман дәрәҗәсендә күрәлмаган мин... аларга кунакка барабыз. Кире уйларга вакыт юк, бәлки әле нәфрәт тә инде кискен үк түгелдер. Өстәвенә, без килеп тә җиттек. Башкалардан артык аерылмый торган йөзләрчә өйләрнең берсенә тукталдык. Күтәрмәгә үк чыгып, безне нииндидер эби, бик тиз билгеле булганча, Сәлимгәрәйнең әнисе, каршылады. Ихатада һава сулап, бераз җилләнеп алгач һәм кулларны югалагач, өйгә уздык. Түрдә — безнеме, түгелме — шаулап самавар көтә һәм без аңа каршы да түгелбез — мәйдан карап өсте ябулы трибунада гына утырырга карамастан, эссе көн барыбер хәлне алган һәм үтереп эчәсе килә. Сүзгә дә әйләнгән теләкләребезне аяк астына ташламыйча, Сәлимгәрәй үз кулы белән ясаган чәйне матур гына берәр чынаяк чөмергәч, телевизор астындагы комодтан ярты литр коньяк белән ярты литр ак килеп чыкты. Хуҗа коньяктан башлады һәм без дә, кунакка тиешле тыйнаклыкны саклап, шуны сайладык һәм бераз ирнәп куйдык.

Сәлимгәрәйнең бала чак кыяфәтен хәтергә китерәм. Ул чакта аның төсе, чырае икенче иде. Хәер, монысын инде без беләбез.

— Әй, Самурай, Хәсән күленә дип килдеңме? Әй, адашкансың бит, Самурай, үз илеңә кит давай!

Егет булып җиткәндә, хәл кыенлашты: гәүдәсе кечкенәрәк хатын-кыз буеннан биегрәк калыкмагач, кушаматына килешсез аергыч өстәлде, күп чакта, бигрәк тә үзе юкта, аны Бүтәкә Самурай дип тә атый башладылар. Ишетми дисәң дә ишетеп кала инде ул моны. Кайчакта күрмәгәнгә са̂лышып, юри кычкыралар. Аның белән дуслыктан күпләр кимсенә. Берәр кызга үчләштеләрме, «Кара, сине Самурай белән йөри диләр, дөресме шул?» дип сорыйлар, теңкәсен корытып үртиләр, котырталар.

Сәлимгәрәй — егет кеше, аның да адәм рәтендә уйныйсы, көләсе, сөясе, сөеләсе килгәндер. Ләкин... ул якынлашса да кызлар читкә

тайпыла, кайчак исә чарылдап та куя, соңыннан, үзен бүтәннәр мыскылламасын өчен, бер дә юктан бер гаепсез кешене тирги: «Китсәнә, Самурай башың белән!» Вакыты иркенрәк чагы булса, тагын өсти, сүзләр җәл түгел, беткеле дә түгел. Шундыйрак мәлләре була Сәлимгәрәйнең: үзенә яман сүз әйтсәләр дә, артык та нык гашыйк булганга күрә, ул кайбер чибәрләр нәрсә әйтсә, ничаклы рәнҗетсә дә, үпкәләми башлый, әрсезләнә, күңелдәге изге тойгыларыннан җиңелеп, кызның гүзәллеген җырлардагы әйләнмәләр белән мактарга керешә. Ә мәгъшука юньсез аны аңлау кая:

— Абау җирәнгеч, адәм төсле булса ни сөйләмәс иде! — ди дә кычкырып ихахайлый.

Сәлимгәрәй шунда гына кызның артык ук гүзәл түгеллеген аңлый һәм кәгазьгә язарга ярамаган сүз әйтеп кул селти.

— Самурай, Самурай, үз иленә кач давай!

Япон башкисәренә ни хәтле нәфрәт булса, шуның эчмүхәсе дә кимемичә Сәлимгәрәй бахыр өстенә түгелә — пычрак, кайнар су шикелле. Ә ни өчен? Ә ни гаебе бар Сәлимгәрәй атлы елтыр күзле малайның? Аның бит үзе теләп, ялынып алган кыяфәте түгел. Ник ата ялгышын аннан түләтәләр? Ник?

Хаксызлык салган, энә очы хәтле вак-вак җәрәхәтләр, әрнеп торган җәрәхәтләр, бергә җыелып, бөтен йөрәкне, бөтен күкрәкне, баш түбәсеннән алып аяк табанына кадәр булган бөтен тәнне каплый. Чак кына кагылсаң, дертләп китә, кызарып кабына Сәлимгәрәй һәм турымы, кыекмы, тиешме, тиешсезме, хаклымы, хаксызмы тәкъдир яудырган нәфрәтләрен учлап-учлап дөньяга, кешеләргә сибә. Әйе, үзе дөнья бәясе күреп гашыйк булган кызлар да шәфкать көтмәсен, Сәлимгәрәй хәзер акыллы, яра да сала ул иң кирәклесен генә:

— Карале, кара, синең тәпиләрең таяк шикелле ләбаса! Кемнең күзе төшәр икән сиңа? Кияүгә чыга алмассың син, апаем.

Кичә генә кычкырып көлгән гүзәл бүген кычкырып-кычкырып еларга керешә!

Ләкин үчләшеп, әрепләшеп кенә бөтен дөньяны җиңү җайлы түгел, анда бит әле яшисе бар һәм яшәргә кирәк, гәрчә исемең Сәлимгәрәй, юк ла, Самурай булса да. Иң әүвәл кеше кыяфәтенә керү хәерле, ни дисәң дә, алама булсалар да, шулар белән яшисе. Әйе, шуның кәсебенә керә дә Сәлимгәрәй. Теге калага, бу оешмага яза, редакцияләргә яза — ярдәм сорый. Ниһаять, озак еллар яза торгач, меңмең хатның берсе максатка барып җитә: аны Ватаныбыз башкаласы Мәскәүнең үзенә чакырып хат килә! Сәлимгәрәй һич ышанмаса да, бәхетен сынамак өчен генә китсә дә, кайткач исә күр, ышан: абзанда — төп-төз борын! Күпләр көнләшерлек! Ләкин...

Ләкин Сәлимгәрәй буен, гәүдәсен, кечкенәрәк күзләрен һичничек тә алыштыра алмый — моңа инде Мәскәү булып Мәскәү докторларының да кодрәте җитми. Шуңа күрә Самурай кушаматы да, гәрчә сирәгәйсә дә, бетмичә, кара сакалдай арттан еллар буе иярә килә.

Шулай да дөньяда тотып тора алырлык кына уңышка ирешкән ул. Ераграк авылдан кәләш тапкан кордашыбыз Сәлимгәрәй тормыш корып җибәрә. Бәхетенә каршы, нык холыклы хатынга тап була — ирен кимсетүләр аны җәрәхәтли алмый икән. Әлбәттә,соңгы көннәрне исәпләмәгәндә. Ә хәзер хатынының да, балаларының да буйлары бәләкәйләнде, чырайларында елмаю күптән яктырмый, онытылды шатлык. Менә моныңында Сәлимгәрәйне гаепләргә мөмкин!

Үзенең шактый ук гаепле икәнен ул, әлбәттә, тоя, ләкин эчендәге кемгә икәне ачык та булмаган үртәлү, үчләшү кемнедер рәнҗетеп кенә җиңеләергә, шактый ук тулы чуан эчендә җыелган әшәке явызлык һәм ваклык махсус бушатмыйча, сытмыйча бетә торган түгел — адәм баласының бүтән хаҗәтләре шикелле үк. Әйе, ныклап уйласаң,

тагын гаебе юк Сәлимгәрәйнең — әй, син, сөекле ата, әй, тәкъдир, Самурай исеме таккан кешеләр! Үзегез иҗат иткән Сәлимгәрәй Байсламов сезгә тиешле җавапны гына кайтара лабаса! Лаеклы җавапны гына бирә! Ә бүтәнчә яши аламыни ул?

Яхшылыктан баш тарту кая, ул үзенең чын исеменә лаек булырга, кешечә яшәргә күпме тырышты: мәктәптә гел бишлегә генә укып, аннары калада финанс-экономик институтын читтән торып булса да бетерде, хисапчы, экономист, хәтта баш бухгалтерлыкка үрләде. Кешеләр аның хезмәт хакын буш итмәделәр, түләделәр, кызганмадылар, ләкин Самурай кушаматы барыбер тәнгә бетмәс кара белән язылган татуировка шикелле, тоныкланмады, төсен җуймады. Кешеләр белән бертөсле булу бәхетен менә шунда аңлады ул!

— Самурай, үз илеңә кит давай!

Иодрыклар үзләреннән-үзләре төйнәлеп буш һаваны кыйный. Ләкин бик тиз тынычлана Сәлимгәрәй, әрепләшеп вакыт әрәм итми хәзер...

Дөрес формага кертелгәч, борын бераз өскәрәк күтәрелде инде. Ләкин әүвәлге җәберләрен олы дөньядан түләтү тойгысы башта гына тынган шикелле тоелды. Юк, ул бөтенләй үк тынычланмады — башта инкубацион чор гына кичерде. Элек кеше арасына керә алмаганлыктан, әллә ни зыян китерә алмаса, хәзер кайбер нәрсәләр башкара алырлык хәлгә килгәч, ул инде нишләргә икәнен белә! Үзе генә җитмәсә, хәзер дуслар да юк түгел. Шуларның иң шәбе — Галибәк Хәмәтдинов...

Һәм менә мин — Сәлимгәрәйнең кунагы. Гаҗәп, бер уйласаң. Бигрәк тә Ильясның бу өйдә утыруына ышану кыен.

Сизелә ки, өчәү булсак та, таган була алмабыз. Сәлимгәрәйнең миңа гына әйтәсе сүзе бар, ә мине Гыйбад абзый белән очрашу көтә. Беребез дә җитди сүз башлый алмаганлыктан, сабан туен, аннары өстәлдәге ризыкларны мактап утырган бер мәлдә... өй алдыннан җиңел генә кыштырдау ишетелде дә, күтәрелеп карасак... Карачкы! Нәкъ үзе карачкының! Һич киметү, арттырусыз! Сакал-мыек баскан кара йөз, тырналып, суелып беткән бит, муен... һәм күкрәк. Изүе ертык, әле генә бик каты сугышкан вәхши диярсең. Һәм шул кыяфәтнең йөзләтә тапкырланышын җыеп, аларып торган күзләр. Бу кыяфәт, бу күренешкә ышаныргамы, ышанмаскамы дип торганда, Сәлимгәрәй, әлеге тавышсыз-нисез кереп бусагада тукталган җеннең нәкъ үзенчә мыштым гына барды да, аның янына ук басып, бераз гына бөкрәя төшеп пышылдады:

— Ни бар, эткәй?

Өй эчендә ничә күз булса, аларның барысы да шул карачкыга текәлгән һәм барча башлар һәм муеннар аңа таба сузылган иде. Бүтәннәр ни кичергәндер, әйтү кыен, ә мин үзем, ачуданмы, чиркануданмы, әллә, кинәт карачкыны танығач, эһ дигән арада яман хатирәләр салкын шикелле булып өскә бөркелгәнгәме, калтырый, өши башлаганымны тойдым. Күз алдымда, колак эчендә мылтык тавышы шартлап алгач, бүз аргамагым җиргә башын төртә дә, яңадан мылтык шартлагач, үзенең гүзәл гәүдәсе белән җиргә сузылып ята... Аннары кышкы караңгы урман шауларга, ыжылдарга кереша.

Тишек чабаталы, ертык чалбарлы елларда, бөтен дөньяны котып салкыны чолгап алган хәерсез дәвердә җылы табу бер кабымлык ризык сыман ук кыен. эш булган чакта, суыклык афәтләрен җиңәргә азапланып узган вакытларда да безне шушы карачкы сагалый иде. Сугышка хәтле елларда урман каравылчысы безнең үз авылыбызныкы булып, көз көннәрендә урманны чистарту йөзеннән һәр өйгә кышка җитәрлек утын әзерләргә җай бирсә, ул сугышка киткәч, менә шушы Гыйбадулла дигән адәм калды аның урынына. Карачкы. Әйе,

ул чакта хәзергедән дә куркыныч, җан өшеткеч адәм иде ул — ялкын һәм салкын чәчеп аларган рәхимсез күзләре, киноларда гына, борынгы кыргыйларда гына була торган, үткен ук сыман мыек һәм чак кына сине мыскыллап елмаймаган кыек иреннәр бер караүда җанга шом тутыра һәм боларыннан да бигрәк яман гамәлләре атаклы иде аның. Элекке каравылчы утынны йорт башыннан булсә, монысы ничек булса да үзенең күңелен күргән кешеләргә генә бирә башлады. Билгеле инде, безнең кебек атасыз, ишле гаиләләр андыйга җөрьәт тә итә алмый, ә җөрьәт итсә, ул дуңгызны туендыру түгел, көн туса үзләренең ач тамакларын тынычландыру хакында хыяллана. Шулай килеп чыкты ки: ул сыйланып, мунчалар кереп, аракылар эчеп, яки ирсез солдаткалар көчып яткан өйләрдә ихата тулы утын була, аларның моржа торбаларыннан төтен явар болыт шикелле куе чыга. Ә андыйга бара алмаган мескен хатыннар һәм безнең кебек ятимнәр төн җиттеме, икешәр-өчәр таяк күтәреп, бот төбеннән кар яра-яра, Гыйбад тотса нишләрбез дип, куяндай калтырый. Агачы янып беткәнче йөрәге яфрак мисалында шыбырдый мескеннең. Бер үк вакытта авылдан-авылга Гыйбадулланың шул суыклардан өшеткечрәк мәкале сәяхәт итә: «Урмандагы һәр агачның һәр ботагы саен ярты литр аракы эленеп тора!»

Әйе, безнең яртылар юк һәм төннәрен кар диңгезендә йөзәбез. Бер эләкмисең, ике ычкынасың, өч тә, дүрт тә котыласың, тик йөзнең берсендә барыбер тотыласың. Кышларның кара төннәре алардан да күбрәк бит. Мин дә эләктем аның тозагына. Беләк юанлыгы икеме, өчме агач кискән идем, юлдан аваз килә: «Чын монда, әй!» — исемем белән эндәшә. Чыктым янына. «Ничә агач кистең?» — «Өч». — «Әйдә минем белән».

Кеше белән тарткалашырга күнекмәгән бит — киттем. Үзе юкта безне күзәтү эшен ул безнең авылның Фазыл картка калдыра торган иде. Шуның өенә алып барып, нәрсәдер язды, кул да куйдырды. Олы башы белән томшык сарысы кипмәгән малайны алдамас дип, карапнитеп тормыйча кул да куйганым хәтеремдә. Эшне зурга җибәртмәү уе белән дә ни кушса шуны үтәргә тырышканмындыр инде. Кәгазьгә кул куеп кайткач та хәлне әнигә сөйләгән идем, ул тиз арада күршеләргә аракы эзләргә чыгып китте, ә мине Гыйбадулланы чакырырга кире аның янына җибәрде. Бүтәннәрчә эшлибез, янәсе. Гыйбад, әлбәттә, килде, соңгы акчаны, авызыбыздан өзеп саткан май акчасын эчеп тә китте. Ләкин бездән чыккач та: «Без кешенең аракысын да эчәбез, аны судка да бирәбез!» — дип мактана йөргән бу. Чынлап та, вәгъдәсендә торган булып чыкты. Ярый әле судта секретарь булып минем дус малай эшли иде: «Бер сыер бәясе штраф салырлык агач язган ул синең өскә», — ди. Юл буенда тырпаеп торган барлык агач төпләрен миңа сылтаган, күрәсең. Судья акыллы кеше иде, яхшылап аңлаткач, дереслекне таба алды һәм тиешлесен генә түләп котылдым. Монысы бер. Ләкин ул мине икенче тапкыр да алдады. Хәтта өченче тапкыр.

Ул чакта дәүләткә тапшыру өчен зелпе тамыры җыю җитди эш санала иде. Шуны җыярга чыккан һәр кешегә көн саен яртышар кило он бирәм, халыкны оештырып чык әле, дигәч, бу адәм үз гаебен йомшартырга тырыша, ахрысы дип, кешеләргә өй борынча кереп чыктым да берничә көн бергәләп җыйдык зелпе тамырын һәм тапшырдык та. Бер көнне он белән килгән бу. Миңа үлчәп торырга кушты. Анысын да тыңладым. Онга карагач яшь тамарга торган чак бит — үлчим кешеләргә, үлчим, он кими, он кимегән саен Гыйбадның күзенә карап, сүзсез генә: «Ә миңа кайчан?» дип сорыйм. Ул сизә, сизә, ләкин ал дими. Ә минем үзем эшләп алганны ялынып аласым килми һәм он... Бәлки зыянлы горурлык булгандыр бу, ләкин бүтәнчә булдыра ал-

мыйм. Ул исә, минем онга нинди тойгылар белән караганымны сизеп, үзенә хас елмаю белән елмаеп, мыегын гына сыпырып торды һәм соңыннан рәхмәт тә әйтмичә, китеп барды.

Өченче тапкыр... Юк, анысында мин инде сөйләшә белдем шикелле.

Чалгы белән урманга рөхсәтсез кертмәгәнлектән, район үзәгенә барып, печән чабарга билет алып кайттым да Гыйбадка тоттырдым — язылган төштә печән чабуыма сүз әйтә алмады. Ләкин икенче көнне килеп җиткән: бу аланны синә ялгыш биргәннәр, бу минем алан дип, мине куарга чамалый. Бүтән җир дә күрсәтми. Сатулашып инде чыныга төшкәнгә, бу юлы курыкмаска булдым: «Мөнә нәрсә, Гыйбад, син адәм түгел, аждаһа бит, әйе, еланның иң зурысы. — (Ул чакларда безнең урман тулы елан, тауларыбыз да шуңа күрә — беренче, икенче, өченче Елан таулары. Шуңа күрә телгә дә елан сүзе еш керә торган иде.) — Әйе, иң агулы елан син! Көнең җитәр, кырмыска оясына ыргытырлар яки үзең килеп аунарсың. Кырмыскалар әшәке тәнеңне ашаганда, нәкъ еландай боргаланырсың, ләкин сиңа беркем дә ярдәм итәргә килмәс!» — дип кычкырдым. Якын килеп, мине кыйнау, куу белән өркетә башлагач, чалгыны күккә күтәрдем дә: «Кил, агулы башыңны хәзер кисеп ташлатасың килсә, кил!» дип, инде ярсып ук акырдым. Шуннан соң гына тынычланды.

Менә шушы кеше инде бу карачкы. Һәм ул минем сүзләрне күңелендә саклаган икән, онытмаган: чынлап та, кырмыска ояларына ятып аунаган, еландай бөтерелгән, тик аннан файда, җиңеллек кенә таба алмаган. Каргышын кире алмасмы дип, үземне чакырткан.

Авырту әчесеннән инде аңы да томалана башлаган — больницадан уләр өчен генә, үзе сорап кайткан, имеш. Уколлар килеп кадасалар да авырту, авыртудан бигрәк — кычыту һич кимеми икән. Теге дөньяны күзләре хәзер күреп торганлыгы үзенә бер карау белән аңлашыла... Һәм ул мине танымады...

Базы буена барып, көн саен пеше тал чыбык алып кайта да, яшьрәк чагын, балалар тәрбияләгән вакытларын исенә төшереп булса кирәк, ул талларны матча ярыгына кыстыра икән дә көн саен диярлек үзенең караватын, урын-җирен чыбыклый икән. Кайбер көннәрдә хатынына, малаена килә дә: «Мә әле, шушы чыбык белән аркамны кыйна», дип тә ялвара икән. Болар тыңламагач, шул үтенече белән урамга чыга һәм күргән бер кешесенә, мине кыйна, кыйна, үтенеп сорыйм, үтенеп! дип ялына. Тик сүзен чынга алучы юк. Чыбык белән кыйнасалар, тәнендәге коточкыч кычыту кимер дип уйлый ул мескен. Менә тагын үз алдындагы барлык кешеләргә шул үтенече — әйтерсең ки борынгы саилчы хәер сорый:

— Зинһар өчен, кызганыгыз, хәлем авыр бит, менә шушы чыбык белән туйганчы бер кыйнагыз ла! Зинһар өчен! — дип, күзләрен гаҗәп тә кызганыч итеп ялварырга керешә ул.

Матчадагы чыбыкларның берсен алды да чыратлап: башта Ильяска, аннары миңа, аннары хатынына, улына сузды. Бүтән чакта сүз булганга күрәме, әтисенә Сәлимгәрәй минем кемлегемне әйткән иде, карачкының ничек шатланганын күрсәгез! Тиз арада яныма ук килеп бераз кашынды да менә шул рәвешле тезеп китте:

— Мин сине, улым, бәләкәй чакларыңда, яшь вакытларыңда бер дә юкка бик каты рәнҗеткәнием бит. Син мине каргаган иең. Ятим баланың каргышы төшми калмый диләр ие — раска чыкты шул. Син мине каргагансың да, сихерләгәнсең дә. Ал кире каргышыңны, кайтар сихереңне дә — укы доганы, күп укып йөргәнсең диделәр. Коткар, коткар, алла хакы өчен, улым, балам! Ярлыка дивана чактагы гөнаһларымны, укы, әйдә, укы доганы!

Шулай диде дә тынып калды — мине хәзер ул кайчандыр үзе бел-

гән муллалары шикелле укынырга тотынып дип көтә. Ләкин ни әйтергә дә белмичә каушап калуымны сизеп тагын да рухланыбрак тезә бирә:

— Яттым исә баш очымда җепкә тезелеп ниндидер агач түмәрләре эленеп тора. Түмәрләр арасында ярты литрлы шешәләр чайкала, шул түмәрләр, аракылар бер-берсенә бәрелә-бәрелә шак-шок итәләр дә шулай шак-шок бәрелешә торгач, пыялалар чабырдап ватылалар да күземә, битемә чәчри, түгеләләр... Ә мин куркам, сикереп торам, кычкырам, ә күзләремне ачсам, ачы чыелдау белән шуа, кача башлыйлар. Күзне йомдым исә яңадан тиз җыелып, тагын чайкала, шакылдый, шалтырый башлыйлар. Йокласам да, йокламасам да шакылдыйлар. Ятарга куркып ятам. Әнис улым, син икәнсең бит бу. Синме бу? Чынлап та син булсаң, оныт бөтен рәнҗешләреңне. Оныт та гафу ит — ал сихереңне, кайтар кире сәламәт тәнемне — җаның теләгән бөтен байлыгымны алып кит, тик саулыгымны кире бир. Укы, укы, балам, дога, дога, дога! — Укынырга җыенмавымны тагын күргәч тагын дәвам итә.— Онытa алмасаң, дога укырга иренсәң, күпсенсәң, алайса, мә, үч ал — барлык үчләреңне берьюлы кайтар, мә чыбык, кыйна күңелең булганчы — минем өчен хәзер шул да бик олы ярдәм бит, сук, мә, кыйна! Ал үчләреңне! Я инде, зинһар, зинһарлап сорыйм лабаса. Курыкма дим, үлсәм дә син гаепле булмассың, үзем зинһарлап сорыйм — бөтен авыл белә, күреп тора!

— Юк, Гыйбадулла абый мин сиңа суга алмыйм, син болай да артыгы белән кыйналасың... — һәм аның аһ-зарларын колагым ишетсә, һич югы, күзләрем күрмәсен өчен, дөресрәге, шушы хәтле дә чирканыч күренешкә түзә алмыйча, читкә тайпылам да тын почмакка текәләм. Колак һаман ишетә:

— Шулаймыни? Син мине кыйный алмыйсыңмы? Шундый да шәфкатьсез кешемени син? — Һәм ул инде тагын кашына-кашына ямьсез елау белән ялваруын белә. — Кырмыскаларың да басмый тәнемә салган кычыту, сызлату зәхмәтләреңне. Басмый бит, ашый гына комсызлар. Менә күпме генә итем калды тәндә.— Шул сүзләрдән соң чүпрәк шатырдап умырылуы ишетелде.

— Мә, кара, үз эшеңне күр, менә нишләттең, менә нинди кыяфәткә керттең син мине!

— Әткәй, нишлисең, әткәй!

Сәлимгәрәй әтисе кебек үк үрсәләнеп кычкыра, ләкин тыңлата, җиңә алмый. Борылып карасам, чынлап та, күгәрмәгән җире юк Гыйбад аркасының һәм ул тагы шуны чыбык белән кыйнатмакчы. Мин инде нәрсә булса да әйтер, хәтта урынымнан кузгалыр дәрәҗәдә түгел идем. Хәлемне аңлапмы, ялварып туйгангамы, Гыйбад улына гына ялына иде инде:

— Улым, актык өметем — син, инде син дә кире какма, мә талны, ал аны, кыйна бер. — Шулай дип, ул чыбыкны улына тоттырды.

Сәлимгәрәй чыбык тоткан кулы белән үк күзләрен угалады да:

— Ярый, әткәй, бар чык үз бүлмәңә, пажалый мин сине тыңлармын, — диде.

Ләкин әтисен рәнҗетте димәгез. Әтисенең күзләрендә — әйтеп аңлата алмаслык шатлык, сөенеч, яктылык.

— Рәхмәт, улым, оҗмахлы булырсың, алла бирса. Ата-ана рәхмәтен алуың әйбәт. Рәхмәт. Тик син тыңла сүземне — башта караватка бәйләп куй мине, югыйсә, сикереп торуым бар. Кычкырсам да кыйна, кыйнама дип ялынсам да сугуыңны бел. Шунда гына тияргә мужыт аның сихәте. Белдеңме? Башта бәйләп куй.

— Ярый, әткәй, башта бәйләп куярмын. Атла.

Улы иярерме, юкмы дигәндәй шикләнеп, Гыйбад артына карыйкарый, аю шикелле йомшак һәм ипсез баса-баса, кәкре аяклары бе-

лән әкрен генә атлап китте. Улы да сүзендә торды — иярә китте. Өй алдына узып, икенче өйгә кереп югалдылар.

Һушыбызга килеп дигәндәй, без дә үз юлыбызны дәвам итәр өчен ишеккә таба юнәлдек. Без чыга гына башлагач та Гыйбадулланың хатыны дөп итеп идәнгә ауды — аны тиз генә икәүләп караватка яткырып, сулышын тыңладык — исән, һуштан гына язган иде. Шулай да врачка хәбәр итәргә кирәк. Шул ният белән без күтәрмәдән төшеп барганда, икенче як өйдән тал чыбык чыжылдавы һәм аркада шартлавы, Гыйбадулла картның исә:

— Житәр, житәр, улым, авырта, алла хакы өчен! — дип, дөнья тутырып кычкыруы ишетелә иде.

Үзем күрмәсәм, мондый хәлне хәтта күз алдыма да мәңге китерә алмаган булыр идем.

— Житәр, авырта бит, үтерәсең, улым, житәр!

Һәм чаж-чож иткән тавыш...

Әти кеше улын кайчандыр үзе дә шулай кыйный торган вакытларын хәтеренә китерде микән? Талларның чак кына гаеп өчен дә матча ярыгыннан чыгарга һәм Гыйбадулла кулына шуып керергә ашыкканы өчен үкенеп сызландымы? Әйтә алмыйм. Юктыр. Ә таллар элекке вазифаларын һаман башкаралар...

*
* *

*7 июнь, 1977.*

Күрәсем килгән авылларда булып чыкканнан соң, юлым тагын шушы Чуаркүл авылы аша үтә. Урамнан узганда, ничектер халык төркеменә тап булдым. Җеназа... Төркемгә таба йөгерүче бер малайны туктатып:

— Кем вафат булган икән, энем, әйтә алмыйсыңмы? — дип сорыйм.

— Бумы? Бу Гыйбад бабайны зиратка алып баралар.

Шулай диде дә малай чабып китте һәм аның артыннан минем уй иярде: «Бу малай кемне алыштырыр да кем тормышын дәвам итәр икән?»

*
* *

*8 июнь, 1977.*

Яше тулгач та райбашкарма советы председателе урынбасары Галибәк Хәмәтдиновны пенсиягә озаттылар. Ләкин аны лаеклы ялга озату тантанасында Рамазанов катнашмады, рәхмәт әйтеп кулын кысмады.

Моның сәбәпләрен кешеләр белә иде.

Чираттагы бәрелеш менә ничек килеп чыкты. Ул чакта Хәмәтдинов өченче секретарь, ә Рамазанов — аның кул астында бүлек мөдире. Сугыш елларында иң алдынгы булып саналган бер колхоз, дөнья рәтләнеп барганда таркалу хәленнән чыга алмаганлыктан һәм өмет тә багларлык булмаганлыктан, авыл кешеләре колхоз председателен алыштырырга кирәк дигән фикергә килгәч, райком да шул карашны куәтләп, яңа председатель сайлауда катнашу өчен Хәмәтдиновны җибәрергә булган. Ә Хәмәтдинов баш тарта. Аның урынына Рамазанов бара.

Электән дә кайбер нәрсәләр сизенгән Рамазанов җыелышны формаль үткәрмичә, авылдагы хәл белән ныклап танышкач, менә нәрсә

ачыла: элекке председатель бәләкәй оештыручы булса да, зур гына масштаблы карак икән. Һәм ул чорналган җепнең бер очы Хәмәтдиновка да барып тоташа. Райком атлары өчен үз җирендә солы чәчәм дигән булып, иске председатель бодай да чәчә торган булган... Һәм солысы райкомга китсә, бодае үзенә һәм Хәмәтдиновка китә торган, ягъни мәсәлән, акчага әйләнгән дә аннары инде мәҗлесләр, бергәләп күңел ачулар башланган.

Яңа председатель сайлап, искесенең эшен Беренчегә җиткергәнче, Рамазанов, яхшылап аңлашып булмасмы дип, әүвәл Хәмәтдиновка кергән. Ә юк, Хәмәтдинов аны үзе чакырткан бит әле. Нинди күрсәтмәләр, янаулар һәм, ихтимал, ялварулар булгандыр, аныси безнең өчен сер һәм ныклабрак уйлый төшкәндә, аларны чамаларга мөмкин. Шушы көнгәчә һәркемгә билгеле: үзенең начальнигыннан узып, Рамазанов Беренчегә бөтен хәлне барыбер сурәтләп биргән.

Мәңгелек закон: хыянәтче һәркемдә хыянәтче күрә, ә карак һәркемдә карак эзли. Бу юлы да шулай булып чыкты.

Райком абруе хакына Хәмәтдинов эшенең зур яңгыраш алмаганын хәтерлим. Райбашкарма председателе урынбасары итеп, элеккеге үз урынына күчерелгәч, нигездә аны аkладылар, тиешле сабакны алыр дип өметләнделәр, дигән фикер туа. Ләкин әнә пенсиягә озатканда, ихтирам бик үк мактанырлык булмаганы ачыкланды.

Коридор. Рамазановның кабул итү бүлмәсенә кергәли-чыккалый торганда, коридорда... кемгә дисез? Әйе, Хәмәтдиновка чак бәрелмәдем. Хәерлегә каршы, ул мине танымады. Бәлки таныса да исәнләшмәс иде. Шунысына гаҗәпләндем: булган барлык хәлләрдән соң, бу йортта аның эше төшәрлек, сүзе үтәрлек кеше калды микәнни? Тик минем өчен шунысы ачык, ул һичкайчан Рамазанов ишеген шакымаячак.

Бирешмәскә тырышты Хәмәтдинов һәм бирешмәде. Үзенә тапшырылган бурычлардан бигрәк тормыштагы үзе чатырдап ябышкан урыннан кубарга пенсия алдыннан да ашыкмады. Ләкин, абруй бәләкәйләнү сәбәпле, үзенә йөкләнгән эшләрне гамәлгә ашыра алмый, еш кына Рамазановның үзеннән ярдәм сорый, елмая, хәтта кунакка да чакыра. Ләкин... бармый Рамазанов. Җитмәсә, якын көннәрдә районда юллар төзүнең барышын тикшерү буенча бюро җыелды да, шунда ачыкланганча, бу тармакны җитәкләүче Хәмәтдинов төзелешне таркаткан булып чыкты. Дөресен әйткәндә, таркаулыклар юлларда гына түгел, тиресеннән чыгардай тырышса да, Галибәк Хәмәтдинов абзагыз инде кешеләр акылына җитәкчелек итү түгел, хәтта хуҗалыкны оештыру өчен дә көчсез икәнен аңлый. Шулай да пенсия белән шөгыльләнеп ятканда, үзен ашыгып җибәрделәр дип, барыбер үртәлә... Шул тискәре тойгы нишләптер Сәлимгәрәй Фәсихов язган хатларда аңкып тора... Һәр хатта шәп кеше буларак — Хәмәтдинов фамилиясе язылган, начар буларак — Җантурин, Рамазанов. Хатлар, жалобалар — төрле авыллардан, төрле шәһәрләрдән. Ләкин аларның барысы да Хәмәтдиновны белә... Хатларны укый торгач, әллә болар туганнармы дип уйлыйсың. Һич югы, кияүләр, бажайлар? Юк, берсе дә түгел, ләкин, ничектер, алар туганнар, бик тә якын туганнар...

Сабан туе көнне уен-көлке арасында ачыграк чырайлы булырга тырышып, Фәсиховка янәсе сүзне дусларча эчкерсезлеккә көйләп, сорау бирдем:

— Әйт әле, дус кеше, бары тик үзем өчен генә ачыклыйсым килә, еллар буена сузылган низаг туйдырмыймы? Болай яшәү кыендыр бит?

Фәсихов һич хәтере калмыйча ихлас елмайды гына һәм, сизүемчә, хак дөресен әйтте:

— Салкын суга бер төшкәнче генә ул... Чирканчык алгач, рәхәтләнеп йөзәсең.

Һәм йөзәләр дә...

Рамазановка кергәч беренче соравым:

— Күпме комиссияләрне бушка эшләткән, күпме кешене төп эшеннән аерган өчен, күпме кешеләрнең теңкәсенә тигән өчен, ниһаять, тормышларын бозган өчен бу адәмнәргә җәза бирергә уйламадыгызмы?

— Явызлыкны явызлык тудыра, җәзасын да үзенә-үзе бирә.

Рамазанов миңа газета подшивкасы тәкъдим итте:

Укыйм: бу кешеләрне хөкемгә тартмаганнар. Артык бәләкәй җанлы кешеләр дип исәплләгәнгә күрә бу сугышчан әшәкеләр белән буләшып торасылары килмәгән. Ләкин аларга партия билетлары белән хушлашырга туры килгән.

— Фәсихов белән Байсламовка, шулай. Ә Хәмәтдиновка?

— Аңысы да җәзасын көн саен ала.

— Аңламадым.

— Үзен белгән барлык кешеләр алдында ихтирам югалтты. Шул кешеләр арасында, аларның карашын көн саен тоеп, яшәп кара. Күз алдына китерә аласыңмы?

— Рәхмәт, аңладым.

Җинүчеләр фәлсәфәсе — кызык. Ә тегеләр җиңсә? Ә бит аларның да җиңүгә бик якын мәлләре булгалаган. Ә җиңсәләр? Аларның Җантуринны хәтта төрмәгә утыртырга да җыенган вакытлары булган... Ә җиңсәләр?

Фаразларны сорауга әйләндергәнче, телефон шалтырады. Югары оешмалардан булса кирәк. Рамазановның әлеге сөйләшүенә илтифат итмичә, мин бераз элегрәк булган сөйләшүне тыңлап утырам.

Республика җитәкчеләренең иң зурысыннан кала икенче зурлыктагысы эндәшә: басылып чыккан тәнкыйтькә карата газетага нинди җавап бирелү белән кызыксына. Рамазанов исә җавапны ашыктырмаган икән. Исәп эшләрен төгәл алып бармаганнары өчен колхоз председателе иптәш Җантуринга шелтә бирелгән, ә баш бухгалтер Сәлимгәрәй Байсламов эшеннән алынган. Шул хакта хәбәр итәчәкләр, имеш.

Икенче. Формулировка дөрес түгел һәм шуннан ялгыш карар килеп чыккан.

Рамазанов. Без вакыйгаларны якыннан күргән кешеләр, үзебезчә...

Икенче. Өстәп язулар белән шөгыльләнү, дәүләтне алдау. Менә нинди формулировка сорала. Тамбов өлкәсендәге өстәп язуларга карата, үзегез беләсез, иң югары директив оешмаларның карары чыкты һәм анда барлык өлкәләр һәм республикаларда бу зарарлы күренешкә каршы ныклы көрәш алып барырга кирәклеге әйтелгән. Ә сез көрәшмәскә уйлыйсызмы? Әйдәгез, алдынгы район бу яклап та үрнәк күрсәтсен әле. Курыкмагыз, сезнең үзегезгә күләгә төшертмәбез, сизгерлек өчен мактарбыз гына. Газетага да ихтирам күрсәтү булыр. Аңлашылдымы?

Рамазанов. Кампаниягә кушылсак, макталачакбыз. Әмма миңа мондый эштә инициативасызлык ошый төшә. Газета мәкаләсе нигезе белән конъюнктураны аңламыйча язылган. Безнең принципиаль караш шушындый.

Икенче. Мәсьәләне болай урайту — акыллы тоелмый, сезгә хас түгел бу, иптәш Рамазанов. Бер кеше, бер генә кеше турында бара сүз. Шул хәтле зур корбанмыни бу?

Кызык, Рамазанов шушы «бер кеше»не, Җантуринны, Фәсиховларга биргән булса? Рамазанов күкрәгендәге геройлык билгесе ни-

чегрәк балкыр иде икән? Әгәр ул шунда ук бәхәсне туктатып, Беренчегә юл тотмаган булса? Аның автомобиле авыл урамнарында тавыклар кыраклата-кыраклата, юлларда тузан туздыра-туздыра калага чапмаган булса? Авыллардагы кешеләр хәзер нәрсә уйлар иде икән? Сабан туйлары хәзергечә күңелле була алыр идеме? Тормыш һәм язмыш тарафыннан рәнҗетелгән кешеләр үзләре дә сизмәстән бәлки хәзер дә берләшә торырлар? Тагын «берәү» корбан ителергә тиеш?

Аларның бәлки дөресен әйткән чаклары була торгандыр, ләкин алар иген үстермиләр. Ә тик геройлар кулындагы түгәрәк ай һәм кояш кушып пешерелгән икмәкне кыерчыкларга кисәләргә, бүлешергә генә тырышалар. Тормышлары шуңа багышланган!..

*
* *

Гомер буе гаделлек, дөреслек эзли кеше. Эзли, таба, югалта, тагын таба. Ә мин? Минем өчен ул кайда? Нәрсәдә?

Минем өчен гаделлек яшел төстә. Һәр яфрак, кыяк бары тик дөреслек дигән туфракта гына үсә ала. Ә ялганнан бары тик ялган ярала.

Икмәк үстергән кеше — хаклы. Ә сүзләре, теләкләре никадәр матур һәм изге тоелмасын, аңа комачау иткән кеше чиста була алмый. Тормышны иҗат итүче хаклы, ә иҗат ителгәнне тартып алырга, шөһрәт казанырга тырышучы түгел. Үзе үстергән игеннең буынга сикергәндәге чыңын ишетә алган кешеләр генә чын игенчеләр һәм бәхетлеләр. Баланы тудыруда ярдәм итүче, орлыкка шытып чыгарга, тагын да ишәергә ярдәм итүче — гадел, ә комачау итүче түгел.

Бала дигәннән, Зөлхиҗә һәм аның улы хәтергә килде. Сабан туйлары шаулап узгач та, ни өчендер, Зөлхиҗә, улын алып, яңадан ниндидер калага китеп барган. Сәбәбе һичкемгә билгесез. Усал кешеләрнең тынычлануына ышанып бетмәгәнме, улы белән тагын ул-бу эшли күрмәсеннәр дип курыкканмы, әллә юкса үз язмышын үзе дә таба алмагангамы, дип сорарга мөмкин. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул тагын бераз ашыккандыр дип уйлыйм. Ә Җантурин авылдан кемдер китә ала икән, мин гаепле дип, нәрсәнедер күреп, тоеп бетермәдем, дип саный... Зөлхиҗә китkәч, Җиреклекүлдә ничектер шатлык, ямь, мәгънә дә кимегәндер сыман. Шулай да зәңгәр ераклыкларда калган аргамаклар Зөлхиҗә улының да хәтеренә төшми калмас әле дип ышанасы килә. Әгәр күргән булса, сагынмыйча, күрмичә булдыра алмас кебек.

Бала белән икмәк авыр килә дөньяга.

Гаделлек һәм дөреслек — икмәктә, балада.

Рамазанов бүлмәсендәге ак һәм кара барометрларны күз алдына китерәм: кайсы аязга якынрак икән, кайсы болытка? Кайсы ягымлырак икән аңа бу минутта? Җиреклекүлдәге Морадым карт кайсы күзе белән карый икән бүген бу дөньяга?

Иртәләр саен тормышыма радио тавышы керә: «Бүген төнлә җылы һава сакланды. Көндез — аязучан болытлы һава. Урыны-урыны белән кыска вакытлы яңгыр булуы мөмкин. Җил, яшен вакытында бик көчле җил...» — Синоптиклар ялгышмыйлар!

Радионы, мөгаен, бу вакытта Рамазанов та, Җантурин да ишетәләрдер. Аралар ерак булса да, синоптиклар һич ялгышмый хәбәр итеп торган һава торышын без бергә тыңлыйбыз, бер көнне дә ишетми калмыйбыз.

Мин моны белеп яшим.

*1977—1978.*

## Сибгат Хәким

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Йөгерә чәчәкләр офыкка

Йөгерә чәчәкләр офыкка,
Йөгерә кыр чәчәкләре,
Кырыс кыр чәчәкләренең
Юк тормыш хәсрәтләре.
Йөгерә чәчәкләр офыкка,
Офыккача туп-туры,
Агыла аларның артыннан
Хисләремнең дулкыны.
Йөгерә чәчәкләр офыкка,
Балкып бер үтәр өчен,
Йөгерә чәчәкләр кемнәрне
Бәхетле итәр өчен?

●

Өстәлем иген кыры күк,
Бүленгән өч басуга,
Каләмем — урак, урагым
Алам да эшкә чыгам.
Ындырда байлыгым, карыйм
Чамалап ындырдагын,
Урам үз кишәрлегемне,
Урамын өлгергәнен.
Арыштан бодайга күчәм,
Жанрдан бер жанрга,
Урамын, калмасын эшем
Көзге карлы яңгырга.
Учмалар үрчи, шатланам;
Эшләдем кичә, бүген...
Кими җир, кими әкренләп
Урасы кишәрлегем.

●

Йөрим-йөрим дә баш иям
Кайтып иске нигезгә,
Мин үзгә, искән җил үзгә,
Буыннар өне үзгә.
Актарам нәсел-нәсәбем,
Исеме ничек, ни атлы?
Утырам иске нигездә,
Әйтерсең лә гөнаһлы.
Үткәнем белән сөйләшәм,
Яна ике яңагым,
Үткәнен оныта торган
Гадәте бар яңаның.
Шушы җир, шушы туфракка
Гомер буе бурычлы,
Ул бурыч нигездә яткан
Таш кебек авыр, очлы.

●

*Тукай дәфтәреннән*

Бер татарда ничә йөзләп шагыйрь,
Һәр шагыйрьне истә тот аерым,
Кайта идем уйлап мин шуларга
Йогынтысын бөек Тукайның,
Яшен кырны яктыртты шул вакыт,
Күренеп китте юлда ат кабат,
Күренеп китте басу уртасында
Карт карама белән карт нарат.
Яшен кырны яктыртты берьюлы,
Менә, дидем, читен мәсьәлә,
Кайсына соң күбрәк төште якты?
Карамага? Атка? Нәрсәгә?
Яшен кырны яктыртты бертигез,
Бер кыр — бер чор кинәт гөлт итте,
Күз алдында җир яшәреп китте,
Берсен-берсе узышып гөл китте.

●

«Килдек, күрештек тә киттек...»
Гүя риза язмыштан...
Кирәк өч кенә сүз калган
Җәлил белән Алиштан.

## Карт

Йортта күп вакыт бер үзе,
Иске гармун, истәлек,
Үзе күк кабыгы тузган,
Тузган форма-эчтәлек.

Уйный күп вакыт бер көйне,
Баса гармун бакасын;
«Дөнья күрми егет булмый,
Күрми дөнья җәфасын».
Йөрмиләр бармаклар хәзер,
Гармундагы бакалар
Күлдәге бакалар төсле
Баталар да калкалар.
Бер каты итеп баса да
Гармуны бакасына,
Ташлый, эш кирәк, эш җитми
Атаклы балтачыга.
Эшләде, түгел дан өчен,
Түгел өстенлек өчен:
«Калмасын җирдә кешегә
Үлгәч өч көнлек эшең».
Балтасы кыстырган, тора,
Үзенең эш балтасы,
Тора бер эшсез иртәдән
Кичке кояш батканчы.
Уйлана балта да кайчак,
Елмая һәм шатлана,
Йөзендә ярыктан төшкән
Сап-салкын шәфәкъ яна.
Шул ук эш җитми аңа да,
Күзәтә бар дөньяны,
Дөньясы, билгеле инде,
Ак йортлы мари ягы.
Елмая: хуҗасы исән,
Исән бу йортның карты,
Тик ятмас, бар икән әле
Гармун уйнарлык дәрте.

●

Күңелгә җиңел, утырсаң
Авыруның хәлен белеп.
Ята өстәлдә дарулар
Янында хәрби билет.
Тоелды ул билет хәзер
Нишләптер ятрак сыман,
Тоелды кечрәеп калган,
Саргайган яфрак сыман.

Тонык нур сибеп, билетның
Тышында янган йолдыз
Сорый күк: очрашкан идек
Фронтта кайсы ел без?
Картайган авыру солдатка
Тормыш һәм сулыш өреп,
Ята шул билет өстәлдә
«Сугыш һәм солых» кебек.

●

*Хәсән Туфанга*

Койрыклы йолдызны күргән
Нинди таң булды икән,
Бала чак хыялы нигә
Аңа тагылды икән?
Койрыгы әйтерсең безнең
Тыкырык буе гына,
Мин шул хикмәтле йолдызның

Тотынып койрыгына,
Узганмын гомер арасын,
Калды тик ах орырга;
Китереп җиткерде мине
Гомерем ахырына.
Кабаттан әйләнә диләр
Ул сиксән, туксан елга,
Очрар күк мин дә бер көнне
Мәңгегә чыксам юлга.

## Язгы кәрваннар

*Аяз Гыйләҗевкә*

Сугыштан соң икенче яз, моңсу
Язы иде кырык алтының.
Без чанада икәү, бездән башка
Эзе дә юк кырда атлының,
Абый белән икәү, озата мине,
Аты ябык, арык ат иде,
Минем күңелем кебек әкрен-әкрен
Эреп барган йомшак март иде.
Сугыштан соң күренеп киту өчен
Кайткан идем, юлым Арчага.
Тик без генә атлы, сугыштан соң
Калган бары бер ат, бер чана.
Безнең атның курка-өркәсе юк,
Дилбегәне абый буш тоткан.
Икенче бер, бүтән бер дөньядан,
Ак кар дөньясыннан, бушлыктан
Кинәт кенә пәйда булды алар,
Ни икәнен сөеп назлауның
Онытып күптән, авыр чана тартып,
Төркеме күк киек казларның
Хатын-кызлар килә иде тезелеп,
Кычкырдылар: ал дип атыңны...
Юк, сукмады абый, әйтерсең ат
Оятыннан читкә атылды.
Оятымнан мин чанадан төштем,
Йөрәгемне арыш тырнады;
Алар тартып кайткан чаналарда
Йоклый иде арыш кырлары,
Йоклый иде бодай басулары,
Йоклый иде яшел дулкыннар...
Чәчми калсаң әгәр шушы кырлар
Гомер буе, беләм, сулкылдар.
Атны абый өйгә таба борды,
Атка җиңел хәзер, ат чаба.
Үземә дә җиңел иде минем,
Мин җәяүләп киттем Арчага.
Горур йөзләр, күзләр, ул карашлар
Күңелемдә язылып калганнар.
Зәңгәр күккә горур башын чөеп,
Бара юлдан язгы кәрваннар.

1978

## Сөләйманова Сажидә

# ГӨЛБАДРАН

ПОВЕСТЬ

## Карарбыз, күрербез...

### I



Талгын җилдә җилфердәгән тирәк яфраклары арасыннан шифаханә бинасы ак челтәр сыман күренә. Җиңелчә киенгән ир кеше салмак атлап, күләгәле сукмактан шул челтәргә карый бара. Челтәрнең бизәкләрен отарга теләгәндәй, бина ягын җентекләп күзәтә. Шәһәрнең баш хирургы Аллаяров Баязит бу. Ике дистә ел таптаган сукмактан көненә ничә килсә дә, монда аны һәрвакыт яңалык көтә.

Бинага җитәрәк, Баязит туктап, ак киндер кепкасын салды, күксел чалбар кесәсеннән кулъяулык чыгарып, маңгаена, муенына тидергәләп алды. Көн бүген дә эссе булырдай, болыт әсәре күренми, күктә берүзе хакимлек итәргә кояш күтәрелеп килә. Әнә ул Каенлы тау түбәсенә менеп кунган да, нурлары белән яктырып, һәммә нәрсәне үтәли күрергә тырыша кебек. Баязит тау ягына бер карап алды да, кепкасын никтер батырыбрак киеп, ишектән кереп югалды. Тау итәгенә урнашкан кечкенә авыл гүя аңа хәер-фатиха биреп калды. Баязитның туган-үскән авылы ул. Кайчандыр өч мәхәлләле иске авылдан яшь гаиләләр аерылып чыккан да, тау куенына кереп урнашкан. Авылга «Яшьләр» дигән исем берегеп калган. Хәзер инде авыл янәшәсендә якты кала үсеп чыкты. Төзелеш шавы ерак яңгырады, авылдан читтә дөнья куучылар, аның кайтавазы булып, кайтып төштеләр. Авыл яңа калага төзүчеләр генә түгел, үз исемен дә бирде, шау-шулы төзелеш шәһри «Яшьләр»гә әверелде.

Баязит буйга җитеп, ярты дөньяны урап кайтканда, шәһәр салына башламаган, авылда картлар гына калган иде. Су буйларына төште егет, клуб тирәсендә урады, ямь таба алмады. Тау кечерәйгән кебек, елга саеккандай, таллар да моңаеп калган. Утлы-төтенле калалар, янган далалар аша үтеп, җиңү алып кайткан Баязит бу тынлыктан тиз туйды. Йорт-кураны карт әнисе белән тол апасына калдырып, янә

җинеп кайтырга вәгъдә биреп, юлга чыкты. Бу юлы ул кулына автомат түгел, китап-каләм алды. Сугышка чаклы очучы булырга хыялла на иде. Унынчыны тәмамлауга, унҗиде яшьлек егетләр класслары белән гариза биреп, фронтка киттеләр. Беренче мәртәбә кан күрделәр, җирдә яткан гәүдәләр аша утка ыргылдылар. Җиңү тантанасы белән очраштылар.

Бүгенгесе көндә Баязит Аллаяров яшен тизлеге белән галәм гизми, сәгатьләр буе бер ноктада басып тора. Бүген ял көне, ә операция өстәле янында ял юк.

Хирург, беренче чиратта, реанимация бүлегенә[1] кагылды. Урамнан кергән киемнәрен алыштырмаганлыктан, авырулар янына узмады, алгы яктан шәфкать туташыннан сорашты:

— Кичә кич китергән егет ничек?

— Теге... мие янганмы?

— Әйе.

— Исән әле...

Андыйлар минутында үләләр, бу әле исән. Исәнлеге, әлбәттә, чагыштырмача. Яшенле яңгырда калып, югары көчәнешле электр чыбыклары тоташтырылган трансформатор будкасына кергәннәр. Егетләрнең икесе утырып торган, бусы аяк өсте. Күрәсең, стенага сөялгән, мие утәдән-утәгә ток белән тишелгән, пуля очып чыккан кебек. Аңына килә алмастыр. Медицинаның һәр очракта көче җитсә, беркем дә үлмәс иде.

Хирург ян баскычтан күтәрелеп, үз бүлмәсенә шым гына узарга теләсә дә, шәфкать туташлары очрады, авырулар күренде. Һәммәсе елмаеп, башларын түбән иеп исәнләштеләр. Баязитның күз алдында түбәнге катта һушсыз ятучы пәһлеван егет. Елмаюлар хирургның ачуын китерә.

Аллаяров кабинетка керде, күлмәген салып, ак халат, башлык, җиңел башмак киде. Кием алыштырырлык кына вакыт биреп, ишек шакыдылар. Дежур врачның кыяфәтен күрү белән, Баязит үзенә яңа эш табылуын сизде.

— Анда бер авыруны китерделәр,— диде Идрисов,— хәле бик авыр. Карамассыз микән?

Ял башланды, дип уйлап куйды Баязит, бәхетсез очраклар ял көннәрендә күбрәк булучан.

Аллаяровның уйларын тыңлагандай, Идрисов элек әйткәннәренә өстәде:

— Направление белән. Тарсубайдан фельдшер үзе алып килгән.

Фельдшер үзе алып килгәч, җитди очрак, димәк. Хирург хәзер барачагын әйтте, Идрисов борылып чыгып китте. Аллаяров аның артыннан ук кабул итү бүлмәсенә төште.

Ак җәймә җәелгән сәкедә ятучы ир кешенең күзләре эчкә баткан, күз төпләре кара янган, сызлануы йөзенә чыккан. Фельдшер кыз кыскача гына авыру тарихын сөйләп бирде. Сәгыйтов Сабит, утыз алты яшендә, оператор булып эшли. Озак вакыт эч авыртуы белән интегә, саруы кайный, авыз тәме юк, соңгы көннәрдә еш коса. Температурасы югары түгел. Баязит башта авыруның пульсын санады. Пульс сирәк. Эченең ашказанынннан түбән өлеше каучук сыман каты, тиресе күгәреп тора. Аллаяров авыруны операциягә салырга кушты.

— Ризамы?— дип сорады үзеннән.

Сәгыйтов берни белән кызыксынмады, сораулар бирмәде, ризалык белдереп баш кына какты. Аның карашы «Бу газаптан ничек котылсам да барыбер» дигәнне аңлата иде. Хәзер ул бернинди Сәгыйтов та түгел, оператор да түгел, бары тик авыру.

[1] Реанимация бүлеге — үтә авыр хәлдәгеләр өчен махсус бүлек. Мөһим органнарның эшчәнлеген тергезү аппаратлары белән җиһазланган.

Авыруны тәгәрмәчле биек сәкегә яткызып, лифт белән икенче катка күтәрделәр. Аллаяров дежур сестрадан өенә шалтыратуын үтенде. Теләге булса, Дәлия машиналы танышлары белән Дәрья-күлгә бара торсын, үзенең исә өйләдән соң гына бушаячагын әйтергә кушты. Шалтыратырга хәзер вакыты юк, дөресрәге, хатыны белән озаклап аңлашасы килми, авыруларның хәлләрен беләм дә кайтам дип киткән иде. Шәфкать туташы баш кагып, йомышны үтәячәген белдерде. Хирургның хатынына ул берничә тапкыр шалтыраткан булса да, үзен якыннан белми. Медицина хезмәткәрләре өчен үткәрелгән тантаналы кичәләрдә күргәне бар. Күзгә ташлана торган чибәр ханым. Иреннән шактый яшь күренә. Чынмы-ялганмы, алар турында хирургия бүлегендә төрле сүзләр йөри. Имештер, Аллаяров ординатурада укыганда санитарка кыз белән шаярган. Эшләр зурга киткәч, үз хатынын ташлап, әлеге кызкай белән яшь шәһәргә килгән. Җил исми агач селкенми ди, бәлки чындыр, кем аның төбен тикшереп йөргән. Сестра телефон трубкасын алып, хирургның йомышын әйтте дә, җавап көтмичә үк әлеп тә куйды. Ни сәбәптәндер, хирургның хатынына аның күңеле ятмый.

Баязит операциягә әзерләнеп, кулларын юганда, Дәлия турында уйланды. Хатынының яшь гомере Аллаяровның эшкә йөргән юлын күзләп узды дисәң дә була. Күңел ачулар тәтемәде аңа. Дөрес, Дәлия үзе дә эшли, әмма аның эше тәүлеккә җиде сәгать белән чикләнә. Ялгыз йөрүне килештерми, театр-киноларга да сирәк бара. Баязит исә тәүлекләр буе больницадан чыга алмый. Аның күңел салган эше шунда. Җәй узып бара, су коенганнары юк, бүген уйланган сәфәр дә барып чыкмады.

Баязит юынуын тәмамлап, операция халаты кигәндә, патологоанатомны[1] ияртеп, Идрисов килде. Аллаяров аңа юынырга кушты: хирурглар телендә бу «ассистентлык итәрсең» дигән сүз.

Авыруның эчен кисеп, кан юлларының очларын төенләүгә, Идрисов та юынып беткән, күрешергә теләгән сыман, кулларын алга сузып килә, клеенка алъяпкычы идән буйлап өстерәлеп, чат-чот итә. Патанатом операция барышын кызыксынып карап тора. Ачып карагач, операция ясарлык булмаса, протоколга кул куярга чакырган аны Идрисов. Авыруның тышкы кыяфәтенә караганда өмет аз иде, эчен ачып карагач, баштагы фикер расланды: эчәкләре карайган.

— Синең эш түгел бу, Аллаяр.

Морг докторы операциянең файдасыз икәнлегенә ишарәли.

— Карарбыз, күрербез,— ди Аллаяров. Бу аның үтә житди очракларда әйтелә торган сүзе. Карайган эчәкләрне кискәндә Баязит фронтта булган бер очракны хәтерләде. Яралыларны дыңгычлап тутырган брезент япмалы машинада кайсының кулы юк, кайсының аягы... Бер мең тугыз йөз кырык икенең август ае иде ул. Батарея Сталинград ягына хәрәкәт итә. Тирә-як шыр дала, кечерәк куаклык әсәре дә күренми. Орудиедән-орудиегә ике йөз метр ара калдырып, ачык даладан баралар. Кинәт дошман самолетлары пәйда булды. Каршыдагы авылга чаклы өч чакрым чамасы ара уч төбендәге кебек ап-ачык. Орудие командиры сержант, дары исе иснәмәгән яшь егет, атларны куарга команда бирде. Солдатлар лафетка чатырдап ябышканнар, атлар чаба, күзгә ак-кара күренми. Янәшәсендәге сержантка Баязит киңәш йөзеннән, җиргә төшеп, чокыр-чакырга яшеренергә тәкъдим итте. Ат белән самолеттан качып булмаячагы һәркемгә билгеле. Сержант кушаяклап чапкан атларны чыбыркылавын дәвам итте. Ул арада самолетлар бомба коя башладылар. Күк йөзе чуарлануын күргәч, Баязит яшелле-күкле тавыш белән кычкырды:

[1] Патологоанатом — мәетне тикшереп, авыру турында соңгы белешмәләр бирүче.

— Җиргә төшегез, егетләр, яшеренегез!

Кайсыларыдыр җиргә сикерде, кемнәрдер аттан төшми алга чапты. Баязит белән сикергән солдатлар төрле якка сибелделәр. Бераз йөгергәч, Баязит снаряд чокырына тап булып, шунда кереп сеңде. Әйләнә-тирәне саңгыраулатып, бомбалар ярыла башлады. Баязитның баш өстеннән снаряд ярчыклары сызгырып оча. Күпмедер вакыт узгач, шартлау тынгандай булды. Баязит башын күтәрде, үз пушкасын эзләп, юлга карады. Ерак түгел бер ат койрыгын болгап тора, ни алга, ни артка бармый. Лафет җимерекләре, җирдә яткан гәүдәләр... Берсе бер кыймылдамый. Үлеләрме, тереләрме? Баязит чокырдан чыкты, миңгерәүләнгән башын бераз селкеп торды да орудие янына китте. Туфрак белән катнашкан гәүдәләрнең йөзләрен өскә әйләндереп карады. Берсе дә исән түгел. Сержантның баш сөяге челпәрәмә килгән. Баязит белән бергә сикергән солдатлардан берәү исән икән, бу якка атлый. Немец карчыгалары китеп өлгермәгәннәр, исән солдатларны күреп, берсе яңадан өскә килә башлады. Ике солдат ике якка ташланды. Якында елга күренә, ләкин Баязит аңа барып җитә алмады, беренче очраган чокырга сикерде, тузан бөртегенә әйләнердәй булып, җиргә елышты. Самолет түбән үк төшеп, пулеметтан сиптерә башлады. Монысын бетердем дип уйлагандыр, икенче солдатны эзләп китте. Баязит шушы минуттан файдаланып, елгага карый чапты. Тыны кысылып, елга ярына җитсә, яр шундый биек һәм текә, сикерсәң, аяк-кулың сынуын көт тә тор. Ә карчыга кабат Баязит өстенә килә. Ул арада Баязит елгага аркылы килеп тоташкан уентык шәйләп алды. Яшен тизлеге белән шунда ыргылды, тал төбенә кереп чумәште. Мессершмитт пулеметтан сиптерә генә... Пулялар уентыкның каршы як ярына выжлап оча, Баязит ягы ышыкта кала. Немец моны абайлап алды да, чокырның теге ягына чыкты. «Үткен күзле, ләгыйнь», дип уйлады Баязит, туп булып, каршы ярга тәгәрәде. Хәзер пуля яңгыры Баязит биш секунд элек яткан җиргә ява. Самолет янә Баязит каршысына чыга, ә Баязит икенче якка тәгәри... Тычкан белән шаярган мәче сыман шулай шактый азаплагач, соры карчыга түбән үк төште дә, коточкыч сирена сызгыртып, солдат өстенә куна башлады. Бетүем шушы, дип уйлады Баязит, бер бомба — и хуш, дөнья!

Гаҗәпкә каршы, карчыга ачыргаланып бер үкерде дә, килгән ягына очып китте. Баязит үзенең исән калуына ышанмыйча, озак кына кузгалмый утырды. «Күрәсең, патроны беткән, бомбасы да калмаган», дип уйлады немец турында, үзенең исән икәнлегенә төшенә башлап.

Өметсез күренгән Сәгыйтовка операция ясаганда Аллаяров әнә шул йөрәк өзгеч вакыйгаларны хәтерләде. Ул чакта фашист һәр совет солдатын аулады, берсен дә исән калдырмаска тырышты. Кеше гомере бик кадерле, хәзер синең кулыңда, хирург...

Хирург карайган эчәкләрне кисә торды, идәндәге таска сала торды. Элпәле олы тас туп-тулы. Каршысындагы ассистентка күз төшерсә, тегенең йөзе ап-ак, үзе исерек сыман чайкалып тора.

— Форточка янына бар, саф һава сулап кил.

Идрисов форточка янына чыгудан баш тартты. Мондый мәсхәрәгә калуын ишетсәләр, иптәшләре күз ачырмас.

— Бүген төнлә начар йоклаган идем,— дип акланып алды ул.— Операция сестрасы Фәрханә шаяртып кына кызыксынып куйды:

— Берәрегезнең туган көнен билгеләдегезме әллә?

Ассистент уфтанып алды:

— Безнең туган көннәр узды инде. Бәби алып кайттым бит, көне буе йоклый да, төне буе елый.

Идрисовның тәмәкене ташлап йөргән чагы. Хәзер медицина институтларына тәмәке тартучыларны алмыйлар икән, дөрес эшлиләр.

Игътибарын Фәрханә бүтән якка юнәлткәнгәме, ассистент бик тиз

элекке хәленә кайтты. Җәрәхәт эченнән карайган кепшәләр тагын-тагын чыккач, ассистентның йөзе кабат ак кәгазь төсенә керде. Хирург, гаҗәпләнеп һәм кызганып, ярдәмчесенә карап-карап ала. Дөресен әйткәндә, Баязитның үзенең дә мондый хәлгә гап булганы юк. Нечкә эчәкнең исән өлеше бер метр чамасы гына. Яшәр дип ышандырып булмый, киресен әйтү җиңелрәк. Шулай да ятып калганчы, атып калу яхшы. Кеше табигате — кара урман. Урмандагы яфракларны һәм тамырларны санап булмаган кебек, кешенең эчке тереклеген дә исәпкә алып бетерү мөмкин түгел. Саламга тотыну суга батучыга ярдәм итми, дигәр руслар, ә менә хирургка шундый салам кисәгенең дә файдасы тиеп куя. Баязитның уйлары кырык икенең август мәхшәренә китте. Дүрт санын исән алып чыга алмады ул аннан, санчастька барып әләкте. Бөтен орудиедән исән калган берничә бөртек кеше шундый ук югалтулар кичергән батальонга кушылды. Карчыгалар тын алырга ирек бирмәделәр, әледән-әле өскә куна тордылар. Берсе утлы тырнаклары белән Баязитның уң кулын әләктереп алды. Старшина белән янәшә ауганнар. Старшина яңа гына госпитальдән чыккан егет, күкрәге тулы орден-медальләр. Ядрә ярчыгы аның башына тигән. Баязитның туктаусыз кан аккан беләгенә яшь кенә кыз жгут салды, җәрәхәтен бәйләде. «Аягыгыз исән, авылга барып җитәргә тырышыгыз,— диде ул, старшинаның маңгаена бинт ураганда,— анда безнең санмашина бар». Кыз үзе бүтән яралылар янына йөгерде. Авылга җитәргә чакрым ярым чамасы гына, ләкин ачык дала дошман прицелендә, үтүе мөмкин түгел. Үтә хәлсез старшинаны ияртеп, Баязит уйсулык аша урап барырга булды. Авылга ул караңгы төшкәч, ялгызы гына барып җитә алды. Старшина утлы көл булып далага чәчрәде. Дошманга уңай мишень ясамас өчен, алар бер-берсеннән ераклашыбрак шуышалар иде. Баязит үзенең җитезлегә аркасындамы, бәхетле очрак беләнме, тамугтан тере чыкты. Авылда яралыларны машиналарга төяделәр дә төнлә белән госпитальгә озаттылар. Баязит ашык-пошык бәйләнгән бинт арасыннан эчәкләре асылынып чыккан солдат белән янәшә баскан. Машинада ятар урын юк. Солдатны ул сул кулы белән кочып, аның җәрәхәтен үз тәне белән каплап барды. Кан кемнән ага — күршесеннәнме, Баязитның үзеннәнме, аерырлык түгел. Машинадагы бөтен сыкраулар Баязит йөрәгенә килеп бәрелә. Арада аның җәрәхәте бүтәннәрнекеннән җиңелрәк.

Госпиталь дигәне — брезент палаткалар. Палаткаларда җыелмалы өстәлләр. Алты-җиде өстәлгә — үсмер кызга охшаган бер хирург. Күрәсең, институт эскәмиясеннән генә килгән.

— Кисәбез,— диде кызый, Баязит үз аягы белән өстәлгә килеп яткач,— югыйсә, үзәк госпитальгә барып җиткәнче гангрена башланачак.

Баязит риза булмады. Мәктәптә укыганда очучы булырга хыялланыуы исенә төште. Карышырга бер сәбәп, янәсе. Югыйсә, кул кемгә дә кирәк.

— Ул чакта кәтәргә туры килә, ярчыкларны чүпләү озакка китәчәк, авыр хәлдәгеләр күп,— диде кызый кискен итеп. Баязит өстәлдән төште. Палаталар ышыгында җиргә ятып, йөзәрләгән солдат чират көтә. Баязит та үз палатасы янына бер кырыйга барып сул ягы белән ятты. Бер йоклап, бер уянып, саташу катыш озак вакыт үтте. Икенче көннең кояшы түбәнәйгәч, операция өстәле янына иң соңгы кеше булып килде.

— Чыдарыгызга ышансагыз гына алынам,— диде кырыс кызый. Анестезия дарулары беткән икән.

— Үлгәнче тырышырмын,— диде Баязит. Сүзендә нык торды. Кызыйның тамарга әзер карлыгандай күзләре бүгенгедәй хәтерендә.

Тәвәккәллеккә Баязитны фронт өйрәтте. Үзәк госпитальдә сугыш-

тагыдан да коточкычрак күренешләргә тап булды ул. Яшәү өчен көрәшнең кискенлеге монда алгы сызыктагыдан һич ким түгел иде. Сугышта — генераллар һәм солдатлар, ә госпитальдә — хирруглар һәм солдатлар. Һәр ике як бер максатка омтылганда гына җиңүгә ирешергә мөмкин. Баязитның кулы шулай сакланып калды. Җәрәхәтнең ни икәнен үз тәнендә татымаган врач сызлауның ни икәнен Баязит кебек үк аңлый алмыйдыр. Әллә шуны уйлап, иң авыр операцияләргә Баязит үзе алына. Позицияләрне көрәшсез бирмик әле, туганкай, дип кабатлады Баязит күңеленнән. Операция тәмамлануга таба бара. Бәлки яшәп китәр кеше. Теге чакта фашист һәр совет солдатын аулады, берсен дә исән калдырмаска тырышты. Кеше гомере бик кадерле.

Баязит операциядән соң юынып, көндәлек ак халатын кигәндә, күз бәйләнеп килә иде. Операционныйдан ул туры кабинетына узды, өстәл артына утырды, ике кулы белән күзләрен каплады. Аның хәзер берни турында да уйлыйсы килми. Хирургның теләү-теләмәвен сорамастан, сестра чәй кертте. Аллаяров аңа күтәрелеп карамый гына рәхмәт әйтте. Аның хәзер сыкраган аякларын сузып ятасы килә. Моның өчен өйгә кайтырга, Дәлиянең сытылган чыраен күрергә (күл буена ялгызы китмәгәнен Баязит белә), нидер аңлатырга кирәк. Хәер, Дәлия күптән инде аңлатулар таләп итми, күнекте дисәң дә була. Ләкин моңа карап хатынның күңеле күтәрелми. Бу хакта уйламас өчен Баязит, иреннәрен пешерә-пешерә, пыяла стаканнан кайнар чәй эчә башлады. Иртәгә якшәмбе, ул-бу булмаса, Дәрья-күлгә китәргә мөмкин. Җәй узганчы бер булса да туйганчы коенырга, урман һавасын сулап кайтырга...

## 2

Якшәмбе көнне иртән Аллаяровлар парлап «Дәрья-күл» санаториясенең шәһәрдә яшәүче хезмәткәрләрен йөртә торган автобусы белән юлга чыгып киттеләр. Дәлия Баязитка сыенып утырган. Дару исе сеңгән шифаханәдән аерып, ирен табигать кочагына алып чыгуына ул чиксез шат. Улларын институтка озаткач, Баязитны ул бала урынына бага. Баязит та гаилә тынычлыгының кадерен белеп яши. Кушылганчы күп хәсрәт чигәргә туры килде аларга. Яшьләргә килеп урнашкач та әле аңлашылмаучылыклар байтак булды. Бигрәк тә Баязитнең «сөекле» этләре аркасында. Дәлия шулай атый аларны. Әййе, этләр белән Аллаяров әкәмәт булып бетте. Институтта чакта ук аңа фән юлы юрыйлар иде. Ә ул, иптәшләрен һәм укытучыларын гаҗәпкә калдырып, фән үзәгеннән яшь калага китеп барды. Тынгысыз хирург монда да кул кушырып утырмады, малайлар тотып китергән урам этләренә операция ясап, тәҗрибәләр үткәрде. Баштарак нейрохирургия буенча, баш миенә. Киселгән кан тамырына уңышсыз операциядән соң, кан тамырларын тегү буенча эзләнә башлады. Тезелештә югары катта тәрәзә пыяласы ватылып, яшь кенә егетнең беләгенә килеп төшә, зур кан юлы (вена) киселә. Хирург кан тамырын ялгап тегә. Ләкин кулның теккән җирдән түбән өлеше акрынлап күгәрә башлый, кан сүлпән килә. Хирург тәүлекләр буе больницадан чыкмый, подвалда, этләр белән кайнаша. Яңача тегү инструменты уйлап таба. Дөресрәге, элек кулланыла торган инструментка шактый җайланмалар, өстәмәләр куя. Ике атна да үтми, яңадан кан юлы киселү очрагы... Хирургиядә парлылык турында Аллаяровның күп ишеткәне бар. Сирәк очрый торган бер авыру килеп чыкса, тиз арада нәкъ шундый очрак буласын көт тә тор. Яшь хирург әлеге серле парлылыкка тап булды. Бу юлы ул кан тамырын үзе тапкан ысул белән текте. Яна инструментның иң мөһим өстенлеге — тамырны теккән чакта да кан йөреше туктамый. Егетнең кулы бер дигән булып

төзәлде. Ә маэмайлар, идән астыннан чыгып, төрле якка сибелделәр. Дәлиянең: «Мендәреңне күтәреп, сөекле көчекләрең янына күченеп кит»,— дип әрләвенә түзәргә була иде әле. Больница территориясендә антисанитария урчеткән өчен баш врач каты шелтә чәпәде. Махсус шартлар булмау сәбәпле, тәҗрибәләр катгый тыелды. Хирург кунарга хатыны янына кайта башлады.

Иген басулары аша сузылган шома асфальт юл урман аланлыгына кергәч, кырт өзелде. Йөзьяшәр наратлар урман серләрен читкә чыгармый гына, башларын бер-берсенә игәндәй итеп, үзара пышылдашалар. Кемнәр килә тагын, бүгенниләр күрәбез, диләр сыман. Үзләренә күтәрелеп карасаң, үрә катып, шып булалар. Урман юлына аркылы баскан челтәрле тимер капка янында автобус тукталды. Ян капкадан кереп, хезмәткәрләр эш биналарына, Аллаяровлар исә күл буена юнәлделәр. Көн иртә әле, ял итүчеләр иртәнге ашларын ашамаган. Күлне ураган сукмак буйлап, тәннәренә сыланган зәңгәр трико кигән йөгерүчеләр күренә. Гәүдәңнең нindiлеген күрсәтер өчен бер дигән кием, асылынкы-салынкы урыннарын яшерә алмыйсың. Тирләгән борынлы, сары башлы олы үрдәккә охшаган ханым йөгерергә азаплана. Зифа буйлы сылулар күз алдыннан тиз югала, карап калырга да өлгермисең. Наратлы яр өстеннән күл кырыена төшкәч, Баязит үзен төсле фильм карагандай хис итте. Күкне чагылдырган күл өсте яшькелт-зәңгәр. Биек наратлар өстеннән үрелеп, кояш аңа биниһая алтын таңкәләр сипкән. Акрынайтылган хәрәкәт белән кадрны тотырып баручы теге ханым гомум күренешне шактый боза бозуын. Суга сикерә торган басма өстендә купальниктан гына камыш сабагыдай кыз басып тора. Ул аз гына янтайган да, озын толымының очын урә. Әйтерсең толымын кояш нуры белән аралаштыра. Кыз үз турысыннан узып баручыларга борылып карады. Аның карашы да күл шикелле кара кучкыл-зәңгәр иде. Дәлия аның белән баш иеп исәнләште. Кыз да җавап итеп, кояш нуры кунган керфекләрен тибрәтеп алды.

— Кем бу? — дип сорады Баязит, шактый ара киткәч. Дәлия елмаеп, иренә күз төшерде. Баязитның тавышында дулкынлану сизелә иде.

— Актриса.

— Ә-ә. Танышсызмыни?

— Сәхнәдән күреп таныйм.

Менә ни өчен Баязит күл буен төсле фильм белән чагыштырган! Басма өстендә — артистка. Әлбәттә, ул үзен берәр рольдә итеп сизә. Бераз дәшми баргач, хатыныннан тагын сорап куйды:

— «Яшьләр»дәнме?

— Нәрсә?

— Нәрсә» түгел, «кем». Артистканы әйтәм. «Яшьләр»дә яшиме?

— Тагын кайда булсын, мин бит театр карарга Парижга йөрмим.

Артистка турында төпченеп сорашу Дәлиягә ошамады, ахрысы, Баязит бүтән сорау бирмәде. Күл эченә кереп торган басмаларның берсе янында алар чишенделәр. Баязит күл кызы ягына күз төшерде. Артистка толымын баш түбәсенә өеп, чәчен ак резин башлык белән каплап маташа. Су коенырга җыена, димәк. Баязит ирексездән Дәлияне актриса белән чагыштырды. Яшь чагында Дәлия аңардан матуррак иде, хәзер гәүдәгә аз гына калынаебрак китте. Йөзенә карaганда артистканы да матурлар рәтенә кертеп булмый. Әмма карашы тәэсирле. Күзе кара булса, «көйдереп ала» дияргә булыр иде...

Газеталар өстенә йомшак сөлге җәеп, бер-берсенә якын ук килеп утырдылар. Дәлиянең йөзенә киң кырлы эшләпә күләгәсе төшкән. Баязит үзенә кәгазь калфак ясап киде. Су чупылдаган тавыш ишетелде. Актриса колач салып, күл уртасына таба йөзә. Баязитның да

каерылып-каерылып йөзәсе килде, әмма тыелып торырга булды. Дәлия йөзә белми, аңа танышы алдында уңайсыз булыр. Су кызы китсен инде. Күл ягыннан күтәрелгән кояшка аркасын куеп, Баязит Дәлия янәшәсенә сузылып ятты. Озын толымлы артистка аңа Казандагы бер кызыйны хәтерләтте. Баязитның беренче операциясе. Беренче мавыгуы дисәң дә була.

Яңа ел алды иде. Баязит Вишневский клиникасында практика уза. Коридорда ул елап утыручы бер кызны шәйләп алды. Янына барды, ни булуын сорады. Буйлы халат кигән кыз, яшенә төелә-төелә, үзенең хәлен сөйләп бирде.

— Аппендицит белән кергән идем... Доктор операциянең кайчан буласын да әйтми. Минем елкага барасым килә...

Кыз тагы үксергә тотынды. Баязит янәшә утырды.

— Тынычланыгыз әле... Мин доктор белән сөйләшеп карармын... Яңа ел бәйрәменә терелеп тә чыгарсыз...

Икенче көнне ул бу хакта үзенең укытучысы профессорга сүз катты. Операцияне миңа ясарга рөхсәт итегез, диде. Яков Свердловныкына охшаган матур сакалын сыйпаштырып, профессор аны шаяртып алды:

— Карыйк, нинди гүзәлгә күзең төште икән?

Икәүләп кыз яткан палатага киттеләр. Обход вакыты иде, бар да үз караватларында. Баязит кызның озын толымнарына, ап-ак муенына әле генә игътибар итте, профессорның сүзләрен исенә төшереп, колагына чаклы кызарды. Палатадан чыккач, профессор һич шаярусыз әйтте:

— Зәвыгың әйбәт, егеткәем, миннән сиңа хәер-фатиха, яхшылап кис кызыйны.

Баязит тагын кызарды.

Билгеләнгән көндә операция җиренә җиткерелеп эшләнде. Гадәттә авыруларга күрсәтелә торган игътибар кызга да күрсәтелде. Авыруны больницадан чыгарыр вакыт җитте.

— Ә минем чыгасым килми,— диде кызый, сабыйларча иренен турсайтып.

— Яңа ел кичәсендә катнашырга теләгән идегез бит. Берсекөнгә утыз бере... Бии алмассыз, әлбәттә, иртәрәк булыр...

Савыккан кызга кайтырга җыенудан башка эш калмады. Киенеп беткәч, коридорда сагалап торып, хирургның каршысына төште:

— Яңа ел кичәсенә килерсезме безгә? Беркем дә булмаячак, эти дә әни генә... Алар да чакырулы.

Баязит бераз уйланып торды да, бәлки барып та чыгармын, диде. Ошый иде аңа кыз. Болай гына дию аз булыр, тәмам башы әйләнгән иде Баязитның. Өйләренә барса, мәңге шунда торып калыр төсле иде. Моны ул кыз больницадан чыгып киткәч сизде. Ап-ак тәнле ялангач еын төшенә керде, муенына сарылды. Үзенең дә бөтен барлыгы белән аңа тартылуын тойды. Декабрьның утыз бере җитте. Кичәгә бару-бармау хакында Баязит кызыйга шалтыратырга тиеш. Барырмы, юкмы — Баязит әле үзе дә белми. Урамда очраган телефон будкасы янында туктальп торды. Озын чират тезелгән. Ары китте. Бер генә будка да буш түгел. Моңа Баязит хәтта шатлана иде бугай. Хәзер генә трубканы күтәреп, ни дияргә белми бит әле ул. Шулай урам буйлап йөри торгач, бер будкага да кермәде. Яңа елны паркта, җем-җем килгән чыршы янында, урам халкы белән бергә каршылады. Гүзәл затның ялангач тәненә орынудан туган тиле хисне практикант Аллаяров шулай җинде.

Кояш кыздыра. Баязит, башын калкытып, тирә-якка каранды. Яр буенда бер кем калмаган.

— Су коенып чыгабызмы?

Ир белән хатын җитәкләшеп, суга керделәр. Дәлия басмага тотынып чупылдаган арада, Баязит колачлап йөзеп әйләнде. Һавадан, судан, кояштан кирәкле микъдарда нур һәм дәрт алгач, урман буйларын урап килергә булдылар.

Җиләкле тау буена җиткәч, яшь егет белән кыз сыман, урман буенда җитәкләшеп йөрделәр. Бер-берсенә карашып елмаештылар. Баязит — сокланып, Дәлия сөенеп карады. Ирен аяк-кул сынган җирдән ерак алып киткәненә сөенде. Баязит кояшта кипкән җир җиләкләре белән озаграк мавыкса да, Дәлия аны икенче якка ашыктырып әйдәде. Эзләп табарлар да, Баязитны аерып алып китәрләр кебек, кеше-кара очраса, читкәрәк качу ягын карый. Тышаудан ычкынган тайлар сыман болыннан болынга күчеп йөрделәр, ул-бу булмады. Имин дөнья нинди матур, нинди рәхәт. Иртән килгәндә шомлы күренгән наратлар да тынычланган, җиләс кичтә оеп калганнар сыман. Бер кем авырмый, бар да сәламәт, бар да бәхетле.

3

Иртән — Баязит урыныннан тормаган иде әле — телефон шылтырады. Баязит ашык-пошык киенде дә, чәй дә эчми чыгып китте. Ашыгыч ярдәм машинасы белән алтмыш бер яшьлек картны алып килгәннәр. Пульс сизелер-сизелмәс, кан басымы түбән. Йөрәге еш тибә. Бораулаучы. Моңа чаклы үзен таза дип йөргән, пенсиягә чыгып, бер атна үтүгә, дизентерия бүлегенә барып эләккән. Төнлә бик авыртынгач, иртән монда алып килгәннәр. Авыруның эчен капшап караугa, ашыгыч операция кирәклеге беленде.

Әзерлекне тиз тоттылар. Аллаяровның диагнозы расланды: перитонит. Аны чистартуга ике-өч сәгать вакыт узды. Ашказанында һәм бүтән урыннарда рак метастазалары. Кисәсен кисеп, авыруның сул ягына торба чыгарудан гайре хирург берни эшли алмады. Кеше соң чиккәчә эшләп йөргән. Эштән бушангач кына чир үзен нык лап сиздергән. Бу чиккә җиткәч, медицина көчсез...

— Шул авыруларың дип, үзең бетәсең бит инде, иртән дә ашамый киттең...

— Рәхмәт, әни, булды.

Баштарак Баязит Дәлиянең әнисенә Кәүсәрия апа дип дәшә иде, үз анасы вафат булганнан соң «әни»гә күчте.

— Бүген минем төнге дежурство, бераз ял итеп алам.

Шифаханәгә якынлашканда Баязит морг ягыннан килүче ике практикантны күреп алды. Тегеләр Баязитка таба йөгерә үк башладылар. Килеп җиткәч, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләп киттеләр. Иртәнге картны чыгарып куйганнар икән. Хирург китеп, ярты сәгать тә үтмәгән, дөнья белән бәхилләшкән. Баязит сәгатенә күз төшерде. Сәгать дүрт. Егетләрне тагын нидер дулкынландыра иде бугай, аяк өсте таптанып торалар.

— Тагын нинди хәбәрләр бар?

— Бер дә үлгән кешегә охшамаган ул, Баязит абый.

— Ничек охшамаган?

— Йөзе алсу...

— Ә йөрәге?

— Тып-тын.

Баязит кулы белән «әйдә, алып барыгыз» диган ишарә ясады. Егетләр алдан йөгерделәр, Баязит алар артыннан китте. Салкын таш бинага керделәр, сәкедә яткан мәет янына килделәр. Чыннан да, мәетнең төсе гадәти түгел. Сөрем белән агуланган кешеләрнең йөзе

шулай алсу була. Монда тизәк перитониты махсус агу чыгарган, күрәсең, агу табигый төсне саклап тора. Аллаяров егетләргә шуны аңлатты. Ләкин сүз белән чикләнү ярамастыр. Булачак хирурглар кисеп, тотып карарга тиешләр. Аллаяров махсус халат киде. Мәетнең сулышы барлыгы-юклыгын, пульсын тикшерделәр, йөрәген тыңладылар. Тормыш әсәре юклыгына ышангач, патанатом белән бергә мәетнең күкрәк читлеген ачтылар. Йөрәк хәрәкәтсез. Практикантлар аны куллары белән тотып карадылар. Шулай күрсәтеп бирмәсәң, яшь хирургларда шик калуы мөмкин.

Аллаяров тирәклектә адашып калгандай атлый. Үлем очрагы, хәтта котылгысыз икәнлеге алдан билгеле булса да, аңа һәрвакыт авыр тәэсир итә. Шимбә көн биш метр эчәгесе кисеп алынган авыруны исенә төшерде. Ул ни хәлдә икән? Студентларны ияртеп, хирург реанимация бүлегенә керде. «Үлгәннәрне терелтә торган бүлмә» дип йөртәләр икән халыкта бу бүлекне.

Операциядән соң авыру өченче тәүлек яши. Температурасы югары тора, пульс ялкау. Зарланмый, үзен нык тота.

— Терeләбезме?

Икесе бер сүздән булуларына ишарәләгәндәй, хирург авыруга күз кысты.

— Терeләбез, Баязит абый.

Авыруның тавышында киеренке көрлек.

— Һичшиксез терeләсең, — диде Аллаяров, сүзенең ихлас икәнлегенә шик калдырмаслык итеп. «Менә шулай, бер-беребезнең кәефен күтәреп яшибез инде», дип уйлап куйды. Сестрага күрсәтмәләр биреп, хирург өске катка күтәрелде.

Коридорлар, палаталар буйлап эзли торгач, хирург үзәктән килгән кунакка тап булды. Аллаяров белгечнең монда киләчәген белә иде инде. Хирурглар көч сынашкандай кулларын кысышып тордылар. Баш хирургның кулы шактый нык икән, дип уйлап куйды яшь белгеч.

Кабинетка кереп, өстәл янына утырырга да өлгермәделәр, ишек шакып, рөхсәт көтмичә үк йончыган йөзле хатын килеп керде.

— Баязит Алмасич, сез мине алыгыз инде...

Хатынның тавышы калтырап чыга.

— Мин бит баш врачка барырга куштым.

— Бардым, ул сездән рөхсәт кирәк ди.

Аллаяров, телефон трубкасын алып, номер җыйды. Теге яктан озын гудоклар ишетелде. Иңенә шактый керләнгән ак бөркәнчек салган хатын һаман басып тора. Аллаяров аңа урын күрсәтте, тегесе ишек янындагы урындыкның читенә утыргандай итте. Аллаяров кабат номер җыйды.

— Мин кичә сезгә сөйләгән ханым турында сез беләсез инде, санитарка булып урнашырга тели. Вакытлыча. Яхшы. — Хирург трубканы элеп, хатынга әйтте: — Баш врач үзендә юк, хәзер сез аның урынбасары янына керегез, бүлмәләре янәшә аларның, үтенечегезне уңай хәл итәрләр.

Хатын кабаланып чыгып киткәч, Аллаяров ни өчендер эшнең нидә икәнлеген аңлатып бирүне кирәк тапты.

— Өч атна элек бер егетнең аякларын кистек, бот төбеннән үк. Янган иде. Өченче стадия. Ай буе дәваладык, уңышсыз. Казаннан махсус белгеч тә чакырдык. Ахыры летальный [1] диде. Ампутация белән коткарып калып булмасмы дип, тәвәккәлләдек.

Бу хатын энисеме икән, дип уйлады Гыйлфан, сүзнең аңа бәйле булуын аңлап.

---

[1] Летальный — үлем белән тәмамланачак.

— Бу хатын аның сөйгән яры, — диде хирург, гаҗиз калгандай, башын чайкап торды. — Эшеннән чыгып, ай буе егетне карады, хәзер менә безгә санитарка булып урнашасы килә, эшләми озак яшәп булмый бит... Авыру карау шулай йончыта, — дип өстәде, кунакның нидән гаҗәпләнгәнен төшенеп.

Тагын ишек шакыдылар. Сестра керде.

— Баязит Алмасич, сезне операция бүлмәсенә чакыралар.

— Ни булган анда?

— Сукыр эчәген таба алмыйлар.

Аллаяров күңелле итеп көлеп куйды:

— Олы юлга чыгып эзләсеннәр, килгәндә төшеп калгандыр.— Житдиләнеп өстәде: — Хәзер барам. — Хирург сөйләнә-сөйләнә урыныннан кузгалды.— Хамелеон кебек ул сукыр эчәк, кисеп ташлауларыннан куркып, нинди генә төскә керми. Сукыр эчәге кеше өчен кирәкмәгән әгъза дип ялгышабыз без, табигать кешегә бер артык, бер ким нәрсә дә бирмәгән.

Аллаяров кунакны алдан чыгарды, операция бүлмәсенә юнәлделәр. Юл уңаенда ачык ишек янында туктадылар. Палатада бер генә карават. Йөзе белән ишеккә карап яткан бөдрә чәчле егет сигарет пыскыта. Гыйлфан гаҗәпләнеп, Аллаяровка карады, тегесе егеткә мөрәҗәгать итте:

— Я, хәлләр ничек?

— Сызлый. Укол рөхсәт итегез.

— Өеңә кайткач нишләрсең?

— Сызлый шул,— диде егет, артык хафаланмый гына.

— Алай гына булыр инде.

Коридор буйлап ары киттеләр.

— Бая сөйләгән егет шушы инде.

Гыйлфан сискәнеп куйды. Ишек артында торып, авыруның аяк очына игътибар итмәгән икән. Бөдрә чәчле егетне кызганып, җаны әрнеп куйды.

— Ничә яшьтә?

— Егерме икедә.

Авыруның хәле белән кунакның кызыксынуын күреп, хирург дәвам итте:

— Консилиум җыйдык. Бер-ике врач ампутация ясамау ягында булды. Күзле бүкән булачак, ата-анасына гомерлек имгәк. Үзе баштарак кистерергә риза булса, түбәннәнрәк кисә идек, протез куярга була иде. Үлүем артык, диде. Үлә башлагач, мине чакырта, төн уртасында. Кисегез, яшисем килә, ди. Соңгы үтенечен кире какмадым. Өч атна яши, шулай яшәп китәчәк дигән сүз. Аллаяров соңгы җөмләсен горурлык кичереп әйтте.

Операция бүлмәсенә кергәч тә Гыйлфан егет турында уйланды. Нинди аяныч хәл. Аллаяров урынында булса, үзе дә соңгы чараны кулланмый калмаячак. Медикларның законы.

Операционныйда яшь кенә өч хирург авыру тирәсендә кайнаша, икесе кызлар. Практикантлар. Хирургның ирләр эше икәнлегенә алар әле күп тапкырлар ышанырлар. Сәгатьләр буе аяк өсте басып торуга, йокысыз төннәргә чыдаудан гайре монда беләк көче дә кирәк. Дөрес, күп очракта хатын-кыз чыдамрак була. Утыз процент кан югалтудан ирләрнең үлүе мөмкин, ә хатын-кыз илле-алтмыш процент югалтуга да түзә. Җирле анестезия[1] белән ясалган операциядә ирләр чыдам. Менә, бүгенге очрак. Үсмер егет. Сукыр эчәген ни гомер эзлиләр, ә ул ыңгырашмый да. Киңәш-табыш белән генә эш чыкмасын

[1] Анестезия — сызлауны сиздермәү чаралары.

күргәч, Аллаяров кулын юып, үзе эшкә тотынды. Гыйлфан чит кеше, карап торудан башкага ярамый. Хирургның үз ярдәмчеләре дә күп.

Шактый вакыт эзләп, «качкын»ны эчәге ярысы эченнән таптылар.

Операционныйдан чыккач, Аллаяров сәгатенә карап, гафу үтенгәндәй Гыйлфанга аңлатты: үзәк больницага консилиумга барасы бар, капкалап алырлык та вакыт калмаган. Иртәгә очрашу турында сөйләшеп, Гыйлфан да китәргә кузгалды. Көндезге ял сәгате икән, түбәндә ишекне ачкыч белән бикләгәннәр, дежурныйлар үзләре юк. Кабул итү бүлмәсе аша чыгарга булдылар. Аллаяров кунакны озын коридор буйлап алып китте. «Мине монда тотып калмагайлары»,— дип уйлап куйды хирург. Күңеле сизгән, ишекне ачып, бүлмәгә аяк атлавы булды, плащын һәм шәл очларын җилбәгәй җибәргән тәбәнәк буйлы хатын ике кулын сузып, хирургның алдына килеп басты:

— Кызымны коткарыгыз, зинһар, ходай хакы өчен...

— Ни булды?

Хатын алгы яктагы сәкегә күрсәтте. Авыру янындагы Касыймов хәлне аңлатты: аналыктан читтә йөккә узу. Егерме бер яшь. Кан агу көчле. Йөзе ап-ак. Монысын Аллаяров үзе дә күрә. Күңелсез хәл. Гинекология бүлегендә ремонт барганлыктан, мондый операцияләр вакытлыча хирургларга йөкләтелгән.

— Операцияне Касыймов ясар. Гинеколог чакырыгыз.

— Юк, юк, сез ясагыз, бары тик сез... Бердәнбер кызым.

Хирург кул сәгатенә күз төшерде дә, «хәзер минем өчен барыбер» дигәндәй әйтте:

— Ярый. Операция өстәленә.

Аллаяров кырт борылып, килгән ягына кире китте. Гыйлфан икеләнеп, баскан урынында таптанып торды да, хирург артыннан иярде. Үз бүлмәсенең ишеген ачарга тукталган Аллаяров аңа: «Син дә мондамени әле?» дигән караш ташлады.

— Әгәр рөхсәт итсәгез,— диде Гыйлфан, хирургның өнсез сорабына җавап итеп. Хирург нindidер ымлык әйтте. Бүлмәгә кереп, сөйләшмичә генә өс киемнәрен алыштырдылар, операционныйга юнәлделәр.

Мондый операцияләрдә Гыйлфанның күптән булганы юк. Мөселман илендә ирләрне хатын-кыз авырулар янына якын җибәрмиләр, ишек төбендә аталары яки җәмәгатьләре саклап тора. Яшьләргә күчеп киләме-юкмы, мондагы эшләр белән танышу Гыйлфанга зыян итмәс. Эш хакында хирургка сүз катарга һаман җай чыкмый. Хәер, кадрлар мәсьәләсен сәламәтлек саклау бүлеге белән баш врач хәл итә. Шулай да Гыйлфанга Аллаяровның фикерен белү мөһим. Хирург озаклап кулын юа. Шул вакыттан файдаланып, эш турында сүз чыгарырга мөмкин булыр иде. Хирург хәзер операция турында гына уйлыйдыр, аның игътибарын читкә җибәрү килешмәс.

— Кан анализы килдеме?

Касыймов:

— Тискәре резус[1]. Бездә бер генә ампула кан бар.

Аллаяровның йөзе караңгылана. Тискәре резуслар белән бәла. Авыруның каны күп югалган, үлү мөмкинлеге йөз процент.

Герметик савытларда парландырылган чиста халатлар киеп, операция өстәле янына киләләр. Ассистент Касыймовның халаты инде канга буялып беткән. Авыруның кан басымы 40, пульсы сизелми, эче кан тутырган ялгаш кебек. Аллаяровның сузылган кулына шәфкать туташы зур гына марля салфетка салды, хирург күтәрелеп карады. Аның гаҗәпләнгән карашына Фәрханә сүз белән җавап кайтарды:

---

[1] Тискәре резус (отрицательный резус) — сирәк очрый торган кан.

— Суырткыч кичә ватылган иде, төзәтмәгәннәр әле...

Хирург сүгенмәде, чиста савытлар сорады. Литр сыешлы банка әзер икән, салфеткага сендереп, хирург канны шул савытка сыга башлады. Ике литрга якын кан җыелды. Авыруның юан кан юлына үз каны кире керде. Аллаяровның үз табышы бу, үз җайланмасы. Канга кытлык чакта бер дигән ысул, юкка гына бүтән хирурглар санламый азапланалар. Мөгаен, инфекция кертүдән куркалар. Ләкин бит кулланыла торган бөтен нәрсә югары дәрәҗәдә эшкәртелгән, стерильно-чиста: марля салфеткалар, хирургның перчаткасы. Кан үзе сөзелә, чистартыла...

Үч иткәндәй, шәһәрдә анестезиологлар калмаган, бәрхет сезонны файдаланырга ялга киткәннәр. Өченче көн Аллаяров сәламәтлек саклау бүлегенә шылтыратты:

— Нигә бөтен анестезиологларны бер юлы ялга җибәрдегез?

— Ә сез үзегезнекен нигә җибәрдегез?

— Мин приказ чыгармыйм бит.

— Аның каравы, гаризага кул куясыз.

Дөрес сүзгә җавап юк. Үз көчләре белән ерып чыгарга туры килә. Гыйлфанга да эш табылды, наркоз өрдерүче интернга[1] алмашка күрек янына баса.

— Пульс сизелә башлады.

Барысының да йөзләре ачылып китте.

— Касыймовның халатын алыштырыгыз.

Тынлык. Яшь балага кидергән сыман, санитарка ассистентка арттан бәйләнешле чиста халат кидерә.

Операция тәмамланып килә. Баязит чигү чиккән кебек вак-вак атлатып, операция ярасын тегә. Авыруның яшәрме-юкмы икәнлеген Фәрханә хирургның җөй тегүеннән чамалый. Мондый чигүле тән белән яшәргә дә яшәргә! Җыештыручы санитарка да моны сизми калмый, аларның уй-фикерләре бөтен больница персоналына күчә, хирург операциядән чыкканчы ук авыруның туганнарына барып ирешә. Җыештыручы хатынның юыну бүлмәсенә чыгып баш чайкавы, янсә ишектән кергән шәфкать туташына шаяртып күз кысып алуы авыруның язмышын алдан билгеләп куя, чөнки аның күрәзәлеге күп очракта раслана. Әгәр инде расланмый икән, моңа ул гаепле түгел, ә операциядән соң кайбер катлауланулар эшне бозган булып чыга.

Аллаяров соңгы җеп очларын төенләде. Җиңел сулап, перчаткасын салыйм дигәндә, каталка белән тәгәрәтеп, шәмәхә трусик кигән егетне керттеләр. Аппендицит. Бүген сукыр эчәкләре шартлау көне, дип уйлады Баязит. Бер башласалар, шартлыйлар да шартлыйлар алар. Кылт итеп исенә төште: ай тулган көн. Күп еллык тәҗрибәсеннән чыгып белә: ай тулган көндә операция ясасаң, кан күбрәк югала. Андый көндә Аллаяров операцияләр планлаштырмый, үз юллары белән керүчеләр дә җитәрлек була. Бүген терапия бүлегенә йөрәк белән керүчеләр күп, травматологиядә — авариягә юлыгучылар. Аппендицитлы егет кергәч, Баязит «нишлибез инде?» дигән кебек, Фәрханәгә карап алды. Тегесе гаепле сыман күзен түбән төшерде. «Сезгә ясарга туры килә, Баязит абый», дию иде аның.

## 4

Шәһре Яшьләр, чыннан да, союзда иң яшь төбәкләрнең берсе икән. Кылычбаев кызыксынган фәнгә монда бәлки әллә нн җирлек тә юктыр. Теге көнне ничә операция булды, гел яшьләр... Шәһәрнең

[1] Интерн — институт тәмамлаганнан соң тәҗрибәле белгеч кул астында эшләүче врач.

сәламәтлек саклау бүлегендә Гыйлфан шундый фикер әйткән иде, аның белән тулысынча кушылмадылар, килергә өндәделәр. Казанда Кылычбаевны авылыннан килгән телеграмма көткән. Агасы каты авырый, тиз көндә кайтуын үтенәләр. Шушы телеграмма бәлки аның Яшьләрдән ашыгып китүенә сәбәпче булгандыр да, күңел сизенү дигән нәрсә бар бит ул. Авыл халкы тиктомалга казна эшендәге кешене телеграммалар белән чакыртмый, шуны уйлап, Гыйлфан Уралга очты.

Чит илдән отпускага кайткан елны ул агасының йорт-курасын караштырган иде. Искене сипләүдән әллә ни файда тапмастай булгач, агасына Гыйлфан яңа йорт юнәтергә акча биреп калдырды. Мәһабәт агач йортны тыкрык башына килеп кергәч тә күрде Гыйлфан. Койма-капка, абзар-каралты да байларныкы кебек, ялт итеп тора. Бөтен авыл белән өмә ясап салганнар. Тыкрыктан менгәндә каршы як күршеләре очрап, бәйнә-бәйнә сөйләп килде. Өмә сыена да мул тотынган агалары.

— Әмма ләкин үзе өзлегеп калды. Район врачына да, шәһәрнекенә дә бардылар. Операциягә ятарга кушалар икән. Яман чир башланган ди. Америкада да төзәтәлмиләр икән аны, дәүләт секретаре Даллес булып Даллес шуның белән үлгән ди бит. Израилга барып, миллиард сум түләгән, савыктыралмаганнар.

Авыл халкының океан аръягындагы шәхси вакыйгалардан хәбәрдар булуларына хәйран калыбрак, Гыйлфан дәшми генә тыңлап барды. Яңа капканы ачып кергәндә абзасының диагнозын ул белә иде инде. Кунакка шатлансалар да, өйдәгеләрнең йөзләре тиз тоныкланды. Үзләре дә беләләр, дип уйлады Гыйлфан. Агасы исә сер бирмәскә тырышты, гадәттә йомыграк кеше, өзми сөйләште. Кичке ашны ашап, тәмәке пыскытырга чыккач кына энесен чакыртып алуның сәбәбенә кагылысы итте.

— Үзеңне дә бик күрәсе килгәние. Син бит зур доктор хәзер, синең белән киңәшмәй хәл юк, операциягә ятарга кушалар.

Салихҗан абыйсы күзгә күренеп ябыккан, йөзенә саргылт төс иңгән. Диагнозның дөреслеген шик астына алырга нигез юк хәзергә. Ашказаны рәсемнәрен авыруның кулына бирмәгәннәр икән, иртәгесен Гыйлфан үзе генә район больницасына барып кайтты да абыйсын Казанга алып китәргә булды. Операцияне аңа бер ай элек үк тәкъдим иткәннәр икән, Салихҗан шәһәргә, энем янына барам дип киткән дә, районда бүтән күренмәгән. Әле хәзер дә аяк терәп каршы тора.

— Әйтмә дә, әйдәмә дә, үлсәм, ничәмә-ничә йөз чакрым җирдән алып кайтып күмәсе була, сиңа мәшәкать, гаиләмә борчу...

— Кем әйтә сине үлә дип? Бер дә мәшәкать булмас, өч атна дигәндә самолет белән очыртып кына кайтарып куярмын.

— Үләсе килмәй килүен... Шундай йорт салгач кына. Кыз, укып чыгып, кеше булды, малай институт бетерә. Рәхәтләрен күреп яшәр чак җиткәч кенә...

Җиңгәчәсе белән икәүләп димли торгач, өлкән Кылычбайны күндерделәр. Хәер, аның карышып маташуы боларның фикерләрен белер өчен генә булды бугай.

Профессор авыруны карагач ук, Гыйлфан аның ни әйтәчәген аңлады. Соңгарак калынган.

— Ачып карарга була. Күңел тынычлыгы өчен.

Гыйлфан үзе ачты. Соң. Бавырга ук күчкән. Кире ябып куйдылар. Наркозны күп бирмәгәннәр иде, Салихҗан өстәлдә үк айныды.

— Бар да әйбәт, абзый, бераз дәваланырбыз да, Уралга.

Салихҗанның кәефе, чыннан да, әйбәтләнгәндәй булды, тамагына каба башлады.

— Әмма кулың алтын, энекәш, бәгъзеләргә алтышар сәгать ясыйлар.

— Ашказанына ябышкан кечтек кенә ит кисәген кисеп аттык, и вәссәләм. Кабат үсеп чыкмасын өчен бераз укол алырга кирәк булыр.

— Кабат үсәргә можетмы?

— Бәлки үсмәс тә, белеп булмый. Әмма дәвалансаң, ышанычлырак.

— Озакка барырмы инде ул?

— Ике-өч атнадан артык сузылмас дип уйлыйм. Бераз дәвалаunion ныйк әле, анда күрербез.

Гыйлфан химиотерапияне күз алдында тота иде. Вакытлыча эффект булачак, өйгә аяк өсте кайтыр. Кайту белән урынга егылмас, ята-тора йөрер. Химиотерапияне кабатлаганда, ел чамасы яшәве мөмкин, хәтта артыграк та... Организмы күпме көрәшә ала. Рак ул күзәнәкләрнең чамадан тыш ишәя башлавы. Күзәнәкләр күбәеп, шешкә әйләнә, сәламәт күзәнәкләрне зарарлый. Башта авырту сизелми. Авырта башласа, организм инде аңа каршы тора алмый дигән сүз. Химиотерапия — авыру күзәнәкләргә каршы юнәлдерелгән препарат белән дәвалау. Гыйлфанның фәнни эше — әлеге даруларның сәламәт күзәнәкләргә тәэсирен өйрәнү. Менә бит, тәҗрибә астына үз агасы килеп керде.

Бу хәлләрне белеп, читтән күзәтеп торган кеше: «Абзыйсы шундый аяныч хәлдә, ә ул пошынмый да», дип уйлар иде. Ә пошынырга Гыйлфанның хакы юк. Савыгуга Гыйлфан үзе дә ышанырга тиеш, икейөзлеләнүне авыру шундук сизә. Авыруның сиземе бишләтә, унлата көчәя, чөнки ул бөтен игътибарын шул бер нәрсәгә юнәлткән була. Үзең ышанмаган нәрсәгә авыруны ышандыру мөмкин түгел, аның күңеле төштеме, аягын сузудан башка берни калмый.

Дәвалау дозасын Гыйлфан көн саен арттыра барды. Көн аралаш биргән уколның уникенчесеннән соң лейкоцитлар[1] кинәт азаеп, бер меңгә калды. Нормадан биш өлеш ким. Химиотерапияне туктатып, витаминнар бирә башладылар, лейкоцитлар артмады. Абзыйсына Гыйлфан Казан базарыннан күгәрчен сөте генә китерми: әфлисуны, йөземе, хөрмәсе... «Мич ашы ашыйсым килә» дигәч, ашханәдән өчпочмак алып килде. Салихҗан аны бер тапкыр да капмады. Кайтарып куярга кирәк, өен сагына дип уйлады Гыйлфан. Дәвалануның беренче циклын ул болай да тәмамлаган иде инде. Рентген рәсемнәре буенча, бавырындагы шеш кайта төшкәндәй. Профессор белән киңәшеп, дәвалануны ике-өч айдан кабатларга булдылар. Ул көнгәчә яшәрме — юкмы, бу хакта берсе дә сүз кузгатмады.

Республика клиникасы химиотерапия өлкәсендә шактый уңышларга иреште. Операциядән соң мондый дәвалануны үткән авыруларның яртысы диярлек өч ел инде яшәп ята. Өчтән берсе ун елдан артык гомер итә. Әле тагын әллә күпме яшәрләр. Медицина ракка актив һөҗүмгә күчте. Теге каһәре дә бирешергә теләми, күп корбаннар алып китә.

Кылычбаев сайлаган фәндә ике юл бар: кыю ачышлар белән фронт сызыгын өзү яки озын-озак көч җыю, тәҗрибә туплау, дошманның яшерен серләренә төшенү. Хәзер шул ачыкланды: дошманны батырлык белән түгел, сабырлык белән җиңәргә кала. Лаборатория тынлыгы. Авырулар белән аралашу. Чиргә шулай якын килү.

Безнең медицинаның, безнең җәмгыятьнең әхлагы — кеше гомере өчен соң чиккәчә көрәшү. Әгәр шулай булмаса, кешенең кадере бетәр, җирдә явызлык өстен чыгар, алдагы көнгә ышаныч калмас иде. Кеше әрләнсыман үз оясына төшеп чумар, мәңгелек кышка әзерләнер,

---

[1] Лейкоцитлар — ак кан шарчыклары.

әдәбият, сәнгать мәгънәсезгә әйләнер иде. Техника прогрессы да әрләп максатлары өчен кулланылыр иде. Бусы инде кешелекнең һәлакәте дигән сүз.

Кеше гомере өчен көрәш белән бергә медицина фәнен үстерү өчен көрәш бара. Гомерен фәнгә багышлаган кеше дөньяда яшәүнең мәгънәсен раслау өчен дә көрәшә.

## Дөнья бу...

### 1

Металл инструментлар чылтырап, таш идәнгә төште.

— Тас кая, тас!..

Баязит ачуланып кычкырмакчы булды, ләкин үзенең карлыккан тавышын ишетеп, туктап калды. Дүрт-биш сәгать өнсез торып, сөйләшүенне онытырсың. Санитарка тасны чистартып китергән иде, урынына куймаган. Фәрханә дә тас эзләп, башын игән, хирургның аңа таба сузылган кулын күрми. Кулы һаман буш торгач, Аллаяров Фәрханәгә ачулы караш ташлады. Бу карашны шәфкать туташы сизми калды, нәрсәгәдер сөенеп, кычкырып җибәрде:

— Таска үзегез кергәнсез бит, Баязит абый!

Хирургның озын алъяпкычы каплаган ак пластмасс тасны санитарка да абайлап алды.

— Таска үзегез кергәнсез бит, Баязит Алмасич,— диде ул, операция сестрасының сүзен кабатлап. Хирургның ачулы йөзенә елмаю әсәре чыкты. Иләмсез озын алъяпкыч итәген күтәреп, тас эченнән клеенка оек кигән юан аякларын алды.

— Үзем кергәнмен икән шул.

Канга буялган инструментлар бу юлы чылтырамый гына төште.

— Аю...

Фәрханәнең яратып әйткән сүзеннән көлешеп алдылар. Баш хирург белән болай шаярып сөйләшү дүртенче дистәне ваклый башласа да кияүгә чыкмаган Фәрханәгә генә рөхсәт ителә бугай. Кайчандыр аларның исемнәрен янәшә куеп сөйләгәннәр, ахрысы. Ул сүзләрнең кайтавазлары хирургия бүлегендәге яңа хезмәткәрләргә дә килеп житкән. Кырыс, чибәр Фәрханәгә алар бераз сагаеп карыйлар. Фәрханәнең шаярып әйткән сүзеннән соң операция бүлмәсендә һава иркенәеп киткәндәй булды. Фәрханә Аллаяровны, чыннан да, ак аюга охшата. Телевизордан котып патшасы турында фильм күрсәткәндә, абыйсының кызларына сөйләп утырды:

— Безнең Баязит абыйның атлап китүләрен күрсәгез! Нәкъ шушы аю. Шул чаклы авыр гәүдәне ничек шулай җиңел йөртә ул?

Операция имин узды. Авыруның хәле чыдарлык. Атна-ун көн эчендә булачак хәвеф-хәтәрләрне уздыралса... Андый хәвефләрне хирург күреп үк тора. Йөрәк эшчәнлеге шәптән түгел. Аннары авыруның аягында кан юллары бүрткән. Андый күренеш бүтән җирендә дә, мәсәлән, башында булуы мөмкин. Димәк, эмболия куркынычы бар, ягъни кан оешып, баш артерияләренең юлын бикләве мөмкин. Операциядән соң берничә көн сынау үтсә, авыру исән кала.

Операцияне тәмамлап, кулын юганда, авыруның аягындагы бүрткән кан тамырлары хирургның күз алдыннан китмәде. Берничә көн элек шундый тамырларга бәйләнешле күңелсез вакыйга булган иде. Командировкага килгән грузин тромбофлебит[1] белән хирургия бүлеге-

[1] Тромбофлебит — веналарда кан оешу.

нә керде. Кичтән ул аякларын ышкып, канын таратырга теләгән. Төрләр кан юллары белән башына менгәннәр, кан юлын каплаганнар, баш миенә азык килү тукталган. Иртәнгә грузинның гәүдәсен моргка чыгарып салганнар. Командировкага килгән оешмасы аның табутын самолет белән иленә озатты. Ләкин аны озату белән эш бетмәде, хирургка олы мәшәкать артты. Палатада бергә яткан авырулар грузинның мендәр эченә кечкенә төргәк яшерүен күргәннәр. Акча булырга тиеш диләр. Күпме икәнен белүче юк. Ни яшергәне дә тәгаен билгеле түгел. Ләкин акча икәнлегенә берәү дә шикләнми, чөнки кем инде ерак командировкага акчасыз йөри? Аллаяров мәетнең урын-җирен җыештырган ике санитарканы чакырып сөйләште. Шик шуларның берсенә төште. Тетя Груня грузин үлгәннән соң ике көн эшкә чыкмады, күршеләре аның кәеф-сафа корып йөрүен ишеттерделәр. Санитарканың электән дә олы бәйрәмнәрне үз белдеге белән озынайту гадәте бар иде. Моның өчен эштән куарга кирәк тә, җыештыручылар хәзер дефицит. Аллаяров санитарканы чакыртып алды да, озын-озак сөйләшмәстән, акчаны китерергә кушты. Күпме икәнен әйтми, үзең беләсең, ди. Тегесе гаепне кире кага, хирург каты торгач, елый ук башлый. «Юкка рәнҗетмимме?» дигән уй Аллаяровның күңелен сыздырып үтә. Бер дәлилсез ташланды бит кешегә, эчеп йөргән өчен генә, үзенең сиземенә таянып кына. Ләкин кире чигенергә соң инде, хирург һаман акча таләп итә. Кунакка килгән кешене талап калу була бит бу, ди, чит республика алдында шәһәребезнең данын сату...

Кичәгенәк тетя Груня үзенең алмашына йөз илле сум акча биреп җибәргән. Газета кәгазенә төргән алты егерме бишлек. Үзе китерергә оялган, күрәсең. Бөтен килеш китергәнме, бераз тотканмы — анысы санитарка вөҗданында. Табылдыкны өлкән сестрага биреп, мәрхүмнең гаиләсенә җибәрергә куштылар. Хирургка, шулай итеп, Шерлок Холмс ролена дә керергә туры килә.

Икенче көнне иртә белән Аллаяровны баш врач кабинетына чакырдылар. Алкина янында Касыймов һәм местком председателе утыра иде. Сүзне Алкина башлады:

— Сез, Баязит Алмасович, тәҗрибәле хирург, эрудицияле врач, шулай да этика дигән нәрсә җитеп бетми үзегезгә.

Аллаяров баш врачның үтә ягымлы да, бик мәрхәмәтсез дә була торган кыяфәтенә карап, вәгазьнең дәвамын көтеп утыра. Бераз тынлыктан соң бер яклы әңгәмә дәвам итә:

— Касыймов белән киңәшми-нитми, аның авыруына операция ясагансыз. Коллегагызның абруен төшерү була бит бу, Баязит Алмасович.

Аллаяров, җавап эзләгәндәй, кабинеттагыларның йөзләренә карап алды. Хөкемдар кебек утыралар. Кичәге операция турында сүз бара. Тикмәгә түгел бу, авыруның, мөгаен, Касыймовка берәр мөнәсәбәте бардыр. Бер-бер дәрәҗәле кешенең хатыны микән? Дәлия әйтә иде аны, Касыймов авыруларның дәрәҗәләрәгән сайлап ала дип... Кан юллары бүрткән авыруга беренче операцияне Касыймов ясап, бөереннән таш алган иде. Касыймов үзе шимбә көнне әнисе янына, авылына кайтып китте, дүшәмбе көн өйләдән соң гына килеп җитте. Ул юкта авыруга бик каты приступ булды, операция ясалган бөер нык ялкынсынган, Аллаяров аны бөтенләй алып ташлады. Ә Касыймовка эшкә соңлап килгән өчен кисәтү ясады. Шулар ошамаган, әләкләргә кергән.

— Касыймов үзе юк иде бит, ә авыруның хәле начарланды.

Касыймовның күзләре тар гына ярыкка әверелде.

— Ә сез мин киткәнне генә көтеп тордыгызмы?

Аллаяровның кинәт ачуы кузгалды. Ни сөйләп маташалар болар? Тәртипне белмиләрме? Бүлек мөдиренең үз бүлегендәге теләсә кайсы

авыруга операция ясарга хакы бар. Сәбәпләрен палата врачына аңлатып тормаса да була. Ахыр чиктә, Аллаяров Касыймовка караганда тәҗрибәлерәк врач. Ә авыруның хәле, чыннан да, мөшкел иде, бөерендә шеш барлыгы ачыкланды. Баш врач Касыймовны яклау юлына баскан икән, Аллаяров бу мәсьәләдә аның белән уртак сүз таба алмас.

— Сезнең алдыгызда мин акланырга җыенмыйм,— диде Аллаяров, үзен тыныч тотарга тырышып,— чөнки гаебем юк. Ике якны да тигез күреп тикшерсәгез, үзегез дә аңларсыз.

Сөйләшүнең дәвамын көтмичә, хирург үз сүзен әйтте дә чыгып ук китте.

Аллаяров озын коридор буйлап атлый. Гаделсезлектән аның йөрәге һәр вакыт чабыш атыныкы кебек ярсый, бүген дә шулай. Һай, күп тоз салды аның канына баш врач. Тырнак арасыннан кер эзләүләр җәнҗаллы бер очрактан соң башланды бугай. Ул вакыйга унае белән бөтен шәһәр шаулаган иде.

Алкина бер ханымга операция ясаган. Катлаулы операция. Нәтиҗә башта уңышлы сыман булган. Ләкин тиз көндә авыру яңадан хирург янына килгән, эче кисеп-кисеп сызлауга чыдар әмәле юк икән. Тикшергәннәр, рентгенга төшереп караганнар. Авыруның эчендә кискеч энә барлыгы беленгән. Операция вакытында оешкан кан эчендә калган. Бу хакта билгеле булгач та, авыруның үзенә әйтмәгәннәр. Яңа операциягә алынырга Алкинаның батырлыгы җитмәгән, чөнки энәне тартып чыгарганда күп кан китү куркынычы бар икән. Авыртулары әледән-әле кабатланганга, ханым республиканың бүтән больницаларына мөрәҗәгать иткән. Ләкин беркем дә кеше гаебен үз өстенә алырга теләмәгән, әлеге шул кан китүдән курыкканнар. Авыруга операция ясаган хирург үзе ярдәм итә ала, дигәннәр. Көннәрдән бер көнне ханым Аллаяров янына килә. Хирург аны операциягә сала, энәне хәвеф-хәтәрсез тартып чыгара. Сызлануларының сәбәбе шушы дип, авыруга күрсәтә. Энәне ханым истәлек өчен үзенә сорый. Истәлек өчен икән, истәлек өчен, күп уйлап тормастан, Аллаяров энәне бирә. Ханым артык нәзакәтле кеше булмый, хәвефле энәне тотып, Алкина янына китә, сүзләрне бик сайлап тормыйча, тегене әрләп чыга. Ул гына да түгел, бөтен шәһәр буйлап, Алкинаның яманатын сатып йөри. Бу хәлләрне белгәч, терапия бүлеге мөдире Динислам коллегасын кисәтеп куйган иде:

— Ну, Баязит, сак бул. Я моннан китеп котыласың, я судка эләгәсең. Алкина үз абруена кагылганнарны кичерә торганнардан түгел.

Динисның сүзләреннән Баязит ул чакта көлеп кенә куйды. Үз эшен намусы кушканча эшли, нәрсәдән курыксын? Ләкин юкка-барга бәйләнү Баязитның тәмам җелегенә үтте. Баштарак хирургның гаиләсе дә берегеп җитмәгән иде, авырткан җиргә кагылып әрнеттеләр. Фәрхананең дә «ярдәме» ярыйсы гына тиде. Әнә ул үзе, икенче катның баскыч башында Аллаяровны каршылый.

— Нигә чакыртканнар, Баязит абый?

Шәфкать туташының ихлас кайгыртучанлыгыннан Баязитның кәефе күтәрелде. Хирург өчен, бигрәк тә авырулар өчен баш врач бар ни дә, юк ни, менә шушы олы җанлы туташлар үзләренең мәрхәмәтләреннән ташламасыннар. Хирург «бер ни дә юк» дигәнне аңлатып, кул селтәде дә, Фәрхانә янында тукталмый ары узды. Ике кулын халат кесәсенә тыгып, баскан урыныннан кузгалмый калган сестрага аның нин-дидер җылы сүз әйтәсе килсә дә, коридор ишеге турысыннан арлыбирле узучыларны күргәч, кире уйлады. Кызның унбиш-уналты яшьлек чагын, аның беренче тапкыр шифаханә бусагасын атлап керүен күз алдына китерде, кыз баланың тиле хисләрен күңеле аша кичерде.

2

Хирург белән шәфкать туташы арасында тел белән әйтеп булмый торган мөнәсәбәтләрне барысы да сизә, тотып кына сөйләрлек вакыйга юк. Кайберәүләр: «Тымызык күлгә җен ияләшә, белмәссен... дөнья бу» кебек сүзләр белән тыңлаучының күңелен кытыклап куялар. Чынлан да, Фәрханәнең серле тарихын Аллаяровтан да яхшырак беркем белми.

Фәрханәнең күз төбендә тумыштан ук төер бар иде. Гади төер түгел, арка мие бүсере. Һәм ул бөтен халыкка күренеп торган җирдә — борын белән күз арасында. Баштарак бу алсу төер зур миңгә охшап тора иде. Фәрханә үзе үскән саен, төер дә үсте. Кызлар арасына керер вакыт җиткәндә теге хәсрәт төере урман чикләвеге кадәрле зурайды, уң күзнең шактый өлешен каплап тора башлады. Укырга сәләтле Фәрханә мәктәптән кайту белән өенә бикләнде. Сигезенчене бетергәч, Фәрханәне артабан укырга үгетләсәләр дә, кыз үз тиңдәшләре арасында калырга теләмәде. Шәһәрдә яшәүче абыйсы аны авылдан алып китеп, үз һөнәренә, электр эшенә өйрәтте. Һәм Фәрханә торак идарәсендә эшли башлады. Күз төбендәге олы кызыл төер кызның кимчелеге турында әллә кайдан кычкырып торганлыктан, Фәрханә кеше белән аралашмады. Унбиш-уналты яшьлек кыз булып җиткәч, абыйсы белән җиңгәсе аны врачларга күрсәтеп карадылар. Һәркайсыннан бер төрле җавап алдылар: кагылырга ярамый, бүсер арка мие сыекчасы белән тоташкан, киссәң, шул сыекча агып чыгачак һәм операция үлем белән тәмамланачак. Яшьтәшләре киенә-ясана, кино-театрларга, танцаларга йөри, ә Фәрханәнең бөтен рәхәте өйдә китап уку. Китап белән ул күз күрмәгән илләргә сәфәр кылды, китап аша ул кеше күңеленең иң тирән чоңгылларына керде. Китаптагы геройлар белән бергә ул мәхәббәтнең татлы газабын кичерде. Кызның йөрәгеп биләр кешесе дә аның хыялында, бары хыялында. Тормышта ул бервакытта да булмас, чөнки Фәрханәне бер егет тә сөймәс. Ул үзе дә беркемгә дә күтәрелеп карамый.

Шундый уйлар эчендә йөргәндә Фәрханәнең җиңгәсе: шәһәргә яшь хирург килгән, адәм баласын җәһәннәм эченнән тартып чыгара икән дигән хәбәр алып кайтты. Фәрханәне шул могҗиза иясенә күрсәттеләр. Хирург төерне бармагы белән баскалады. Үзе Фәрханә каршында утыра, үзе бөтенләй бүтән дөньядан килгән дә, мондагы кешеләрне танымый сыман.

— Мөмкин булыр төсле,— диде хирург, Фәрханәнең абыйсына карап.

— Нәрсә мөмкин булыр?

— Кисәргә мөмкин булыр.

— Куркыныч түгелме соң?

— Һәр операция куркыныч. Һәр операциядә көтелмәгән хәлләр булырга мөмкин. Киңәшегез, хәл итегез,— диде хирург, бу юлы Фәрханәгә карап.

— Мин уләргә дә риза!

Уналты яшьлек кызның катгый сүзеннән моңарчы җитди кыяфәтле хирург елмаеп куйды. Фәрханә тавышын йомшартыбрак тагын кабатлады.

— Мин үләргә дә риза, доктор, кисегез генә. Бүген үк кисегез.

— Бүген үк булмас,— диде хирург, тагын ягымлы итеп елмайды. Кәгазьгә нидер язды, Фәрханәгә тоттырды.

— Шушы язу белән стационарга барыгыз, анда сезне койкага салырлар. Шунда инде ныклап уйлашырбыз.

Фәрханә, кәгазьне алып, кош тоткандай чыгып китте. Кайда барырга икәнлеген ныклап аңламаса да, төпченмәде, абыйсы беләдер әле.

Хирург кисәргә мөмкин, диде. Бу җаваплы сүзне нигезсез генә әйтмәде. Бармагы белән баскалап караганда, бүсер эчендәге сыекчаның эчкә таба агып китмәвен тойды ул. Әгәр бүсер арка мие сыекчасы белән тоташ булса, бармак белән басканда артка чигенергә, бармакны алгач, кире кайтырга тиеш. Хәрәкәтсез, димәк, төер арка миеннән аерылган, мөстәкыйль булып төйнәлгән. Һәм хирург тәвәккәлләде.

Авыртуны нык сиздермәс өчен берничә укол бирделәр. Тирене хирург каш арасыннан кисте. Каш җөйне яшерергә тиеш. Кыз бала бит, йөзендә операция эзе беленмәсә әйбәтрәк. Бүсерне кисә башлагач, Фәрханә кинәт кычкырып җибәрде:

— Ай, күзем авырта!..

Шул чак ярадан күзнең пыяла матдәсенә охшаган сыекча ага башлады. Эш харап, дип уйлады хирург, каш ясыйм дип, күз чыгару шушы була икән... Сыекча килүне доктор бармагы белән басып туктатты, бармакны тампоннар алыштырды, бүсер алынды, җәрәхәт бик пөхтәләп, нечкә ефәк җеп белән тегелде. Җәрәхәтне кызның уң күзе белән бергә бәйләп куйдылар. Хирург бу төнне йоклый алмады. Кыз аны гомере буе каһәрләячәк. Күзсез булуга караганда, күз төбендә төер белән яшәү йөз өлеш артыграк. Иртән яктыру белән ул Фәрханә янына чапты. Бүген кызның язмышы билгеле булачак.

Вакыт бик иртә иде әле. Кызыйның уянуын көтеп, хирург коридор буйлап йөренде. Палатаның ачык ишегеннән Фәрханәнең тәрәзә каршындагы караваты коридордан күренеп тора. Уяныгра уйламый да бугай, селкенми дә ята бирә. Кичә операция ясалган кызны уяну белән процедурныйга чакырырга дежур сестрага кушып, хирург ординаторскийга керде. Анда да үзенә эш таба алмый аптырады. Ниһаять, сестра авыруның процедурныйда хирургны көтеп утыруын хәбәр итте. Коридордан узганда хирург үзен билгесез операциягә баргандай хис итте. Ак җәймә ябылган сәкедә утыручы кызны үзенең язмышын хәл итүче итеп тойды. Ишектә доктор күренүгә кыз торып басты. Дулкынлануын тыярга тырышып, доктор Фәрханәнең хәлен белеште: «Күзең сызламыймы?»— дип сорады. «Әзрәк кенә сызлый»,— диде кыз. Хирург, үзе дә сизмәстән, кызның каршысына иелде, күзен томалаган бинтның читен бераз ачты.

— Сул күзегезне кулыгыз белән каплагыз әле. Хәзер уң күзегезне акрын гына ачыгыз. Авыртмыймы? Яхшы. Нәрсә күрәсез?

— Сезне күрәм,— диде кыз, хирургның соравын мәзәккә санап.

Хирург елмайды, кыз да елмайды.

— Ачык күрәсезме?

— Ап-ачык. Ике теш арасында бәләкәй генә ярык та күрәм.

Мондый җаваптан хирург көлеп үк җибәрде.

— Молодец, бүгенгә бу күзең ял итеп торсын, иртәгә тагын карарбыз.

Хирургның сөенече чиктән ашкан иде. Кызны ул палатасына үзе озатып куйды.

Җәрәхәте җөйләнеп, больницадан чыккач, Фәрханә үзен кая куярга белмәде. Ике рәт ап-ак тешләрен күрсәтеп елмаеп торган хирург аның күз алдыннан китмәде. Аны күрмичә яшәү мәгънәсез тоела башлады. Ул аны һәр вакыт күрергә, тавышын ишетергә тиеш. Бюллетенен яптырырга барганчы алты көн вакыт бар, ул көннәр һичкайчан да узмас төсле тоелды Фәрханәгә. Алты көн үзенә урын таба алмый үрсәләнде ул: әледән-әле көзгегә карады, күз төбенә ябыштырылган бинтны тизрәк алып ташлыйсы килде. Ишегалдында, урамда кешедән кимсенми йөрер чаклары кайчан җитәр? Бинт астында теге каһәр төер тагын үсеп чыкмады микән? Кагылырга ярамый, үләсең дип, Фәрханәнең котын алып бетерделәр. Хәзер ул күз төбенә ябыштырылган бинтка тияргә дә курка. Яшерен урында ниләр булмас... Юк, хирург

булмаган җирдә өмет тә, шатлык та юк икән. Бары ул, бары ул гына Фәрханәне өметләндереп, ышандырып торган.

Больницага бару көнен Фәрханә операция көткәннән дә ныграк дулкынланып көтеп алды. Ул кирәсе егерме дүртенче бүлмә ишеге төбенә озын чират тезелгән. Фәрханә кем ахыргы дип сорашмады, халыктан читкәрәк бер урындыкка барып утырды. Аның нияте иң соңгы булып керү. Менә, иң азактан кергән ир дә ишектән чыкты. Фәрханә дулкынланудан дерелдәгән кулы белән ишек шакыды, эчтән хатын-кыз тавышы керергә чакырды. Фәрханә ишекне ачты, изге урынга аяк баскандай, оекчан килеш бусагадан атлады. Керсә, үз күзләренә үзе ышанмады. Өстәл янында сестрадан башка какча йөзле бер ир-ат ишектән кергән кешегә күтәрелеп карамыйча нидер яза. Сестра утырырга кушты. Фәрханә кадаклап куйгандай бер урында тора бирде. Язуын тәмамлап, какча йөзле врач, ниһаять, кызга күтәрелеп карады.

— Әйдә, узыгыз, ни йомыш?

Фәрханә, аксыл-зәңгәр төстәге бюллетень кәгазен тотып, ни диярга белми басып тора.

— Ә-ә... Баязит Алмасович юкмыни?

— Ул бу бүлмәдә кабул итми. Бүген аның, гомумән, кабул итү көне түгел. Фамилиягез? Шулай, бирегез бюллетенегезне. Шулай, үзегезне ничек хис итәсез?

Какча йөзле хирург Фәрханәнең күз төбенә ябыштырылган бинтны җәһәт кенә куптарып, чүп савытына ташлады, кыз аның кулын тота алмый да калды. Шуннан врач тагын өстәлгә иелде. Зәңгәр кәгазьгә нидер язды да Фәрханәгә сузды.

— Яхшы, эшкә чыга аласыз. Бүтән кеше юкмы анда?

Сестра ишекне ачып карады. Кеше беткәнлеген әйтте. Какча йөзле врач Фәрханәнең чыгып китмәвенә дә игътибар итмичә, әйберләрен җыя башлады. Фәрханә исә Аллаяров турында сорашырга җай көтә иде. Тегеләрнең сөйләшергә бик теләп тормаганнарын күргәч, ничек керсә, шулай чыгып китте. Менә шул гына. Каш өстенә ябыштырылган җилемле бинтны алдылар да, чүп савытына ордылар. Бар да яхшы. Фәрханә эшкә чыга ала. Әйтерсең берни дә булмаган. Әйтерсең ул гомере буена кимсенеп, хурланып яшәмәгән. Әйтерсең ул үләргә дә риза булып, пычак астына барып кермәгән. Беркем гаҗәпләнми, беркем сөенми. Фәрханә сумкасыннан чыгарган нәни көзгесенә караган хәлдә, уң кашын сыйпаштырып, аулак почмакта оекчан килеш утыра. Әнә, җыештыручы апа озын, киң коридорның аргы ягын юып, бу якка килә. Китәргә вакыт, димәк. Фәрханә резин итеген киде, пальтосын алды, күпереп торган коңгырт чәчен кулдан бәйләнгән йон башлык белән каплады. Йокыдан уянып җитмәгән кеше сыман, пальтосын кияkия, баскычтан чайкалыбрак төшеп китте. Түбән катта тукталып, регистратурада утыручы кыздан сорарга кыюлыгы җитте:

— Әйтегез әле, зинһар, Аллаяров кайчан кабул итә?

Кыз Фәрханәгә карамый гына җавап бирде:

— Чәршәмбе көн сәгать өчтән бишкә чаклы.

— Рәхмәт. Ә-ә кайсы бүлмәдә?

Фәрханә икенче соравын биргәләгәнче, ак башлыклы кыз китеп барды. Аллаяровның кайсы бүлмәдә кабул итәчәге билгесез калды. Ярый, анысын чәршәмбе көнне килгәч, сорап белермен дип юатты үзен Фәрханә. Бүген дүшәмбе. Берсекөнгә эш беткәч килергә була икән. Кара буяу белән саннар суккан ак ишекләргә карый-карый, Фәрханә чыгу ягына китте. Кайсы ишек булыр? Моны белмичә китә алмый ул хәзер. Регистратура ягына кире борылды. Бераз көткәннән соң баягы тәрәзә янында ак яулыклы, ак халатлы бер апа күренде.

— Әйтегез, зинһар, чәршәмбе көн Аллаяров кайсы бүлмәдә кабул итәчәк?

Тотлыгып тормас өчен сорауның һәр сүзен Фәрханә алдан әзерләп куйган иде.

— Уңдүртенчедә.

— Рәхмәт!

Уңдүртенче бүлмә урам ишегеннән ерак түгел. Фәрханә аны бая ук күреп киткән иде. Хәзер, әлеге бүлмәдә кем утырачагын белгәч, тылсымлы әйбер янына килгәндәй, ишек янында туктальп торды. Кереңгә кертүчеләр күренми, узып йөрүчеләр генә бар. Ишеккә кагылырга Фәрханә кыймады, урамга чыкты. Аллаяровны очрату хәстәре хәл ителгәч, ул үзенең күз төбендә төере юклыгын исенә төшерде. Урамнан ул беренче тапкыр башын түбән имичә үтте. Эшкә баргач, Фәрхәнәне таныры лык түгел, матурланган сын, шәһәрнең беренче гүзәле булгансың дип мактадылар. Хатын-кыз ах-вах килде. Ир-ат шаяртып маташты. Атнаның икенче көне шулай тиз үтте. Чәршәмбе көненең яртысын Фәрханә үткәрә алмый җәфаланды. Берничә өйгә заказ алды да, аларны тиз генә йөреп чыкты. Төшке ашны ашап тормады, өч тулганчы дип, больницага йөгерде. Аллаяровны эшкә килгәндә күреп каласы килә иде аның. Өлгерде, өч тулмаган әле. Ишек каршындагы барлык урындыклар тулы, басып торучылар да байтак. Барысы да Аллаяровка микән? Фәрханә хирургны килгән чакта күрердәй, ләкин үзе күренмәстәйрәк җиргә барып басты. Өч тулды. Хирург юк. Дүртенче китте, юк. Шулай ук бүген дә күреп булмас микән? Ашыгыч операция килеп чыккандыр. Әнә инде дүртенче ярты да булды. Килмәс, юкка гына дулкынланган, юкка гына көткән Фәрханә. Нигә генә озаграк авырып больницада ятмады? Анда көненә әллә ничә мәртәбә күрә иде. Көн саен бер тапкыр аның белән сөйләшә иде. Анда калган кешеләр бәхетлеләр... Фәрханә әллә ничә тапкыр урамга чыгып урады. Ишек яныннан ерак китмәде. Белмәссең, кайсы капкадан йөридер хирург. Ә хирург, Фәрханә аны инде күптән көтми башлагач, кинәт пәйда булды. Өстендә тезеннән югарырак күн пальто, башында тар кырыйлы эшләпә. Кулында көрән төстәге портфель. Аллаяров беркемгә дә төбәлми исәнләште дә уңдүртенче сан сугылган ишектән кереп югалды. Юл өстендә торган Фәрханәне, әлбәттә, күрмәде.

Кыз ишек төбендә халык беткәнен сабырлык белән көтте. Бер заман коридор бушап калды. Соңгы авыру чыкканда аңа ишекне ябарга да юл куймыйча, Фәрханә эчкә узды.

— Ә-ә, менә кем килгән безгә!— Аллаяров кызны сабый бала каршылагандай каршы алды.— Әнә ничек чибәрләнгәнсез.— Хирург Фәрханәнең кашын сыйпап карады.— Җөе дә сизелми диярлек. Бераз гына бар, ел тулганда ул да тигезләнәчәк.

— Чынмы?

Фәрханә куанычыннан туктаусыз елмая. Бүген ул икеләтә шатлык кичерә. Хирургны күрүенә дә сөенә, күз төбендәге җөйнең бөтенләй югалачагына да куана. Кайсы шатлыгы зуррак, үзе дә белми. Хирургның йөзендә дә елмаю сүнми.

— Чын булмыйча, хәзер иң шәбен генә сайлап, кияүгә чыга аласыз.— Фәрханә кара күзләрен түбән төшерде.— Әллә укырга уйлыйбызмы?

Кыз бераз дәшми торды. Аннары күптән уйлап йөргән карарын әйткәндәй, катгый итеп әйтте:

— Укырга уйлыйм.

Чынлыкта исә ул моны хирургның соравыннан соң гына хәл итте. Хәзер инде саубуллаш та чык. Сүз бетте, эш калмады. Монда торуны сузудан мәгънә юк. Фәрханә кискен генә саубуллашты да, күз ачып йомганчы чыгып та китте. Саташкан сыман язгы гөрләвекләр аккан урамнардан резин итеге белән су ерып йөрде. Элекке гадәте белән ул кешесез сукмакларны, аулак тыкрыкларны сайлый. Көн кичекте. Ә

нигә олы урам буйлап беркемнән дә курыкмый үтмәскә, дигән уй белән Фәрханә шәһәр үзәгенә чыкты. Кешеләрнең үзенә игътибар итүләреннән курыкмыйча, салмак кына атлый кыз. Каршы очраучыларның кайберләре аның йөзенә карый, кайсылары аягына күз сала. Электр яктысында ялт иткән урам буйлап Фәрханә ут янып бара. Йөзенә карасалар, каш өстендәге җөйне күрәләр дип, ике бите кызыша башлый. Аякка нигә карыйлар икән дип, үз аягына күз сала. Шунда гына ул үзәк урам тротуарларының коп-коры икәнен, бар да туфлидән, бары ул гына кызыл резин итекләрен балкытып баруын күрә. Күрүе була, эш белән барган кеше кебек кызу-кызу атлап китә. Эш кешесенә ни кисә дә гафу ителә. Язгы юл өзекләрен үтеп йөриләр бит алар. Моңарчы ул берни уйламый йөрде. Язгы табигатькә кушылып ярсыган хисләрен бер эзгә салырга тырышты. Өенә якынлашкач, хирургка әйткән җавабын исенә төшерде. Укырга уйлыйм диде бит. Ә кайда укырга уйлый? Классташларының кайберсе ФАШка[1] китте. Ул да шунда барачак. Карар кабул ителгән, алгысынган күңеле басылгандай булды. Күңеленә тагын бер кыю уй килде: кинәшү өчен Аллаяров янына барырга тагын бер сәбәбе бар!

Икенче көнне үк Фәрханә, китапханәгә кереп, уку йортлары турында белешмә сорап алды. Бөгелмә техникумы турындагы сүзләрнең берсен дә калдырмый шакмаклы дәфтәренә күчереп язды. Өенә кайткач, документларын барлады. Мәктәп дәреслекләре эзләргә тотынды. Шулай итеп укырга китәргә әзерлек башланды. Хирург янына ул берничә атнадан, җөй тигезләнгәч барырга ниятләде. Ләкин түземе җитмәде, киләсе чәршәмбедә үк больницага таба юл тотты. Гадәтенчә, ишек төбе бушаганын көтте, соңгы пациент булып хирург кабинетына керде. Хирург, гадәтенчә, балкып елмайды. Бәлки шулай елмаешырлар да, гадәттәгечә, бер-берсенә сәламәтлек теләп аерылышырлар да иде. Ишектә бер ханым күренде. Кыз аңа нигәдер гаҗәпләнеп карады. Ханым ап-ак халаттан, зифа буйлы, төскә-биткә ясап куйган кебек. Озын керфекләренә кара сөрмә тарткан, иреннәрен җиләк төсенә буяган. Чибәр ханым Фәрханәгә исе китмичә генә Аллаяровка дәште:

— Бетәме әле синең?

— Хәзер кайтабыз, Дәлия, соңгысы,— диде Аллаяров, Фәрханәгә ымлап. Хирургның йөзендә елмаю сүрелә төште.

— Хәлләр ничек соң?— Монысы Фәрханәгә төбәлгән иде. Дәшүе әлеккечә, ягымлы, йөзе мөлаем.

— Әйбәт, Баязит абый,— диде Фәрханә, кинәт кызарып. Ул чибәр ханымның хирург хатыны икәнлеген аңлады.

— Бар да әйбәт,— дип кабатлады ул, зиһенен җыеп.— Болай күренергә генә килдем. Ярый, сау булыгыз!

Аллаяров нидер әйтте, Фәрханә аның тавышын ишетте, мәгънәсен аңламады. Чибәр ханымга карамаска тырышып, ашыгып чыгып китте. Коридорда урындык өстендә калган пальтосын иненә элде, башлыгын кулына алып, йөгереп диярлек урамга чыкты. Ни булды соң әле? Аллаяровның хатыны, баласы барлыгын элек тә белә иде бит ул. Йөрәге нигә болай чыгарга җитешеп кага, битләре уттай яна? Аллаяровның үзеннән нәкъ ике мәртәбә олы икәнлеген дә белә бит ул. Яратса да, атасы кебек күреп ярата бит ул аны. Бернигә дә өмет сузмый. Китәргә, онытылырга! Әйе, онытырга түгел, онытылырга. Оныта алмаячагын Фәрханә бик яхшы белә. Әйбәт тә булды әле, укырга китү хакында да әйтмәде. Берни белдермичә кинәт югалырга!

Фәрханә кичләрен, бөтен нәрсәсен онытып, дәресләренә чумды. Хәзер аның бөтен хыялы — өч елдан фельдшер дипломы белән Аллаяров каршына килеп басу.

---

[1] ФАШ — фельдшерско-акушерская школа.

— Күренергә килдегезме?— дияр хирург.
— Хәл белергә килдем,— дияр Фәрханә.
— Кайда болай озак югалып тордыгыз?— дияр хирург.
Шунда Фәрханә кызыл тышлы (ә бәлки башка төследер?) кенәгәсен чыгарып салыр.
— Менә кайда югалгансыз икән?— дияр Аллаяров.— Безгә кайткансыздыр инде? Специалистлар бик кирәк.
Кинәт кенә ризалык бирергә ярамас.
— Калыгыз бездә, бергәләп эшләрбез,— дияр Аллаяров.
— Сезнең утенечне аяк астына салып таптап булмас инде, иптәш Аллаяров,— дияр Фәрханә.
Шундый ашкынулы хыяллар белән керү имтиханнарына хәзерләнә Фәрханә.
Яз үтте, җәй житте. Фәрханә документларын күрше шәһәргә илтеп кайтты. Имтиханнарны да уңышлы тапшырды. Эштән расчет алып, китәргә әзерләнәсе генә калды. Соңгы көн эшкә чыкты, соңгы заявкаларны алып, квартиралар буйлап, розеткалар төзәтеп, пробкалар тикшереп йөрде. Шул чак аның башына бер уй килде: Аллаяровлар квартирына кереп тә электрларын тикшерергә мөмкин бит! Аның кайсы урамда, хәтта кайсы йортта яшәгәнен белә инде Фәрханә. Җәй көне әллә ничә мәртәбә хирургның парк аша эштән кайтуын яшеренеп көтеп торды, үзенә күренми генә озатып барды. Подъездын да белә. Хәзер исә квартира адресын торак идарәсенә кереп белергә була. Ул йорт Фәрханә участогына карамый каравын, ләкин Аллаяров өчен монын нинди аермасы бар? Үз заявкаларын бетерү белән, электрик кыз ниятләгән йортка китте. Һәр ишек янында подъездда яшәүчеләрнең исемлеге эленеп, квартир саннары язылып куелган. Үзе эзләгән фамилияне тапты, торак идарәсенә кереп тә торасы булмады. Ишек кыңгыравына барып кагылганчы каршыдагы паркка кереп йөрде. Аллаяровның өйдә чагын туры китерергә кирәк. Бәлки юлда очрар? Мондый мөмкинлектән куркып, кыз бакчаның аргы почмагына юнәлде. Сәгать биш тулып узгач, ни үле, ни тере килеш, кыңгырауның кара сәдәфенә килеп кагылды. Бер кызның шундый кыю адымы турында ул китапта укыган идеме, кинода күрдеме. Китаптамы, кинодамы кызның гыйшкы төшкән кеше буйдак иде бугай... Өйдә хирургның хатыны да булу мөмкин дигән уй шунда гына күңеленә килде. Аяк тавышларына колак салып, Фәрханә тын алмый тора. Авыр адымнар, Аллаяровныкы. Чыннан да, ишекне чалбар өстеннән чыгарып салган буйлы күлмәк кигән хирург ачты. Башта ул Фәрханәне танымады, ни йомыш дигәндәй, тукталып калды.
— Исәнмесез! Электрик,— дип, Фәрханә эчкә узарга тиеш. Башка өйләргә ул шулай керә һәм монда да шундый әзерлек белән килде. Ләкин хирургны күрүгә коелып төште. Хирург елмайды, кыз да аңа шундый ук елмаю белән җавап бирде.
— Ә-ә, Фәрханә! Әйдәгез, рәхим итегез!
Фәрханә керде.
— Гафу итегез, мин электрик. Тикшерергә килдем...
Аллаяров кызның хәйләсен белгән сыман тоелды. Фәрханә комач кебек кызарды.
— Мин — электрик,— дип кабатлады Фәрханә, зиһенен җыярга тырышып.— Төзәтәсе әйберләрегез юкмы?
Шунда ук Аллаяровның җавабын көтмичә, кыска коридорны үтеп, кухняга узды. Өстәлдә чәйле стакан тора, яртысы эчелгән. Өйдә ялгызы гына, дип уйлады Фәрханә, юкса, стакан бер генә булмас иде.
— Баязит абый, мин ФАШка укырга кердем, бу юлы хушлашып та чыгыйм, дидем.
Аллаяров җитдиләнеп киткәндәй булды.

— Шулаймыни? Котлыйм, котлыйм.

Бер тел ачылганда сөйләп калыйм дигәндәй, кухня ишеген каплап баскан Аллаяровның күзенә карап, Фәрханә дәвам итте:

— Баязит абый, сез минем коткаручым. Мин сезгә бөтен гомерем буена бурычлы. Мин ул бурычны беркайчан да түләп бетерә алмам. Сез ни боерсагыз, мин шуны үтәргә әзер!..

Фәрханәнең бит алмалары алсуланып яна, кара күзләре гүя Баязит өстенә йолдызлар сибә. Кызны мондый хәлдә күреп, Баязит куркынгандай, чигенергә әзер булып, басып тора.

— Ни сөйлисез сез, ни сөйлисез, бу — минем бурычым, һәр врач эшли торган эш...

Кыз яшен ташы кебек Баязитка таба атылды, хирург читкә тайпылды. Секунд эчендә Фәрханә ишек янында иде инде.

— Хушыгыз, бәхетле булыгыз, Баязит абый!

Фәрханә биек баскычтан ничек төшкәнен, урам аша чыгып, ничек бакчага килеп кергәнен үзе дә искәрмәде. Читтән караганда кеше аны янгын эченнән чыккан дип уйлар. Хәтта кызның җилдә җилфердәгән ак күлмәге дә ялкынланып яна төсле. Фәрханә бакчаның аргы ягына җитеп, аулак урында үскән каенга барып сарылды. Каенның салкын кәүсәсенә кайнар бит алмаларын алмаш-тилмәш куйды.

— Бетте,— дип уйлады ул,— укуны тәмамлап кайтканчы, мин аны күрергә тиеш түгел.

Бу юлы ул сүзендә нык торды.

Баязит Фәрханәнең үзенә булган мөнәсәбәте гади ихтирам гына түгел икәнен белә. Нигә яшерергә, беркемнең кулы тимәгән гүзәл кызның саф хисләре аның җанына рәхәтлек бирә. Янында Фәрханә торганда ул операцияләрне җиңелрәк ясый. Баштарак шулай булды. Ләкин соңга таба кызыйның язмышы Баязитны нык борчый башлады. Тән гарипләгән бетереп, җан гариплеге ясамадымы ул яшь кызга? Бер яклы мәхәббәт рухи яктан да, матди яктан да кешенең матурлыгын тулысынча ача алмый. Шундый язмышка дучар итәр өчен Баязит кызның йөзендәге кимчелекне бетердемени? Фәрханә үз парын табып бәхетле яшәсе, хирург та үз эшеннән канәгать булып калыр иде.

Баш врач яныннан чыгуга Аллаяров икенче катка кызулык белән генә менгән икән, үз бүлмәсенең ишегенә барып орынгач, кире борылды. Баягы урында Фәрханә юк иде инде. Хирург түбәнгә төшеп китте. Кичә бөеренә ясалган хатын реанимация бүлегендә ята, аның хәлен белергә кирәк. Баш врач чакырганчы ул шунда төшәргә җыенган иде. Авыруның хәле нормада. Туганнары, якыннары, бигрәк тә авыруның үзе өчен үтә авыр булып тоелган хәл врачлар өчен «нормада». Температурасы — 39 градус. Операциядән соң гаҗәп түгел. Авыру вакытывакыты белән саташа, йөрәк тибүе еш. Шулай булуы табигый. Каты сызлауны басар өчен укол бирәләр. Шулай ук табигый, тәненне кисkәләсеннәр дә, бер дә сызламасынмы?

### 3

Аллаяровның мин-минлегенә кизәнеп сугар бер җай чыкты. Хирург өчен бу көтелмәгән афәт булды. Авыру хатын китерделәр. Дөресрәге, ул үз аяклары белән приемный покойга килеп керде. Ә иртән операция

өстәлендә анын үле гәүдәсе ята иде. Операцияне төнге дежур Аллаяров ясады. Касыймов аңа ассистентлык итте. Кай арада белеп өлгергәндер, иртәнге җидегә хирургия бүлегенә прокурор ярдәмчесе килеп җитте. Көтелмәгән үлү очрагыннан тетрәнгән Баязит өчен бу яңа бәла булды. Бәхеткә каршы, авыру тарихын ул тутырып өлгергән һәм ассистенттан кул куйдырган иде. Прокурор ярдәмчесенә җавап биргәндә, димәк, фактларны бер таба да үзгәртеп булмаячак. Моны Касыймовка карата уйлап куйды Баязит. Вакыйгалар төштәге сыман тиз куерып китте дә, ялыктыргыч булып бер урында әйләнә башлады. Ак халатлы, күзлекле прокурор ярдәмчесе башта Аллаяровтан сорау алды, һәр сүзен кәгазьгә теркәде. Аннары хирургның үзенә тәфсилләп аңлатма язарга кушты. Шуннан ординаторскийга бүтәннәрне чакырта башлады. Аңлатма язу өчен хирург үз кабинетына чыкты. Барысын да салкын кан белән искә төшерергә кирәк иде. Мәетне инде моргка чыгарып салдылар. Өендә дүрт яшьлек баласы калган. Ул ятим баланың анасы Аллаяров пычагы астында үлде. Ничек булды соң әле? Барысы да хирург күз алдында, онытырга тырышса да, оныта алмас.

Унҗиде сәгать ун минутта кабул итү бүлмәсенә олы гәүдәле юан хатын терапевт направлениесе белән килде. Ирене куе кызылга буялган. Шик — сукыр эчәк авыртуга булган. Бит һәм тән тирәсендә үзгәрешләр юк, үпкә һәм йөрәге гадәттәгечә. Теле алсу-кызыл. Тире астында май катламы мул булганлыктан, эче ярыйсы гына калку. Каты түгел, сулыш алуда катнаша. Кул белән баскалап караганда, туры эчәк юнәлешендә авырту сизелә. Щеткин-Блюмбер билгеләре [1] юк. Бавыры нормадан зураймаган. Үт куыгы һәм бөерләрне капшап булмый. Авырү үз аңында, утыра, тора, йөри ала. Күбрәк ята. Эч китү, косу булды. Анализлардан соң, авыруның эче һәм тозлы ризык: гөмбә, тозлы кәбестә ашаганы ачыкланды. Терапиядән дежур врач чакырылды, ул беренче карауда ачык кына диагноз куя алмады. Янадан хирургны чакырдылар, бергәләп киңәштеләр. Авыруның хәле начарланмый, температура һәм пульсы гадәттәгечә. Косуы тукталды. Хатын-кыз авыруы юкмы икән, дигән шик белдерделәр. Авыруның әйтүенә караганда, шушы көннәрдә генә гинекологка күренгән, андый-мондый авыру тапмаганнар. Шулай да хирург хатын-кыз авыруы буенча шикләнде. Хатын артык симез булганлыктан, аның эчендә җыелган кан бармы-юкмы икәнлеген белерлек түгел. Ике врач киңәшеп, якынча диагноз куйдылар: гастроэнтероколит — ашказаны һәм эчәк авыруы. Авыруны приемный покойның аерым бүлмәсенә салып, терапевт күзәтчелегенә калдырдылар. «Кечкенә балам ялгыз калды»,— дип, авыру үзен кайтарып җибәрүләрен сорый. Авыру кичке тугыз белән ун арасында туалетка барырга кузгала һәм шунда аңын югалта. Консультациягә яңадан хирургиянең дежур врачы Аллаяровны чакыралар. Авыруның хәле кинәт начарлана. Йөзе агара, эче калкулана. Эчендә сыекча барлыгына шик туа. Уң яктан Щеткин билгесе унай. Пульсы ешая, минутына йөз егерме. Авыру йокымсыраган хәлдә ята. Хирург хатын-кыз авыруы, ачык әйткәндә, аналык торбасы ярылудан шикләнә. Ләкин ханым бу шикне кире кага. Ире ерак командировкада булганлыктан, берничә ай бергә яшәмәүләрен әйтә. Ләкин бөтен билгеләр Аллаяровның шигенә туры килә: йөзенең агаруы, Щеткин билгесе, аң югалту,

[1] Щеткин-Блюмбер билгеләре (бу билгеләрне беренче ачкан врачлар исеме белән йөртелә) — эчке әгъзалар тишелү нәтиҗәсендә эчтә сыекча җыелу.

пульсның ешаюы. Хирург авыруга ашыгыч операция тәкъдим итә. Хатын ризалык бирми. Авыруны күндерергә ышанып, Аллаяров төнге унбердә операциягә әзерләнергә боерык бирә. Сәгать уникедә авыруны ирексезләп диярлек операция өстәленә салалар. Операция мәйданын ачу белән, авыруның эченнән кан түгелә башлый. Канны, үзенә кире кертү максаты белән, чиста колбаларга җыялар. Ләкин анализ канның артык майлы булуын күрсәтә. Эмболия куркынычыннан сакланып, авыруга үз канын бирмәскә булалар. Салфеткаларга сеңдереп, канны аерым савытка җыялар. Өч литрдан артык кан җыела. Хатынның бөтен каны диярлек агып беткән! Авыруга донор каны бирәләр. Эчне үргән май катламы зарарланган урынга якын килергә ирек бирми. Хирург көч-хәл белән моңа ирешә, ләкин авыруның пульсы һәм тын алуы юк дәрәҗәсенә төшә. Авыруга кислород иснәтәләр, кардиомин һәм башка уколлар кадыйлар. Артериягә кан җибәрәләр. Пульс начарлана, аорта кысыла. Берничә минуттан авыруның тын алуы туктала. Бер сәгать буена ясалма сулыш алдырырга тырышалар. Диафрагма һәм күкрәк читлеге аша йөрәккә массаж ясыйлар. Шул чаралар белән йөрәкне туктатмый торалар. Иртәнге өч белән дүрт арасында хатын үлә.

Аллаяров аңлатма кәгазен язып бетергәндә, прокурор ярдәмчесе түбән катка, баш врач кабинетына күчкән, сорау алуны шунда дәвам итә иде. Хирургтан аңлатманы алып, бүтән кәгазьләренә теркәп куйды, докторның үзен тоткарламады. Аллаяров өске катка күтәрелгәндә, баскычта Фәрханә очрады. Төнлә ул дежур иде, операциягә булышты. Фәрханә Баязитка кызарган күзләре белән күтәрелеп карады да башын түбән иде. Берни дәшмичә, үз юлына китте. Сорау алырга чакырганнар. Баязит Фәрханәнең чын дөресен генә сөйләячәген белә. Бу хакта аның күңеле тыныч. Нигә соң Фәрханәне күрүгә йөрәге чымырдап куйды? Бая ул аңлатма кәгазен язгач, ординаторскийга сугылды. Анда Касыймов белән Фәрханә сөйләшеп торалар иде. Аллаяровны күрүгә шып туктадылар. Касыймов буйдак кеше, Фәрханәгә күңеле төшкәнгә охшый. Әһә, Баязитның йөрәге шуңа кузгалган икән. Прокурор ярдәмчесенә ни катнашы бар соң әле моның? Бөтен хезмәткәрләр чын дөресен генә сөйләячәкләр. Касыймов операция сестрасын Аллаяровка каршы котыртыр дип уйлау гөнаһ булыр. Касыймов үзе дә мондый әшәкелеккә бармас, Фәрханә турында әйтеп торасы да юк. Бернәрсәгә дә кулы бармыйча үз кабинетында утырганда, хирургны сискәндереп, телефон шалтырады. Дәлия. Иртәнге тугыз, син һаман юк, ни булды, ди. Бүген аның үзенә икенче сменага барасы. Ваклыкларына тукталмыйча, Баязит күңелсез хәл килеп чыкканын әйтте. Үзе аңа әллә ни әһәмият бирмәгән төсле кыланды. Эшкә килгәч, Дәлия, әлбәттә, барысын да беләчәк. Шулай да алдан ук кайгырып тормасын. Хирургның хатыны шушы ук медсанчастьта башка бинада эшли. Күңелсез хәлнең нидән гыйбарәт икәнен хәзер үк әйтсәң, иртәнге чәен дә эчмичә йөгереп киләчәк.

Аллаяров теге чакта Динисның «Я китеп котыласың, я судка эләгәсең» дигән сүзен исенә төшерде. Күптән булган сөйләшү, менә кайчан расланырга тора... Раслану-расланмавы ничек булыр, ул хакта хирург уйламаска тырыша.

Беренче курсны бетереп кайткач, Баязит болай гына район больницасына сугылды. Нишләптер, тирәсендә егет-җилән кайнашкан регистратура тәрәзәсенә үрелеп карады. Тәрәзәчек артында яшь кенә кызый утыра. Баязит ирексездән тукталып карап торды. Яңа ачылган чәчәк кебек, кыздан сафлык, самимилек бөркелеп тора, караган саен карыйсы килә. Баязит ул җәйне, сәбәп табып, больницага тагын бер-

ничә тапкыр керде. Ләкин тирәсендә егетләр уралган үсмер кыз белән чытлыклануны килештермәде. Ул бит инде фронтлардан урап кайткан ир-егет.

Икенче җәйдә Баязит җилбәзәк кызый белән танцада очрашып, бер-ике танго биеде. Дәлия исемле икән гүзәлкәй. Егет башкасын сорашмады, икенче көнне Баязитның бертуган апалары Дәлиянең тәрҗемәи хәле белән таныштырдылар. Әнисе белән читтән килеп яшиләр икән. Әнисе больницада санитарка, әтисе сугышта үлде, диләр. Хәзер килде-китте хатын-кызга җиңел, бөтенесен сугышка сылтыйлар да вәссәлам... Дәлия үзе алты класстан ары укымаган, эшкә кергән. Анасының хезмәт хакы аз, җитми, ди. Баксаң, ялкаудыр, укыйсы килмидер, бер баласын укытмаган нинди ана ди ул...

Мондый имеш-мимешләргә карап, Баязитның күңеле сүрелмәде, киресенчә, кызга аның саен көчлерәк тартыла башлады. Егетләргә хас мавыгу хисенә олыларча кайгырту, кызгану хисе өстәлде. Зифа сынлы, ак йөзле үсмер кызны үз канатына аласы, аны имеш-мимешләрдән аралыйсы килде. Ул җәйне беренче тапкыр үбештеләр. Яңгырдан соң ләмгә әйләнгән урам аркылы Баязит Дәлияне күтәреп алып чыкты. Кыз каз мамыгыдай җиңел, гомер буе күтәреп йөртсә дә, Баязит авырсынмас кебек иде.

Уку елы житте. Баязит Казанга студент тормышында кайнарга китте. Хат алышмадылар. Сүз куешмаганнар, вәгъдәләр бирешмәгәннәр иде. Өченче курста Баязит профессор кызы белән чак кына мавыгып китмәде. Дөресрәге, кыз үзе Баязит белән нык кына мавыгып алды. Баязит курс эшләре белән профессор янына баргалый иде. Профессор Баязитка зур өметләр баглый, үзенең алмашы итеп тәрбияләү турында уйлаштыра икән. Аның йортында Баязитны үз кеше итеп каршылыйлар, җылы итеп озаталар, Баязит өчен шәп перспектива ачылды дип, иптәшләре авыз чайкый башлады. Кызның холык-фигыле дә ярыйсы, тышкы кыяфәте дә тел тидергесез. Ләкин моңлы карашы белән Дәлия күз алдына килә дә баса. Кичер, профессор кызы, булмый... Акыллы кыз, Баязитны сүзсез аңлады.

Дүртенче җәй зилзиләле һәм Дәлиясез килде. Кызый унсигез яше тулуга хәрби хезмәтен тутырып кайткан морякка кияүгә чыгып куйган. Хат алышып торганнар икән, Баязит бит хат та язмады. Дәлияне чынлап яратканын Баязит шунда гына аңлады. Элегрәк яшь дип, җилбәзәк дип карады, әнисенең, апаларының сүзләренә колак салды, тиң булмас дип уйлады. Әйе, шулай уйлады. Алай уйламаса, кош теледәй бер хат язар иде. Күбәләктәй нәфис җанны кулыннан очырып җибәрде бит! Очраштылар. Хас авыл егетләречә, Дәлиянең су юлына төште Баязит, судан кайтканын көтеп, тыкрык башына чыкты. Сулы чиләкләре белән йөгереп китә алмас дип исәп тотты, ахрысы. Баязитны күрүгә Дәлия башын түбән иде. Озын керфекләрен сирпеп кенә егетнең сәламен алды да, чүәк очларына карап атлый башлады. Көянтә-чиләкләре салмак кына чайкалып бара. Ни әйтсен Баязит? Нигә алдадың, вәгъдәңдә тормадың дисенме? Бәхетле бул дисенме? Хаталангансың, Дәлия, син минеке, дип кычкырасы килде Баязитның. Ул сүзләрне дә теш арасыннан чыгармады. Чирәмле тыкрык буйлап шулай сүзсез генә атлый бирделәр. Тыкрык очына җитәрәк егет телгә килде:

— Дәлия, тукта әле.

Алгарак узган Дәлия каерылып Баязитка карады. Аның күзләрен яшь томалаган иде. Баязит озын кара керфекләрдән тәгәрәп төшкән яшь тамчыларын күреп, телсез калды. Дәлия елый... Ул бәхетсез!.. Кыз күз яшьләрен селтәп төшерергә теләгәндәй, башын кискен итеп селкеп алды да үз юлына китте. Баязит аны бүтән очратмады. Бу оч-

рашу өчен дә өйдәгеләр күз ачырмадылар: ир хатыны, бала көтә... Соңгысы Баязитның башына килмәгән икән.

Казанга киткәч, Дәлия турында бер-бер артлы ике хәбәр килде. Дәлия ирен ташлап әнисе янына кайткан! Дәлия кичке мәктәпкә укырга кергән!

Күңелләрне алгысытып, очрашулар җәе житте. Китапханәдә бергә туры килеп, кыска гына сөйләшеп алдылар.

— Сездән көнләп җанымны өтте, Баязит абый. Яшьлегемне калдырмады. Кешеләр әллә ниләр ишеттергәннәр.

— Бала көтә, дигәннәр иде сезне?

Дәлия агарынып киткәндәй булды, керфеген аска иеп, башын чайкады.

Баязит урынсызрак сорау биргәнен аңлап, бу хакта башка сүз кузгатмады. Ни дисәң дә, ул врач бит әле.

— Техникумга керергә телим, Баязит абый, кайда керим икән?

Баязит үзе белгән берничә техникумны тәкъдим итеп карады.

— Юк, медицинскийга керәм,— диде Дәлия. Күрәсең, моны ул алдан хәл итеп куйган, шушы хакта Баязитның фикерен беләсе килгән.

— Кер, бергә укырбыз,— диде Баязит, Дәлиянең сулып калган ак йөзенә кызгану катыш сөю белән карап.

— Нигә, сез укуыгызны тәмамламадыгызмыни әле?

— Мин ординатурада укыячакмын.

— Ничә ел?

— Өч.

Дәлия сөенүен яшермичә әйтеп куйды.

— Техникум да өч еллык!

— Бик әйбәт, бергә-бергә укырбыз.

Дәлиядәге җилбәзәклекнең әсәре дә калмаган. Бу сөйләшүдән соң Баязит аны үзенә тиң түгел дип башына да китермәде. Апалары теләсә ни әйтсен, Баязит аларның бер сүзенә дә колак салмаячак.

Дәлия өченче курста укыганда аларның балалары туды. Законлы никахлары юк иде, чөнки моряк аерылышырга ризалык бирми җәфалады. Яшь бала белән торыр куыш табу гүр газабына әйләнде. Ярый әле, Баязитның иптәшләре ярдәм итте. Яшертен-качыртын яшь әти белән әнигә бер бүлмә бушаттылар. Баязит фән юлыннан китәргә, институтта калырга тиеш иде. Квартир хәсрәте һәм никахсыз яшәү тудырган борчулар аны бүтән юл сайларга мәҗбүр итте. Министрлыктан направление алып, яшь нефть шәһәренә китәргә булдылар. Анда бераз яшәгәч кенә гаиләләрен законлаштырдылар. ЗАГСка гариза китерә килгәч, күзлекле ханым юка гәүдәле, ак чырайлы Дәлиягә карап торды, аннары имән өрлектәй Баязиттан сорап куйды:

— Беренче мәртәбә өйләнәсезме?

Көтелмәгән сораудан Баязитның күңеле рәнҗеде. Ул да ирексездән Дәлиягә күз төшерде. Янәшәсендә үсмер кыз кебек җиңел, сылу зат басып тора. Тупас, әдәпсез соравы өчен «күзлекле»гә каты гына шелтә сүзе әйтәсе килде. Ләкин ничек әйтсәң дә, Дәлиягә кагылыр төсле, икенче тапкыр иргә чыгучы ул бит. Хәер, паспортларны актарып карагач, «күзлекле» үзе дә уңайсызланып китте.

Яңа урында яңа тормыш башлап җибәрделәр. Әле соңыннан да Казаннан яки башка җирдән килгән коллегалары Дәлиянең яшьлегенә ишарә ясап, сорап куйгалыйлар иде:

— Беренче хатыныңмы?

Мондый сорау һәр вакыт Баязитның күңелен әрнетә һәм бу хакта сүз озайтмаслык итеп җавап бирә:

— Сугышта өйләнергә туры килмәде, соңлабрак өйләндем, кайтып институт тәмамлагач кына...

Дәлия бөтен тирә-якта үзенең иреннән дә әйбәтрәк хирург юк дип исәпли, шуңа бүтән врачлар белән, шул исәптән баш врач Алкина белән дә башын бик түбән иеп исәнләшми. Кичәләрдә (яшьрәк чакта йөргәлиләр иде) Баязит белән үзе генә бии. Алар икәү бергә сирәк булалар. Дәлия бергәлекнең кадерен бик белә. Баш врач Дәлиянең итәгатьсезлеге өчен дә Аллаяровка ачулы түгел микән әле. Дәрәҗәле хатын-кыз үз затыннан булган икенче берәүне илтифатсызлыгы өчен генә түгел, чибәрлеге өчен дә кичерми. Әгәр инде ул затка үзенең күңеле төшкән ир-ат караса, үләр дәрәҗәгә җитеп куралмый. Һәрхәлдә, Аллаяровның Дәлиягә уңайлырак эш шартлары тудыру турындагы таләпләренә Алкина игътибарсыз калды гына түгел, аяк чала килде.

Бүген Аллаяров әллә ничаклы истәлекләргә бирелеп утыра ала, аның ишеген беркем килеп шакымый. Ул үзе дә, прокурор һәм мәет турында уйламаска теләптер, бүтән кичерешләр белән мәшгуль. Кинәт ул тынлыкның озакка киткәнен чамалап алды, тик утырудан оешкан тәне салкыннан калтырап куйды.

**(Дәвамы бар.)**

## Ямаш Игәнәй

# И ГҮЗӘЛ ГАМЬ...

•

Тауларның теге ягына
Минем дә барасы бар:
Юлдагы ташны, кыяны
Урталай ярасы бар!

Тауларга җибәр мине, Ил,
Мин дә бер барып багыйм,
Кояшка манчып каләмне,
Берәр җыр язып карыйм...

•

Бала чакны бөтенләйгә
Ник калдырып китим инде?
Хәзер аңа кайтам кабат —
Салават күперен үтим инде...

•

Елга өсте чуп-чуар:
Боз өстендә бөрчек-бөрчек
Балыкчылар, балыкчылар...

Уймак-уймак бәке уйган:
Бәкеләргә — нурлар тулган.
Боз — салават күпере сыман!

Зәп-зәңгәр күк, зәп-зәңгәр боз,
Зәп-зәңгәр боз — зәп-зәңгәр күк.
Балыкчылар бөрчек-бөрчек...

Битне суык ала өтеп.
Балык каба бәхет кебек:
Берәүгә — юк, берәүгә — күп...

...Балыкчылар беткән китеп...
Алар өйдә инде күптән.
Җем-җем итеп төнге күктән
Җемелдәшә йолдызлар тик —
Алар тишкән бәкеләр күк...

●

Яңгыр койды, яңгыр койды!
Сыйлы итәр быел туйны:
Тамчыда — кыңгырау чыңы...

●

Язмыш буенча әйләнгән чакта
«Җир» дип аталган кораб-җисемдә
Синең йөрәгең килеп юлыкты
Минем бәхетнең тарту көченә.

Гомеребезнең орбитасында
Күктәге ике җисем шикелле
Галәм киңлеген урап йөрибез
Без бу дөньяның ике бөрчеге...

●

Бөтен җирдә гел син:
Кояш нурында — син!
Барыр юлымда — син!
Син — гөл керфегендә,
Син — чык бөртегендә!
Ишетелгән һәр көйдә,
Кешеләр телендә...
Менә монда гына,
Минем каршымда син.
...Офык артында син.

●

Тәрәзәмне кара пәрдә сыман
Ялангач төн кочып торган чагы.
Күңелемдә уйлар йомылганнар
Яшь бөркетләр кебек, кыядагы.

Тик бераздан таң яктысы балкыр,
Төн карасын ялкын ялмап утәр.
Шул ялкында утлы ярчык булып
Күтәрелер күккә яшь бөркетләр...

## Ничек китәсең

Китәр идем бәлки моннан мин:
Аягыма юллар уралган.
Күзләремә — дөнья, гүзәллек,
Тегәллисе эшләр — кулларга...

Йөрәгемә — туар җырларым,
Калдырасы эзләр юлларда...

Никадәрле — килер иртәләр,
Мәшәкатьләр алда көтәләр.
Бөтенесен шуның сүтәсем,
Очларына чыгып җитәсем
Булган килеш ничек китәсең?!.

## И гүзәл гамь...

Агылдың да назлы бер көй булып,
Сихерләдең тоташ — отып алдым.
И гүзәл гамь, синең белән хәзер
Һәрбер күзәнәге тулы җанның...

●

Аваз гына салганмын мин бишегемнән:
Сандугачлар туган телем алып килгән.

Аваз гына салганмын мин бишегемнән:
Кыр казлары моң аһәңен бүләк иткән...

Ялгышмамдыр бит, илдәшләр, атка менгәч
Шуларны мин җыр юлымда байрак итсәм?!..

●

Алтын бәхет кошын эзләп йөргән чакта
Юлыктым мин яраланган кыр казына.
Дәваладым. Аннан кошым китте очып,
Сыңар каурый гына калды кулларымда.
Кыр казының җан авазы ишетелерме
Шул каурыйның эзе булган моңнарымда?!.

## Ростислав Побережный

# ЗӘҢГӘР КОНВЕРТ

хикәя



Иртән иртүк рядовой Наил Сафиуллинның күңеле төште. Һаваның начар булуы да үзенекен итте булса кирәк, җил ком катыш кар туздыра, тышта тын алырлык түгел иде. Ә Наилгә көнозын автопаркта ачык һавада эшләргә туры киләчәк. Өстәвенә взвод командиры урынбасары белән дә әйтешеп алдылар. Наил җыештыручы итеп билгеләнгән иде. Рота физзарядкага чыгып киткәч, ул тәрәзәләрне ачты һәм казарманы себереп, кичәдән тапталган идәнне ялтыратыйм дип кенә торганда, дөбердәшеп егетләр кайтып керделәр. Әллә инде тизрәк әйләнделәр, әллә үзе ашыкмады, кыскасы — эшен төгәлләргә өлгермәде Наил.

Наилнең авылдашы, авылдашы гына да түгел — классташы сержант Мамотов, ризасызлыгын белдереп, аңа карап алды, ә ротаның тел бистәсе Юрпков авызын ерып, мыскыллап: «Без бит карт солдатлар... Ә карт солдат ул кара эш белән маташмый», — дип кычкырды. Ләкин сержантның ачулы йөзен күреп шундук тавышы киселде.

— Ә сезнең белән, Сафиуллин, соңыннан сөйләшербез, — дип сержант китеп барды.

«Ярар, сөйләшербез, — диде Наил. Ул койкасын рәтли иде. — Кара син аны «сезгә» күчүен, берәр хәл булса, я өйдән зәңгәр конвертлы хат килә калса, үзе һаман минем белән серен уртаклашкан була».

Үзләре белән бер класста укыган Фатыймадан нәкъ менә шундый зәңгәр конвертлы хатлар килә иде. Кыз икесенә дә ошый. Мамотовның турыдан-туры мин Фатыймага өйләнәм дип ычкындырганы да бар. Ә Наил исә Фатыйма турында үзенчә генә хыялланып йөри. Газапланса газаплана, ә серен берәүгә дә чишкәне юк.

Хат алды исә Мамотов аның янына йөгереп килә. Берәр аулак урында Наилне тотып ала да күзләренә карап: «Наил, өйләнәм!» дип пышылдый.

Мондый минутларда Наилнең йөрәгенә ут кабына. Тотасы да Фатыйманың үзенә туп-туры язып ачыклыйсы килә. Ләкин килгән

хатны ротадагылар күрүе бар. Шуннан уңайсызлана Наил. Сеңеленә язган сирәк-мирәк хатларның берсендә читләтеп кенә сораштырган да иде үзе, тик кызчык аңлап бетермәде булса кирәк. Наилнең Сергей Мамотов белән төшкән фотосын Фатыйма үз өстәлендә тота дигән җавап килде. Җитмәсә: «Сергей булгангадыр инде...» дип тә өстәгән.

«Бетте дуслык», — дип уйлап куйгалый иде Наил күңелсез генә. Ә бит нинди планнар корганнар иде. Армиядән соң бергәләп я Самотлорга, я башка берәр төзелешкә китәргә хыялландылар. Икенче классны шоферлар кайда да кирәк. Йокларга яткач еш кына (караватлары янәшә иде) чышын-пышын сөйләшәләр. Шулай яшәп ятканда... Хәлләр!

Отделениене иртәнге барлауга тезеп Мамотов: «Равняйсь, смирно!» — диде дә, аннары көтмәгәндә аның: «Рядовой Сафиуллин, сафтан чыгыгыз!» — дигән командасы ишетелде.

Наил аптырап калды. Янәшәсендә торган Юриков: «Сине чакыра!» дигәч кенә каушабрак алга атлады һәм кырт итеп сафка йөзе белән борылды.

Беренче карашка солдатлар битараф кына басып торалар кебек тоелса да, аларның үзенә карата теләктәшлек итүләрен Наил сизә иде.

— Безнең взводта яшьләр дә, картлар да юк, — дип кистерде Мамотов.— Моны аңларга вакыт, аңларга теләмәүчеләргә... чарасын күрербез!

Сержантның вакыйганы артык куертасы килми иде булса кирәк. Шуңа күрә ул:

— Бу юлы сүз белән генә бетерик... Сафка басыгыз! — дип үзенең тәрбия эшен тәмамлады.

Биек тимер койма белән әйләндерелгән автопаркта җил ыжгыра иде.

«Берәр рейска-мазарга җибәрмәсәләр ярар иде, — дип, Наил «ЗИЛ»ның капотын күтәрде. — Бу һавада юлы рәтле түгел инде».

Сафиуллинның машинасы һәр вакыт төзек булыр. Кайчан гына кушма, ул, машинасын кабызып, дөнья чигенә барырга әзер. Наил, шоферлар гадәтенчә, буш вакыт тиде исә машинасында казына. Теләсәң, эш табыла инде ул.

Сафиуллин янына Мамотов кыяр-кыймас килеп чыкты. Иреннәрен чәйнәп бераз торганнан соң:

— Наил, син миңа үпкәләмә инде. Шулай кирәк. Взводта егетләр ни дияр иде бит? Якташлар, яклаша димичә калмаслар иде, — диде.

— Сез, иптәш сержант, җаныгызны бушатырга бүтән кеше эзләгез,— дип, Наил дә сыртын күпертте.— Хәрби дисциплинаның нәрсә икәнен беләбез.

Иртән Наилнең аңа бик тә ачуы килгән иде шул. Бернинди зәңгәр конвертларга игътибар итмичә үзен аның белән рәсми тотарга сүз бирде.

— Ихтыярың,— диде Мамотов көлемсерәп,— бу сөйләшү миңа караганда синең үзеңә кирәгрәк.

Дөресен генә әйткәндә, Наилнең дә дусты белән элеккечә рәхәтләнеп бер сөйләшәсе килә иде. Берәр ышыграк җиргә кунаклап, сигарет көйрәтә-көйрәтә гапләшәсе, дусларча итеп: «Аңлашыла, Серега, служба!» диясе иде дә бит. Бәлки ул шулай иткән дә булыр иде, ләкин паркның дневальные килеп:

— Сафиуллин, сине ротный чакыра, тиз бул,— диде.

КТПның тәмәке төтене таралган бүлмәсенә кереп Наил честь бирде һәм килүен әйтте.

— Машинагыз ни хәлдә, Сафиуллин?

— Нормально, иптәш капитан.

Һәм шунда ул ротный янында утырган түгәрәк йөзле, киң кашлы прапорщикны күреп алды. «Шактый таушалган бу», — дип уйлап куйды Наил эченнән генә. Тегенең кыяфәте, чыннан да, йончыганга охшый иде.

— Хәзер прапорщик белән юлга чыгасыз, — дип, капитан киң кашлыга ымлады.— Төянеп, йөкне Н-скига илтерсез. Бәлки әле караңгы төшкәнче кайтып та җитәрсез.

«Булмас, буран бит, бәлки көтәргәдер», — димәкче иде дә Сафиуллин, дәшмәде. Күнегелгән хәрәкәт белән честь биреп, китәргә борылды.

— Тукта, ашыкма. Моңарчы сырт аша чыкканың бармы, юкмы? — диде прапорщик.

Сигаретын кабызып маташкан капитан үпкәләгән сыман итеп:

— Сорап торуның кирәге юк, прапорщик. Сафиуллин безнең иң яхшы шоферлардан. Рейсларга күп йөри, Н-скида да булганы бар...

— Мин болай гына,— дигән булды прапорщик, уңайсызланып.— Анда юл начар бит, шуңа соравым...

Йөкне тиз төяделәр. Прапорщик һәр әрҗәне үзе җайлап тезде. Йөк бик җаваплы иде булса кирәк.

Аннан ул кузовны каплаган брезентны тикшереп чыкты һәм кыенсынып кына:

— Син, Сафиуллин, монда тартып ал инде, юлда тагын берәр җирдә туктарбыз. Ату мин тәмәке төтенен сөймим,— диде.

— Ә мин, иптәш прапорщик, юлда тартмыйм, — диде Наил елмаеп: юлдашы ярыйсы гына адәм күренә лабаса.

Наил машинасын әйләнеп күз йөртеп чыкты, тәгәрмәчләргә типкәләде һәм кабинага кереп утырды. Киттеләр!

Автострададан борылып гади юлга чыккач, кар салган урыннар очрый башлады. «ЗИЛ» аларны сытып буран эченнән алга бара бирде. Бер туктаусыз мотор гүелдәве, тәрәзә чистарткычның «шылтшылт» эшләве генә ишетелә иде.

«Сергей белән сөйләшәсе калган,— дип уйлап куйды Сафиуллин. — Начар егет түгел бит. Бергә үстек, укыдык... Фатыйманың аны сайлавында ул гаепле мени». Шулай да Фатыйма турында уйлап барган Наил каршында Мамотовның яхшы яклары шактый уңа төштеләр. Фатыйма белән җиңел түгел шул! Ул аларның берсен дә аермады, өчәүләшеп кинога, танцыга йөрделәр, армиягә дә икесен берьюлы озатты. Ә хатлары менә Сергейга гына килә. Хат алган саен Сергей аның сәламен генә тапшыра, ә бүтән ләм-мим.

Кинәт Наил кулындагы руль бер якка тайпылып куйды, алгы тәгәрмәч ниндидер йомшак әйбергә килеп төртелде.

Сафиуллин шундук тормозга басты. Прапорщик чак кына тәрәзәгә бәрелми калды.

— Утын төядең мәллә? — дип сукранды ул.

Наил алгы тәгәрмәчләрне дә эшкә җикте: юлда беленер-беленмәс эз төшкән көрт ята иде. «Мөгаен, «Жигули» үткәндер»,— дип уйлады шофер.

— Алда берәрсе кереп утырган булса, үтеп булмаячак, — диде Сафиуллин прапорщикка.

— Нишлик соң?

— Барыйк әле, анда күрербез.

«Жигули»ны алар тауга күтәрелә башлаганда очраттылар. Машина янында свитер кигән озын буйлы ир-ат маташа иде.

Кабинадан чыгып, Наил аның янына килде. Артыннан, кыска аякларын алпан-тилпән китереп, прапорщик иярде.

— Кереп утыргансың икән, — диде Сафиуллин.

— Шул-шул менә! — диде тегесе башын кагып.

— Моторыңны кабыз, эттерәбез, — диде Наил. Һәм озын буйлының аңламавын күреп, ишарә белән аңлата башлады.

«Жигули» хуҗасы иңнәрен сикертеп, кулын гына селтәде, мотор эшләми, янәсе.

— Хәлләр! — дип сузды Сафиуллин.

Тау сыртында җил тагын да көчәя төште. Берничә минуттан көчле «ЗИЛ» салган эзләр дә күмелеп тигезләнделәр.

— Кузгалырга кирәк. Тагын егерме минут торсак, бүген өлгереп булмаячак, — дип, Наил прапорщикның колагына кычкырды.

— Ә боларны нишләтәбез? — диде прапорщик, кабина тәрәзәсенә борыннарын төртеп утырган ике балага күрсәтеп.

— Буксирга алабыз.

Көрәк белән юлны чистарта-чистарта, сырт аша озак бардылар. Прапорщик тәгәрмәчләр астына такта, агач кисәкләре кыстырды. Югарырак менгән саен кабинадан ешрак чыгарга туры килде. «Жигули» хуҗасының салкын машинадагы ике кечкенә кызы туңа башлады. Аларны бушлат белән төрделәр.

Эңгер-меңгердә генә сыртны аркылып, таудан төшә башладылар. Аста утлар җемелдәшә иде. Җил тәмам тынды, юлга салган кар да сирәгәйде. Буран сыртның теге ягында гына котырынган, ахры. Шәһәргә керер алдыннан «Жигули» хуҗасы озак итеп аларның кулын кысты, рәхмәтләрен әйтте.

Йөкне тиз генә тапшыргач, кире юлга кайтырга чыктылар. Таудан төшү ансатрак иде, ләкин Наилнең тәне бик каты кыза башлады.

— Тиздән кайтып җитәбез, аз гына түз, Наил, — дип, прапорщик авырый башлаган солдатка ялварды.

Кайтып машинасын автопаркка куйганын Наил хәтерләми...

Ул күзенә кояш нуры төшүдән уянып китте. Уянды, ләкин кайда ятканын аңлый алмады. Буран үзе дә, сырт аша чыгу да, онытыла барган төш шикелле, томан эчендә иде. Сак адымнар белән бүлмәгә ак халатлы ханым килеп керде.

— Ну, хәзер хәлләр җайланды, — диде ул, Наилнең маңгаена кулын куеп. — Син, Наил, өч төн саташып, бураннан аерыла алмый ятканда, дустың тәрәзә каршыннан китмәде. Хәлең яхшыруын белеп, сиңа менә шушыны тапшырырга кушты.

Ул Сафиуллинга тасма белән бәйләнгән зәңгәр конвертлар сузды. Өстә кечкенә генә язулы кәгазе дә бар иде. «Наил, — ул шундук Мамотовның кулын танып алды, — мине гафу итә күр, бу хатлар сиңа кагыларак бирә... Укыгач аңларсың».

Тышта яз башланды. Якты тамчылар дөп-дөп итеп калай тәрәзә төбенә тамалар иде.

Самат Шакир

# УТЛЫ ЕЛЛАР ӘЛЕ ДӘ ХӘТЕРДӘ



Язгы кояшлы көннәрнең берсе. Агачларның шау чәчәктә чагы. Күк йөзе зәп-зәңгәр, әйтерсең лә зәңгәрсу пыяла. Әнә шул зәңгәрлектә якты һәм җылы кояш йөзә. Табигатьнең иң күркәм, иң гүзәл вакыты.

«Газик» машинасы таш юлдан элдерә генә. Машинада шофер һәм урта яшьтәге кеше. Шофер авылга якынлашканда машинаны әкренәйтә төште. Озын буйлы, озынча яңаклы, килешле төз борынлы кеше шоферга карап болай диде:

— Сугышта минем бик якын дустым бар иде, ул дошманга каршы һөҗүм сугышларында һәлак булды. Батыр һәм кыю сугышчы иде. Ул үләр алдыннан шундый васыять әйткән иде: «Якташ, әгәр мин бу сугыштан кайта алмасам, Кукмара районындагы туган авылыма барып әти-әниләремне, сеңелем Настяны күр, аларга минем ничек һәлак булуымны сөйлә. Туган җирдән читтә, туган туфрактан еракта соңгы сулышымны алуымны алар белеп торсыннар. Без газиз туган ил өчен кан коеп, соңгы сулышыбызга кадәр сугышып, нәселебезгә тап төшерми һәлак булабыз!»

Аннары әлеге кеше авыр сулап куйды һәм бөтен йөрәгеннән чыккан әрнү сүзләрен әйтте:

— Сугыш имәндәй таза бик күп егетләрне әрәм итте. Ничә еллар үтсә дә, әле һаман сугыш җәрәхәтләре саклана. Озак еллар үтүгә карамастан, мин әлеге сугышчының васыятен җиренә җиткереп үти алганым юк. Менә шуны уйлап төннәр буена йоклый алмый ятам...

Машина авыл уртасындагы бер капкага туктады. Капка төбендә торучы бер агайдан Иваннарның йортын сорадылар. Агай сорауга каршы үзе сорау бирде:

— Ә сез кем буласыз?

— Иван белән бер дивизионда хезмәт иттек. Аның соңгы сәламен тапшырырга килдем.

— Бик изге эш эшлисең, — диде агай һәм Иванның әти-әнисе торган йортны күрсәтте. Аргы очтарак иде ул йорт. «Газик» тагын кузгалып китте. Йорт янына килеп җитү белән капка төбенә яшь кенә хатын, олы яшьтәге агай һәм балалар чыкты. Машинада утырып



килгән озын буйлы кеше аны шунда ук танып алды. Сугыш вакытында ул үзенең фоторәсемен Иванга җибәргән иде. Шактый вакыт узуга карамастан, әлеге кешенең хәтере ялгышмады, яшь хатын, чыннан да, Настя булып чыкты. Настя үзенең абыйсы белән бергә фашистларга каршы сугышкан кешене таныды (чөнки алар сугыш елларында хатлар алышканнар, фоторәсемнәр бүләк итешкәннәр иде).

— Нургали! — диде Настя, аның күзләренә мөлдерәп яшь чыкты.

Олы яшьтәге кеше Нургалине кысып кочаклады. Озак кына сөйләштеләр алар, узган авыр сугышларны, Иванның батырлыклары, аның бик матур итеп җырлавы, авылдан хатлар алуы, тиздән дошманны җиңеп, туган якларга кайтырбыз! — дип йөрүләре телгә алынды. Озын буйлы кешенең — Нургали Сафинның да күзләренә терекөмеш кебек булып яшь бөртекләре чыкты. «Их, авыр, авыр да соң Иванның туган авылга кайта алмый, ерак сугыш кырында ятып калуы!» — дип уйлады Нургали.

Капка төбенә авыл халкы җыйналды. Барысы да Иванның кешелекле булуы, колхозда алдынгы булуын телгә алдылар. Сугыш кырында күрсәткән батырлыклары аерата калку итеп, яшьләргә үрнәк итеп сөйләнде. Озак та үтмәде, колхоз председателе, авыл активлары килеп җитте. Алар да Иванны мактап телгә алдылар, аның фоторәсеме мәктәп-музей почмагында торуын, исеме авыл уртасындагы һәйкәлгә уелып язылуын әйттеләр.

Өй эчендә чәй кайнап чыкты. Барысы да түгәрәкләнеп өстәл тирәсенә утырып чәй эчтеләр, Иванның фоторәсемнәрен карадылар. Настя аның соңгы хатын эзләп тапты. Барысы да шул хатны кулданкулга йөртеп укыды. Бик тирән фикерле, йөрәкләрне тетрәтерлек сүзләр язылган иде анда. Авыл кешеләре сугышны башлап җибәргән фашист илбасарларына мең-мең ләгънәт укып, Гитлерны сүктеләр, авылдан киткән икейөзгә якын кешенең борылып кайтмавын әйттеләр.

Чәй эчелеп, Иван турында истәлекләр сөйләнгәч, аның кайда һәм ничек һәлак булуы турында Нургали бик тәфсилләп аңлатты. Аның каберенә сукмак өзелмәвен, мәктәп балаларының шефлык итүен, чәчәкләр-гөлләр белән бизәвен әйтте. Соңыннан ул Иванның әтисе, сеңелесе һәм туганнары белән хушлашып китеп барды. Аны Иванның туганнары һәм авыл халкы озатып калды.

Нургали юл буе авыр сугыш елларын уйлап кайтты. Аның үзенең дә Иванныкы кебек әти-әнисе, туганнары бар иде. Алар аңа сугыш кырыннан исән-сау кайтуын теләп хатлар язалар, немец-фашист илбасарларны тизрәк тар-мар итеп, өйгә кайтуны телиләр иде. Элекке солдат, хәзер исә запастагы майор Нургали Сафин үзенең башыннан үткәннәрне күз алдына китерде.

Бөек шагыйрь Г. Тукай мактап телгә алган Казан арты авылы Мәмсәдә туды Нургали. Бу 1920 ел иде. Әтисе Сафа абзый, әнисе Гаффәбану апа авылның эшчән, тырыш кешеләре иде. Сафа абзый граммоталы кеше булып, Мәмсәдә генә түгел, тирә-як авылларда хөрмәткә ия иде. Аның тапкыр, җор сүзләре, төпле киңәшләре һәркемне үзенә җәлеп итә иде. Нургали дә бала чагыннан ук укуга бик тырыш булды. Ул алты яшендә үк үзлегеннән укый-язарга өйрәнде, беренче класста укыганда башка балаларга үрнәк булып торды. Өченче-дүртенче классларда укыганда укытучыга ярдәм итә, артта калучы укучыларны дәрестән соң өйләренә барып өйрәтә, математикадан мәсьәләләр чишә, кыскасы, һәрнәрсәгә өлгерә идә. Авыл халкы арасында да, «Сафа абзый малае мәктәп күләмендә беренче урын алган», дип сөйлиләр иде. Җәйге каникул вакытларында Мәмсә болынында төрле төстәге хуш исле чәчәкләр җыюлар, Ашыт суында коенулар, зират артындагы борма сукмактан Иске Кенәр авылына әбиләренә кунакка барулар. Ташкичү аланлыгында җиләк җыюлар әле дә күңел түрләрендә сакланалар. Нургали бала чакларында сабан туйларында көрәшә, сөлге-тастымаллар ала иде. Бала чак шуклыкларыннан аның хәтерендә тирән булып уелып калганы агач башындагы карга оясын туздыру булды. Әтисе моның өчен бик каты орышты. Дөрес, кул күтәреп сукмады, әмма әйтәсе сүзләрен әйтте: «Менә синең йортыңны туздырсыннар әле, нәрсә эшләр идең? Кошлар да шулай ук рәнҗиләр, оя туздыручыларны бер дә яратмыйлар!» — диде Сафа абзый. Нургали кызарды, әтисе алдында башын иеп, бер сүз дә әйтми басып торды, аннан күз яшьләрен сөртеп, күңеленнән генә: «Моннан соң бер кош оясын да туздырмам, йомыркаларын ватмам!» — дип ант итте. Иске Кенәр авылыннан килгән туганнары да Нургалине шелтәләделәр. Малай алар алдында да үзенең гаебен таныды, гафу үтенде. Яшьлек җүләрлеге генә булган ул. Әнә шул күңелсез хәлдән соң кош оясын вату түгел, башка малайларны да тыя, кошларның файдалы якларын әйтә, аларга тияргә, рәнҗетергә ярамавын аңлата иде.

Гомер дигән нәрсә тиз уза шул. Әле кайчан гына Мәмсә урамнарын гөр китереп җырлап узган, Ашыт суында балык тоткан малайлар хәзер инде Яңа Кенәр мәктәбендә укып йөриләр. Алар хәзер олылар кебек фикер йөртә башладылар, биш километрлы араны җырлар җырлап кайталар, куян куалар, такмаклар әйтәләр. Нургали Тукай, Такташ шигырьләренә гашыйк иде. Ул Тукайның «Шүрәле» поэмасын яттан белә. Такташның «Мокамай» шигырен җыр итеп көйли. Бу елларда немец-итальян фашистлары Испания халкына каршы сугышалар иде. Нургали үзе дә испан балалары белән бер сафта фашистларга каршы көрәшергә тели. Бу турыда әтисенә дә әйтә. Сафа абзый көлә генә. «Испания бик ерак ул, улым, анда бару өчен диңгезләр кичәргә кирәк. Әле яшь син, үсеп җиткәч тә өлгерерсең, — ди. Аннары өстәп куя. — Сугыш һич кенә дә кирәк нәрсә түгел! Сез, улым, сугышны күрмәгез, тыныч, бәхетле яшәгез! Сугыш авырлыкларын бик күп татыдык инде без, улым!»

Ләкин шулай булса да йөрәгеннән генә сызлана: «Немец фашистлары бик котыра, ахыры хәерле генә булсын инде».

Яңа Кенәр мәктәбе зур һәм алдынгы мәктәпләрнең берсе. Нургали Сафин шул мәктәпнең алдынгы пионеры була, соңыннан комсомолга кабул ителә һәм җиде классны уңышлы тәмамлый. Ул үз авылында бөтенләй төпләнеп калырга, тракторчы булырга тели. Нәкъ менә шул елларда яшьләрне завод-фабрикага, производствога чакырып Совет хөкүмәтенең карарлары була. Нургали Сафин да гигант төзелешләргә ашкына. Ул моның өчен үзен квалификацияле эшче итеп әзерләргә кирәклеген аңлый һәм Казанга килеп электромонтер-

ар курсына кере. Курсны уңышлы тәмамлап, Казанда эшли. Тырыш һәм сәләтле егетне шунда ук күреп алалар һәм акчалата бүләклиләр. Аның эш тәҗрибәләре турында газеталарга язып чыгалар. Этисе Сафа абзый Казанга килгәч улының рәсемен стена газетасында күреп шатлана. Ул монтер улының тырыш хезмәте белән горурлана, улының аркасыннан сөеп:

— Молодец, улым! Синең кебекләр урамда шар сугып йөргәндә, син исә стахановчылар сафына басып эшлисең икән. Моның өчен үзеңә бүләк — тун! Суыкта туңмассың, рәхәтләнеп киеп йөр! Ә бусы — җылы бияләй. Монтер тышта эшли бит ул. Кулың туңа башласа, пушы бияләйне киярсең. Эшең уң булсын, миннән хәер-фатиха!

Әнә шулай тырышып эшләп йөргәндә Кызыл Армия сафына китәргә дә вакыт килеп җитә. Гәүдәгә таза, озын буйлы, ыспай һәм гыйбәр егетне тупчы итеп алалар. Нургали әти-әнисенә бу турыда белдереп, үзенең шинель, кызыл йолдызлы шлем кигән кызылармеец булуы белән горурланып хат яза.

Алар туплардан туры һәм төз атарга өйрәнәләр. Занятиеләр вакытында Нургали актив катнаша, төз атуы өчен командирлар мактап телгә алалар. Дөрес, авыл малаена рус телендә алып барылган дәресләр бераз кыенрак була, әмма тырышлык монда да җиңеп чыга. Нургали алдынгы кызылармеец булып Ерак Көнчыгышта да хезмәт итә.

1941 елның 22 июне. Ерак Көнчыгыш чикләренә кайгы хәбәре яшен тизлегендә тарала: «Немец фашистлары сугыш башлаган!»

Кызылармеец Нургали Сафин мәктәптә укыган вакытта ук фашистларның ерткычлыклары турында газеталардан укып белә иде. Менә шул фашист явы — соры чума Советлар Союзына ябырыла.

Нургали Сафин отличник кызылармеец-тупчы булганлыктан, 1941 елның декабрендә аны полк мәктәбенә укырга җибәрделәр. Курста укулар көнгә унар сәгать алып барыла. Укытучыларның күбесе Бөек Ватан сугышында булып, дары исе иснәгән командирлар. Алар яралары төзәлеп тә бетмәгән килеш полк мәктәбендә укыталар, сугышта күргәннәрен сөйлиләр, тәҗрибәләрен уртаклашалар.

Уку тәмам туйдыра Нургалине. Ул яңадан алгы сызыкка — фронтка җибәрүләрен сорап гариза яза. Аның гаризасын кире кагалар.

1942 ел. Япония чигендә тынлык. Яз якынлаша. Курсантлар чыгарылыш имтиханнары тапшыралар. Сафин барлык фәннәрне дә отличнога тапшыра, сержант дәрәҗәсе алып, отделение командиры була.

Сугышның беренче айларында японнар да тик ятмадылар. Алар чик аркылы шпионнар кертергә, Советка каршы җимерү эшләре алып барырга маташтылар. Ләкин совет пограничниклары аларны шунда ук юкка чыгаралар иде. Комсорг Сафин үзе дә берничә япон шпионын фаш итте һәм тиешле органнарга тапшырды.

Сафин өчен көткән көннәр килеп җитте. Бу 1944 елның август ае иде. Аларның дивизиясе Көнбатышка юл алды. Вагон тәрәзәләреннән карап баручы солдатлар арасында Нургали дә бар. Ул сопкаларга, тайга урманнарына карап моңлана, туып-үскән Татарстанын, туган авылы Мәмсәне сагына. Авылдан чыгып киткәнгә дә дүрт ел булган. Хәзер анда калган балалар зур булганнардыр, әти-әнисе дә олыгая төшкәннәрдер, авылның таза ирләре сугыштадыр...

Вагонда төрле милләт уллары бар: руслар, украиннар, белоруслар, казакълар, татарлар, башкортлар... Алар барысы да бер генә нәрсә турында уйлыйлар: дошманны җиңеп тиздән туган якларга кайту! Һәркемнең изге теләге иде бу! Туплар һәм солдатлар төялгән эшелон шактый озын юллар урап, күп кенә республикаларны, өлкә-

ләрне һәм крайларны үтеп, Мәскәүгә якынлашты. Сержант Сафин сагынуына түзә алмый җырлап җибәрде:

*Сандугачлар килгән безгә,*
*Китмәсләр микән көзгә?*
*Язгы сабан туйларына*
*Кайтырбыз әле без дә.*

Эшелон Мәскәү өлкәсе җирләреннән шактый барганнан соң, бер станциягә килеп туктады. Солдатлар вагоннардан коелдылар. Алар кайсы су алырга, кайсы якташларын очратырга теләп станциягә таба йөгерделәр. Сержант Сафин да вокзалга ашыкты. Вокзал тулы халык. Менә шулар арасында ул үзләренең якташларын эзләде. Ләкин бер генә таныган кеше дә очрамады. Ул як-ягына каранып кешеләрнең арасыннан узып түргә килде. Анда Иске Кенәр авылыннан килгән бер агайны очратты. Аның белән исәнлек-саулык сорашып сөйләшә генә башлаган иде, паровоз китү хәбәрен белдереп озын итеп кычкыртты. Сержант тиз генә хушлашты дә вокзалдан йөгереп чыгып китте. Арттан кемдер кычкырды:

— Нургали!

Сафин борылып карады һәм үзләренең авыл кешесен танып алды. Ләкин сөйләшә алмадылар, эшелон кузгалды. Сафин йөгереп килеп вагонга ябышты, аны сугышчылар кулыннан тартып менгерделәр. Авылдашы кычкырды:

— Җиңеп, исән-сау кайтыгыз! — дип кулын изәде авылдашы. Нургали пилоткасын селки-селки кычкырды:

— Рәхмәт, яхшы сүзеңә!

* * *

Нургали Сафин хезмәт иткән дивизион Беренче Белоруссия фронтында. Бу вакытта Нургали Сафин өлкән сержант иде. Фашистлар шәһәрләрне җимереп бетергәннәр. Кая карама ватык танклар, туплар, үлгән немец солдатлары ауный. Еракта авыр артиллерия туктаусыз атып тора. Сафин еракка ата торган тупларга ориентирны күрсәтеп торучы радист. Ул үзенең тупчыларын җыйнап алда торган бурычлар турында сөйли:

— Дошман мәкерле һәм көчле. Аның техникасын һәм җанлы көчләрен юкка чыгару безнең бурычыбыз! Аерата безгә уяу һәм батыр булырга кирәк!

Тупчылар үзләренең комсоргларын яраталар, аның һәрбер сүзен үзләре өчен кирәкле икәнлеген чын күңелдән тоялар иде. Сафин сөйләп бетергәннән соң, күп кенә сугышчылар сораулар бирделәр. Әнә шулай итеп җанлы әңгәмә башланып китте. Бер үзбәк егете болай дип сорады:

— Советлар Союзыннан фашистларны куып чыгарганнан соң сугыш бетәрме?

Сафин бу сорауга шунда ук җавап бирде:

— Фашистларны тәмам тар-мар итәргә, Берлинны алырга тиешбез, дуслар!

Үзбәк егете башын кашый-кашый әйтте:

— Ай-яй, Берлин бик ерак бит әле, иптәш өлкән сержант.

— Ерак араны да якынайтырга, Берлинны, рейхстагны алырга, җиңүчеләр булып туган илгә кайтырга тиешбез!

Сугышчылар барысы да аңа рәхмәт әйттеләр. Сафин аларның йөзендә җиңүгә булган ышаныч, тәвәккәллек күрде. Аерата ул аларның бердәм тату семья кебек һәр боерыкны җиренә җиткереп үтәү-

ләренә шатлана иде. Әйе, сугышта төрле хәл була, бәлки аларның кайберләре булачак сугышларда һәлак булыр. Әмма бу аларны куркытмый, алар туган ил өчен үлемнең күзенә карап баралар. Алар чын совет патриотлары!

Тупчылар төн буе хәзерлек эшләре алып бардылар. Ә таң дошман оясына төзәп атылган авыр снарядлар шартлавы белән башланды. Еракка атучы туплар — гаубицалар тирә-якны җимерә, яндыра, дошман оясын туздыра. Радист — өлкән сержант Сафин күрсәтмәләре нигезендә тупчылар снарядларны тиешле урыннарга гына төшерәләр иде. Моны күреп торган дивизион командиры шатлыктан кычкырып җибәрде:

— Молодцы, егетләр!

Дошман каушады. Фашистлар тәртипсез ата башладылар. Ләкин аларның утлары тупчыларга зыян китерә алмый иде. Шуның өчен фашистлар танклар белән һөҗүмгә күчтеләр. Тупчылар килбәтсез һәм зур «Тигр»ларга төзәп ата башладылар. Беренче төркем танклар сугыш кырында дөрләп яналар иде. Бу коточкыч хәлне күргәч, икенче төркемнәре кире борылырга мәҗбүр булды. Берничә «Тигр» шактый ук алга килә алса да, радист — өлкән сержант аларны шунда ук күреп алды һәм тупчыларга тиешле күрсәтмәләр биреп, бер-бер артлы сафтан чыгартты. Иң кирәкле чакта снарядлар килеп җитми иде. Сафин ярсулы кычкырды:

— Тизрәк кыймылдагыз! Фашист танкларын алга җибәрмәгез!

Снарядлар авыр булганлыктан, берничә сугышчы ташый, кайвакытта яралылар да булыша иде. Сугыш каты булды. Тупчылар да сафтан чыктылар. Яралы сугышчылар үзләренең сөекле комсорглары белән бик авыр хәлдә хушлаштылар. Чөнки алар биш елга якын бергә хезмәт иткәннәр иде бит. Сугышта төрле хәлләр була шул. Яраланып, дусларыңны калдырып госпитальгә китү дә, яки бөтенләй һәлак булуың да мөмкин. Нишлисең. Сугышның үз законнары бар.

Дошманның өстен көчләрен тар-мар итеп, еракка атучы тупчылар ял-йокы күрмичә алгы позициягә күчтеләр.

Бу — Белоруссия җире иде. Немец-фашист илбасарларыннан зур җәфалар күргән картлар һәм карчыклар, хатын-кызлар һәм балалар Совет Армиясе сугышчыларын шатлык белән каршы алалар. Араларында беренче бөтендөнья сугышында катнашкан сугыш инвалидлары да бар. Алар аксый-аксый алга чыгып Совет Армиясе сугышчыларын кочаклап үбәләр, фашистлар тырнагыннан коткарулары өчен зур рәхмәт укыйлар, кайберләре инвалид булуга карамастан, сугышчылар сафына алуны, корал бирүне үтенеп сорыйлар. Остап исемле карт Сафинны кочаклап, үксеп елап җибәрде:

— Син минем улыма охшагансың. Улымны немец фашистлары пленга алганнар һәм авыр таш бәйләп тере килеш суга ыргытканнар. Нәләт төшсен аларга! Шуның өчен үч алырга телим мин алардан. Дөрес, минем бер аягым юк, әмма минем кулларым бар, мин әле автоматтан ата алам! Улым, ал мине үзегезнең сафыгызга!

Өлкән сержант Нургали аңа үзенең тупчы булуы, ә тупчыларның аяклы булырга тиешлеген аңлата. Бу белорус карты кайсы ягы беләндер аның туганнарына охшый. Шуның өчен Нургали аны кабаткабат кочып үбә һәм киткәндә истәлеккә үзенең фоторәсемен бүләк итеп калдыра. Белорус карты баш иеп рәхмәт әйтә һәм рәсемне куен кесәсенә тыгып куя.

Белоруссияда вакытта Сафин туган авылыннан берничә хат ала. Хатка авыл хәлләрен әйтеп язганнар. Өлкән сержант аларны йотлыгып укый һәм сугышның авырлыгы, ягарга утын, кияргә кием, ашарга икмәк җитмәве, аның яшьтәшләренең күбесе сугыш кырында ятып

калуы, колхозда эшләү өчен ир-атның аз булуын, шулай булса да фронт өчен тырышып эшләүләре турында белә. Сержант Сафинның йөзенә фашистларга каршы үч, нәфрәт һәм ярсу тагын да куәтләрәк булып бәреп чыга. Ул ярсулы хәлдә дивизион командиры янына китә. Ләкин штабка барып җитә алмый, һава тревогасы башлана. Сафин, башка сугышчылар белән бергә, агачлар арасына кереп кача. Кара тәреле самолетлар авылга шактый зыян китерәләр: йортлар яна, үлүчеләр һәм яралланучылар да байтак була.

Сафин яткан җиреннән күтәрелеп карый һәм бер яралы атны күрә. Атның алгы аяклары яралы, ләкин ул бомбалар шартлавыннан куркып качарга тели, яралы аяклары белән аксый-аксый чаба...

Немец самолетларын совет очкычлары куа китә. Сафин дивизион командирына үзенең үтенечен белдерә:

— Ни өчен бер урында озак торабыз? Минем эчем поша башлады, иптәш командир!

Дивизион командиры елмаеп куйды һәм өлкән сержантның аркасыннан җиңелчә кагып, болай диде:

— Яратам синең кебек тынгысыз сугышчыларны! Совет Армиясе шуның белән көчле дә! Син комсорг та бит әле, тәртипне беләсең, югарыдан күрсәтмә бирелми торып, ашыгырга ярамый.

Алар икесе дә урман итәгендәге сукмактан киттеләр.

Сафин землянкага кайтканда тупчылар кайгылы хәбәр әйттеләр. Бомба ярчыгы снаряд биреп торучы өлкән яшьтәге Тимофеевны каты яралаган. Санбатка алып барганда ул соңгы сулышын алган. Бу турыда ишетеп, өлкән сержантның якташы Иван Терентьев та бик борчылган. Ул тәмәкесен каты итеп суырды да көрәктәй кулларын селки-селки әйтте:

— Фашистлар нинди кешебезне әрәм иттеләр. Юк, моның өчен без аларны эссе табада биетербез әле!

Сафин да кайгыны авыр кичерде.

Иртәгесен яңа боерык килде: дошманга һөҗүм итәргә! Барлык сугышчылар да бу хәбәрне шатланып кабул иттеләр. Тупчылар сугышчан әзерлектә торалар иде. Нәкъ 12 сәгатьтә һөҗүм башланды. Авыр артиллерия — сугыш алласы җир тетрәтеп туктаусыз утялкын өрде. Авыр снарядлар тиешле урыннарга төшеп, җирнең астын-өскә китерделәр.

Сугышчылар әнә шулай һаман алга юл ярдылар. Белоруссияне азат итеп, Польша җиренә аяк бастылар.

Познань янында барган каты сугышларда Сафинның якташы, Кукмара районыннан килгән сугышчы Иван Терентьев снаряд төшеп һәлак булды. Бу ачы кайгыны тупчылар бик авыр кичерделәр. Өлкән сержант сугышчан дустының кабере алдында аның батырлыклары турында сөйләде, якташының намуслы һәм тыйнак булуын әйтте. Соңыннан барысы да баш киемнәрен салып, тын гына басып тордылар. Сугышчан иптәшне хөрмәтләп, автоматлардан атып салют бирделәр.

Варшаваны азат итү сугышлары. Сафин анда «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде.

Варшава шәһәре турында Сафин авылда чакта ук гражданнар сугышы ветераннарыннан ишеткәне бар иде. 1920 нче елны генерал Пильсудский җитәкчелегендәге ак поляклар яшь Совет республикасына каршы сугышканнар иде. Польша фронтында булган Сафиулла солдат әле хәзер дә исән. Аның әйткәннәре Сафинның колак төбендә яңгырый кебек:

— Варшау бик матур шәһәр. Ләкин без анда кадәр барып җитә алмадык, мир булды. Без өч айдан соң өйләребезгә кайтып киттек.

Менә шул Сафиулла мактап телгә алган Варшауның урамнарыннан үз аяклары белән уза Сафин. Кем булып диген әле? Җиңүче солдат булып! Польша халкы фашистларның ерткычлыгыннан тәмам туйган, шуның өчен ирек алып килүче совет сугышчыларына меңмең рәхмәт әйтә. Урамнардагы халыкның кулында чәчәк, йөзе көләч һәм шат. Алар җиңеп килгән совет офицерларына һәм солдатларына чәчәкләр бирәләр, бергәләп биилар, җырлыйлар.

Польшаны азат иткәннән соң Беренче Белоруссия фронты сугышчылары Германия җиренә аяк басты. Германиянең күп кенә авылларын һәм шәһәрләрен фашистлардан чистартып, Беренче Белоруссия фронты гаскәрләре Берлинга якынлаштылар. Өлкән сержант Нургали Сафин үзенең көндәлегенә болай дип язып куйды: «Дөньяны яулап алырга хыялланган фашистлар кая кереп качарга урын тапмыйлар. Алар, коралларын ташлап, куркып-каушап кулларын күтәрәләр һәм «Гитлер капут!» диләр. Ә без аларга: «Башта ук — сугыш башлаган вакытта ук әйтергә кирәк иде ул сүзләрне!» дибез».

Гаскәр ташкыны фашизм оясы Берлинга агыла. Һәркем беренче булып фашистлар оясын туздырырга һәм беренче булып шул шәһәргә бәреп керергә ашыга. Маршаллар, армия генераллары һәм полковникларның карталарында Берлин кызыл һәм зәңгәр карандаш белән дүрт-биш мәртәбә уратып алынды. Пленга алынган немец офицерлары һәм солдатлары, куркып, калтырап кулларын күтәреп, «Гитлер капут!» диләр. Хәтта генераллары да: «Сугышны Гитлер башлады, без гаепле түгел, безне атмагыз, Гитлер капут!» дип акланырга телиләр. Өлкән сержант Нургали Сафин, авыр һәм озын юллар үтеп, Берлин янына килеп җиткән татар егете, Мәскәү янында барган кан коюлы сугышларда катнашкан рус егете Степан Богатырев, Орел — Курск дугасы сугышларында катнашкан украин егете Петро Сыроежкин ачулы хәлдә немец әсирләренә карап торалар. Степан Богатырев өлкән сержант Сафинның, иңенә кулын куеп, фрицларга төртеп күрсәтә:

— Нинди мескен хәлгә килгәннәр, күзгә чебеш кебек. Мәскәү янына килеп җиткәндә күкрәкләренә сугып, «Без — җиңүче!» дип мактаналар, кулларын алга сузып, «Хайль Гитлер!» — дип кычкыралар иде.

Тупчылар тирә-яктагы җимерелгән йортларга, сынган агачларга һәм снарядлар сөреп бетергән басуларга күз төшерделәр. Баш очыннан гына кызыл йолдызлы самолетлар оча иде. Сафин фуражкасын югары күтәреп, аларга карады һәм шатланып әйтте:

— Безнекеләр! Берлинга күчтәнәчләр алып баралар.

Тупчылар аны куәтләделәр.

— Тиздән Берлинга һөҗүм башланачак! — диде Степан Богатырев.

— Гитлерның оясын туздырачакбыз! — дип өстәде Петро.

Кичкырын яңгыр ява башлады. Берлинга бара торган юллар тәмам изрәде. Тупчыларга бу аерата кыенлык тудыра иде. Шулай булса да, штабтан катгый приказ килде: «Авыр артиллериядән Берлинга төзәп ут ачарга!»

Тупчылар шатлыктан тыпырдап биеп алдылар, бер-берсен кочаклап үптеләр, һәр тупчы беренче снарядны Берлинга атарга тели иде. Бу бәхет өлкән сержант Нургали Сафинга туры килде. Снарядларга «Берлинга!», «Гитлерның башына!» дип яздылар. Тугыз потлы снарядны туп көпшәсенә кертеп, беренче булып атып җибәрделәр. Аннан соң икенче, өченче, дүртенче снарядлар очты. Башка тупчылар да үзләренең күчтәнәчләрен Берлинга «бүләк иттеләр». Еракка атучы авыр туплар Берлин янындагы ныгытмаларның астын-өскә китерде. Озакка сузылган авыр артиллерия атуларыннан соң танклар һәм автоматчылар һөҗүмгә күчте. Берлин өстенә йөзләгән совет самолетла-

ры күтәрелде. Фашистлар оясы яна, җимерелә, тетри. Өлкән сержант Нургали әнә шул ут-ялкынга карап торды да уенын-чынын бергә кушып дусларына эндәште:

— Безнең снарядлар Гитлерның башына ук төшкәндер әле.

— Гитлер канцеляриясенә төзәп аттык бит,—диде төзәүче.

— Берлинны фанатик фашистлар, иң явыз СС дивизияләре саклый, диләр. Ә без аларның барыбер сырт сөякләрен сындырачакбыз! —диде комбат. Ул бинокль белән тирә-якка карады да кычкырып җибәрде:

— Каршыга җиңел машина килә, мөгаен, штабтандыр. Барыгыз да урыннарыгызга!

Тупчылар үз урыннарына бастылар. Комбат ялгышмаган иде, килүчеләр штаб начальнигы һәм артдивизион командиры булып чыкты. Алар килеп җитү белән штаб начальнигы машинадан төште, башка командирлар белән тупчылар янына килде һәм исәнләшеп, хәл-әхвәлләрен сорашты. Сафин төз басып честь бирде һәм:

— Кәефләр бик яхшы, иптәш полковник! Чөнки Берлин янына килеп җиттек! Тиздән фашистлар оясы безнең алда тезләнәчәк!—дип җавап бирде. Штаб начальнигы елмаеп аңа карады:

— Бик тиздән, иптәш өлкән сержант.

Штаб кешеләре тупчылар белән әңгәмә үткәргәч, сугыш кирәкяракларының җитәрлек булуы-булмавы белән кызыксындылар. Авыр снарядлар җитәрлек хәзерләнгән иде. Әнә шулай сугышчан хәзерлекне карап йөргәндә, һава тревогасы күтәрелде. Немец самолетлары тупчылар урнашкан җиргә якынлашты. Зенит туплары телгә килде. Свастикалы козгыннар якын килә алмадылар, бомбаларын кирәксез урыннарга ташлап качу ягын карадылар. Берничә «Мессершмитт» атып төшерелде. Парашют белән сикергән очучыны тупчылар пленга алдылар... Ике тимер тәреле бу очучы сорау алган вакытта елап җибәрде. Ул штаб начальнигына үзенең исеме язылган пистолетын биреп болай диде:

— Бу пистолетны Мадридны бомбага тоткан өчен бүләк итеп биргәннәр иде. Аннан соң Белград, Афина, Прага, Париж өчен... —дип тезеп китте фашист. Әмма аңа сөйләп бетерергә ирек бирмәделәр, тупчылар сүзне кыска тоттылар.

— Мәскәүне бомбага тоткан вакытта Берлинга килеп җитәрләр дип уйлап та карамагансыздыр әле!—диде Сафин, ачулы хәлдә, немец очучысына.—Елап торыр көннәрегез турында башта уйларга кирәк иде!

Шул вакыт олы юл буйлап бик күп немец әсирләрен алып килүләре күренде. Немец очучысы аларга карап торды да тагын үксепүксеп елый башлады.

— Нинди көннәргә калдык бит... Бу бары да Гитлер эше, аның башсызлыгыннан килеп чыкты...

Штаб начальнигы аңа кискен итеп җавап бирде:

— Ике йөзлеләнмә, майор әфәнде, әйдә, моннан үкчәңне күтәр!

Ике тупчы майорны тиешле урынга илттеләр. Төш авышып барганда гвардия минометлары — «Катюша»лар телгә килде. Тупчыларга яңадан атуны дәвам итәргә диген күрсәтмә бирелде.

*
* *

Берлин өчен каты сугышлар дәвам итә.

Өлкән сержант Сафин, комсомолларны җыйнап, алда торган бурычлар турында сөйләгәч, яшь егетләргә болай дип белдерде:

— Безнең каршыда— рейхстаг. Без шул фашизм оясына—Гитлер канцеляриясенә ут ачачакбыз!

Тупчы егетләр шатланып бер-берсенә караштылар. Өлкән сержант аларның күңелләрен күтәреп, дәрт өстенә ялкын өстәде:

— Иң беренче снарядны батыр комсомолец Салаватов атачак. Чөнки ул гитлерчыларга каршы сугышта үзен аерата күрсәтте!

Башкортстаннан килгән Салаватов өлкән сержантка честь бирде:

— Приказыгыз үтәлер, иптәш өлкән сержант!

Озак та үтмәде, штабтан приказ алынды. Анда рейхстагка һөҗүм башларга кушылган иде. Тупчылар үз урыннарына бастылар. Радист Сафин приборларны көйләп, тиешле күрсәтмәләрне бирде. Авыр туплар рейхстагка төбәлгәннәр иде. Салаватов һәм берничә сугышчы «Рейхстагка!» дип язылган снарядны туп янына алып килде. Тупны кордылар.

— Рейхстаг өстенә төзәп атарга! — дигән команда яңгырады. Снарядлар рейхстаг өстенә очты. Шундый ук снарядлар туп көпшәсеннән бер-бер артлы чыга торды. Берлин урамнары янып торучы свастикалы танклар белән тулы. Йортлардан, подваллардан, чардаклардан аталар. Аерата «Фаустпатрон»нар алга барырга комачаулый, танкларны, тупларны яндыра, урам сугышларында шактый кеше һәлак була иде. Геббельс үзенең явыз пропагандасын тормышка ашырган: урамнарда «Бер генә немец та пленга төшмәскә, капитуляция турында уйламаска тиеш!» дигән листовкалар ябыштырылган. Хәтта гитлерчылар халыкны һәм армияне ялган уйдырмалар белән куркытканнар. Шуның өчен немецлар ашый торган ашларын да ашамыйча йортларын калдырып качалар. «Совет кешеләре безне кырып бетерә»,— дип уйлаганнар. Совет гаскәрләренең картларга, балаларга, хатын-кызларга тимәгәнен күргәч, алар аптырап калалар, яралыларга совет врачлары ярдәм иткәнне күргәч, елап җибәрәләр.

Сафин һәм аның отделениесендәге тупчылар Берлинга беренчеләр булып бәреп керделәр. Ләкин фанатик гитлерчылар тиз генә бирелергә теләмәделәр, һаман каршылык күрсәттеләр. Совет сугышчылары яулап алган җирләрдә фашистлар бөтен әйберләрен калдырып качып киткәннәр. Тупчылар берничә йортка кергәч аптырап калдылар: ишекләр бикләнмәгән, йорт җиһазлары, кием-салымнар, хәтта өстәлдәге савыт-сабалар, самавар һәм чынаяк-тәлинкәләр шул килеш калган, ә хуҗалары юк. Соңыннан ачыкланды: болар иң явыз фашистлар булып, Совет Армиясе Берлинга бәреп керүгә куркып качканнар. Ә кайбер йортларда, подвалларда, чардакларда үз-үзләрен үтергән немецлар табылды. Семьяларын—хатын-кызларны, балаларны агулап яки атып үтергән СС офицерлары, хәтта генераллары да табылды. Өлкән сержант соңгы минутларында үзләрен агулап яки атып үтергән бу ерткычларга җирәнеп карады, ә гөнаһсыз яшь балаларны кызганды. Урамнарда да яшь балалар үлеп ята иде. Совет Армиясе Берлинга якынлашкач, фашистлар малайларны да мобилизацияләп, корал һәм кием биргәннәр. Менә шул малайлар чардаклардан аталар, суларны, ашамлыкларны агулыйлар, теш-тырнаклары белән каршылык күрсәтәләр иде. Аларның берничәсен тупчылар пленга алды. Өлкән сержант Сафин аларга ачулы эндәште:

— Әле борын төбегез дә кибеп җитмәгән, ни өчен корал алып безгә каршы сугышасыз?

Бер малай чәрелдәп җавап бирде:

— Без фюрерның боерыгын үтибез! Үлсәк тә изге Германия өчен үләчәкбез!

Сафин аңа:

— Нинди изге Германия ул?! Фашистларның Германиясе юк! Гитлер һәм аның фашистик Германиясе җиңелде, бары тик халык Германиясе бар!—диде.

Малай күзләрен өлкән сержантка текәп ялварды:

— Сез безне атып үтермисезме?

— Гаебегез булмаса, атмабыз!

— Безне Геббельс агентлары котыртты, алар корал бирде... Минем гаебем юк,—диде малай, дер-дер калтырап. Өлкән сержант малайларга консерв һәм бер кирпеч икмәк бирде. Тегеләр йотлыга-йотлыга ашый башладылар.

Сугыш тәмам булды. 9 май.

Бу көнне шатлыкның иге-чиге булмады. Тупчылар тупларын корып һавага атып салют бирделәр. Өлкән сержант Нургали каскасын салып тирләгән маңгаен сөртте. Ул шатланып елмайган хәлдә, күк йөзенә карады. Май кояшы нур чәчә иде. Тирә-якта дары һәм төтен исе аңкып тора. Янып торучы йортларга карап, өлкән сержант йөрәк түреннән чыккан сүзләрен әйтте:

— Моның дәвамы кирәк түгел!

Совет армиясе һәм союзниклар армиясе Эльбада очраштылар. Сафин аларның телләрен аңламый иде. Ләкин йөрәктән чыккан сүзләр бер нәрсә турында иде:

— Моннан соң сугыш булмасын! Тынычлык! Тынычлык! Дуслык! Туганлык! — диделәр сугышчылар.

1945 нче елның 24 июнендә Берлинда Җиңү парады үткәрелә. Өлкән сержант, дивизион комсоргы Нургали Сафин Җиңү парадында катнашты. Аларны Советлар Союзы Маршалы Г. К. Жуков тәбрикләде.

Сугышларда чыныккан, еракка ата торган тупчыларның отделение командиры Почет грамоталары, Верховный баш командованиедән рәхмәт кәгазьләре һәм медальләр алып туган якларына кайтты. Авыр тупны корып һәм дошман өстенә атып сөялләнгән куллар хезмәтне сагынып кайтканнар. Нургали Сафин туган авылы Мәмсәгә кайтып ял да итеп тормады, райкомга килде. Аңа җаваплы эш тапшырдылар. Ул Кызыл юл районы комсомол комитетының беренче секретаре булып эшли башлады. Аннан соң партия өлкә комитеты каршындагы партия мәктәбен тәмамлады. Яхшы укуы һәм оештыру сәләте, тырышлыгы өчен аны җаваплы эшкә күтәрделәр. Ялкынлы йөрәкле коммунист, Бөек Ватан сугышы каһарманы Нургали Сафин Чепья районында КПСС райкомының беренче секретаре итеп сайланды. Аннан соң КПССның Балтач райкомының беренче секретаре булып эшләде. 1962 нче елның мартыннан КПССның Татарстан өлкә комитеты аны Алабуга производствосы идарәсенә өлкә комитетының парторгы итеп җибәрде.

Хәзерге вакытта Сафин Нургали Сафа улы — КПССның Әгерҗе райкомының беренче секретаре. Тырыш хезмәтләре өчен ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. 1957 елдан КПСС өлкә комитеты члены, 1963, 1967, 1971 һәм 1975 нче елларда Татарстан АССР Верховный Советы депутаты булып сайланды. Ул Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXIII съезды делегаты. Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен Нургали Сафин ике мәртәбә «Батырлык өчен», «Варшаваны азат иткән өчен», «Берлинны алган өчен» һәм башка медальләр белән бүләкләнде. Бу тырыш җитәкче турында язучы Г. Әпсәләмов һәм Л. Ихсанова журнал һәм китапларда язып чыктылар.

Әгерҗе районында Нургали Сафинны яраталар, якын күрәләр. Аның турында сүз чыктымы, колхозчылар һәм коммунистлар мактап телгә алалар:

— Безнең Нургали Сафин — сугышта батырлык үрнәкләре күрсәткән солдат. Тыныч төзелеш елларында да армый-талмый эшли, халык бәхете өчен көрәшүчеләрнең алгы сафында бара, тырышып эшләгән кешенең кадерен үзе дә белә!

Әйе, чын күңелдән, бик дөрес әйтелгән хөрмәт сүзләре бу!

Кояш Тимбикова

# КАЗАН КЫЗЛАРЫ



Поезд Казанга якынлашкан саен аларның күңелен биләгән уйлар куера гына барды. Дөрес, иң үзәктә торганын башкалары күмә алмый: «Җиңдек! Олимпия батыры булдык! Казанга алтын медальләр алып кайтабыз!»

Бу җиңүне Казан күптән көтә иде. 1960 елгы Олимпия уеннарыннан соң республиканың мондый зур бүләкне күргәне юк иде. Ул чакта Казан егете Александр Курыновның авырлык күтәрү буенча яулап алган алтын медале Татарстан спорт осталарының Олимпия ярышларында да сынатмас көч икәнен раслаучы бердәнбер дәлил булып тора иде һәм бу бүләкне ишәйтергә бик кирәк иде.

Ниһаять, 1976 елда Монреальдә үткәрелгән XXI җәйге Олимпиада нәтиҗәләре теләкләргә канат бирде. Казанның «Динамо» спорт җәмгыяте рапирачылары, СССРның атказанган тренеры Владимир Васильевич Житлов тәрбияләп үстергән кызлар: СССРның атказанган спорт мастерлары Валентина Никонова, Наилә Гыйләҗева, Ольга Князева Олимпия чемпионнары булды.

1976 елның 28 июле иде. Монреаль университеты спорт залында хатын-кыз рапирачыларның турниры тәгәлләнде. Безнең кызлар алдан ярымфинал уенын үткәрделәр. «Көндәшләре» — Германия Федератив Республикасыннан килгән шактый җитди спортчылар иде. Көрәш гаҗәп киеренке барды. Хәер, монда һәр уен көтелмәгәнчә килеп чыга, һәр ил командасы өр-яңа сыйфатын ача. Барысының да җиңүче буласы килә. Көчеңне чамаламыйрак сарыф итеп куйдыңмы яки саксызрак адым ясадыңмы, костюмыңа кылыч очы кадалып китүне көт тә тор. Җиңүне дә, аянычны җиңелүне дә мизгелләр хәл итә.

Германия Федератив Республикасы кызлары СССР командасы тарафыннан 9 : 3 исәбе белән җиңелде. Алда Франция командасы белән соңгы көрәш калды. Бу уенны да кызлар, читтән карап торганда, бик җиңел үткәрделәр. Шул очрашуда җиңүнең нинди җитезлек, тапкырлык, тизлек нәтиҗәсендә яуланганын алар үзләре генә белә...

Менә хәзер, поезд купесында көлешә-көлешә Казанга кайтып килгәндә, ул мизгелләрдә баштан үткән уйлар искә төшә дә, йөрәкләр «жу-у» итә. Кызлар ул чактагы кичерешләрен тренерга да аңлатмакчылар. Өчесе өч яктан берьюлы сөйли башлый. Владимир Васильевичның мондый хәлне беренче күрүе түгел, тик елмаеп тора. Үзенең дә җанын тантана биләгән. Сүзләргә урын юк. Нибары ун ел эчендә илгә Олимпия батырлары үстереп җиткерү җиңел булмады, ай-һай, җиңел булмады! Бу кызларның хәзерге халәте тренерга аларның үзләренә караганда ачыграк аңлашыла.

Владимир Васильевичның берни эндәшми утыруы кызларга д тәэсир итте. Тынып калдылар. Һәркем үз тойгыларын тәртипкә са лырга булды, кыз бала өчен бигрәк тә сәер күренгән кылычлы кө рәштә гаҗәеп зур җиңүгә китергән биниһая катлаулы юлны һәр кем кабат күңеленнән кичерде...

## Валентина

Татарстанда рапирачыларның халыкара масштабта мактап телгә алырлык яшь буыны үсеп чыкканын беренче булып Валя Никонова уңышлары хәбәр итте. Шәһәрдә яшь спортчыларның өченче мәктәбе ачылганнан соң, 1966 елдан башлап, ул Владимир Васильевич Житлов кулы астында тәрбияләнде. Кыз, беренче караш-ка, башкалардан әллә ни белән аерылып та тормый иде. Дәресләргә минут та соңга калмый йөрүе, рапира дип аталган шул дүрт кырлы кылычка тәмам гашыйк булуы, тренер кушканны төгәл үтәү өчен тешен кысып түзүе аңарда спортчы өчен кирәкле башка сыйфатларны ныгытырга ярдәм итте. Хезмәт сөю, тиешле нәтиҗәгә ирешү өчен түзә белү — алдагы җиңүләрнең нигезе. Тренерлар бу сыйфатларны һәр спортчыда беренче көннән үк тәрбияли башлый. Рапирачыга исә түземлек бигрәк тә кирәк.

Валяның исемен дөньяга шаулаткан 1970 елгы чемпионат Минск шәһәрендә үткәрелде. Рапирачылар дөньяның егерме алты иленнән җыелган иде. Арада бик тәҗрибәлеләре, халыкара ярышларда кат-кат катнашканнары да күп. Казан кызына барысы ят, яңа иде әле. Ярыш тәртипләре дә Валя моңарчы катнашкан турнирлардагы кебек кенә түгел. Аеруча тантаналы, җитди, купшы.

— И-и, Владимир Васильевич, ник кенә килдек без монда! — Кыз тренерына сыена. — Болар бит бигрәк хәтәр кылана!

— Сабыр итик әле, Валечка! Алдан ук өметсезлеккә бирелмик!

Беренче очрашу җиңү китергәч, яшь спортчы тагын аптырый. Хәлен сорап кергән тренерга да аның сүзләре сәер тоела.

— Бик җиңел булды бит бу! — ди кыз.

Владимир Васильевич Валяда шундыйрак хис туарга тиешлекне алдан ук сизенгән иде. Чөнки әзерлек дәресләрендә, күнегүләрдә алар гаять күп көч түктеләр. Күнекмәләр, ярышта туачак киеренкелекне күздә тотып, бик катлаулы итеп сайлана иде. Тренер уенча, әнә шул кыен сынауларны шактый уңышлы чишә килгән Валя, халыкара көрәштә дә югалып калмаска тиеш иде. Тик алдан башка да кермәгән кечкенә генә бер каршылык еллар буе әзерләнгән нигезеңне какшата да куя. Менә хәзер дә Никонова беренче уңышыннан соң: «Монда бик җиңел икән лә!» дигән ялгыш нәтиҗәгә килсә, алдагы очрашуда аны җиңүләре дә бик мөмкин.

— Бүген сиңа көчсезрәк рапирачы туры килде. — Тренер, халыкара аренада беренче уңышка ирешкән Валяның кәефен дә кырмаслык, һаваланып китәргә дә урын калдырмаслык итеп аңлатырга тырыша. — Аннары монда синең алымнарыңны белмиләр бит әле. Саклану ысулларың да, һөҗүм ясау алымнарың да мондагыларга яңалык. Беренче уенны барысы да күзәтеп торды, серләрең чишелде. Алда сак булырга туры киләчәк.

Валя моңа кадәр ил күләмендә узган чемпионатларга катнашкалаган иде инде. Минскидагы халыкара турнирга ул спорт мастеры нормасын үтәп килде. Һәм бу юлы искиткеч зур җиңүгә иреште...

Мәктәпкә аяк басуына нибары дүрт кенә ел үткән кыз — дөнья чемпионы! Валентина Никонова, егерме алты ил рапирачыларының барысын да җиңеп, Казанга чемпион исемен алып кайтты.

Җиңү кешеләрне горур итә. Җиңү — алдагы җиңүләргә рухландыручы илһам чыганагы, җиңү — остазың һәм ватандашларың алдында йөз аклыгы, җиңү — яшәү мәгънәсен аңлаткан иң ышанычлы дәлил ул!

СССРның атказанган спорт мастеры булганчы, Олимпия алтын медале турында хыяллана башлаганчы, Валентина Никонова бер-бер артлы тагын берничә җиңү яулады. Иң истәлеклесе — 1973 елда Гетеборг шәһәрендә уздырылган ярышлар булды. Монда ул, һичнинди икеләнүләргә урын калдырмыйча, алга чыкты, дөньяның абсолют чемпионы итеп танылды.

Швециянең Гетеборг шәһәрендәге бу ярышларга Казанның педагогия институты студенткасы Ольга Князева да катнашкан иде. Ул көмеш медаль алды. Шул ук елны Бөтенсоюз яшьләр ярышында Наилә Гыйлаҗева исеме телгә керде. Таллинда уздырылган бу очрашуларда Наилә җиңүчеләрнең өченче басмасына күтәрелде. РСФСРның җыелма командасы составында исә ул да беренчелеккә иреште, алтын медальгә ия булды.

Валяның дуслары әнә шулай ишәйде. Уртак омтылыш кызларны бик тиз дуслаштырып өлгерде. Аларның һәрберсенең үзләренә генә хас кыйммәтле сыйфатлары бар. СССРда фехтованиенең данын арттыру өчен Наилә дә, Ольга да — алыштыргысыз осталар.



## Наилә

Уникe яшьлек кызының Пионерлар сараена фехтование түгәрәгенә йөри башлавын ишеткәч, әнисе:

— Колагым ул сүзне бүтән ишетмәсен! Ике аягыңның берсен ул якка атлыйсы булма! Сайлаганың — кыз бала уены түгел, — дип, өйдә зур тавыш күтәргән иде.

Әмма Наилә, каршы сүз әйтеп тормастан, үзе теләгәнне эшли бирде. Тренер өйрәткәнчә, иртә тору белән физик күнегүләр ясый. Дәресләрен дә бик бирелеп укый, режим белән ял итә, ныгытып ашый, үз вакытында ятып йоклый. Моңарчы итәк-чабуларын җыештырырга һич өлгерә алмый интеккән кызларының эшлекле кыяфәткә кереп, укырга да, спорт түгәрәгенә йөрергә дә, өйдә булышырга да ашкынып тора башлавы эти белән әнине сокландырмый калмады. Наилә күрер күзгә чибәрләнеп, ныгып китте. Элек ул ел саен диярлек һавалар алмашынган чакларда берәр мәртәбә салкын тидереп ала, дәресләрен калдыргалый иде. Хәзер әнә кышкы урамда спортчылар киеменнән генә чаба — бит алмаларын алсуландырып, елмаеп кайтып керә. Күзләре — ут. Кызны алмаштырып куйганнар диярсең.

Наилә елмаюлы йөзләрне ярата. Мушкетерлар түгәрәгенә сайлап алганда, аны тизлеккә, игътибарлылыкка сынадылар, кулларындагы көч микъдарын чамалап карадылар. Күнегүләр шактый катлаулы иде. Күңелгә: «Булмас инде... Төшеп калырмын...» дигән шомлы уй кереп оялаган. Шикләнү исә — спортчының иң явыз дошманы. Кыз, күзләрен мөлдерәтеп, тренерга карый. Шул минутта, мөлаем елмаеп, күңелдә ышаныч тудыра алганы өчен беренче тренеры Кислюнинга нинди генә рәхмәт әйтсәң дә, аз булыр кебек. Нәкъ менә шул хуплаулы караш, шәфкатьле елмаю Наиләнең алдагы җиңүләренә нур булып төште сыман.

Җиңү тәмен Наилә 1968 елдан татый башлады. Аны мәктәп укучыларының Бөтенсоюз Спартакиадасына җибәргәннәр иде. Җиңүчеләр баскычының иң югарысына Наилә күтәрелде. 1970 елда ул

РСФСР чемпионы булды. 1971 елда аны РСФСРның җыелма командасы составына алдылар.

Алга барышында кеше һәрчак таянычларга мохтаҗ. Наиләгә, шөкер, адым саен теләктәшләр табыла торды. Өйләрендә аның омтылышларын апасы Флера яклап чыкты. Ул үзе дә сәяхәтчеләр юлыннан кайтып керми. Себер якларын, Саян, Урал, Карпат тауларын йөреп чыкты Флера. Сеңелесенең фехтованиегә гашыйклыгы башта аны да сәерсендергән иде. Шулай да апа кеше тиз аңлады. Хәтта сеңелесенең иртәнге күнегүләренә дә кушылып китә торган иде.

Наилә остара барды. Һәм Татарстан спортчыларының гына түгел, илнең бөтен спорт сөючеләре өметенә әверелде. Бу ышаныч кызны укуына, хәтта ял сәгатьләренә дә җитди карарга мәҗбүр итте.

Монреальдәге Олимпия уеннарын күзәтеп барган журналистлар: «...финалда француженкалар белән очрашу безнең рапирачылар өчен бик җиңел узды»,— дип яздылар. Бу сүзләрне укыганда, кызларның кашлары җыерылды. Олимпиаданың финал ярышында очрашу ничек инде җиңел була ала ди?! Тәнендәге һәр күзәнәк ике хис кичерә сыман: һөҗүм һәм чигенеш, чигенеш һәм һөҗүм. Спортчының бөтен җанын шул халәт биләгән: һөҗүм — чигенеш, һөҗүм — чигенеш... Нәтиҗәсе — җиңү яки җиңелү. Бернинди урталыкның булуы, җанны ял иттерә торган тыныч мизгел тууы мөмкин түгел.

Фехтованиедә бу кичерешләр аеруча кискен, барысы да мизгелләр эчендә хәл ителә. «Ә!» дияргә дә өлгермисең, электрик җайланма синең костюмга каршы як кылычының очы кагылып киткәнен тамгалый да куя.

Наилә Монреаль Олимпиадасына әзерлек йөзеннән уздырылган СССР чемпионатын аеруча гыйбрәтле очрашулардан саный. 1976 ел язында башкалабыз Казанда уздырылды ул. Илнең иң көчле рапирачылары җыелган иде. Беренчелекне җитмеш ике спортчы өмет итә, җиңүчеләргә билгеләнгән басмалар саны исә нибары өчәү генә. Ярыш нәтиҗәләре спортчыларның Монреаль Олимпиадасына барырга лаекмы-юкмы икәнен дә күрсәтәчәк иде. Беренчелекне даулаучылар арасында Белова, Сидорова кебек дөньякүләм танылган рапирачылар да бар.

Елена Белованы Наилә 1974 елда Греноблдә узган дөнья чемпионатында очраткан иде. Аның осталыгы Наиләне сокландырган иде. Дөрес, СССРның җыелма командасы составында ул чакта Наилә дә үз мөмкинлекләрен иң күркәм яктан ачты. Бронза медаль алды. Һәм команданың алтын медаль алуында нәкъ менә Наиләнең салкын канлылыгы хәлиткеч роль уйнады.

Казан чемпионатының финалы исә бөтенләй көтелмәгәнчә килеп чыкты. Билгеле булганча, финал уеннарына алты спортчы сайлап алына. Казан кызларының иң тәҗрибәлесе — Валентина Никонова финалда катнашырлык очколар җыя алмады. Гаҗәп хәл иде бу. Ничәмә-ничә еллар буе дөнья рапирачыларының маягы булып балкыган Валяның Орджоникидзе шәһәреннән килгән, моңарчы телгә дә кермәгән спортчы Дзагоева тарафыннан җиңеләчәген кем уйлаган?!

Финал ярышларын Казан кызлары Наилә белән Ольга Князева башлап җибәрде. Тап-тар юлдагы спортчыларның икесе дә үз шәһәренеке икәнен белгәч, тамашачылар тәмам аптырады. Боларның кайсын хупларга соң? Икесе дә җиңсен иде! Әмма моның булуы мөмкин түгел, берәүсенең җиңелүе котылгысыз.

Ольганың һөҗүмнәре тәвәккәлрәк булды. Наилә уеннан төшеп калды...

Җиңелүләрдән соң җанны биләгән хисләрне аңлатып бирү мөмкин микән? Кайчак үкенечле уйлар өстенлек ала. Мендәргә капланып елыйсың, аннары елыйсы да килми башлый. Кешеләрдән читләшеп торасың. Мондый халәтне кичермәгән кеше юктыр, мөгаен. Наилә исә ярышта җиңелүнең дә үз холкын ныгытырдай, төшенкелеккә юл калдырмый торган әмәлен тапкан.

— Җиңелү — башкаларның хәлен аңларга өйрәтә. Җиңүләр спортчыны горур итсә, кәтелмәгән чигенешләр күңелгә шәфкать сала. — Наилә Гыйлаҗева әнә шулай уйлый. — Дөнья бу! — дип куясың. Һәм ул тоташ бәйрәмнән генә тормый. Җиңүгә омтылу өчен җиңелү аянычын да татып карау кирәк. Чигенешнең күздән яшь чыгара торган ачысын татымыйча, иңнәрең күтәрә алмастай данның ләззәтен ничек тоймак кирәк?..

Монреальдә булачак Олимпиада уеннары аларның төшләренә кереп йөдәтә иде. Бу олы юлга илтүче беренче сукмак — Казан чемпионаты исә Татарстан рапирачыларына әллә ни зур уңыш өстәмәде. Ольга Князева да, менә-менә алтын медаль ала дип торганда, бер-бер артлы җиңелүләргә дучар булды, бронза медальне дә ычкындыра язды. Ярышлардан соң Ольга:

— Сездән башка җиңүчеләр басмасына менүе дә рәхәт түгел, кызлар, — диде, дуслары Валя белән Наиләгә карап, — бергәләп рәхәт!

Аңлашыла: зур ярышларда аларга Валяның җыйнаклыгы, Наиләнең мәсьәләне тиз арада, ләкин салкын кан белән чишәргә сәләте, Ольгадагы тәвәккәллек — барысы бергә булганда күбрәк ярдәм итә.



## Ольга

Рапирачыларның челтәр битлеге дә, ялт-йолт итеп торучан ап-ак костюмы да, хәтта аларның кискен көрәшләрдә очраша торган тар юллары да Ольганы беренче көннән үк гашыйк итте. Кубәләкнең утка кызыгуы кебек. Баксаң, бу киемнәр бик авыр, шактый җайсыз икән. Юлының тарлыгы — мушкетерлар уенының биниһая четеркле булуына ишарә сыман.

Ольга Князева — ярышларда өзлексез эзләнүчән спортчы. Аның уены илнең иң тәҗрибәле тренерлары өчен дә еш кына һич көтелмәгәнчә башлана, уйламаган нәтиҗәләр белән тәмамланып куя. 1975 елны аны рапира уйнатуда илнең иң яхшы спортчысы дип таныдылар. Ул дөнья яшүсмерләре арасында көмеш медальгә лаек булды. Олимпиадага катнашканчы илнең җыелма командасы составында берничә тапкыр чемпион да булган иде.

1974 елның җәендә булган дөнья чемпионаты Ольганың хәтерендә аеруча тирән уелган. Шәхси исәптә Казан кызлары әллә ни зур уңышка ирешә алмадылар. Беренчелек Венгрия рапирачылары кулында иде. Командалар ярышын Ольга Князева башлап җибәрде. Аның каршына Венгриянең шәхси очрашуларда дөнья чемпионы исеменә лаек булган атаклы спортчысы Сольноки үзе чыкты. «Башланган эш — беткән эш», — диләр. Спортка бигрәк тә туры килә бу әйтем. «Эһ» итәргә өлгермисең, әле генә башланган уеннарның нәтиҗәләре турында сөйләргә тотыналар. Бөтен хикмәт әнә шул искиткеч тизлек белән очлана торган ярышның нииндирәк рухта башланып китүендә.

Сольнокиның чемпион титулыннан шүрләп, Ольга беренче адымыннан ук оттырып куйса, СССР командасына ярышны уңышлы дәвам итү кыенга калачак. Монда бит әле һичнинди үлчәүләргә сый-

мый торган күңел дигән нәрсә бар. Спортчы күңеле. Аны биләп алган хисләр. «Булмады инде» дигән күңелсез уй бастымы — җиңү хакында хыялланма да!

Хәлиткеч минутлар. Дулкынланудан Ольганың һичкем белән дә сөйләшерлек чамасы калмаган иде. Владимир Васильевич аңа соңгы күрсәтмәләрен бирә. Күңелдә әллә кайчаннан, сабыйлык елларыннан отып калынган көй чыңлый. Керәшен җырларын аңа әбисе Варвара өйрәтә иде. Гаҗәеп моң ул җырларда. Ольга аларны бер ишетү белән диярлек отып ала, аннары көннәр буе җырлап йөри. Эти-әниләре: «Әллә инде бу кызыбыздан җырчы чыга?» — дип көлешәләр. Тик, мәктәпкә кергәч, Оля китаплар һәм физкультура дөньясына ныграк тартылды. Җырлар күңелгә сеңеп, тирәнгәрәк кереп оялады.

— Ну, Оля! Әйдә, тәвәккәлләдек!

Тренерның соңгы сүзе шушы. Сольноки белән сынашу минутлары җитте. Соңгы мизгел. Сүзләргә вакыт юк. Күңелгә эленгән көйнең сүзләре генә яңгырый.

...Әйдә, әйдә! Кая, кая?

Менә Оля көрәш сукмагында. Мизгелләр, мизгелләр. Нигә монда шулай озын кебек тоелалар алар? Кызлар арасындагы көрәш һөҗүм ноктасына килеп җиткәнче еллар үткән кебек булды. Зал тып-тын. Һөҗүм! Үзәкне өзгеч «а-а!» авазы яңгырый. Бу тавышны гаҗизләнү билгесе дип тә, җиңү шатлыгы дип тә атап булмый. Аның бөтен тирәнлеген рапирачылар үзләре генә аңлыйдыр, мөгаен. Мәгънәсе шул: я синә «кадап» өлгергәннәр, я син уңышлы һөҗүм ясагансың. Электрик таблода кызыл ут кабынган.

Үзенең Сольнокины җиңәчәген Ольга алдан ук сизде. Бөтен барлыгы шуны тели, шуңа ышанган иде. Бу хиснең ни икәнен дөньяның бер галиме дә, иң сизгер электрон хисаплау җайланмасы да белә-сизә алмый. «Көндәшең» өстенә бер караш ташлыйсың да, аның үз-үзен тотышындагы бер чатаклыкны эләктереп аласың: «Әһә, син әле мондый икәнсең!» — дигән тәкәбберлек белән һөҗүмгә күчәсең. Шуннан китә, китә. Һөҗүм, тагын һөҗүм — һәм «а-а» яңгырый. «Көндәш» ялгыш адым ясавына үкенеп кычкыра, син тантана белән аваз саласың: «А-а-а!»

Кызларның ул елны Франциядән алтын медаль алып кайтуларында Ольга җиңүләренең өлеше бик зур булды.

Спортта җиңүләрнең берсенә дә озак ышыкланып яшәргә ярамый. Берәр ярышта «көндәшләр»нең көрәш алымындагы яңалыкны күздән ычкындырсаң, икенче очрашуда үкчәңә китереп басуларына гаҗәпләнмә инде.

Рапирачының күңеле шагыйрьнекенә дә, моңлы көйләр иясе композитор күңеленә дә охшаш. Иң киеренке вакытта ул тота да үзенең көен сузып җибәрә.

...Әйдә, әйдә! Кая, кая?
Әйдә барыйк урманга!..

Соңгы вакытта бу җыр аңа аеруча ошый башлады. Бу җырда Ольга үз омтылышларының да чагылышын тоя.

— Кит инде, ике керәшен егетенең кара-каршы җырлашуында спортның ни катнашы булырга мөмкин? — диләр аңа.

— Бар, күрәсең, — ди Ольга. —Әнә бит, шобага салу турында да сөйләшәләр алар. «...Авылыбызда бер матур бар, әйдә салыйк шобага!» — диләр. Безнең спорттагы кебек. Кемнең кайчан көрәшкә чыгасын жирәбәгә салабыз ич!...

Шаян кыз ул Ольга! Шулай булуы әйбәт тә. Валяның, Наилә-нең, Ольганың өчесенең өч төрле булуы Владимир Васильевич Житловка, төрле тәҗрибәләр ясый-ясый, илгә җиңү яуларга мөмкинлекләр тудыра.

## Владимир Васильевич Житлов

Ул, спорт дөньясына аяк басканда ук, Олимпия батырлары тәрбияләү хакында хыялланган дисәк, Владимир Васильевич турындагы мәгълүматларны күпертү булыр иде. Әмма кул астына Валентина Никонова, Наилә Гыйлаҗева, Ольга Князева кебек җаны-тәне белән спортка бирелгән талантлы кызлар туплангач, Татарстан рапирачыларының киләчәге бик өметле икәненә аның һичнинди шиге калмады. Югыйсә институттагы шактый җайлы эшен калдырып, яшь спортчылар мәктәбендә хезмәткә баштанаяк бирелер идемени соң ул?!

Хәер, монда әллә нинди күрәзәчелеккә урын юк. Олимпияга таба беренче адымнарның балалар спорт мәктәбеннән башлануын тренер яшерми. Монреальдән алтын медаль алып кайткан көнне Казан вокзалына аларны каршыларга килүчеләр алдында Владимир Васильевич:

— Олимпия сәфәренә без моннан ун ел элек чыккан идек. Мәктәбебезнең унъеллык юбилеена шундый уңыш өлгертүебез белән чиксез бәхетлебез, — диде.

Мәктәп ачылган 1966 елдан башлап тренер күп ярышларда булды. Нинди генә илләрдә, кайдагы гына спорт сарайларында чыгыш ясамадылар алар?!

Кызларның мәктәпкә беренче мәртәбә килеп керүләрен күз алдына китерсә, Владимир Васильевичны сөенеч били. «Ярый әле, игътибарлы булынган! Ярый, бу кызларның күңелен төшерерлек саксыз сүз ычкындырылмаган! Гайрәтләрен чигерелмәгән!» Әле һичнинди сәләтләре дә ачылырга өлгермәгән 5—6 нчы класс укучыларының кылыч уйнатуда илгә уңыш китерәчәкләрен танып алу гаҗәп кыен. Бу өч кызның мөмкинлеген билгеләү генә түгел, алардан дөнья чемпионнары, Олимпия батырлары үстереп җиткерү Владимир Васильевич Житловның педагог буларак та, спорт белгече буларак та сокландыргыч талантын раслый.

Бүгенге көнгә кадәр башкарганнары инде аңа бераз сабырланып, тынычланып калырга да хокук бирә сыман. Тик тренер бер генә көнгә дә тукталып тормый. Кызларның һәр чыгышы аңа мең чишелмәгән сорау алып килә. XXI Олимпиада алдыннан Казанда үткәрелгән СССР чемпионатында Никонова ник каушап төште? Алтын медаль котеп торганда, Ольга ник кинәт артка тәгәрәде? Әле быел җәй башында Парижда «Жанти» кубогына үткәрелгән халыкара турнир финалында Наилә ничек итеп, Елена Белованы да уздырып, икенче урынга чыкты?

Казан кызларының чит илләрдә чыгышлар вакытында котелмәгәнчә җитдиләнеп калуларын тренер күптән сизеп йөри. Шунлыктан ул Казан чемпионатындагы җиңелүне ул кадәр үк авыр кичермәде дә. Монреальдә ачылып җитәчәкләренә өметләнде.

Олимпиада исә чит илләрдә моңарчы күреп өйрәнгән ярышлардан күп аерыла икән. Мондагы шартлар тәҗрибәле тренерның үзен дә гаҗәпкә калдырды. Олимпия яңалыкларын дөньяның төрле ягына хәбәр итеп тору өчен Монреальгә 2800 журналист килгән иде. Үзәк стадионга куелган ике зур таблоның бер-берсенең мәйданы ике йөз квадрат метрга якын. Аларга язылган белешмәләрне өч йөз метр ераклыктан рәхәтләнеп укып була.

СССР рапирачыларының команда ярышларында яулап алган уңышлары да шул таблога язып куелды. Кызлар күптән көтелгән бу уңышның чынлыгына ышанып җитә алмый гаҗизләнделәр. Барысын да үзләре башкарып чыкты бит инде югыйсә! СССР командасы өчен иң кирәкле хәлиткеч адымны Ольга ясады. Көндәше француз кызы иде. Тәвәккәл шәкертен соңгы сынауга озатып калганда тренер:

— Ну, ничек, Оля? — дип сорады.

— Гомер булмаганча, җиңәсем килә!

— Болай булгач, җиңәбез, нык бул!

Исәп — Оля файдасына, ягъни СССР җыелма командасы файдасына ачылып китте: 4:0. Тагын һөҗүм. Тагын тәвәккәлләү. Исәп 5:1 булды.

Бу инде җиңү дигән сүз иде. Әмма кызлар күңеле мондый зур җиңүгә әле һаман ышанып җитми. Котлаулар, рәхмәт сүзләре ява. Ниһаять, җиңүчеләрне пьедесталга чакыралар, мактау басмасының иң биегенә! Советлар Союзы Гимны яңгырый...

Фехтование спортның иң авыр төрләреннән санала. Ул спортчының физик авырлыкка чыдам булуын да, шахматтагы кебек үк зиһенлелеген, хәйләкәрлеген һәм психологик ныклыгын да таләп итә. Владимир Васильевич Житлов Валя, Оля, Наиләдә бу сыйфатларны арттыра, үстерә, ныгыта бара.

Монреальдәге көч сынашулардан соң күп ярышларда булдылар алар. Кызларга бер генә тәүлек тә кул кушырып утырырга туры килгәне юк. Беләләр: алда көрәшнең тагын да кискенрәкләре көтә.

СССРның атказанган спорт мастеры исемен яулаган рапирачыларыбыз хәзер бөтен көчләрен 1980 елда Мәскәүдә уздырылачак Олимпиада уеннарында җиңүгә юнәлтәләр. Тренерның яңа уңышларга өмете зур. Татарстанда үсеп килүче яңа буын рапирачыларның уңышлары да бу өметне нигезле итә. Хәзер бездә дөнья чемпионы титулына ия егетләр дә бар инде. Ә яшь спортчылар мәктәбендә дүрт йөздән артык рапирачы тәрбияләнә. Аларның һәрберсе: «Мин дә дөнья чемпионы була алам!» — дигән омтылыш белән яши. Алдагы зур ярышларның финалында спорт сарайларын, стадионнарны рухландырып Советлар Союзы Гимны яңгыраганда, җиңүчеләр басмасында Казан кызлары, Татарстан егетләре басып торачак икән, моңа һич кенә дә гаҗәпләнүче булмаячак. Совет фехтованиесен алга чыгарган кызларыбызның фидакарьлеге бу пьедесталга моннан ун-унике ел элек юл ярды.

Шамил Монасыйпов

# ТАТАР СКРИПКА СӘНГАТЕ

Татарлар арасында скрипка XVII йөздә таралыш ала. Милли скрипка сәнгате борынгы чорлардан ук яшәп килгән кыллы уен кораллары сәнгате казанышлары җирлегендә формалаша. Шуңа күрә дә скрипкада уйнаучыларның башкару осталыгы башлангыч этапта ук инде шактый югары булуы белән аерылып тора. Скрипка көнкүрешкә үтеп керә башлаган вакытта ук инде бу уен коралын үзләренең төп һөнәрләренә әверелдергән музыкантлар күренә. Һәвәскәрләрдән аермалы буларак, профессиональ башкаручылар бәйрәм көннәрендә һәм табын-мәҗлесләрдә генә түгел, ә шәһәр ярминкәләрендә, авыл базарларында, юлчылар туктый торган кунакханәләрдә, югары катлау кешеләренең йортларында да чыгыш ясыйлар. Бу җәһәттән олы ярминкәләр аеруча күренекле урын тота. Татар музыкантлары өчен дә ярминкә үзенә күрә культура тарату үзәге булып хезмәт итә. Шунда ук җырчылар, тел осталары да осталыкларын күрсәтә, музыкантларның кара-каршы ярышлары халыкта зур кызыксыну уята. Идел буенда бу традиция атаклы Болгар базары чорыннан ук килә, мәшһүр Казан һәм Мәкәрҗә ярминкәләрендә дәвам итә.

Кайбер атаклы скрипкачыларның исемнәре, телдән-телгә күчеп, безнең көннәргә кадәр халык хәтерендә сакланып калган. Аларның берсе — Мәкәрҗә кушаматлы Гайса, икенчесе — Ончы Фәхри. Шундый музыкантларныкы дип уйланылган һәм аларның исемнәрен йөрткән көйләр әле дә яши. Казагыстанның Петропавловск шәһәрендә яшәүче Шәфиева моннан берничә ел элек авторга язган хатында бала чагында Ончы Фәхринең скрипкада уйнавын үзе күрүе хакында хәбәр итә.

Татар музыкантлары рус авылларында уздырылган ярминкәләрдә дә еш кунак булганнар, төрле күңел ачуларда катнашканнар. Рус художнигы И. М. Прянишниковның «Авылда бәйрәм» исемле картинасында, мәсәлән, скрипка һәм барабан тоткан ике татар музыканты сурәтләнгән. Сәнгать белгечләре фикеренчә, әсәрнең сюжеты Идел буенда яшәүче халык тормышыннан алынган.

Скрипкачыларның халык тормыш-көнкүрешендә киң урын алуы, башкару сәнгатенең шактый югары булуы милли скрипка сәнгатенең үсеше өчен ныклы нигез тудыра. Әмма татар халкының матди тормыш шартлары моңа комачаулык итә. Тикшеренүчеләр язганча, XVIII йөздә христиан динен кабул итмәүчеләрне экономик яктан кысу политикасы аеруча көчәя. Патша указлары нигезендә, Казан ягының мөселман хезмәт ияләренә авыр түләүләр салына. Күп кенә өстен катлау кешеләренең дә биләмәләре һәм хокуклары тартып алына. Биләмәләр һәм алпавыт сарайлары белән бергә дөньяви культура учакларының да байтагы юкка чыга[1]. Мондый шартларда

[1] А. Можаровский. Изложение хода миссионерского дела по просвещению Казанских инородцев с 1552 по 1867 г. Мәскәү, 1880 ел, 32—36, 91 битләр.

музыкантларның җәмгыять тормышындагы урыны нык кечерәя. Аеруча зур привилегияләр белән файдаланучы аерым татар феодаллары гына үз йортларында музыкантлар тоталар. Музыкантларның иң зур күпчелеге башка төрле яшәү чыганаклары эзләргә, еш кына авыр физик хезмәт белән шөгыльләнергә мәҗбүр була. Шулай итеп, скрипкачылык ул чорда башлыча ярым профессиональлек дәрәҗәсеннән узмый.

Халык массаларының дини, милли изелүгә каршы актив көрәше нәтиҗәсендә көчләп чукындыру политикасы уңышсызлыкка дучар була. XVIII гасыр ахырына табан татар музыкасындагы профессиональ башкаручылыкка да ихтыяҗ арта төшә, музыкантларның шактый өлеше скрипка уйнауны яңадан үзенең төп кәсебе итә. Шәһәрләрдә генә түгел, зур авыл базарларында да профессиональ скрипкачыларны еш очратырга мөмкин була. Алар шулай ук төрле күңел ачу йортларында да татар көйләрен уйнап, халык арасында популярлык казана[1]. Ләкин нәкъ шул чорда аның алдында яңа киртә пәйда була — татар музыкасына каршы мөселман руханилары һәм татарның югары катлау кешеләре күтәрелә башлый. Чөнки хөкүмәтнең исламга карата тоткан политикасы үзгәрә, патша указы белән мөселман дине рәсми рәвештә яшәүгә хокуклы дип таныла, мөселман руханилары өчен җирлек ныгый. Ислам дине әһелләре дөньяви аң-белемнәр, алдынгы культура, мәгърифәтчелек үсешенең мөселман дине нигезләренә нинди куркыныч белән янавын яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә алар барлык көчләрен Европа һәм алдынгы рус культурасы йогынтысына каршы көрәшкә туплыйлар. Мәгърифәтчелек идеяләре, һәртөрле хөр фикер, сәнгать җимешләре зарарлы, дин өчен хәтәр нәрсә итеп карала. Руханиларның һәртөрле яңалыктан шулай качарга тырышуын Галимҗан Ибраһимов та күрсәтеп үтә[2].

Халыкның рухи камиллеккә омтылуы белән тыгыз бәйле булган музыка аша татар тормышына рус һәм башка Европа илләренең музыкаль культурасы элементлары, төрле уен кораллары үтеп кергән. Дөньяви бәйрәмнәр, күңел ачулар, сабан туйларында яңалыкка омтылыш аеруча нык чагыла. Мәсәлән, үткән йөздә яшәгән вәгазь-нәсихәтчеләрнең берсе халык бәйрәмнәренең шәригатькә зур зарар китерүе хакында яза. Намаз һәм дога укуга караганда кәеф-сафа коруны артык күреп, мөселманнар шәригатьне оныталар, Европа кешеләренә әверелләләр, дин каршындагы бурычларын үтәмиләр, мәчеткә иганә бирмиләр, ди ул[3].

Музыканы эзәрлекләү XIX гасыр ахыры, XX йөз башында, ягъни музыкаль башкаручылык нык таралып килгән чорда, үзенең иң киеренке ноктасына җиткән. Халыкның борынгыдан килгән җыен бәйрәменә каршы көрәш мисалында бу бигрәк тә ачык күренә. Җыр һәм музыка зур урын алган, җыр-биюле күмәк уеннардан тыш музыкантлар ярышлары да оештырылган җыен бәйрәмнәренә[4] каршы ислам дине фанатиклары XIX гасырда кискен көрәш башлыйлар. 1861 елда, мәсәлән, мөселманнарның Дини идарәсе җыеннарны тыю хакында рәсми карар кабул итә. Шундый ук карар икенче тапкыр 1885 елда чыгарыла[5]. Әмма алар музыка сәнгатен көнкүрештән тулысынча кысрыклап чыгару максатына ирешә алмыйлар. Дөрес, милли музыкаль культура үсеше нык тоткарлана, халык бәйрәмнәре һәм йолаларының музыкаль ягы зәгыйфьләндерелә. Профессиональ башкаручылык практикасы төрле ярминкә һәм күңел ачу йортлары белән чикләнергә мәҗбүр була, музыкантларның тормыш хәле сизелерлек җиңеләйми. Шунлыктан XIX йөз урталарында да профессиональ һәм һәвәскәр башкаручылар бер-берләреннән әллә ни аерылмыйлар. Хәер, һәвәскәр башкаручыларның осталыгы бу чорда да шактый югары дәрәҗәдә була. Халык музыкантлары вибрато һәм портаменто кебек скрипка уенына хас алымнарны кыю кулланалар, алар көйне күп санлы фиоритура, пентатоник борылышлар, мелизмнар белән мул бизиләр. Ә бит бу алымнарны нык үскән һәм шомарган техник аппаратка таянганда гына иркен кулланырга мөмкин.

---

[1] Х. Габәши. Музыка вә шигырь фаидәләре, алар хакында ислам галимнәренең һәм Мәрҗанинның фикере. Кара: «Мәрҗани». Казан, 1915 ел, 562—566 битләр.
[2] Г. Ибраһимов. Татарлар арасында революция хәрәкәтләре. Казан, 1925 ел, 22 бит.
[3] Җыен кыйссасы. Казан, 1881 ел.
[4] Кара: В. А. Мошков. Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края. Известия ОАИЭ, XII том, I чыгарылыш, Казан, 1894 ел, 54 бит.
[5] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. Мәскәү, 1967 ел, 412 бит.

Димәк, сүз татар скрипкачыларының фольклорчы галимнәрне гаҗәпкә калдырырлык дәрәҗәдәге виртуоз осталыгы турында бара.

Халык музыкантларының репертуары гадәттә бай һәм күп төрлелеге белән аерылып торган. Милли көйләр белән генә чикләнмичә, алар Азия һәм Европа халыкларының күп кенә көй үрнәкләрен дә башкаралар (Европа музыкасыннан полька, мазурка, краковяк кебек бию көйләре, русча марш һәм вальслар, халык көйләре һәм такмаклар). Скрипкачылар башкарган татар көйләре теге яки бу җырның инструменталь варианты була, аларга диапазон киңлеге, бизәк муллыгы хас. Моңа татар фольклорын өйрәнгән Н. Никольский, А. Эйхенвальд, И. Козлов кебек күп кенә тикшеренүчеләр игътибар иткән. И. Козлов, мәсәлән, көйне скрипкада башкарылганга караганда, җырчы авызыннан отып алу күп җиңелрәк дип яза[1]. Скрипкачылар репертуарында ул чорда ук инде халык инструменталь жанрлары дип аталырлык әсәрләр була. Шулар исәбенә импровизация характерындагы салмак озын көйләрне һәм бию көйләрен кертергә мөмкин. Музыкантлар, озын һәм кыска көйләрне берләштереп, ике кисәктән торган үзенчәлекле цикл эшлиләр: прелюдия яки инструменталь ария роле озын көйгә бирелә, ә җитез һәм җыйнак бию көе йомгак өлеше булып килә.

Скрипка сәнгатебез яшәешендә яңа этап Урта Иделдә капитализмның интенсив үсеше, татар иҗтимагый-мәдәни тормышындагы үзгәрешләр белән бәйләнгән. Бу этапта милли фольклорга, әдәбиятка тартылу көчәя, мәгърифәтчелек хәрәкәте тотрыклы агымга әверелә, рус культурасы белән кызыксыну арта бара. Халык музыка коралларыннан скрипка, гармун, курай һ. б. киң таралыш ала (күп кенә күренекле мәгърифәтче галимнәр, шул исәптән, И. Хәлфин, М. Мәхмудов, К. Насыйри үзләре дә скрипка уйныйлар). Татар «ир һәм хатын-кызлары» рус театрларына, бал-маскарадларга һәм башка төрле кичәләргә йөри башлыйлар[2].

Шушы ук чорда татар интеллигенциясенең аерым вәкилләре, дәүләт югары уку йортларында белем алып, Россия культура тормышы мәйданына күтәреләләр. Шундыйлар арасында, мәсәлән, Исмәгыйл Аитов кебек скрипкачылар да була[3]. Ул үткән гасырның сиксәненче-туксанынчы елларында Казанда опера оркестрының концертмейстеры булып эшли. «Музыка сөючеләр түгәрәге» каршындагы музыка мәктәбендә укыта. Аның Париж, Лондон, Берлин шәһәрләрендә гастрольдә булып, зур уңыш казануы билгеле. Татар дворяннары гаиләләреннән һәм православие диненә күчкән керәшеннәр арасыннан тагын Саратов консерваториясе профессоры М. И. Солтановны (1875—1918), күренекле скрипкачы, дирижер һәм композитор А. Л. Панаевны (1862—1919) күрсәтергә мөмкин[4].

Казан шәһәре ул чорда да Россиянең культура үзәкләреннән берсе була. 1864 елда биредә Рус музыка җәмгыяте бүлеге ачыла, җитмешенче еллардан башлап даими рәвештә опера труппасы эшли, беренче хосусый музыка мәктәпләре күренә башлый, шуларның берсе 1904 елны рус музыка җәмгыяте каршындагы музыка училищесы итеп оештырыла.

Боларның барысы халыкның культура тормышына да тәэсир итми калмый. Музыка шәһәрнең аерым йортларына үтеп керә, яшьләр аның белән гаилә эчендә махсус шөгыльләнә башлыйлар, белгечләрдән музыка дәресләре алу популярлаша, көнкүрештә фортепиано, мандолина, гитара һәм башка инструментлар киң тарала. Шул елларда ук сәүдәгә «музыкаль тартмалар», милли көйләр язылган пластинкалар чыга (аларны җирле һөнәр иясе Г. Сәйфуллин эшләп чыгара). Публика өчен башкару да торган саен киңрәк колач ала. Күңел ачу урыннарыннан тыш, укымышлы кешеләрнең йортларында музыка кичәләре үткәрелә башлый, кече форма сәхнә әсәрләре уйнала[5]. Ниһаять, XIX гасыр ахырында рәсми власть вәкилләре һәм мөселман

---

[1] И. А. Козлов. О народной музыке северных мусульман. 1921 елның 5 апрелендә сөйләнгән доклад.

[2] Материалы для географии и статистики России. Каз. губ. сост. М. Лаптев, СПб, 1861 ел, 229 бит.

[3] Кара: «Волжский вестник», 1884 ел, 8, 21, 22, 23, 121 саннар. «Социалистик Татарстан», 1977 ел, 10 апрель саны. Проф. Р. И. Нәфиков белән интервью.

[4] Биографический словарь музыкантов-исполнителей на духовых инструментах. Ленинград, 1968 ел, 102 бит. «Некрасовский сборник», V, Ленинград, 1973 ел, 310—312 битләр.

[5] Кара: «Волжский вестник», «Казанский телеграф», 1898 ел, 154 һәм 1913 саннар.

руханиларының аяусыз эзәрлекләүләренә дә карамастан, алдынгы татар яшьләре рәсми тестә ачык концертлар оештыруга керешәләр. Шундый концертлар 1894 елда Мәскәүдә, 1899 елда Петербургта, 1900 елда Казанда һәм башка кайбер шәһәрләрдә үткәрелә [1].

Беренче рус революциясе татар сәнгате, шул исәптән музыка сәнгате үсешенә дә көчле этәргеч ясый. Царизм азчылык милләтләргә туган телләрендә матбугат булдыру, культура-агарту чаралары үткәрү, концертлар, драма спектакльләре кую, төрле кичәләр оештыруны инде ачыктан-ачык тыя алмый. Үзәкләрдә генә түгел, татарлар яшәгән бик күп шәһәрләрдә культура, әдәбият, сәнгать учаклары, төрле җәмгыятьләр барлыкка килә. Әдәби-музыкаль кичәләр, түләүле концертлар даими төс ала, музыкаль тормыш та беркадәр стабильләшә. Концертлар гына түгел, драма спектакльләре дә, күңелле ял кичәләре дә музыкасыз узмый: татар көйләре спектакль алдыннан тәнәфес вакытларында, спектакль беткәннән соң дивертисментларда яңгырый. Көйләрне уен коралында ялгыз башкару белән бергә, инструменталь ансамбльләр чыгышлары да даими оештырыла башлый — сәхнәләрдә скрипкачылар дуэты, инструменталь трио һәм милли оркестрлар аеруча зур популярлык казана. Оркестр составында берничә скрипка, мандолина, думбра, курай (яисә флейта), гармуннар, фортепиано була. Ансамбльдә катнашучылар саны еш кына егерме-утыз кешегә җитә. Репертуарларында, милли көйләрдән башка, Азия һәм Европа музыкасы әсәрләре дә була. Оркестрлар һәм культура-агарту җәмгыяте, ярым профессиональ һәм һәвәскәр драматик труппалар каршында да яшәп килә. Казанда берничә музыкаль ансамбль була (Шәрык клубында, «Сәйяр» труппасы каршында кыллы оркестрлар, «Свет» кинотеатрында төрле уен коралларыннан музыкаль ансамбль һ. б.). «Дин вә мәгыйшәт» журналында язылганча, хәтта мәдрәсәләрдә дә шәкертләрнең ятаклары өстендә стенага эленгән скрипка, гитара кебек музыка коралларын күрергә мөмкин була [2]. Тагын шунысы характерлы: моңа чаклы фәкать ир кешеләр өчен генә дип саналган уен коралы скрипкада хатын-кызлар да уйный башлый. Мәсәлән, «Тормыш» газетасы 1917 елның 29 январь санында Уфада хатын-кызлар өчен концерт оештырылуы, концертта кызлар оркестры чыгыш ясавы хакында хәбәр итә.

Милли оркестрлар татар инструменталь башкаручылыгын яңа сыйфат баскычына күтәрә, музыка репертуарының киңәя баруына, башкару осталыгының үсүенә ярдәм итә. Кагыйдә буларак, тәҗрибәле һәм танылган музыкантлар җитәкләгән бу милли оркестрлар тора-бара татар музыка һәм башкаручылык сәнгате үзәкләренә әверелә. Яшьләр анда музыкаль грамота нигезләрен, теге яки бу уен коралында милли көйләрне башкару алымнарын, халыкның башкаручылык традицияләрен өйрәнәләр. Шулай итеп, халык уен кораллары оркестрлары бер үк вакытта милли музыка мәктәпләре ролен дә үти. Һәм, чыннан да, шушы оркестрларда уйнаучылар арасыннан соңрак С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, М. Яушев, З. Яруллин, Ф. Биккинин, М. Йосыпов кебек татар композиторлары һәм атаклы музыкантлары үсеп чыга.

Музыкаль әсәрләрне ялгыз башкаруга да зур игътибар ителә. Шул елларның вакытлы матбугат битләреннән күренгәнчә, концертларның берсе дә скрипкачы-солистлар катнашыннан башка узмый. Шундыйлар арасында Казанның скрипка осталары Мөхәммәтша Мостафин (1850—1909), Гали Мостафа улы Зайпин (1876—1918), Хәбибулла Әхмәдуллин (1875—1943), Уфа музыканты Г. Ишбулдин, Оренбургтан чыккан Зыя аеруча зур популярлык казана.

Рәсми тестә ачык концертлар үткәрелә башлау белән алар бу кичәләрне оештыруда да актив катнашалар, аларда, керем чыганагы булудан бигрәк, халык мәгърифәтенә хезмәт итүнең яңа формасын күрәләр. Икенче яктан, тамашачылар алдында даими чыгышлар ясау халык музыкантының артист-музыкант булып формалашуына ярдәм итә.

Музыканы төп һөнәре итеп сайлаган кешеләр белән бергәттән, концертларда төрле катлаулардан чыккан күп санлы һәвәскәрләр дә катнаша. Шундыйлар исәбеннән татар кызлары гимназиясе укытучысы Газиз Булатов (1885—1921), актерлар Ну-

---

[1] З. Хәйруллина, Я. Гиршман. Музыка тарихыбызның үткәне. «Татар музыкасы мәсьәләләре» исемле җыентык. Рус телендә. Казан, 1967 ел.

[2] 1914 ел, 12 декабрь саны.

ри Сакаев, Касыйм Шамил, Ташкент шәһәрендәге «Чишмә» җәмгыяте җитәкчесе Мостафа Мансуров, аталы-уллы Мөшәрәп һәм Мәсәллим Вәлиевләрне күрсәтергә мөмкин. Соңга табарак аларның күбесе музыканы үзенең төп һөнәре итә. Газиз Булатов, мәсәлән, Петропавловск шәһәре симфоник оркестрының беренче скрипкачылары группасында уйный. Актер Кудашев-Ашказарский концертларда скрипкачы буларак та чыгыш ясый һәм берничә тапкыр граммофон пластинкаларына языла[1].

Башкаручылар арасында бу елларда да, сирәк булса да, академик музыка белеме алган кешеләр очраштыргалый. Әлбәттә, патша Россиясендә «чит милләт» исәпләнгән халык вәкилләренең бик азы, бары тик бай катлау кешеләренең балалары гына махсус югары белем алуга ирешә. Шундыйлар арасыннан Казанда беренче «милли оркестр» оештыручыларның берсе Вәли Апанаевны[2] (1889—1922) һәм Берлин консерваториясендә укыган Барый Кәримовны күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Татар скрипка осталары, җырчылар, милли оркестрлар төрле шәһәрләргә, шул исәптән Мәскәү һәм Петербургка да, гастрольләргә йөриләр. Шушы елларда күпләп чыгарыла башлаган граммофон пластинкаларына да язылалар. Мәсәлән, скрипкачы Хәбибулла Әхмәдуллиннан Нижний Новгород студиясендә туксәнлап халык көе язып алына[3].

Болар, әлбәттә, музыкантларга таләпне арттыра, милли скрипка сәнгате үсешендә сыйфат үзгәрешенә китерә, репертуарны Көнбатыш Европа, рус музыкасы эшләнмәләренең оригиналь әсәрләре белән баетуга этәрә.

Шул ук вакытта скрипка өчен махсус иҗат ителгән беренче милли пьесалар күренә башлый. Аларны, тамашачыларның рухи ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү теләгеннән чыгып, яңа заман сулышын, халыкның яңа теләк-омтылышларын чагылдырырга тырышып, музыкантлар үзләре иҗат итәләр. Әсәрләрнең үз заманы өчен иң популяр жанрлар калыбында эшләнүе нәкъ менә шуның белән аңлатыла да. Мондый жанрлар арасында иң егәрлесе марш була. Башкаручы музыкантларның игътибарын маршның көчле ритмик хәрәкәте, өндәүле-чакырулы актив интонацияләре, чорга аһәңдәш булган башка хасиятләре җәлеп итә. Шул елларда иҗат ителгән маршлардан Г. Зайпинның «Сада», Х. Әхмәдуллинның «Аккош» һәм «Казан» әсәрләрен күрсәтергә мөмкин[4].

Маршлар белән берраттән, скрипка өчен бию жанрында да пьесалар туа башлый (Мәсәлән, Г. Ишбулдинның 1910—1914 елларда иҗат иткән «Мазурка»сы). Бу әсәрләрнең барысы да стиль һәм форма ягыннан халыкның музыкаль иҗаты белән тыгыз бәйләнгән була, төп тема итеп халык көйләре яки халык моңнарына якын торган мотивлар алына. Әмма күләм-үлчәм ягыннан алар халык көйләреннән бермәбер озын.

Скрипка өчен язылган әсәрләр кайбер башка сыйфатлары белән дә җыр жанрыннан аерылып тора. Әйтик, халыкның традицион көйләрен башкарганда музыкант көйне берничә тапкыр кабатлый, кабатлаган саен яңа вариацияләр тудыра. Бу алым музыкантларга бертөрлелектән качып, көйнең колачын киңәйтергә, шулай ук уен коралының мөмкинлекләрен тулырак күрсәтергә ярдәм итә. Үз әсәрләрен башкарганда да скрипка осталары шушы традицияне дәвам иттерәләр. Аерма тик шунда— әсәрнең соңгы кабатланышында аның аерым тема тәшкил итүче икенче өлеше төшеп кала, музыкаль пьесаны тематизм ягыннан гадәттә көчлерәк, тәэсирлерәк булган беренче өлеш тәмамлап куя. Әсәр, шулай итеп, вариациялелек фонында өч кисәккә бүленә.

Шул рәвешчә, татар мәдәни тормышында 1905 ел революциясеннән соң башланган үзгәрешләр нәтиҗәсендә музыкантларның публика алдында концерт белән чыгыш ясаулары даими төс ала. Бу исә татар скрипкачылары алдына яңа таләпләр куя һәм аларга музыка сәнгатендә ирешкән казанышларны үстерү, милли башкаручылыкның эчке мөмкинлекләрен тулырак файдалану буенча яңа һәм җитди бурычлар йөкли

---

[1] Граммофон пластинкалары каталогы. Казан, 1910 ел, №№ 100456, 108104, 108105 һ. б. Пластинкалар каталогы. Казан, 1912 ел, «Зонофон» фирмасы язмалары.

[2] Вәли Апанаев Казан музыка училищесының скрипка классын тәмамлаган. 1905 елда студентлар манифестацияләрендә катнаша, концертлар оештыруга күп көч куя, үзе дә еш чыгыш ясый. 1910 еллар башында каты авырып китүе аны бу эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр итә.

[3] Бу мәгълүматлар Х. Әхмәдуллинның кулъязма истәлегеннән алынды. (Истәлек музыкантның кызы Р. Әхмәдуллинада саклана.)

[4] «Казан» маршының авторы тәгаен мәгълүм түгел, Х. Әхмәдуллинныкы дип уйланыла гына.

әйтергә кирәк, бу һич тә ансат бирелми. Стиле, үзенә хас техник чаралары белән милли татар музыкасыннан шактый нык аерылып торган Европа музыкасы әсәрләрен башкару бигрәк тә кыен проблема булып тора. Мәсәлән, И. Козлов зур оста Г. Зайпинның татар көйләрен гаять матур башкарып та, Европа композиторлары әсәрләрен уйнаганда үзен иркен хис итә алмавы хакында яза [1].

Бу проблеманы хәл итүдә татар музыкантларына Казанда һәм башка кайбер шәһәрләрдә яшәгән рус һәм чит ил музыкантлары зур ярдәм күрсәтә. Болар арасында Казан музыка училищесы укытучылары А. Амиго, Прага консерваториясен тәмамлаган Карл һәм Иосиф Русс, Казанда яшәүче скрипкачылар И. Козлов һәм Васильевларны атап әйтергә мөмкин. Татар концертларында солист, аккомпаниатор сыйфатында яисә скрипкачылар дуэты һәм төрле ансамбльләр составында даими рәвештә чыгышлар ясап килгән И. Козлов башкаручыларның профессиональ әзерлекләрен күтәрүгә турыдан-туры булышлык итә. Татар музыка сәнгатен баетуда Оренбург татарларының музыка җәмгыяте чакыруы буенча килгән рус музыкантлары билгеле бер роль уйный. Алар ярдәме белән монда яшь татар музыкантлары өчен ун айлык курслар ачыла.

Шунысын да әйтеп үтик, рус музыкантлары татар башкаручыларын скрипка өчен язылган классик репертуар, рус һәм Көнбатыш Европа скрипка мәктәпләре казанышлары белән таныштырып кына калмыйча, татар скрипкачыларының беренче оригиналь әсәрләрен гармонияләштерүгә дә булышалар. Ә бусы композиторлык юлына баскан яшь музыкантлар өчен аеруча читен мәсьәләләрнең берсе була. Х. Әхмәдуллин истәлекләрендә язылганча, аккомпанимент белән уйнау гадәте профессиональ татар скрипкачылар практикасына XIX йөз ахырында гына керә. Чәйханә һәм кунакханәләрдә бу максат өчен гармун кулланылса, респектабельле кәефханәләрдә дәрәҗәлерәк уен коралы фортепианодан файдаланалар. Татар музыкантлары мажор-минорлы гармоник системаны үзләштерүдә әле беренче адымнарын гына ясаган чакта, шул системада тәрбияләнгән һәм аны пентатоника белән берләштерү буенча гасыр башында инде берникадәр тәҗрибә туплап өлгергән рус музыкантларының ярдәмнәренә ни дәрәҗәдә зур ихтыяҗ булганлыгы аңлашылса кирәк [2].

Әлбәттә, татар скрипка сәнгате алдында торган барлык проблемаларны аерым музыкантлар ярдәме белән генә ахырынача хәл итү мөмкин булмый. Моның өчен барыннан да элек милли музыка сәнгатен тирәнтен өйрәнү эшен җәелдерергә һәм милли музыка кадрларын тәрбияләп үстерү, академик белем бирү бурычын хәл итәргә кирәк иде. «Инородец»ларның культура үсешенә һәртөрле киртәләр куеп килгән патша самодержавиесе исә моңа ирек бирмәде. Бары тик Бөек Октябрь революциясеннән соң гына милли культураларның чәчәк атуы өчен тиешле шартлар тудырылды.

---

[1] Ход развития театра и музыки у казанских татар. Казан, 1925 ел.

[2] Рус композиторларының кыллы уен кораллары өчен татар көйләре темаларына язган беренче әсәрләреннән берсе — Карл Шубертның кыллы квартеты (1862 ел). Бу хакта «Санкт-Петербургские ведомости»ның 69 санында Кюи рецензиясендә әйтелә. И. Козлов та 1896 елда скрипка һәм фортепиано өчен «Татар көе» әсәрен яза.

# БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

*ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!*

*Бүгенге поэзиябезнең актуаль мәсьәләләре, үсеш тенденцияләре һәм, гомумән, шигъриятнең халкыбыз тормышында тоткан роле турында фикер алышуны күздә тотып башлап җибәрелгән сөйләшү журналыбыз сәхифәләрендә 1979 нчы елда да дәвам итә.*

*Бу рубрика узган елның март аенда шагыйрь Р. ФӘЙЗУЛЛИН һәм әдәбият галиме И. НУРУЛЛИН арасындагы әңгәмә белән ачылган иде. Сөйләшү ел дәвамында барып, анда Х. ГОСМАН «Яшьләр һәм остазлар» (5 сан), Т. ГАЛИУЛЛИН «Җитмешенче еллар авазы» (7 сан), М. ГЛУХОВ «Сабыр төбе—саф алтын» (9 сан), Р. МӨХӘММӘДИЕВ «Әгәр син янмасаң...» (10 сан), Ш. ӘХМӘДУЛЛИН «Әдәби тәнкыйть һәм эстетик тәрбия» (10 сан), Р. ХАРИС һәм М. ВӘЛИЕВ «Шигърият шәхестән башлана» (12 сан), Ф. САФИН «Шигырьләр яңәшәлеге» (12 сан) дип исемләнгән мәкаләләр белән чыгыш ясадылар. «Казан утлары»ның 9 нчы санында бер төркем укучылар хатларыннан өзекләр дә бирелгән иде. Укучы фикеренә алга таба да игътибар зур булачак.*

*Мәкалә һәм хатлардан күренгәнчә, бүгенге поэзия турында сөйләшү башлап ялгышмаганбыз. Чынлап та, уртага салып фикер алышыр һәм уйланырлык мәсьәләләр байтак икән. Ләкин, табигый булса кирәк, ул мәсьәләләрнең һәркайсын әлеге сөйләшү барышында гына бер дәрәҗәдә ачыклау, хәл итү мөмкин дә булмас. Шуны истә тотып, редакция һәм редколлегия сөйләшүне алга таба үзәккә бер проблема — гаять күп кырлы, әһәмиятле һәм актуаль булган гражданлык мәсьәләсен куеп дәвам итү урынлы булыр дигән нәтиҗәгә килде. Поэзия сөюче укучыларыбызны, шагыйрьләр һәм тәнкыйтьчеләрне дә, иң беренче чиратта, әлеге юнәлештә уйланырга чакырабыз.*

*Бу санда сүз шагыйрә Саҗидә Сөләймановага һәм яшь шагыйрь Рашат Низамиевка бирелә.*

## Саҗидә Сөләйманова

# ШАГЫЙРЬ—ЗАМАН БАЛАСЫ

Бөтен укучыларның, хәтта профессиональ тәнкыйтьчеләрнең бер шагыйрь иҗаты турында уртак фикергә килүе мәҗбүри түгел, бу мөмкин булмаган хәл. Шагыйрь үз заманының катлаулы яклары, бәхәсле мәсьәләләрен кузгата икән, бу автор турында бәхәсләр табигый. Тәлгать Галиуллин 1978 елда «Казан утлары» журналында чыккан мәкаләсендә Мөдәррис Әгъләмов иҗаты турында уртак фикергә килә алганыбыз юк әле дигән иде. Ул: «М. Әгъләмов әсәрләренә заман билгесе җитешми, аларда гражданлык пафосы тонык яңгырый, вакыт-вакыт шагыйрь артык сентименталь, тар булып китә», диючеләрне яклавын сиздергән иде. Шагыйрьнең яңа китабы бу фикерне үзгәрткәндер дип уйлыйм.

Тәнкыйтьченең «артык тар» дигән бәяләвенә алда тагын кайтырга ниятләп, лирик шигъ рьләрдәге заман билгесе һәм гражданлык хисе турында уйланырга чакырам. Ел әйләнәсендә миңа көчле тәэсир иткән шундый шигырьләрнең берсе Мөдәррис Әгъләмовның «Китә алмыйм» дигән шигыре булды.

**Мин китәргә тиеш таңга чаклы,**
**Ә бу кичә кабатланачакмы! —**
**Кабатланачакмы бу кичә! —**
**Китә алмыйм шуны белмичә.**

Үтә шәхси бер факттан шагыйрь үзе дә сизмәстән олы борчылуга, халык, Ватан, дөнья язмышын кайгыртуга күчә. Шагыйрь заман алдында сораулар гына куймый, кешелек тудырган материаль һәм әхлакый байлыкларны якларга әзер торуын белдерә. Шигырьнең ашкынулы динамикасы безне шуңа ышандыра.

Соңгы елларда шагыйрьләр чорның, яшәешнең мәгънәсен билгеләргә, аңа үз мөнәсәбәтләрен ачыкларга омтылалар. Бу омтылышта хезмәт кешесенең урыны аерым игътибар үзәгендә. Шул юнәлештә үземнең дә эзләнүләр чорына туры килдеме — Сибгат Хәкимнең Әхмәтшин Фоатка багышланган («Казан утлары», 1977 ел, 3 сан) шигыре мине ишекле-төрле йөрергә мәҗбүр итте. Ул шигырь укучыны да битараф калдырмагандыр дип ышанам, хәтергә төшерик:

**Кайта ул көтү алдыннан**
**Тоеп дөнья киңлеген.**
**Әйтерсең майда Берлинга**
**Килеп кергән көн бүген.**

. . . . . . . . . . . . . .

**Читенә басам-басам дип,**
**Бата барган кояшның,**
**Атлый... шагыйрь башым белән**
**Атлавыннан көнләштем.**
**Көнләштем, хәрәкәтендә**
**Сизелә бөек заманы,**
**Атлый, кырларның өстендә**
**Ике канат — кожаны.**

Чагыштырмача кыска шигырьдә елларның, чорларның бәйләнешен тою, тою гына түгел, аларны йөрәгең аша үткәрү, йөрәгеңдә төенләү бар. Хезмәт кешесенең бөеклеге көтүченең атлавы, кырлар өстендә җилфердәгән ике канат — кожаны аша сәнгатьчә сурәтләнгән.

Мәкаләдән-мәкаләгә бер үк исемнәр... Моның сәбәбе, минемчә, шагыйрьнең бер яңгырап, соңыннан да тынычланмавында, шигырь мәйданына килгән яңа көрәшчеләр белән янәшә, ясә алардан алда баруында, заманча яңгырашында, шагыйрьнең буыннар эстафетасы чылбырыннан ычкынып, төшеп калмавында.

Заманча яңгыраш, билгеле булганча, космик ачышлар, бөек төзелешләр булган КамАЗ, БАМ турында язуларга гына кайтып калмый. Бигрәк тә декларатив өндәүләр хәтердән тиз төшеп кала. Шагыйрьнең шәхесенә, җанына кагылган һәм ирексездән шигъри юллар булып агылган чор төсмерләре килер буыннарга мирас булып кала. Шагыйрьнең, һәммә кешенеке кебек үк, төрле чаклары була. Гел көчле, гел киеренке лозунглар кычкырып торса, аңа ышаныч кимер иде. Физиология фәнендә мускуллар гимнастикасы дигән төшенчә бар. Мускулларны бер киеренкеләтеп, бер йомшартып тору аларны чыныктыра, организмга энергия өстәлүгә китерә. Күңеле нечкәргән чакларда шагыйрь үз халәтен ак кәгазьгә (ягъни укучыга) ачып сала икән, укучының аңа ышанычы, мәхәббәте арта. Хәсән Туфанның 50 нче елларда басылып чыккан, якын кешесен югалтуга бәйле тетрәткеч шигырьләре укучының шагыйрьгә булган мәхәббәтен көчәйтте. Шагыйрь хәсрәте шәхси хәл рәвешендә генә кабул ителмәде, ил кичергән бер чор булып килеп басты. Моның сәбәбе — шагыйрьнең иҗтимагый фикерләвендә. «Хәлләрең ничек дисең син...» шигырен искә төшерик:

Бүген дә җилле, давыллый,
Һавада циклон бугай.
Минем дә давыл күңелдә,
Минем дә көннәр шулай.

. . . . . . . . . . . .

Алжирда ничек икән көн!
Кубада ничек икән!
Шикәргә киткән кораблар
Исән-сау җитте микән!
Тетрәтеп куя йөрәкне
Ниндидер моңсу тавыш.
Мөгаен, синең тавыш бу,
Тынычлык көткән Лаос.

Дөньяда азатлык, гаделлек өчен көрәшүче илләр арта барганда, дуслыкка мохтаҗлык, дуслыкка ышаныч булганда мондый шигырь вакытлар үтү белән дә искерми. Бу сүзләрем белән мин хәтта анда дөньякүләм, илкүләм төшенчәләр булмаса да, интим шигырьләр дә заманча яңгырый ала дигән фикерне үткәрмәкче булам. Тик ул шигырь кеше кичерешләре турында булсын, кешелекле булсын. Кешедән башка кешелек юк. Кеше бәхетсез булганда, кешелеклелек дип лаф ору — буш сүз. Бу фикерне Зөлфәт шигъри юллар белән искиткеч итеп әйтеп бирде:

Керфекләрең синең яшьле чакта,
Яшьле чакта көнең, төнең, таңың, —
Мәйданнарда
шигырь сөйләдем мин,
Юатмакчы булып... бар дөньяны!
Бер җылы сүз, бәлки, җитәр иде.
Юатуга җаның мохтаҗ чакта, —
Мин,
Кешелек җанын юатыйк дип,
Лаф органмын, тинтәк, һәрбер чатта,
Керфекләрең синең яшьле чакта...
Ут якканмын галәм җылытам дип,
Керфекләрең синең яшьле чакта, —
Ялгыз гына син туңгансың янда,
Тәрәзәсе бозлы төнге йортта...

(«Керфекләрең синең яшьле чакта.»)

Шагыйрь бәлки шәхси кичерешләрен язгандыр. Шигырьнең тетрәткеч фаҗигасына карaганда, бу тәгаен шулай. Әмма шигырь иҗтимагый яңгырашка ия. Кешелек турында күп сөйләнеп тә, кеше турында онытсак, кешелексезлек була дигән фикерне шагыйрь үз «Мин»е аша кичереп әйткән.

Ә менә шул ук темага, ләкин шагыйрьнең шәхси кичерешенә түгел, ә читтән күзәтеп, аңлатуга корылган шигырь:

Бар дөньяга ачуланган,
Ә тешли кешеләрне —
Аһ, күңелсез, күңелсез...
Ә шулай да хакыйкать бар:
Дөнья —
Кеше дигән сүз.

Бар дөньяга гашыйк бүген,
Ә үбә кешеләрне —
Барлык кеше бүген үз...
Ә шулай да хакыйкать бер:

Кеше —
Дөнья дигән сүз.

Һәр ике шигырь сәнгатьчә эшләнгән, аңлаешлы, кайсы кемгә күбрәк ошый, бусы бәлки зәвык эшедер. Шушы нисбәттән соңгы вакытта безнең тәнкыйтьчеләр һәм шагыйрьләр кузгаткан «Сюжетлы шигырь әйбәтрәкме, әллә фәлсәфи шигырьме?» дигән мәсьәләгә кагылып үтәсе килә. Бер чыгышында Межелайтис болай дигән иде: «...для того, чтобы выжить, поэзия все усложняется, становится «умнее», философичнее. Поэзия чувства, только чувства уступает место поэзии мысли. Ничего не поделаешь, такой век». Олы шагыйрьнең шушы сүзләренә кушылган хәлдә, бәхәс кузгатучыларга эш формада түгел, эчтәлектә дип әйтәсе килә. Эш фикер тирәнлегендә, хис кайнарлыгында, бу төшенчәләрнең укучы күңеленә, кеше язмышына ни дәрәҗәдә кагылуында.

Шагыйрьнең «Мин»е аша биреләме ул, бүтән шәхескә мөнәсәбәте аша тасвирланамы — кеше язмышы укучыны һичкайчан битараф калдырмый. Ни өчен Такташның «Мокамай»ы, «Алсу»ы, Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» безне һаман дулкынландыра һәм дулкынландырачак? Анда бәхете, хәсрәте, фаҗигасы белән кеше язмышы ярылып ята.

Шагыйрьлек тә ярый —
моның өчен
Үзең белән кирәк түләргә.

Әхлакый һәм иҗтимагый проблемаларының кискенлеге, художество чараларының төгәллеге ягыннан Мөдәррис Әгъләмовның «Исәнме, йөрәк» җыентыгы һәм Зөлфәтнең «Утлы бозлар»ы соңгы елларда чыккан иң яхшы китаплар рәтендә торырлык. Алар тоташ янудан ярatylган шикелле. Шатланып та, борчылып та яна шагыйрьләр, сөеп тә, сагынып та. Кыз язмышы, егет хыялыннан башлап, халыклар киләчәге турында уйланалар, уйланалар гына да түгел, дөньяга актив мөнәсәбәтләрен игълан итә алар.

Киек яна тозактагы килеш,
Тозак салган аучы, кайда хәйләң!
Кузлар чөеп «бишташ» уйный афәт
Һәм фаҗига уйный әйлән-бәйлән.
Кем ут салды сиңа,
Заманадай
Шаулап торган биек, көчле урман!
...Күктән янып төшкән самолет күк
Янып төшеп калды
җавап
чордан...
(«Янабыз».)

Уйлап чыгарылган шигырьләр була. Җанны ярып чыккан шигырьләр була. Бу бигрәк тә публицистикада шулай. Публицистиканы риторика белән буташтырырга ярамый, публицистика да мәхәббәт лирикасы кебек үк йөрәкне ярып чыгарга тиеш. Зөлфәтнең югарыда китерелгән шигъри юллары нәкъ әнә шундый.

Ир егетнең җан байлыгын еш кына аның хатын-кызга, мәхәббәткә мөнәсәбәтеннән дә белеп була. Зөлфәткә әхлакый идеаллар белән өртелгән мәхәббәт эзләү хас.

Син уемда уйлар чакларымда,
Уйда — уйламастай чакта да.
Ап-ак сының һәрчак хәтеремдә,
Син биектә, һаман ак тауда.
. . . . . . . . . . . .
Актарылсын дөнья! Сөю тавы
Күргән саен керсен мең төскә!
Син мәңгелек хыял кызы сыман
Гел биектә килеш кер төшкә.
(«Гел биектә килеш».)

Шигырьдәге кыз — мәхәббәт символы, шагыйрьнең эстетик идеалы. Тормышның язгы сулар сыман кайнаган, җәйге урман сыман шаулаган, көз сарылары иңеп, саргайган чаклары була. Мәхәббәт шагыйрьне биеккә, яктылыкка, сафлыкка чакырып тора. Бары мәхәббәткә турылыклы яры булганда гына шагыйрь эстетик идеалына ирешә алачак.

«Мәхәббәттән һәм кайгыдан тының кысылмаса, шигырь язма да,» — дип язды С. Гудзенко. Мәхәббәт шигырьләре һәр шагыйрьдә бар. Һәм, ни өчендер, безнең тәнкыйтьтә мәхәббәт темасын читләтеп узалар. Артык нәфис, нечкә тема булганга кагылырга куркалармы, яисә аны башка җитди мәсьәләләр белән бер рәткә куюдан саклананалармы? Ә бит укучы, бигрәк тә яшь укучы, нәкъ әнә шундый шигырьләрне яратып укый... Үсмер чакларыбызны, яшь чакларыбызны искә төшерик: Пушкинның, Лермонтовның, Есенинның, Такташның мәхәббәт лирикасын йотылып укымадыкмы, ятлап, күңелдән сөйләп йөрмәдекме? Соңгырак елларга килсәк, Шәукәт Галиевнең моңлы һәм шук, Илдар Юзеевның якты, Хисам Камаловның сагышлы шигырьләре безнең күңелләрне биләмәдеме? Инде менә хәзерге көннәргә кайтсак, Радиф Гатауллин, Равил Фәйзуллинның алгысынулы шигырьләре, Ренат Харисның акыл контроле астында язылган сөю шигырьләре, Гәрәй Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Разил Вәлиев, Фәннур Сафин, Роберт Миңнуллиннарның яшьлек хисе ургылып торган мәхәббәт лирикасы безне үзләренә битараф калдырамы?

Хезмәт сөю хисе, ватанны сөю хисе кебек үк мәхәббәт тә кешенең яшәү принципларын, эчке дөньясын күрсәтә; шагыйрьнең күңел япмасын ачып ташлый, укучы алдында шәрран-яран калдыра, бу очракта да шагыйрьгә кыюлык кирәк. Сугыш темасындагы кебек үк, мәхәббәт темасында да шагыйрь алдаша алмый. Һәр ике очракта йөрәген ул я бөтенләй бирергә, я бөтенләй ачмаска тиеш. Хәер, йөрәген тулысынча ачмаса, шагыйрьнең бүтән пландагы шигырьләре дә ышандырмый.

*

* *

1977 елда Татарстан китап нәшрияты «Кызлар җыры» дигән шигырь китабы бастырып чыгарды. Анда соңгы елларда актив иҗат итүче, вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле күренеп баручы хатын-кыз авторларның әсәрләре тупланган. Китапны төзүче Илдар Юзеев кызлар иҗатына аеруча сизгер килгән, иң әйбәт шигырьләрне сайларга тырышкан.

Поэзиядә яңа исемнәр... Укучыга нәкъ шулар соңгы елларда матур-матур шигырь бәйләмнәре бүләк итәләр. Язучылар союзы членнары, байтак китап авторлары Мәрзия Фәйзуллина, Энҗе Мөэминова, Клара Булатоваларны оныттыра төшеп, поэзиягә үзенчәлекле шагыйрәләр килде. Лена Шакирҗанова, Роза Хәлиуллина, Флера Гыйззәтуллина, Нурия Измайлова, Венера Туктарова, Сәлимә Шәрипова... «Кызлар җыры»нда Роза Хәлиуллина белән Илсөяр Ганиевага күләм ягыннан өстенлек бирелеп, аларның букетлары аеруча мул булып чыккан. Шул муллыктан иң күркәмнәрен сайлап алу эше укучыга калдырылган, шуңадырмы, шигырьләрдә бертөрлелек сизелә: аерылышу сагышы, югалту ачысы өстенлек алган шикелле... Бу өлкәдән Илсөяр Ганиева йөрәк каны белән язылган «Давылларга очты ал яулыгым» шигыренә әллә ни өсти алмаган. Роза Хәлиуллина исә «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Кайнана» поэмасы белән яңа яктан ачылды, оныгын багарга БАМга киткән ана образы аша үз иҗатына киң яңгыраш яулады.

Флера Гыйззәтуллина «Чишмә юлы» дигән беренче китабы белән үк укучы игътибарын үзенә җәлеп иткән иде. Шагыйрә тормышка реаль карый, ирешелмәгән хыяллар томаныннан сөеклесен эзләми, ирешелгәненнән канәгать булып, шул нигездән яңага омтылып яши белә. Флераның шигырьләрендә тормышчанлык, халыкчан тапкырлык бар.

**«Болай ни эшлисең,— дисең,—**
**Атлыгып таңнар белән!»**
**Туй күлмәкләре тегәм мин,**
**Туй күлмәкләре тегәм!**

**Кыз киткән өй ким булмасын**
**Килен төшкән өйләрдән.**
**Түргә сөлгеләр эләм мин,**
**Түргә сөлгеләр эләм.**
**Кигән киемебезне лә,**
**Чигелгән сөлгебезне...**
**Безнең кемлегебезне!**
**Кодалар белеп торсыннар**

Флераның көче — гади көнкүрешне шигъри юлларга салып, олы итеп, әһәмиятле итеп күрсәтә белүдә.

Гомумән, шагыйрәләрнең күпчелеге китаптан түгел, тормыштан килә. Алар хис кайнарлыгын, йөрәк көчен куяр урын эзләп иҗат итәләр, көндәлек хезмәт, бала тәрбияләү һәм ир багудан артып калган вакытларын шигъриятькә бирәләр.

Чаллы шагыйрәсе Сәлимә Шәрипова хезмәт героикасын тоеп яза.

**Шагыйрьнең җырында,**
**Гитара кылында,**
**Җырчының моңында**
**Макталган чагың,**
**Шәһәрем Чаллы.**

Кырыс һәм дөрес моңга салынган шушы юллары белән генә дә Сәлимә Чаллы турында язган байтак авторлардан аерылып тора. Җир кешесе буларак, тәзүче Сәлимә шул ук вакытта җиргә, туган туфракка тартыла. Башаклар турында кем генә язмаган?

**Иелгән башлар, иелгән,**
**Бөртекләр саллыгамы!**
**Алар да минем шикелле**
**Җиренә табынамы!**

Ә шулай да Сәлимә үзенчә, яңача яза алган, темага шигъри ачкыч тапкан.

Миллион тапкыр кабатланган Ана образын яңа яктан ачу җиңел түгел, шагыйрә аның да үзе күргән ягын шигырьгә сала алган:

**Иртә караңгыда**
**Әнкәем уяна,**
**Әнкәем артыннан**
**Дөнья кузгала.**

Әйе, әнкәйләр үзләре артыннан дөньяны да уяталар, алар уяу булганда, дөнья якты. Гади, төгәл, матур әйтелгән.

Моңарчы әйтелгән хис-тойгыларны төрле теземнәргә салып, шигырь ясаучылар хәзер байтак. Элек ишетелгән ноталар булганга, андыйлар артык дулкынландыра алмый. Шигъриятә үз юлын эзләүчеләр рәтенә мин Венера Туктарованы да кертәм: «Кызлар җыры» җыентыгында аның шигырьләре үзе генә тапкан ачышлары белән аерылып тора.

**Сөю беркемнән дә сорап килми.**
**Килгән икән, ул бит диңгез,**
**Үз ярларын үзе күрми.**

Яисә:

**Автовокзал — Әлмәт йөрәге,**
**Нефтьчеләр эшкә барышлый**
**Аның пульсын тыңлый элгәре.**

Лена Шакирҗанова белән Нурия Измайлованы да махсус телгә алмау мөмкин түгел. Лена Шакирҗанова үзенең ачышлары һәм югалтулары, мәхәббәте һәм ачынулары белән тәэсирле. Кабатланган аһәңнәр? Лена аларны үзенчә кичерә, үзенчә җыр-

гә сала. Ул җыр табигый агышы белән дә күңелгә ятышлы. Гадәти мәхәббәт җырына кәтелмәгән яңа аһәң килеп кушыла, җыр дәртлерәк, ышанычлырак яңгырый башлый.

Бишек элдек бүлмәгә,
Бии-бии тирбәлә.
Күрше-күлән, дус-ишләр
Килде бәби күрмәгә,
Калмады бер килмәгән.
Кояш элдек бүлмәгә...
Тәрәзәдән ай кергән
Шул кояшны күрмәгә...

(«Бишек элдек»).

Җиңел, шат, якты.

Гадәттә, поэзия турындагы докладларда, мәкаләләрдә бөтен шагыйрәләрне бер җепкә тезеп телгә алалар. Ир-егет шагыйрьләр белән бер рәткә куярдай шагыйрәләр булмауданмы бу? «Әйе» дип тә, «түгел» дип тә катгый җавап бирүе кыен. Шигырьнең тәэсир көче, күтәргән темасы, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан килгәндә, безнең көннәрдә язылган иң яхшы шигырьләр белән янәшә торырдайлары бар, минемчә. Сайлап алсаң, көнләшерлек юллар, строфалар, шигырьләр табарга була. Нилектән соң шагыйрьләр белән шагыйрәләр исеме янәшә йөрми диган сорау алдында туктапып, уйланып торсаң, моның сәбәбенә төшенү алай ук кыен булмас. Баксаң, хәзерге татар поэзиясендә бөтен гомерен әдәбиятка багышлаган шагыйрә юк икән. Шигырь язучы хатын-кызларның күпчелеге гомерләренең бер чорында гына иҗат белән мавыга: яисә үсмер чакта, гаиләгә бәйләнгәнче, яисә, киресенчә, гаилә җепләреннән арынгач.... Хатын-кызның тавык чүпләп бетерә алмас хуҗалык эшләре талантлы дигәннәрен дә каләм-кәгазьдән озак вакытка аера. Аһ, күп кирәк хатын-кызга матур-төзек тормыш кору өчен: өең ямьле, ашың тәмле, урын-җирең чиста булсын. Өстәвенә, киенәсе-ясанасы, театрга барасы, кино карыйсы килә. Балаң «5» легә укысын, музыка яки художество мәктәбенә йөрсен, вузга керсен... Ә поэзия сине кисәклэп түгел, бөтенләй сорый, ул синең озаклап парикмахерскийда утыруыңны да күпсенә. «Ахирәтләр, ташлагыз барсын да, ак кәгазь өстенә генә капланып утырыгыз!» дип чакыру ташларга җыенмыйм. Күңелдә җыелганы, әгәр ул шигъри күңел булса, кәгазьгә бер төшә ул, ә булмаганны сыгып язудан файда аз.

Хәзерге көндә язып килгән шагыйрәләр тормышның төрле якларын яктыртып, бер-берсен тулыландыралар. Мәсәлән, Гөлшат Зәйнашеваның җыр өлкәсендәге уңышларына хәзер бер кем дә күз йома алмый. Шагыйрәләр тормышның нәкъ ирләр күрмәгән өлешен шигъри юлларга сала. Ишеткәнем бар, ир-егетләр хатын-кызның поэзиядә дә нәкъ менә хатын-кыз булып калуын телиләр. Тәнкыйтьчеләр исә андый шигырьләргә «тар», «артык интим», «гражданлык хисе җитми» диган гаеп тагарга торалар. Шундый сүздән куркып-өркеп беткәнгә, югарыда китерелгән мисаллар өчен мин махсус иҗтимагый яңгырашлы шигырьләр сайладым. Күреп, белеп торыгыз, хатын-кыз поэзиясендә дә гражданлык хисе ирләрнекеннән ким түгел, диясем килде.

Сүзне мәхәббәт шигырьләреннән, алар турында да нинди дә булса фикер әйтергә кирәклегеннән башлап җибәргән идек. Әйтергә кирәк, «Кызлар җыры»ннан сагышлы үкенечле шигырьләр күбрәк истә кала. Бу турыда да уй йөртеп, сәбәпләрен ачыкларга тырышып карыйк. Мәхәббәт һәр вакыт бәхетсез, ягъни җавапсыз гына булмый, шагыйрь өчен ул илһам чыганагы, бәхет чишмәсе дип беләбез. Шигырьдә җан тетрәткеч сагыш тоябыз икән, шагыйрә аны шул сагышы белән ялгыз калганда язган. Ә бәхетле чагында аның ак кәгазь белән икәүдән-икәү калырга вакыты юк һәм бәлки теләге дә юктыр. Андый чакларда ул үзенең көч-куәтен, бәхет-шатлыгын эшкә сала, тормышка күчерә. Ул үзенең күңел назларын кәгазьгә түгел, сөйгәненә бирә. Ак кәгазьгә исә күп очракларда ялгызлык сагышы төшә.

Иманым камил, мәхәббәт шигырьләре дә иҗтимагый яңгырашка ия. Сүземне түгәрәкләп, Нурия Измайлованың «Казан утлары» журналында басылган бер шигырен хәтергә төшерәм:

Үз-үземнән китәр идем
Киң күкрәкле көчле ярыма.
«Тилекәем» дисә, келәр идем
Һәм тилерер идем тагын да.
«Бәләкәчем» дисә, елар идем,
Тезләренә сарыла-сарыла.
Горур башкаемны ияр идем,
Үлән булыр идем алдында.
Акылсыз һәм көчсез калыр идем,
Көчле ярым булса янымда.
[«Син көчле» диючеләргә».
«Казан утлары», 8 сан].

Бу шигырьне тар һәм интим дип кем әйтә ала? Ир-егетләрне ул көчле, игътибарлы, кешелекле булырга өндәмимени? Мөнәсәбәтләр гармониясенә, әхлакый камиллеккә чакырмыймыни? Соңгы еллар поэзиясендә шагыйрь күңелен укучы алдында шул кадәрле дә шәрран-яран ачып салу очраклары бик еш булып тормый. Шагыйрь үзен кешеләргә, заманага ышанып тапшыра, чөнки аңа шушы кешеләр белән, шушы замана белән бергә атлыйсы. Шагыйрьнең көче — әнә шул ышанычта.

## Рашат Низамиев

# ШАГЫЙРЬЛӘРГӘ ЗАМАН ТЕКӘЛГӘН...

Барлык проблемаларны берьюлы колачлау мөмкин түгел. Биредә сүз, нигездә, яшьләрнең шәхес һәм гражданин, шагыйрь буларак өлгереп җитүләре, тормыш тәҗрибәсе һәм әдәби осталык мәсьәләләре тирәсендәрәк барачак. Бүгенге поэзия турында сөйләшкәндә сүзне яшьләргә таба бору гаҗәпкә калдырмас. Чөнки яшь алмаш һәм аның проблемалары турында уйлану — әдәбиятның киләчәге турында уйлану дигән сүз ул.

Тукай үзенең шигырьләрен «күңел җимешләре» дип атаган. Икенче бер күренекле шагыйрь «шигырьләр — күңел биографиям» дигән фикер әйтә. Иҗат процессында кешенең акылы, зиһене дә актив катнаша. Ләкин кем дә булса поэзияне «акыл җимешләре» дип атый икән, бу көлке булыр иде. Әйе, әдәби әсәр баш мие күзәнәкләренең «тырышлыгы» гына түгел, шагыйрьнең яшәешеннән аерылгысыз булган социаль, рухи, физик, эмоциональ һәм психологик факторлар кушылмасының үзенчәлекле чагылышы ул! Күңелнең киеренке хәле гап-гади сүзләрне очкынлатып, дөрләтеп җибәрергә сәләтле. Шигырьләренә шагыйрь үзенең җанын, эчке дөньясын бүлгәләп сала. Шулардан чыгып кына да шагыйрьнең шәхесен, яшәешен шактый тулы күзалларга мөмкин. Мәсәлән, без Пушкин, Есенин, Тукайларны исән вакытларында күреп белмибез. Иҗатлары белән якыннан танышу исә безгә аларның сөйгән халкы һәм Ватан өчен өзгәләнеп яшәүләрен, гаять олы җанлы, кешелекле булуларын аңларга булышлык итә. Азатлык җырчысы Тукайның авыру чагында язылган шигырьләрен укыганда мин аның газаплы йөткерүен аермачык ишетәм. Йөрәккә егерменче гасыр башындагы әрнеш уклары кадалгандай була...

Теләсә кайсы поэзия үрнәге — билгеле бер чор кешесенең, шагыйрь шәхесенең үзенчәлекле чагылышы, кайтавазы ул. Һәр аерым шигырьне күңел биографиясеннән бер фрагмент, өзек, кисәкчә дип аңларга кирәк. Шуңа күрә гомерен иҗат эшенә багышларга уйлаган кешенең тормыш биографиясе, фантазиясе, эчке культурасы, эмоциональ һәм әхлак тәҗрибәсе, һичшиксез, зур әһәмияткә ия. Болардан башка гомумкешелек интересларын чагылдырган көчле сәнгать әсәре иҗат итү мөмкин түгел.

«Тукта, мин тормышны өйрәним әле», — дигән максат куеп, каләм һәм блокнот белән коралланып, кешеләр арасына махсус чыгып китү сәер булыр иде, әлбәттә. Тормышны, дөньяны, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнү һәм үзләштерү процессы күзебез ачылып, баш миенә акыл иңә башлаган сәгатьтән алып, һәр минут, һәр даим өзлексез дәвам итә. Тормышны үткен күз белән күзәтү, һәр күренештән мәгънә таба белү — каләм остасы өчен бик тә кирәкле сыйфатлар.

Тәнкыйть еш кына яшь язучыларны, шагыйрьләрне тормышны белеп җиткермәүдә гаепли. Минем ышануымча, бездә тормышны белмәгән, аның кайгы һәм шатлыкларын, ак, кара һәм башка төсләрен аңламаган шагыйрьләр юк — яшьләр поэзиясендәге иң яхшы үрнәкләр шуны раслый.

**Бардыр миндә тулпар елгырлыгы,**
**Бардыр, бәлки, уклар үткере.**
**Бардыр канда дала кыргыйлыгы,**
**Сезнең учакларның ут сере.**

**Чаба вакыт Болгар тулпарыдай,**
**Киләчәккә китеп барам мин.**
**Кайчагында сездән калган ташка**
**Уйларымны бәреп ярам мин.**

**Нәрсә гаҗәп! — Беркөн килеп кемдер**
**Бездән калган ташка абыныр.**
**Күкне теләр вакыт ракетадай**
**Һәм кемнәрдер безне сагыныр.**

Әлеге юллардан күренгәнчә, Зөлфәт үткән белән бүгенгенең бәйләнешен, яшәүнең бөеклеген һәм мәңгелеген сәнгатьчә осталык белән ачып бирә алган. Лирик геройның киеренке халәте, уйлары синең дә рухыңа көчә, синең дә кичерешләреңә әверелә.

«Шагыйрьнең иң уңышлы шигырьләре үз тәҗрибәсе белән бәйләнгән», — ди Ә. Баянов мәкаләләренең берсендә һәм мисал рәвешендә Н. Арсланов, Ф. Ярullин иҗатындагы кайбер моментларга тукталып китә. Тормыш тәҗрибәсе шагыйрьнең күңел дөньясы, фантазиясе белән баетылганда гына сәнгать югарылыгына күтәрелә. Кемнең фантазиясе ничек бит — мәсьәләнең ул ягы да бар. Кем өчендер күкнең биеклеге болытларга чаклы гына булырга мөмкин... Әйе, иҗат эшендә үз тәҗрибәңә, хыял байлыгыңа таянмыйсың икән, ул вакытта аңлы яисә аңсыз рәвештә кайчандыр ишеткән-укыган, хәтердә калган «запас» белән эш итәргә туры килә. Бу исә литератургщинага, рационализмга, эрудициянең шигырь язуына этәрә. Йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып җитә дигән сүзләрдә зур хаклык бар. Хәсән Туфан иҗатындагы моңсулык һәм оптимизм, мәхәббәт һәм нәфрәт нәкъ менә «йөрәктән чыккан» булулары белән тәэсир итү, ышандыру көченә ия.

**Кил әле, кил,**
**Үбим үзеңне бер! —**
**Яратам мин сине, и Җирем!**
**Кочагыма минем сыймасаң да,**
**Җаныма бит**
**Сыясың минем.**

Яки:

**Дөнья бирде кирәкне,**
**Еламаска өйрәтте...**

Кайсыгызның кулы җылы! —
Бәйлисе бар йөрәкне...

Менә нинди зур ул Туфан! Аның мәхәббәте Җирне, димәк, тормышны, кешеләрне, табигатьтәге барлык тирбәнешләрне илаһи бер ярату белән кочаклап алыр иде. Тагын шунысы игътибарга лаек: шагыйрьнең моңсулыгыннан да оптимизм, яшәүгә сусау, тормышка мәхәббәт көче бөркелеп тора. Җир кешесенең шатлык һәм сагышлары бер җанга этешми-төртешми генә сыйган да утырган — искиткеч камиллек, табигыйлек бу! Шушы камиллек хис һәм акылыңны биләп ала, рухи тәҗрибәңне баета, тормышны яратырга өнди. Әйе, шулай булмаса, шагыйрьнең төн утырып язуы, януы-газаплары бушка, мәгънәсезгә үткән гомер булыр иде.

Әдәбиятка, шул исәптән поэзиягә дә, үз-үзен аямый эшләүче, дөньяның олы гамьнәре белән яшәүче якты шәхесләр кирәк. Бөек шагыйрьләрнең һәркайсы өнә шундый биеклектә тора. Әдипнең шәхесе никадәр зур булса, аның иҗаты да шул кадәр олы, масштаблы. Без шагыйрьнең гражданлык йөзе турында сөйлибез икән, бу — аның шәхесе турында сөйләү дигән сүз. Гражданлык — поэтик шәхеснең асылы, киеренке халәте, эчке хасияте ул. Шагыйрь дөнья каршында, чор һәм заман, бүгенге көн каршында җаваплылык тоеп яши. Чөнки тормыш үзенең мең төрле төсләре, мәшәкатьләре, шатлык һәм борчулары, бихисап сораулары белән шагыйрьгә текәлгән, ул аннан җавап көтә. Шагыйрь битараф була алмый, гражданлык намусы аны үзеннән-үзе тормыш эченә бәтереп алып керә.

**Дулкыннар шикелле**
**Арышлар ишелгән.**
**Шатланыр урында**
**Елыймын эчемнән...**
**[С. Хәким].**

«Ява да ява гел». «Арышлар сөрлеккән»... Әнә шуларга карап борчыла шагыйрь. Гап-гади юллар, ә ничек тәэсирле! Монда шагыйрьнең кешелекле, олы җанлы булуы аермачык ярылып ята.

Сибгат ага Хәким — Бөек Ватан сугышы ачысын үз җилкәсендә татыган буын вәкиле. Кешелеккә әйтеп бетергесез фаҗига китергән сугыш турында ул күп кенә әсәрләр язды.

**Әле һаман куркып уянамын**
**Төшемдә мин төшеп әсиргә.**
**Нигә мине эзәрлекли сугыш,**
**Санылмы ул таза, яшь иргә!**

Туплар тавышы тынып, инде күпме сулар аккан... Нигә соң шагыйрь һаман да сугыш темасына мөрәҗәгать итә? Дөнья гамьнәре белән яшәүче шагыйрьнең җаны тыныч түгел: чөнки җирдә дары исенең ни икәнен дә белмәгән яшь буын үсеп килә. Алар әтиләре кичергән фаҗигане беркайчан да кичермәскә тиеш! Шагыйрь сугышка каршы кискен протест ташлый, кешелекне кисәтә, уяу булырга чакыра. Юк, әлеге юллар үзенең актуальлеген, социаль яңгырашын югалтмаган әле.

Гражданлык йөзен шигырь юлларындагы өндәү билгеләренең күплегенә карап үлчи торган заманнар артта калды. Шагыйрьнең дөньяга, тормышка карата мөнәсәбәте ничек, нинди идеалларны яклый ул, кайсы көрәш утларында яна — бүгенге көндә гражданлык йөзен билгеләүдәге төп критерий әнә шулдыр.

Шагыйрьнең шәхесе, гражданлык йөзе көрәштә аеруча калку чагылыш таба. Кайберәүләр: «Кискен көрәшләр чоры артта калды, хәзер тын заман, салмак заман», — дип расларга омтылса, бу ялгыш фикер булыр иде. Безнең заман — рухи батырлык, әхлак гармониясе өчен көрәш заманы. Явызлык һәм гаделсезлек, вөҗдансызлык һәм куркаклык, мәкерлек һәм икейөзлелек, рухи гариплек һәм культурасызлыкка каршы көрәш беркайчан да туктамаячак! Шагыйрьнең поэтик шәхесе халыкны әнә шушы олы максатлар өчен көрәш юлыннан ияртеп алып бару көченә ия булырга тиеш — моны бездән заман үзе таләп итә.

**Көрәшчеләр кирәк!**
**Беләклеләр җитә,**

**Йөрәклеләр кирәк!**
**Куәтлеләр җитә,**
**Теләклеләр кирәк!**
**Көрәшчеләр кирәк!**

Равил Фәйзуллинның «Көрәшчеләр» поэмасыннан алынган бу юлларны югарыда әйтелгән көрәш идеяләренә актив чакыру дип кабул итәргә кирәктер. «Кеше җаны өчен көрәш барган» заманда битарафлык — үзе җинаять, поэма әнә шундый иҗтимагый пафос белән сугарылган.

**Тирбәләбез, бу җир безгә бишек,**
**Юк, ул — коймә, без барабыз ишеп.**
**Кеше кулы тойган матурлыклар**
**Безнең белән бара тирбәлешеп.**
**Бездән соң да шулай барачакмы!**
**Бу диварлар мәңге калачакмы! —**
**Меңләп сорау, меңләп уй килә...**
**Китә алмыйм шуны белмичә.**

Бу юллар исә Мөдәррис Әгъләмовныкы. Җир белән бергә-бер торып, күзгә-күз карап ихластан сөйләшә ул. «Шагыйрьнең җаны бәргәләнә...» — аның турында Сибгат ага Хәким кайчандыр шулай дип язган иде. Мөдәрриснең бу сыйфаты югалмады — көчәя, тирәнәя генә барды. Үзе өчен түгел, иле, халкы өчен яна, дөнья гамьнәре белән борчылып яши. Шагыйрьнең уйлары, яшәеше, гражданлык йөзе шигырьләренә саркып керә.

М. Горький, һәр кеше үз гомерендә бер китап яза ала, дигәнрәк фикер әйтә. Бу — һәркемнең үз биографиясе, тормыш тәҗрибәсе, кешеләргә сөйләр сүзе барлыгына ишарә белән әйтелгән сүзләр булса кирәк. Ләкин бөтен бәла шунда ки, күп кенә яшьләр үзләренең белгәннәрен, кичергәннәрен, тормышны аңлауларын сәнгатьчә югарылыкта биреп бетерә алмыйлар. Бай һәм матур биографияң булырга мөмкин, ләкин шагыйрьгә аның биографиясенә карап түгел, иҗатыннан чыгып бәя бирелә. Газета-журналлар янсә яшьләрнең «Идел» альманахы битләрендә яңа исемнәр белән танышканда кайчак мондый күренешкә юлыгасың: менә дигән шигъри тема, табышлар, образлар бар, ләкин... шигырь юк. Ул яртылаш өлгергән алма хәлендә генә калган.

**...Гомерләре яшен булган**
**Кешеләрдән көнләшәмен.**
**Ишетәсеңме, замандашым,**
**Мин сиңа да эндәшәмен:**

**— Сиңа хәзер егерме биш!**
**Бу вакытта нәрсә кырдың!**
**Илең өчен ни эшләдең,**
**Халкың өчен нәрсә кылдың!!**

Яшьтәшем Ренат Хәйретдиновның «Туган көндәге уйлар» исемле шигыре («Идел», 9 нчы сан) әнә шундый кешелекле уйлар, гражданлык хисләре белән тәмамлана. Ният изге, матур! Әмма бик тә таныш, кабатланган, маңгайга бәреп әйтелгән шушы декларатив чакыруның замандашка актив йогынты ясавына шикләнеп карыйм мин.

Бернәрсә бәхәссез: яшь шагыйрь никадәр иртәрәк өлгерсә, бу — иҗатының уңышлы үсеп китүе өчен шул кадәр яхшы. Бездә яшь алмашның өлгерүе нигездә тизләктә бара, бу процессның тиешенчә баруы өчен шартлар җитәрлекме!.. КПСС өлкә комитеты тарафыннан иҗат яшьләренең республика семинары үткәрелү ел саен истә калырлык вакыйга була. Шуның өстенә районнарда яшь шагыйрьләрнең зона конференцияләре уздыру, әдәби ел йомгаклары, секцияләрдә яшьләрнең кульязмаларын янсә беренче җыентыкларын тикшерү, әдәби консультацияләр һ. б. — болар бар да әдәбият тормышында, алмаш әзерләү процессында билгеле бер эз

калдыра. Газета-журналларның да яшьләр иҗатына шактый киң урын бирүен искә төшерик. Күргәнебезчә, шартлар җитәрлек икән. Шулай да бездә, миңа калса, яшьләрнең шәхес һәм гражданин булып формалашуы акрын бара. Яшь шагыйрь дигәнебез формалашып өлгергәнче, аның инде чәче агарган була. Ни өчен соң яшьләр соңарып өлгерә? Хикмәт нәрсәдә?

Беренчедән, хикмәт талантның ни дәрәҗәдә булуында. Табигать биргән талант орлыгың кечкенә икән, өстенә гомер буе кояшлы яңгыр явып торса да, аның җимешләре барыбер кечкенә булачак. Икенче сәбәпнең тамырлары исә шактый тирәнгә китә. Анысын чорга, заманга бәйләп аңлатырга кирәктер. Телибезме-теләмибезме, безгә яшь шагыйрьләрнең соң өлгерүен заманабыз өчен хас күренеш дип танырга туры килә. Цивилизация һәм фәнни-техник революция кешелек җәмгыятен елдан ел югарырак баскычка күтәрә бара. Кешелек җәмгыяте эшләп чыгарган фәнни һәм рухи байлыкларны үзләштерми торып, заман белән бер сафта атлау мөмкин түгел. Яшь кеше 16—17 яшенә кадәрге гомеренең күп өлешен парта арасында үткәрә, аның вакыты һәм энергиясе югарыда әйтелгән байлыкларны өйрәнүгә, үзләштерүгә сарыф ителә. Бу — бертөслерәк, программага салынган әзер тормыш, яшәү рәвеше. Бала дөньяны күп очракта дәреслекләрдән генә өйрәнә, мөстәкыйль фикер йөртергә мәйдан аз кала. Югары уку йортларында әлеге процесс тагын биш ел чамасы дәвам итә.

Субъектив сәбәпләр дә юк түгел. Безгә, яшьләргә, иҗтимагый активлык, әдәби хәрәкәттә һәм тормышның олы проблемаларын хәл итүдә якыннан катнашу, өлкәннәр белән нәтиҗәле аралашу, олы «казанда» кайнау җитеп бетми. Уйлавымча, шагыйрьнең шәхесе иҗатында гына түгел, яшәешендә, көрәшендә, үз-үзен тотышында да чагылырга тиеш. Яшьләрнең иҗат активлыгы әнә шушы сыйфатлар белән дә баетылса, камилләшсә, моңардан әдәбият бары отачак кына.

Р. Фәйзуллин да, яшьләрнең соң өлгерүен истә тотып, болай ди: «Күренәсе талант утыз яшькә хәтле күренә инде ул». Моның белән килешергә дә мөмкин, ләкин югарыда әйтелгән сәбәпләргә күз йомарга ярамый. Әдәбиятка һәркемнең атылып килеп керүе мөмкин эш түгел, төрле кеше төрлечә килә, төрлечә иҗат итә. Мәсәлән, соңгы биш-ун ел эчендә өлкән шагыйрь(!) Нури Арсланов шундый яхшы поэзия үрнәкләре бирде ки, хәтта бу көтелмәгән хәл күпләрне гаҗәпкә калдырды.

Халыкның шигърият чишмәсе саекмый, өлкәннәргә алмашка яшь көчләр килә тора. Зөлфәт, М. Әгъләмов, Ф. Сафин, Р. Миңнуллин, Э. Мостафин, З. Мансуров, Р. Юнысов, Х. Әюпов һ. б. күп кенә исемнәр үзләренең сәләтле һәм өметле икәнлекләрен расладылар инде. Поэзиябезнең матур традицияләрен шигъриятне ихластан сөйгән, аны иманы, кыйбласы итеп сайлаган әнә шундый яшьләр дәвам иттерәчәк. Бу — җиңел бурыч түгел. Киләчәктә поэзиядә үз-үзеңне раслау тагын да кыенрак булачагы көн кебек ачык. Чөнки дөньяны иҗади үзләштерү юлында шагыйрьләр тарафыннан том-том китаплар язылган — шигъриятең, иманың алдында ант иттеңме, син инде башкаларны кабатламыйча үз дөньяңны ачарга тиеш буласың. Шулай булмаганда бер урында таптану килеп чыга, үсеш туктала. Фәнни-техник революция заманы кешенең тормышына, психологиясенә, аңына зур йогынты ясавын дәвам иттерә, кеше һәм тирәлек арасындагы мөнәсәбәтләр катлауланa бара.

Александр Блок үзенең иҗат васыятендә мондый сүзләр язып калдырган: «Цивилизация тудырган дәүләт һәм җәмгыятьнең кулы җитмәслек төпсез тирәнлекләрдә аваз дулкыннары тәгәрәшә...

Шагыйрьнең рухы ирешкән, тирәннән күтәрелгән шушы аваз... ныклы һәм тоемлы сүз формасына әверелергә, авазлар һәм сүзләр бердәм гармония барлыкка китерергә тиешләр». Шул рәвешчә, А. Блок шагыйрьнең бөеклеген, ул башкарырга тиешле эшнең асылын тирәндә яткан һәм күпләр ишетми торган авазларны, моңны ача белүдә, камиллеккә ирешүдә күрә. Әйе, шагыйрьнең яңа бер дөнья ачарга тиешлеге — бәхәссез хакыйкать. Пушкин һәм Блок, Тукай һәм Такташлар дөньясын искә төшерик... Никадәрле байлык, хәзинә, рух җимешләре анда!

Галәмнең үзе шикелле үк, тормыш һәм кеше күңеле дә бетмәс-төкәнмәс киңлекләр, кул тимәгән серләр һәм катламнар белән уратып алынган. Шагыйрьләр ачасы дөнья әле — дөнья кадәр! Ул үзенең яңадан-яңа шигъри «колумб»ларын көтә.

## ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Габделхак Кудашев**

# КАМИЛЛЕК ҺӘМ НӘФИСЛЕК ЮЛЫННАН

Бөек Октябрь революциясеннән соң татар әдәби теленең функциональ базасы гаять дәрәҗәдә киңәйде. Партия һәм хөкүмәтебез үткәргән мөһим чаралар телебезнең үсү-камилләшүе өчен реаль шартлар тудырды.

Телнең үсү, камилләшүендә, аның структур үзгәрешләрендә тарихи һәм иҗтимагый факторлардан башка, табигый факторларның да роле бик зур. Физиканың төп принципларыннан берсе булган минималь гамәл принцибы шундый факторлар җөмләсенә керә. Бу принцип буенча, табигатьтә барган хәрәкәт вакытында гамәл минималь микъдарда сарыф ителә; гамәл исә энергиянең вакытка тапкырчыгышына тигез. Димәк, гамәл минималь булсын өчен, вакыт һәм энергия минималь сарыф ителергә тиеш.

Табигатьнең бер өлеше буларак, кешеләр (һәм бөтен кешелек җәмгыяте дә) минималь гамәл принцибы нигезендә эш итә, энергия һәм вакытны азрак сарыф итәргә — экономия ясарга омтыла. Шуны да әйтергә кирәк, кешеләрнең энергия һәм вакытларын азрак сарыф итәргә омтылулары дәвердән-дәвергә дәвам иткән яшәү өчен көрәш нәтиҗәсе булып тора, ул табигый сайланыш тәэсирендә барлыкка килгән күренеш. Шунлыктан, кешеләрдәге бу омтылыш күп вакыт, уйланып, фикер йөртү юлы белән эшләнми: көчле яктылык төшкәндә күзебезнең йомылуы шикелле, үзеннән-үзе — табигый рәвештә килеп чыга.

Табигатьнең катлаулы һәм гүзәл күренешләреннән булган кешенең җанлы сөйләм теле дә минималь гамәл принцибының чагылышыннан читтә калмаган: әдәби телебезнең үсү һәм камилләшү процессында бу принцип зур роль уйнаган.

Материалистик диалектика күзлегеннән карaганда, сөйләүче кешенең ихтыяҗы белән шул чорда кулланылган телнең ресурсы — байлыгы арасындагы каршылык телне үсү һәм камилләшүгә алып баручы төп чыганак булып тора. Сөйләүче кеше, башкалар белән аралашканда, үзенең практик тормышында уй-фикерләрен, теләкләрен төгәлрәк, тулырак итеп аңлатырга тырыша — бу аның ихтыяҗы. Ләкин шул чорда кулланылган телнең ресурсы — байлыгы бу ихтыяҗны тулысынча канәгатьләндерергә мөмкинлек бирми. Шушы каршылыкның чишелешендә минималь гамәл принцибы зур роль уйный.

Билгеле булганча, һәрбер авазны әйтү өчен сөйләүче кеше энергия һәм вакыт сарыф итә. Сөйләм озаграк дәвам иткән саен, сөйләү өчен сарыф ителгән энергия дә зурая: күп кешеле зур аудиториядә рәттән берничә сәгать лекция сөйләгән яки доклад ясаган кеше зур физик эш башкарган шикелле үк арый. Шунлыктан кешеләр сөйләгәндә, язганда, укыганда, үзләре дә сизмичә, энергия һәм вакытларына экономия ясарга омтылалар: сөйләү өчен азрак вакыт таләп иткән авазлар, сүзләр һәм әйләнмәләр кулланырга тырышалар, әйтергә теләгән уй-фикерләрен тыңлаучыга җиңелрәк аңлату өчен яңа сүзләр ясыйлар, башка телләрдән сүзләр алалар. Шуның нә-

тиҗәсендә тел беркадәр камилләшә, санча һәм сыйфатча югарырак баскычка күтәрелә. Ләкин тел бу хәлендә тукталып калмый: югары баскычка күтәрелгән телгә җәмгыятьнең таләбе дә югары була. Тел алдына яңа бурычлар, югарырак таләпләр куела. Шулай итеп, телдә яңа эчке каршылык килеп чыга. Бу каршылыкның чишелеше телне тагын да камилрәк дәрәҗәгә күтәрә.

Минималь гамәл принцибы татар теленә генә хас нәрсә түгел, билгеле. Бу принципның чагылышын башка телләрдә һәм төрле диалектларда күзәтергә мөмкин. Ләкин үсү, камилләшү шартлары, эчке закончалыклары башка булган телләрдә бу принципның чагылышы татар телендәгегә караганда башкачарак булуы табигый хәл. Шунлыктан бер тел өчен чит булган күренеш икенче тел өчен норма булуы мөмкин. Мәсәлән, татар, алтай, казакъ телләренә караганда госманлы төрекләре телендә яңгырау тартыклар киңрәк кулланыла. Татар теленең урта диалектына караганда көнчыгыш диалектында тартыкларның саңгыраулашуы көчлерәк булу тикшеренүләр белән исбатланган факт.

Бу мәкаләдә әнә шул урта диалект кичергән структур үзгәрешләрне минималь гамәл принцибы күзлегеннән тикшерү максат ителде.

Әдәби телебездә сузык авазларның кулланылуы белән бәйле ике очракны карап китик. «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында без түбәндәге строфаны укыйбыз:

**Зөләйха әйдер: «Сезләр гаян күрдеңезму!**
**Бәнем бәңзем сулдыгын белдеңезму!**
**Бер бакмакдин әлләреңез кәсдеңезму!**
**Бихуд улып төштеңезму сезләр имде!»**

Г. Кандалый шигырьләрендә дә шундый ук форма еш очрый.

**И алтыным, бәян әйлә:**
**Сүзем кабул итәрмүсән!**
**Шулай тилмертеп үк әллә**
**Бүтән ярга китәрмүсән!** [1]

Бу мисаллардан күренгәнчә, борынгы чордан алып XIX йөзнең икенче яртысына кадәр әдәби телебездә озын сузыкларга тәмамланган му-мү кушымчалары бик киң кулланыла. Ләкин шушы кушымчалар белән беррәттән кыска сузыкка тәмамланган мы-ме кушымчалары да гамәлдә йөриләр. Мәсәлән, Г. Кандалыйның «Гомерең үтәр» дигән шигырендәгечә:

**Җәмалендин я алданып торамы!**
**Сылумын, дип, матур, дип, лаф орамы!**

Милли әдәби телебез нормалашкан чорда му-мү кушымчалары кулланылыштан чыга, ә кыска сузыкларга тәмамланган мы-ме кушымчалары әдәби телдә ныклап урнаша. Минималь гамәл принцибы күзлегеннән караганда, сөйләгән вакытта му-мү урынына мы-ме кушымчаларын куллану сөйләүченең вакытына һәм энергиясенә экономия бирә, сөйләү процессын җиңеләйтә.

Борынгы һәм иске әдәби телебездә кулланылып йөргән *тулун, сатуп, канлу, кайгу* сүзләренең хәзерге телебездә *тулы, сатып, канлы, кайгы* рәвешендә кулланылулары да кыска сузыкларның озын сузыкларга карата активлыгын, сузыкларның үзара алмашынуларында минималь гамәл принцибының чагылышын күрсәтә.

Телебездә нечкә сузыкларның ишәя баруы тенденциясе дә шул принципка нигезләнгән. Лотфи Яфаров калын сузыкларның нечкәләр белән алмашынуларына карата: «...татар телендә нечкә әйтелешле сүзләр активлаша, күбәя бару тенденциясе ачык бер күренеш булып тора. Бу — чынлап та, тенденция, тел фактлары үсешендә билгеле бер юнәлеш, ягъни татар теле үсешенең эчке законы» [2],— дип яза.

Әгәр без рус һәм татар телләрендә янәшә яши торган күп кенә сүзләрне чагыштырсак, татар телендәге нечкә сузыкларның активлыгын ачык күрербез. Мәсәлән, баран — бәрән, бревно — бүрәнә, капуста — кәбестә, коза-кәҗә, мак-мәк һ. б. Татар

---

[1] Г. Кандалый. Шигырьләр. Казан, 1960 ел, 97 бит.
[2] Лотфи Яфаров. Татар теле үсештә. Казан, 1955 ел, 67 бит.

телендә нечкә әйтелешле сузыкларның активлашу тенденциясен күрсәткән мисаллар топонимика өлкәсендә дә күп очрый. Мәсәлән, Москваны без Мәскәү дип йөртәбез, Татарстанның Сарман районындагы Языково, Останково дигән рус авылларын татар халкы Язикәү, Әстәнкәү дип йөртә.

Билгеле булганча, кеше тирәнрәк сулаганда, эчкә суланган, шулай ук эчтән сулап чыгарылган һаваның күләме арта, сулыш процессында катнашучы органнарның хәрәкәтләре һәм деформацияләре дә катлаулана. Үз чиратында бу хәл сулыш алу өчен сарыф ителгән энергия һәм вакытның микъдары артуга сәбәп була. Калын сузыкларны әйткәндә, сулыш нечкә сузыкларны әйткәндәгедән тирәнрәк була. Моны исбатлау өчен калын һәм нечкә иҗекләрдән генә торган **ала, әлә; кала, кәлә; кулы, күле; җырлый, җирли** сүзләрен тыныч кына, бер үк көчәнеш белән, берсе артыннан берсен әйтеп карау да җитә.

Авыз куышлыгына күчеп, мисал өчен **бала** һәм **били** сүзләрендәге **а** һәм **и** авазларының әйтелү механизмнарына күз салыйк. Бала сүзендәге **а** ларны әйткәндә, били сүзендәге **и** авазларын әйтүгә караганда аскы ияк ныграк түбәнәя, авыз куышлыгының күләме зурая, иякне йөртүче мускулларның хәрәкәтләре дә көчлерәк була. Физикадан билгеле булганча, бу хәл нечкә сузыкны әйтүгә караганда күбрәк энергия, күбрәк вакыт сарыф итүне сорый.

Шуны да әйтергә кирәк: нечкә сузыкларның активлашу тенденциясе һәрвакыт һәм һәр җирдә үзен күрсәтә алмый. Киресенчә, билгеле шартларда калын сузыклы сүзләрне кулланырга кирәк була. Әмма сузык авазларның үзара алмашынулары сүзләрнең эчке мәгънәләренә кагылмаска — аларны үзгәртмәскә тиеш. Менә бу кагыйдә дә калын әйтелешле сүзләрнең нечкәгә күчүләренә тоткарлык ясый. Мәсәлән, **ат** сүзен **әт** сүзе, **ала** сүзен **әлә** сүзе белән алмаштырып булмый: сүзләрнең эчке мәгънәләре бозыла.

Тартык авазларның үзара алмашынулары мәсьәләсенә карата профессор Латыйф Җәләй болай дип язды: «Икенче төрле әйткәндә, яңгыраулар тавыш бирү ягыннан, саңгырауларга караганда, ипләшә төшкән авазлар санала алалар. Менә шушы хәлдән чыгып, бәлки саңгыраулар борынгырак, яңгыраулар чагыштырмача соңгырак дип әйтергә була торгандыр»[1].

Латыйф Җәләйнең бу карашын Лотфи Яфаров конкретлаштыра. Ул бу турыда: «Татар телендә, шул ук вакытта башка төрки телләрдә дә, саңгырауларның яңгыраулаша баруы эпохалар буена килгән үсеш, үзгәреш һәм камилләшү процессы буларак, телдәге күп кенә тарихи фактлар белән исбатлана»[2],— дип яза.

Ләкин борынгы һәм иске әдәби телебездә мәсьәләнең бу рәвешчә куелышын расламый торган мисаллар да аз түгел. Мәсәлән, «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында **дора, әйдер, зиба, дөшәр, дагы** формасында кулланылган сүзләр хәзерге әдәби телебездә: **тора, әйтер, зифа, төшәр, тагы** рәвешендә йөриләр. Бу мисалларда саңгырау тартыклар яңгырауларны алмаштырганнар. Шуны да әйтергә кирәк, тартык авазларның үзара алмашынулары саңгырау һәм яңгыраулар арасында гына чикләнеп калмый; андый алмашынулар саңгырау тартыклар белән саңгыраулар, яңгырау тартыклар белән яңгыраулар арасында да була. Борынгы һәм иске әдәби телебездә мондый мисаллар күп. Г. Кандалый бер урында хәзерге **үпкәлисең** сүзен **үфкәлисән** дип, ә икенче урында **калфак** сүзен **калпак** дип яза. Беренче очракта **п** авазы **ф** авазын алмаштырган булса, икенче очракта **ф** авазы **п** авазын алмаштыра. Бу күренеш **д** белән **т** авазлары арасында аеруча еш очрый. Тартык авазларның үзара алмашынулары — гаять дәрәҗәдә катлаулы, шуның белән бергә, аз тикшерелгән мәсьәләләрнең берсе әле. Бу алмашынуларны да минималь гамәл принцибыннан чыгып тикшерергә кирәк.

Сөйләгән вакытта катлаулырак хәрәкәт, катлаулырак деформация таләп иткән авазларны әйтү тел өчен авыррак була. Теле яңа гына ачылып килә торган кайбер балалар **р** авазын әйтә алмыйлар, аны **л** белән алмаштырып, **барам** урынына **балам, китерәм** урынына **кителәм, утырам** урынына **утылам** дип сөйлиләр. Бу күренеш тел-

---

[1] Латыйф Җәләй. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан, 1954 ел, 71 бит.
[2] Лотфи Яфаров. Күрсәтелгән хезмәт, 64 бит.

нең тиешенчә деформацияләнә һәм хәрәкәтләнә алмавыннан килеп чыга. **Л** авазын әйткәндә, телнең очы элекке (тигезләнү) торышыннан артык ерак китми — өске тешләрнең төбенә генә барып терәлә. **Р** авазын әйткәндә, телнең очы каты аңкауга йомшак кына терәлә һәм ул периодик рәвештә аңкаудан аерыла — калтырап тора[1].

Шул рәвешчә, тартык авазларның үзара алмашынуларында билгеле юнәлеш: саңгырау тартыкларга карата яңгырау авазларның гына актив булуы кебек күренеш юк дип әйтә алабыз. Тартыкларның үзара алмашынулары һәр юнәлештә булырга мөмкин. Конкрет шартларда әйтелүе өчен азрак вакыт, азрак энергия таләп иткән тартыклар, әйтү өчен күбрәк вакыт, күбрәк энергия таләп итүче тартыкка карата активлык күрсәтәләр — аны алмаштыралар.

У. Ш. Байчураның тикшеренүләреннән без тартык авазларның әйтелү дәвамы аларның чолганышларына карап йөрүен беләбез[2]. Шуннан чыгып, бер үк авазны әйтү өчен сарыф ителгән энергия дә авазның чолганышына карап үзгәрә дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Шунлыктан бер чолганышта актив булган тартык аваз икенче чолганышта активлыгын югалтырга мөмкин. Мәсәлән, алмашынулары ике яклы булган **д** һәм **т** авазларының артикуляцион базалары бер-беренә бик якын урнашканнар һәм аларны әйтү өчен сарыф ителгән энергия һәм вакыт арасында да аерма бик аз. Шунлыктан бу авазларның фонетик чолганышында булган бик кечкенә үзгәреш аркасында да тел бер авазның артикуляцион базасыннан икенче аваз базасына җиңел генә күчә ала. Борынгы әдәби телебездә **дәгел, датлы, дырнак** формасында йөртелгән сүзләрне без хәзер **түгел, татлы, тырнак** рәвешендә кулланабыз. Шул ук борынгы әдәби телебездә **тиде, түрт, тәкый** формасында кулланылган сүзләр хәзерге әдәби телебездә **диде, дүрт, дәхи** рәвешендә йөртеләләр. Бу очракта **д** авазы **т** гә карата актив булып киткән.

Артикуляцион базалары бер-беренә шулай ук якын булган **м** һәм **б** тартыкларына карата Латыйф Җәләй: «Бу авазларның артикуляцион базалары бер-берсенә бик якын. **М** иреннәрнең бикләнүе, **б** исә, киресенчә, бикләнгән иреннәрнең кинәт ачылулары белән ясала»[3], — дип яза. Әдәби телебезнең камилләшү процессында **м авазы б** авазына карата үзенең активлашу тенденциясен шактый нык күрсәтә. Мәсәлән, Г. Кандалыйның «Бән һәм сән» дигән шигырендә түбәндәге строфа бар:

**Сәне анда, бәне бонда яратты,**
**Бәне саңа, сәне баңа каратты**[4].

Бу строфаны хәзерге әдәби нормага җайласак, ул түбәндәге төсне алыр иде:

**Сине анда, мине монда яратты,**
**Мине сиңа, сине миңа каратты.**

Безнеңчә, бу ике аваздан берсенең активрак булуы аларның барлыкка килү механизмына бәйләнгән. **Б** авазын әйткәндә, йомык иреннәр кинәт кенә ачыла да, авыз куышлыгындагы һава чагыштырмача зур көч белән атылып чыга, тыштагы һавага чагыштырмача зур басым ясый. Бу каршылыкны җиңәр өчен сөйләүче энергия сарыф итәргә тиеш була. **М** авазын әйткәндә, иреннәр йомылып, тигез генә килә торган һава агымының юлын каплыйлар, аның зур өлешен борын куышлыгына җибәрәләр.

Әдәби телебезнең тамыры еракка — кабиләара телгә барып тоташа. Кабиләара телдән күчкән сүзләр арасында тышкы формалары үзгәреп, аерым авазлары, аваз төркемнәре ташланган яки аваз төркемнәре әйтергә җиңелрәк кисәкләр белән алмашынган сүзләр дә шактый күп очрый. Шушындый ук хәл борынгы һәм иске әдәби телебездән күчкән сүзләр арасында да күзәтелә. Әдәби телебезнең үсү һәм камилләшүендә зур урын тоткан бу күренешкә тел белгечләребезнең дә игътибары көчәйгәнлек сизелә. Мәсәлән, В. Х. Хаковның «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» дигән монографиясендә бу мәсьәләгә зур урын бирелгән.

Чыннан да, мәгънә аңлату ягыннан әһәмияте булмаган аваз һәм аваз төркемнәренең сүздән ташлануы — сөйләү процессын җиңеләйтүгә, телебезне камилләшүгә алып

---

[1] В. А. Богородицкий. Введение в татарское языкознание. Казан, 1953 ел, 33 бит.
[2] У. Ш. Байчура. Звуковой строй татарского языка. Казан, 1961 ел, II кисәк, 49—122 битләр.
[3] Л. Җәләй. Күрсәтелгән хезмәт, 68 бит.
[4] Г. Кандалый. Шигырьләр, 55 бит.

барган көчле чараларның берсе. Монголлар һөҗүменә кадәр Идел, Кама буйларында яшәгән төрки кабиләләрнең тел үзенчәлекләрен чагылдырган төркичә-гарәпчә сүзлектә **йомыртка, уклагу, бузагу**[1] формасында кулланылган сүзләр хәзерге әдәби телебездә **йомырка, уклау, бозау** рәвешендә язып һәм әйтелеп йөртеләләр.

Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Г. Кандалый шигырьләрендә кулланылган **берлән, иркән, дугъмаз, тугъры, егълау** сүзләре хәзерге әдәби телебездә **белән, икән, тумас, туры, елау** формасында йөртеләләр. Бу очракта да **р, гъ, л** авазларының ташлануы, сүзләрнең эчке мәгънәләренә зарар китермәгән хәлдә, сөйләмне җиңеләйткән, телгә нәфислек биргән.

Борынгы һәм иске әдәби телебездән күчкән сүзләр арасында аерым авазлар гына түгел, аваз төркемнәре, кушымчалар ташланган яки үзгәртелгән сүзләр дә күп очрый.

Г. Кандалыйның «Күрешербез микән?» шигыреннән ике юл китерик:

**Һаваң зур тотма, сындыргыл,**
**Ки бер җанымны тындыргыл.**

Бу строфадагы **сындыргыл, тындыргыл** сүзләре хәзерге әдәби телебездә **сындыр, тындыр** рәвешенәдә кулланылып йөриләр. Икенче зат боерык фигыльнең ахырына ялганып, үтенү яки боеру төсмерен көчәйтү өчен хезмәт иткән гыл-гел (кыл-кел) кушымчалары әдәби телебез формалашкан чорда кулланыштан төшеп калалар

Сүзләрдәге аваз төркемнәренең үзгәрүенә мисал итеп, тагын **үкенүбән, күтәрүбән, килүбән, күрүбән, янубән** сүзләрен күрсәтергә мөмкин. Хәзерге әдәби телебездә **үкенеп, күтәреп, килеп, күреп, янып** формасында йөргән бу сүзләрдәге дүрт аваздан торган **убән-үбән** кушымчаларының ике генә авазлы **ып-еп** кушымчалары белән алмашынулары сөйләмгә җыйнаклык бирә. **У-ү** сузыкларының кыска **ы-е** сузыклары белән алмашынулары сөйләүченең вакытына һәм энергиясенә тагын өстәмә экономия ясый. Әдәби телебез нормалашканда кулланыштан төшеп калган **дыр-дер** һәм **тыр-тер** кушымчалары хакында да шуны әйтергә мөмкин. Бу кушымчаның **торыр** сүзеннән килеп чыгуы фәнгә күптән мәгълүм. В. Х. Хаков бу кушымчаның эволюцион үзгәрешен өч баскычлы схема аша бирә: бетә торыр > бетәдер > бетә. Шулай итеп, **җөмләдән тулы бер сүз төшеп кала, ә телгә һич тә зарар килми, киресенчә, ул камиллөшә генә.**

Көндәлек тормышта исемнәрне кыскартып сөйләү, кыскартып язу — киң таралган күренешләрнең берсе. Бала чакта бергә уйнап үскән иптәшләрем арасында Шәрәфетдин, Кәшфеләсрар, Габдеррәүф, Кәлимулла, Әхмәтгали, Хәлиррахман исемле малайлар бар иде. Бервакытта да без аларны тулы исемнәре белән атамадык. Кәшфи, Рәүф, Кәли, Әхмүч, Хәллә дип кенә йөртә идек. Моның өчен алар да, ата-аналары да ачуланмады. Олы яшьтәгеләрнең исемнәрен кыскартып сөйләү гадәте дә гомумхалык арасында киң таралган күренеш. Мисал өчен кайбер әдип, галим һәм артистларның кыскартылмаган исемнәрен китереп үтик: Фәтхи Бурнаш (Фәтхелислам), Мәҗит Гафури (Габделмәҗит), Гадел Кутуй (Гаделша), Зәйни Солтанов (Зәйнелгабидин).

Болай кыскартылган исемнәр сөйләү һәм язу процессын нык җиңеләйтә һәм алар «мулла куйган» исемгә караганда ягымлырак та яңгырый.

Авыл исемнәрен кыскартып-үзгәртеп сөйләүгә дә мисалны күпләп китерергә мөмкин. Мәсәлән, Бикмәт, Әлмәт шикелле торак исемнәре Татарстан территориясендә бик күп очрый. Алар Бикмөхәммәт, Әлмөхәммәт сүзләреннән кыскартылганнар. Кыскарту нәтиҗәсендә кайбер авыл исемнәре шулкадәр үзгәргәннәр ки, хәтта аларның нинди сүздән алынуларын табу да шактый кыен (Зеленодольский районындагы Әҗәле, Сарман районындагы Нөркәй һ. б.). Каюм Насыйриның тикшеренүләреннән без Әҗәле сүзенең Хаҗ Гали дигән кеше исеменнән үзгәртелүен беләбез. Хаҗ Гали дигән сүзне халык кыскартып **Аҗали** дип йөрткән. Сөйләгәндә, җиңеләйтү аркасында Аҗали сүзе **Әҗәлегә** әйләнеп киткән. Нөркәй исеме ул авылга беренче нигез салучы кешенең исеменнән — Нуретдиннән үзгәргән булырга тиеш. Халык Нуретдинне Нуркай дип йөрткән. Заманалар узу белән Нуркай **Нөркәйгә** әйләнгән.

Хәзерге көндә күп сүзләрдән торган рәсми оешма һәм завод-фабрика исемнәрен кыскартып сөйләү, кыскартып язу да киң таралган. Мәсәлән, Кама автомобиль

[1] В. Х. Хаков. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан, 1972 ел, 38 бит.

заводын «КамАЗ», Байкал-Амур магистрален «БАМ» дип сөйлибез һәм язабыз һ. б. Рәсми рәвештә кабул ителгән бу кыскартулар сөйләүче, тыңлаучы, язучы кеше сарыф итә торган энергия һәм вакытны экономияләү максаты белән эшләнә.

Югарыда китерелгән барлык мисаллар телебез кичергән структур үзгәрешләрдә минималь гамәл принцибының чагылышын ачык күрсәтсәләр кирәк.

Әдәби телебез кичергән катлаулы үзгәрешләрнең бик күбесен җиңел генә һәм әйгәзле рәвештә аңлатырга мөмкинлек биргән бу принцип тел белгечләребезнең игътибарыннан читтә калмас, тел белеме өлкәсендәге киләчәк тикшеренүләрдә киңрәк кулланылыш табар дип ышанасы килә.

**Лотфи Яфаров,**
филология фәннәре кандидаты

# ТУКАЙЧА ТӨГӘЛЛЕККӘ

Ритмның гүзәллек хасиятләрен киң төшенеп, шигърияттнең үз кануннары булуын тирән тойган бөек Тукай шигырь үлчәме тигезлеген, поэзиядә сүзнең музыкаль яңгырашын бервакытта да истән чыгармаган. Сүздәге һәр кисәкнең үзенчәлеген эчтәлекне аныклаучы, аңа эмоциональ төс бирүче деталь итеп караган. Шигырьнең ритмик төгәллегенә комачау иткән, мәгънәгә һичбер кимчелек китерми торган иҗекне төшереп калдыру (авылым урынына аулым, әләкми урынына ләкм...), бәйлекне сүзгә кушып язу кебек күп төрле «операция»ләр бер дә икеләнмичә ясала шагыйрь тарафыннан. Тукайда, мәсәлән, көйләгәли, сорсалар, сабаны туйларын, җәмгатенә, торышалар һ. б. бар.

**Уенчылар матур көйләр көйләгәли,**
**Баш өстендә алтын зонтик күләгәли.**
**(«Япон хикәясе»).**

Сөйләшеп, карашып, сорашып формаларын киң аңлаган Тукай «бер-берсенә карашып торалар» сүзләренең мәгънәсен «торышалар» дигән бер сүз белән бирү уңышына ирешкән:

**Беркөн чәй эчкән вакыт, укый Сабит шартлатып,**
**Әти белән әнисе торышалар шаккатып.**

Ягъни шаккатып бер-берсенә карашып торалар дигән сүз ич бу.

Икенче бер әсәрендә шагыйрь:

**Ах, дүдәк-дүдәк-дүдәк —**
**Басма өстендә балүрдәк,—**

дип язып, «балүрдәк» сүзенә мондый аңлатма биреп үтә: «Җырлаганда «бала үрдәк» дип әерып әйтмичә, ике сүзне кушып җибәрәләр», — ди.

Шигъри әсәрнең идея-стилистик характерына комачау иткән, чагыштырмача артык еш очрамый торган ритмик төгәлсезлекләрдән текстны арындыру кыюлыгы шагыйрьләрнең үзләрендә дә, нәшрият работникларында да, кызганычка каршы, әлегә җитенкерәми. Әйтик, М. Җәлилнең 9-9 лы үлчәмендә язылган «Ана бәйрәме»ндә «тибеше» сүзе «тибше», «Алмаз кылычы» дигәндә «кылычы» түгел, «кылчы» булып басылырга тиеш иде. Ә менә «Кылыч» шигырендә исә һәр өч очракта да «кылычын» дип алу дөрес бирелгән.

Тагын бер мисал:

**Күңел тоя, илнең көчле тавышы,**
**Яңгырый һәрбер мылтык атуда.**

10-9 үлчәмендәге «Окоптан хат» шигыренең шушы тезмәләрендә «тавышы» сүзен «таушы», «яңгырый» сүзен «яңрый» дип... «Моабит дәфтәре»ндә шагыйрь үзе язганча бирергә кирәк иде.

Шигырьнең эчтәлеге һәм формасына бер үк дәрәҗәдә әһәмият биргән шагыйрьләр ритм таләпләренә игътибарсыз кала алмыйлар. Әйтик, ритмик төгәллекне күз алдында тотып: күңеле, бәхете, вакыты, тавышы, авылы, утырып... кебек сүзләрнең берәр иҗеген (икенче сузыкны) кыскартып: күңле, бәхте, вакты, аулы, утрып,— дип бирергә кирәк икән, һичшиксез, шулай эшләнергә тиеш тә. Бу күренеш Тукай поэзиясендә аеруча калку төс ала. Һәм ул бу мәсьәләдә дә һәр шагыйрьгә үрнәк булырлык гаҗәеп кыюлык һәм тәвәккәллек күрсәткән олы шагыйрь.

Әсәрнең төп идеясенә кимчелек килми икән, Тукай шигъри гармонияне өстен күргән.

**Ләктереп булмас микән дип бер тагын,**
**Бай чәчәргә башлый юк сүз борчагын.**

Нигә соң сүзләрнең язылыш формасына бу кадәр игътибар(?) диючеләр булыр. Мәсьәлә шунда ки, укучы язуда чагылыш тапкан авазларны, гадәттә, ничек язылган, шулай укырга тырыша. Әгәр җырда, шигырьдә үлчәм тигезлеге сакланмый икән, ул, югарыда әйтеп үткәнебезчә, котылгысыз ритмик төгәлсезлеккә китерә.

Ритмик төгәллеккә ирешүнең практик ягы теория белән дә бәйләнгән. Әдәбият белгече Нил Юзиевның Тукай премиясенә лаек булган «Шигырь гармониясе» китабында бу мәсьәлә шактый киң яктыртылган һәм олы әдәбият белгечләренең уй-фикерләре белән дә дәлилле итеп исбатланган. «Известия» газетасында басылган (1977, № 78) «Телефонная грамматика» исемле мәкаләдә: «Тел нормаларын лингвистлар карарлаштырмый, алар аны тик бәян итә, классификацияли, ә нормалар алар объектив рәвештә урнашалар, тел практикасы процессында халыкның үзе тарафыннан тудырылалар», — диелгән. Һәм моның белән килешәсе килә.

Сүз башында үзе генә дә ачык иҗек ясау сәләтенә ия булган э(ләктереп), ә(ләшеп), ы(шанып) кебек протеза ролендә килә торган сузыклар аерым очракларда бик җиңел төшеп калалар. Бу хәл шигырьдә ритмик төгәллеккә ирешүгә кирәкле шарт тудыра. Ул мөмкинлектән дә Тукай бик оста һәм киң файдаланган: ләктереп, ләкми, ләктерим, ләккән, ләкте формаларын уңышлы кулланган. Шагыйрь ритм һәм рифма төзеклеген күз уңында тотып, «өчен» бәйлеген дә еш кына «ө» сузыгыннан башка кулланыны мөмкин санаган. Ә бу исә шигъри әсәрнең музыкаль яңгырашына көч өстәп җибәрә:

**Кайгысы безнең песинең тик бары шул нәрсәчен,**
**Күзләре булган тишәрлек һәр караган нәрсәсен.**

Егерменче еллар татар шагыйрьләренең шигырь төзелеше турындагы уй-фикерләрен, бу юнәлештә эзләнү, бәхәсләшүләрен искә төшереп, шагыйрь Хәсән Туфан: «... нинди генә тәҗрибәләр ясасак та... ритм дигән нәрсәне ташлап китә алмадык. Кайбер юлларның кыскартылган яки озынайтылган булуына карамастан, һәркайсының нигезендә билгеле бер ритм бар»,— дип язды. Әйе, шигырь кануннарына буйсынып, ритмик төгәллеккә игътибарлы иҗат итәлгән шигырьләрдә дә юлларның озынайтылган яки кыскартылганнары булгалый. Ләкин анда-санда очраган ул арттыру-киметүләр ритмлы шигырь системасын барыбер бозмый, җимермиләр.

Тукай томнарының яңа басмасын (1975—76) хәзерләгән иптәшләрнең бу юнәлештәге уңышлары аеруча куанычлы. Мәсәлән, элекке басмалардагы **үзенне үзең** сүз тезмәсе хәзер, ритмик төгәллек таләбен искә алып, **үзеңнүзең** дип бирелгән. **Исеме, бакча эчендә** сүзләре дә **исеме, бакчаэчендә** формасында языла. Эчтәлекнең шигъриятенә куәт бирүче мондый мисалларны әле байтак китерергә мөмкин булыр иде. Әмма кайбер төгәлсезлекләргә дә әле урын калдырылган. Әйтик, нәрсәчен түгел, нәрсәчен кирәк иде. Тукайда тутасычен формасы бар бит инде.

Мәгънәгә кимчелек китерми, әйтелеш-ишетелешкә җайсызрак килгән артык иҗекне кыскарту белән генә чикләнмичә, җитешмәгән очракта берәр иҗек өстәү кебек кыюлыкларны да Тукай нигезле итеп, икеләнмичә эшләгән. Шагыйрьнең төрле әсәрләреннән берничә юлны гына искә алыйк:

**Инде л ә к м ә м, җәйгә дә һәм кышка да...**
**Кайт әле монда ватанга, кайт әле, с а р г а й т м а л е...**

**Күп тә үтми, бу бала куйды тәмамлап д ә р с е н е...**
**Бу авылның мин җыен, мәйдан, с а б а н ы т у й л а р ы н...**

Инде бүгенге татар поэзиясе үрнәкләренә игътибар итик (текст эчендәге җәяләрдә, безнең карашыбызча, мөмкин булган вариант китерелә):

**Шигъриятнең лирик миллəтеннән,**
**Бер каннандыр безнең бу җаннар...**
**Менә шулай сагына (сагна) бу айларда**
**Хәсәнегез сезне, туганнар.**
**(Х. Т у ф а н).**

**Берлинда дуслык йортында**
**Уйлап-уйлап таң калдым,**
**Тагын да көчлерәк яңгырый (яңрый)**
**Җыры читтә татарның.**
**(С. Х ә к и м).**

**Аптырады шагыйрь мескен,**
**Тема тапмый язар өчен,**
**Тәнкыйть диеп, фәлән диеп,**
**Инде борынын (борнын) кая төртсен!**
**(Г. А ф з а л).**

**Дан безнең кызларыбызга,**
**Гөл сибик юлларына,**
**Эшләре яңгырар (яңрар) аларның**
**Безнең ил җырларында.**
**(Н. И с ә н б ә т).**

**Яңгырый күк әле дә (әл дә) Алатауның**
**Кар каплаган биек сыртлары:**
**Каршы алып бөек көрәш давылын (даулын)**
**Ачыла күп кыргыз йортлары.**
**(Н. А р с л а н о в).**

**Җырны кирәк дәртле яңгыратырга (яңратырга)**
**Табыннарда һәм дә туйларда.**
**Җыр өйрәтә матур яратырга,**
**Җыр өйрәтә матур уйларга.**
**(З. Н у р и).**

**Мин ахры (ахрысы) сабыйлыктан —**
**Шигырьдән китә алмамдыр (китәлмәмдер).**
**Сине беркайчан да тулы**
**Бәхетле итә алмамдыр (итәлмәмдер).**
**(Р. Ф ә й з у л л и н).**

Әйтергә теләгәнебез прогрессив процессны тану омтылышыннан бүтән нәрсә түгел. Шигърият закончалыкларына тәңгәл килешендә **яңгырар**, **ыңгыраша** сүзләре **яңрар**, **ыңраша** дип (М. Җәлил); **Минзәлә**, **тәрәзә** сүзләре Минзәл, тәрәз дип (Х. Туфан); чөнки, әле дә, кадрен, барсын сүзләре **чөн**, **әл дә**, **кадрене**, **барсыны** дип (Г. Тукай) кулланылган икән, нигә бу шигъри принцип бүген онытылырга тиеш соң әле?

Әлбәттә, бер үк сүз төрле вариантта да кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, М. Җәлилдә **яңгырау** сүзе, шигырь таләбе буенча **яңгырау** булып та, **яңрау** формасында да килә.

**Яңгыра, җыр, хаклык байрагының**
**Утлы сүзе булып һавада. («Ә й д ә, җ ы р ы м»).**
**Бокалларның көмеш чыңы белән,**
**Табын җыры яңрар тагын да. («С у г ы ш т а н с о ң»).**

Шагыйрь Х. Туфанның «Кояшлы» циклына кергән шигырьләреннән «Онталмасам нишләрем» әсәре дә ритмик төзеклеге ягыннан игътибарга лаеклы:

**Мин дә әйттем аңа сүзсез генә,**
**Ул да әйтте сүзсез хисләрен:**
**— Сине менә гомрем буйларына**
**Онталмасам әгәр, нишләрем...**

10-9 лы үлчәмгә корылган бу шигъри юлларда тулы ритмик төгәллек бар. Г. Тукай иҗатында шактый киң урын тапкан әлеге шигъри чара татар поэзиясенә гомумән хас күренеш. Халык җырларына яисә әдәбиятыбыз тарихында урын алган шагыйрьләребезгә генә игътибар итик.

**Чөнки ярды ирсә балык карныни,**
**Тыңла, гакыйль, имди таңере соңгыни** [1].
**Хак зиядә кыйлыр аның малыни,**
**Ахирәтдә хуш кыйлыр әхвалени.**
**(XVI йөз шагыйре Мөхәммәдьярдан).**

**Оер** [2] **юлдашиның анда йөзини,**
**Чебен басмыш тәмам ике күзини.**
**Ишетди Казый чөн аның сүзини,**
**Күреб рәхме әйләде** [3] **чыкмыш күзини.**
**(Һибәтулла Салиховтан, XIX йөз башы).**

Чагыштыру өчен Тукайдан да тагын бер строфа китерик:

**Бик тынычлап сайрагыз сез, мин тимим сезгә, тимим,**
**Әллә иркендә торуның кадрене белмимме мин!!**

Сәнгатьтәге каршылыклар — иске сыйфат торышыннан яңа сыйфат торышына күчү, күркәм традицияләрне дәвам итү — шагыйрьләрнең үз кыюлыкларына тапшырылган. Әйтик, кара урман, бардымы икән, Минзәлә миләше, ышанып, озатып, әлекми, әйтә алмадым, йөзә аласыңмы кебек сүз һәм сүз тезмәләрен шагыйрь кирәктә: карурман, барды микән, Минзәл миләше, шанып, затып, ләкми, әйтелмәдем, йөзәләсеңме формасында бик иркен, бик хуш күреп яза ала. Чөнки поэзиядә һаман дәвам итеп килгән бу прогрессив процесс татар шигырь төзелешенең закончалыклы тенденциясе булып та яшәп килә. Мисал-фактлар белән расланган объектив закончалыклар исә тәнкыйтьчеләр тарафыннан да яклау табарга тиешләр. Закончалыклы тенденцияне белеп, аңлап, аңа җәмәгать фикерен җәлеп итү зарур.

Ритмик төгәллеккә омтылыш Тукайда гына түгел, замандаш шагыйрьләребез иҗатында да бик еш үзенең чагылышын таба һәм шигърияттә ул нәфислек көчен ачыктан-ачык гәүдәләндерә. Югарыда китерелгән мисал-фактларда орфография кагыйдәләренә каршы килгән яки кагыйдәгә сыймаган бер генә очрак та юк бит. Әлбәттә, бүген үз яңгырашын тулысынча канәгатьләндергән **гайрәт, курыкмыйм** сүзләрен, хәтта классик шагыйрьләрне күчергәндә дә, **гъәйрәт, куркъмыйм** формасында язу һични белән дә акланмый, яклана да алмый. Сүз мондый бозулар турында бармый.

Процесс дәвам итә, дидек. Шул уңайдан тагын берничә сүз.

1976 елның язында Р. Риановның «Агыйделгә бер сүзем» дип исемләнгән шигырен укыган идек. Анда мондый юллар бар:

**Әгәр суы мул булмаса**
**Ул Идел — Иделмени!**
**Син дә Караиделдән башка**
**Ак булыр идеңмени!!**

Әгәр монда Кариделдән дип кенә бирелгән булса, «Караиделдән» варианты безнең алга сикәлтә булып килеп басмас иде.

Күптән түгел басылып чыккан «Бер ананың биш улы» повестында исә («Казан утлары», 1977, № 9) Хәсән Сарьян башкача яза: «Каридел бик котыру елга икән... Аны Каридел белән Агыйделнең һәр борылмасын белә дип сөйләделәр». Хәтта эпик әсәрдә дә, үз урынында килгәндә, «Каридел» матур яңгырый икән лә.

---

[1] Соңгыни — көчен.
[2] Оер — йоклаган.
[3] Рәхме әйләнде — кызганды.

## «НУЖА КАЛАЧ АШАТА»

Бер уйлаганда нужа сүзенә тукталуның хаҗәте дә юк шикелле. Гадәттә, бу сүз татар теленә рус теленнән килеп кергән дип санала. Бәлкем ул шулайдыр да, тик бу очракта без сүзнең беренче мәгънәсен ачыкламакчы булабыз. Татарча-русча сүзлектә нужа сүзенә карата аңлатма бирелгәннән соң **«Нужа калач ашата»** дигән мәкаль дә китерелә. Тик ничек итеп нужа калач ашата икән соң? Элекке заманда берәү авыр тормыш кичерсә, **«Әй, нужа чигә лә»** диләр иде. Менә бу «нужа чигә» сүзе астында бер-бер яшерен мәгънә ятмый микән? 1407 елгы рус елъязмасында без «...христиан ведящь с нужею повязавший» дигән гыйбарә очраттык. Менә моннан инде «нужа»ның башта нинди мәгънәдә кулланылуы аңлашыла төшә. Нужа башкача — бау, аркан дигән сүз. Элек Идел, Ока, Кама, Сура, Дон, Урал елгалары буйлап бурлаклар «нужа»га бәйләп көймәләр тартып йөргәннәр, «нужа чиккәннәр». Барып җитә алганнары, получка алгач, «калач ашаганнар». Менә кайдан килә икән ул — «Нужа калач ашата».

Нужа сүзе кала исемендә дә очрый. Археологлар әйтүенчә, Сура елгасы буенда борынгы заманнарда Нужавар исемле калачык булган. Бу исем нужа һәм вар сүзләреннән барлыкка килгән. («Вар» кисәкчәсе элекке кала исемнәрендә һәм хәзерге Венгрия шәһәрләре исемнәрендә еш очрый. Безгә мәгълүм X йөз Болгар патшасы Әлмушның ләкабе Билгевар булган. Күрәсең, нужа сүзе бик ерак гасырлардан килә. Нужавар да, ихтимал, Идел, Ока, Сура буйлап мал-товар ташучы көймәләрнең тораk урыны, пристане булгандыр. Көймә хуҗалары тирә-яктагы халыкның малын, угыл-кызларын су буйлап ерак илләргә сатарга алып киткәннәрдер. Һәм шуңа күрә бу урын көймәчеләр, лямка тартучылар, нужа чигүчеләр, «калач ашаучылар» атамасын кабул иткәндер.

Күренә ки, бер сүз күпме юл үткән, күпме мәгънәдә йөргән һәм халыкның үткән тарихыннан күпме нәрсәне аңларга ярдәм итә.

**ӘХМӘД БУЛАТОВ.**

## ЧӨЙГӘНЕ ШОҢКАР БУЛГАН...

Дәрдмәнд читтән сүз алырга яраткан дип язалар кайбер галимнәр [1]. Телгә колорит бирер өчен шагыйрьгә, ихтимал, ятрак сүзләр дә кирәк булгандыр. Әмма җентекләбрәк күз салганда, шагыйрь әсәрләрендә очрый торган шундый күп кенә сүзләр онытыла төшкән татар һәм гомум төрки сүзләре булып чыга. Берничә мисал китерик.

Дәрдмәнднең бер шигырендә шундый юлларны укыйбыз:

**Менгәне толпар икән, ди,**
**Чөйгәне шоңкар булган.**

---

[1] Дәрдмәнд. Сайланма әсәрләр. Кереш сүз. Казан, 1959 ел.

Бер карасаң, бу юллар борынгы чорларга, ата-бабаларыбызның ат менеп, өйрәтелгән бөркет яки лачын белән киек-җәнлек аулап йөргән заманнарга алып китә сыман. Чыннан да, Идел белән Урал якларында инде хәзер шоңкар чөймиләр, сунарның бу төрен дә очратып булмый. **Шоңкар** сүзе үзе дә актив кулланылыштан төшеп, тарих истәлекләре сәхифәләрендә генә калган дияргә мөмкин. Ә шулай да кайсы дәверләргә кадәр килгән соң бу сунар кошларын асрау, өйрәтү гадәте? Һәм, хосусан, шагыйрь Дәрдмәнд ул сүзне кайдан алган һәм шоңкар чөюгә аның нинди катнашы булган? Булган икән шул.

С. Кириков дигән рус натуралисты шагыйрь яшәгән Юлык авылы хакында 1928 елга карата менә ни дип яза:

«...Кананикольскига[1] таүге килүемдә үк Михаил Степанович һәм Әпсәләмнән[2] татар авылы Юлыкта кышын зур ярминкә булуын, анда сунар кошлары сатылганны ишеткән идем.

— Ярминкә үтмәдеме әле? — дип сорадым мин юлда Әпсәләмнән.

— Юк әле. Ун көннән ачыла. Ә нигә сорыйсың?

— Барып күрергә телим. Нинди кошлар саталар икән?

— Бөркет саталар. Лачын, карчыга, әтәлге була. Элек кошны күп китерәләр иде. Хәзер әз. Бөркет, лачын өйрәтүне халык онытып бара».

«...Юлык, Эткол шикелле үк, Урал артында урманлы далада ята. Тирә-якта сырт, үрләрдә каен кулкалары[3] аралаш болынлык, игенлек. Юлыкта бөтен ихаталар сатарга китергән печән, мал-терлек белән тулган. Һәр өйдә — килгән кеше. Кунар урын көчкә табылды. Иртән ярминкә шаулый башлады. Күбрәк башкортча сөйләшәләр. Ләкин шунда ук руслар, татарлар, мордва, казакълар сөйләше ишетелә. Кошлар сатылган урамда хәтта үзбәкләр, төркмәннәр бар.

Бик ерактан, үзбәкләр — Әндиҗаннан, казакълар — Әмба елгасы башыннан, төркмәннәр — Ургенечтән Юлыкка баулы кош алырга килгәннәр.

Юлдашым, кош хакын игенгә әйләндереп, аңлатып бирде: «Ике бөркет — бер йөк бодай. Лачын, карчыга — берәр капчык он».

Ул чакта кошларның кыйммәтлегенә гаҗәпләнгән идем, соңыннан нигә бик ерактан Юлыкка кош алырга килүне аңладым. Төркмәннәр яхшы бөркеткә дөя биргәннәр икән»[4].

Димәк, Юлыкта — Дәрдмәнд өч яшәр бала чакта килеп, өч дистә елдан артык торган татар авылында — ау-сунар кошларын яхшы белгәннәр. Шагыйрьнең кордашлары, аны күргән кешеләр, мәсәлән, Әдһәм ага Чанышев[5], Дәрдмәнднең әтисе Садыйк картның һәм Закирның кулбашка, ияр кашына, күн бияләйгә кош кундырып ауга чыгуларын да беләләр. Бәс, шулай булгач, «шоңкар чөю»не шагыйрь яхшы белгән һәм бу сүзне ул «читтән» алмаган.

Казакъ, кыргыз, башкортны әйткән дә юк, шоңкар сүзен уйгурлар, үзбәкләр, төркмәннәр һ. б. да белә. Алар аны **сунгур** диләр. Белми ни, күктән төшкән түгел лә ул. Ак лачынның иркәге. Ана кош икән — әтәлге булыр. Юлыкта әтәлге дә булганын әйтә бит Әпсәләм карт.

> **Көн кызды, кызды һава монарланып.**
> **Сагымлап кыр белән дала чобарланып.**
> **Һава тымык — шылт итми!.. Кысылды тын:**
> **Яңгыр көтә җирнең йөзе комарланып...**
> **Күренде күк йөзендә кара болыт,**
> **Болганып гайрәт белән уҗарланып.**

Кайбер тикшеренүчеләр бу шигырьдә парадокс бар дип уйлыйлар[6]. Имеш, татарча язылса да, татар аны аңлап бетерми. Дөрес, монда, бүгенге күзлектән карасаң, ятрак тоелган сүзләр юк түгел. Ләкин менә **комарлану** сүзе татарда әле дә

---

[1] Уралда элекке заводтан калган авыл.
[2] Эткол авылы сунарчысы.
[3] Далада кечкенә урман.
[4] С. В. Кириков. «Көньяк Урал урман һәм далаларында». Зоогеограф язмалары. Мәскәү, 1953 ел, 22 бит.
[5] Ул хәзер Сибай шәһәрендә яши.— Автор.
[6] Ә. Харисов. «Башкорт халкының әдәби мирасы». Уфа, 1966 ел, 42 бит.

кулланыла. Ул сүзлекләргә кергән. Элек-электән халык телендә яши. Әдәби телдә хан заманнан бирле йөри. «Әйтик, үткән йөздә шундый мәҗлесләр хорырга бер бик комар кеше үз заманының берничә шагыйрен чакырган», дип яза Н. Исәнбәт[1]. Академик В. Радлов аның байтак төрки телләрдә булуын әйтә[2]. Әлеге шигырьдә ул «бик теләп», «сабырсызланып», «азартланып» мәгънәсендә килә.

**Сагымлап, сагым** (чагым)да бер Көньяк Урал сүзе генә түгел. Казакъ, кыргызда да ул **сагым** рәвешендә кулланыла. Төркмәндә — салгым, кумыкта — салгын булып, рәшә, томса һава дигәнне белдерә. Мираж булган төбәкләрдә шул мәгънәне дә үз эченә ала.

**Тымык** та тымызык формасында татар телендә актив кулланыла торган сүз. **Монар** сүзен башкортныкы дип әйтергә мөмкин. Ләкин Оренбург татарлары аны әллә кайчан үзенеке иткән. **Ужарланып** — гомум төрки сүз. Башкорт әдәби телендә ажарлану формасы кабул ителгән. Төректә бу сүз ажар калыбында күренә. Бу «Яңгыр» исемле шигырьдә астарак янә ике чит сүз бар :«Күк селкенеп украна», «Мал чулашып уртага алып балаларын...» ди классик.

**Украналы** башкорт һәм татар сүзлекләреннән табып булмый. Шагыйрьнең җыентыгында «борынгы үзбәк телендә ат кешнәвен аңлата» диелгән. Уйгур телендә уакъыраш — аваз салу, елау, кычкыруны белдерә. Кыргызда окурануу — акрын гына ат кешнәү була. Димәк, бу сүз безгә бик яхшы таныш булган акыру-бакыру (уакыру-уакырыну) тамырыннан булып чыкмыймы соң? Шагыйрь бу сүз аша күкнең яшеннән чыңлап китүен, күк күкрәвен әйтә.

**Чулашу** сүзе төрки телләрдәге сүзлекләрнең берсендә дә юк бугай. Ләкин, һәркемгә билгеле, бер тел дә сүзлеккә сыймый. Ниндидер сөйләштә ул, мөгаен, «куркышып» дияр төштә булгандыр. Бу сүзгә охшаш кыргыз сүзе «чогулуу» бергә җыйналу-туплану дигәнне аңлата.

Иң ахырдан әйтик инде, бу шигырьдә парадокс юк. Үз вакытында ул яхшы аңлашылган. Әмма аңарда хәзер башкорт та, татар да аңламаган, искергән сүзләр бар. Бу — шигырьнең кыйммәтен киметми, чөнки «укымастан элек барып җитү», бик җиңел аңлашылу — әсәрнең бердәнбер кыйммәте түгел.

**ЙОСЫФ ГӘРӘЙ.**

≈≈≈≈≈≈

---

[1] «Г. Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында» дигән мәкалә. «Казан утлары», 1976 ел, 4 сан, 129 бит.
[2] «Төрки сөйләшләр сүзлеге тәҗрибәсе». Икенче том, 945 бит.

# ДӨНЬЯНЫҢ ГАМЬНӘН БАШКА ЯМЕ ЮК

Язгы ташуларда
Аккан бозга басып,
Икәү килә елга буйлатып,
Берсе җырлый шашып,
Изүләрен ачып,
Икенчесе килә уйнатып:
— Сау булыгыз, кызлар,
Сагынырсыз, кызлар...

Гаҗәп самими бу җыр. Ярсулы. Кыю. Аккан бозлар кебек шаулап-гөрләп үтә дә, якты бер моңсулык тарата. Ачык тәрәзәләрдән яз җиле сыман ургылып керә дә, күңел гөлләрен уята.

Көен кем язгандыр, җырын белмәгән кеше юк. Шигъри сүзнең чынын, асылын халык үзе сайлап ала. Сайлап ала, җыр итә, мәңгеләштерә. Күрәсең, шагыйрьнең халыкчанлыгына иң беренче үлчәү шулдыр.

Илдар Юзеевның поэмаларында да көе-моңы саркылып торган, җыр булып канат чыгарган юллар аз түгел.

Димәк, «башыннан ахырына чаклы яшьлек турында» җырлап мәйданга кергән шагыйрь бүген дә яшьлек җырчысы булып кала? Әгәр яшьлек җыры дигәнебез киң мәгънәсендә кешегә һәм тормышка мәхәббәт турында икән, бу — чыннан да, шулай.

**Сибгат Хәким: «Безнең революцион традицияне бүген дәвам итүче яшьлек — Юзеев иҗатының төп рухы. Мин аның әсәрләренең менә шушы сау рухын, оптимистик зур рухын яратам».**

Илдар Юзеев шигърияте, заман һәм, гомумән, яшьлекнең үзе кебек үк үсеш-үзгәрештә. Бу аның соңгы җыентыгы белән танышканда да күренә[1]. 25 еллык иҗатыннан аерым үрнәкләрне бер җепкә теркәгән әлеге басма Юзеев иҗатының «гомер боҗраларын» азмы-күпме күзалларга мөмкинлек бирә һәм аның асылда ябалдашка түгел, тамырга үсүе, ныгуы турында сөйли. Әлеге үсеш хис-кичереш муллыгыннан — рух-җан диалектикасына, уй-мөнәсәбәт аныклыгыннан — фикерне пар канатлы, табигый офыклы итүгә юнәлгән.

Тагын шунысы бәхәссез: Илдар Юзеев шигырьләренең мең халәтне берләштергән табигатендә бер фасыл өстенлек итә. Яз. Кайнар хисләр һәм сафлык-садәлеккә омтылу фасылы, яңару-дәвам һәм мәңгелек белән очрашу фасылы. Менә шунда, шушы лейтмотивта — шагыйрь иҗатының тәкәнмәс рухы.

Шагыйрьнең җырына күчкән дөньяны шүрлекләргә аерып, кысаларга тутырып булмый. Әйе, Илдар Юзеев иҗаты, асылда, яшьлек һәм тормыш-яшәеш, ватандарлык һәм тынычлык турында. Әмма бу темалар арасында кискен чикләрне аеру мөмкин түгел. Иң мөһиме, шагыйрь шигырен саегудан, вакланудан саклый, нинди генә дулкында язмасын, үзәккә кеше язмышын, табигать баласы язмышын куя.

Кеше — кодрәтле көч,
Кеше — алла — тиңсез.
Юк, мин китмәм Җирдән,—
Дөнья нишләр минсез!

Юзеевның лирик герое тормышның төрле өлкәләренә үтеп керергә, аны бөтен катлаулылыгы белән аңларга омтыла. Шагыйрь күңеле заманның җиде җиленә, барлык үзгәрешләренә ачык. Аңа тарихның мәңгелек мизгелләрендә үз урынын билгеләргә, үз максатын һәм таяну ноктасын табарга кирәк.

[1] Илдар Юзеев. Өзелмәс кыллар. Шигырьләр, җырлар, поэмалар, балладалар. Казан, 1978 ел.

Бу нисбәттән, Илдар Юзеевның табигать, заман һәм кеше мөнәсәбәтләрен калку итеп куйган «Моң турында баллада», «Бакчачы турында баллада», «Карурман» кебек әсәрләре аеруча игътибарны җәлеп итә. Табигатьне аңлау һәм саклау, әлбәттә, зур проблема, дулкынландыра һәм борчый торган проблема. Әмма шагыйрь цивилизация белән табигать арасындагы каршылыклар турында бәхәсләшү өчен генә сүз алмый. Аның шигъри уйланулары нигезе — кешенең рухи тамырлары туган җирдә диган фикердән башлап, ил-көн, халык язмышы турында гамьгә кадәр. Бит «дөньяның гамьнән башка яме юк».

Мине елга иткән чишмәләрдән
Калмадыммы икән аерылып?..

— ди ул.

Аңлашыла: чишмә янсә карурман — табигатьнең традицион символикасы гына түгел. Шигъри контекстта бу төшенчәләр гаять киң мәгънәгә ия була. Халыкның күңел хәзинәсе, якты рухы, мәңгелек идеаллары — менә ул тормыш һәм иҗатның даими яңарыш чишмәсе, дип раслый шагыйрь. Һәм шул чишмәләр сау булганда гына «мең һәм миллион кыллы зур тормышның» симфониясен «күммәс башка көйләр дулкыны».

Табигать — ул әле туган тел стихиясе дә. Халык иҗаты чишмәсеннән бәрәкәтле һәм игелекле рәвештә файдаланучы шагыйрь тулысы белән шушы хакыйкатькә тугрылыгын дәлилли. Әнә шуңа да Юзеевның күп кенә шигырьләрендә әллә кайдан кычкырып торган гражданлыкны, декларатив тышчалы гражданлыкны күрмисең. Туган ил, тынычлык, табигать турында язганда да, мәхәббәт, бәхет һәм моң-сагыштан торган юлларда да гражданлык шигырь материясе белән берегеп туа. Бәет-дастаннардан ук килүче драматизм заманча фикерләү рәвеше белән кушыла.

Гомумән, Илдар Юзеев — халык иҗаты рухындагы шагыйрь. Халык иҗатының илһамландыручы йогынтысы аның шигырьләрендә традицион сурәт-бизәкләрнең тузаны сөртелгән асылташлар сыман ялтырап китүендә генә түгел. Форма кысалары фикер богавына әверелмәсен өчен стереотиплардан арынырга омтылу да, төптән уйлап караганда, тамырлары белән халыкның җыр-такмазаларына тоташкан. Илдар Юзеев шигъриятендәге ритмик сыгылмалык һәм полифониянең дә чыганагы әнә шунда. Ритм һәм төс контрастлары белән оста идарә итү шагыйрьгә поэтик дөньясын тудыруда бөтенлеккә, ышандыру көченә ия булырга ярдәм итә.

**Эдуардас Межелайтис: «Ал төсләргә манчылган сәнгатьнең бәясе сукыр бер тиенгә дә тормый... Алсу төс — тирәнлек билгесе түгел. Тирәнлеккә кара һәм канлы-кызыл төс аша баралар... Чын сәнгать — һәр вакыт катлаулы сәнгать».**

Мең авазлы шигъри «карурман». Җыентыкны янә бер тапкыр күңелдән кичергәндә, ул әнә шундый булып күз алдына килә. Бу «карурман» аша челтерәп торган «таныш моңнар» үтә. Ягъни, шигъриятебез үсешендә туган мәгълүм яңа тенденцияләр тәэсирендә, үз тәҗрибәсе һәм эзләнүләре нәтиҗәсендә шагыйрьнең тавышы нығыса-көчәйсә дә, ул беренчел нигезләргә тугрылыклы булып кала. Ул үзенең бөтен иҗаты белән, Зур Хакыйкат — мәхәббәт һәм тормыш фәлсәфәсе диган ике «кыл»ның яңгырашы бергә кушылган төштә, дип раслый.

Хис юмартлыгына һәм фикер тыгызлыгына Илдар Юзеев шигырьнең һәр сүзен саллы итү, һәр элементын эчке мәгънә белән баету хисабына ирешә. Ил хакына кылынган батырлык турында җырлаучы «Үнөченче» балладасын гына алыйк. «Хәбәрсез югалган... билгесез каһарман» образына гыйбрәтле гомумиләштерү көче салынган: ул, бер тамчы чыкта зур Кояш чагылган кебек, бөтен халкыбыз батырлыгына аһәңдәш. Шул рәвешле, кыска гына балладада батырлык һәм гадилек төшенчәләре һич тә көтелмәгән ягыннан ачылып китә.

Юзеев үзенең фикер агышына тәңгәл алымнар ярдәмендә әсәрнең офыгын киңәйтә, эчке логикасын көчәйтә һәм укучы күңеленә юлны кыскарта. Пространство-вакыт күчешләреннән һәм башка шундый сәнгатьчә шартлылык алымнарыннан кыю файдалану аңа шигырьнең мәгънә-хис бөтенлеген тудыруда яңа мөмкинлекләр ача. Бу «Соңгы сынау» һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан иҗтимагый-фәлсәфи диалог дип бәяләнгән «Таш диварлар авазы» драматик поэмаларында аеруча ачык чагылды. «Өзелмәс кыллар» җыентыгындагы «Кара багана» балладасының гомумиләштерү көче — әлеге мөмкинлекләрдән уңышлы файдалану җимеше.

Күбәйсә әгәр
Кара багана,
Һич гафу итмәс
Килер Замана!

Лирик героеның заманнар буйлап «күчеше» ярдәмендә шагыйрь «Өзелмәс кыллар» поэмасында да фикерен калку итеп бирүгә ирешә. Тормышның катлаулы фәлсәфәсен ачуда аның шигъри алымы отышлы: дүрт язмыш, дүрт хис, гомернең дүрт мизгеле скрипка кыллары аша бирләштерелә. Ләкин әсәрдә лирик геройның киңәя баручы рухи дөньясы, тарихи дәвамлылык тулысынча ачылып җитмәгән. Алмашынып торган күренешләр кайвакыт теге яки бу фикергә иллюстрацияне генә хәтерләтә башлый. Бу хәл поэманың сюжет сызыгы катлаулы юлдан — персонаж-характерлардан бигрәк персонаж-идеяләр аша үсүдән килә. Шагыйрь нияте буенча, «скрипка тоткан чал карт» образы әсәр тукымасында мәгънә үзәген тәзергә тиеш булган. Шулай да дүрт кылга кагылудан туган көй-фәлсәфәдә һәр вакыт бер бөтенлекне тою шактый читен. Шушы уңайдан поэмадагы бик гыйбрәтле юллар хәтергә килә:

Җанга керим дисәң,
Нык тарттырма,
Бушатма да,— тап кыл уртасын,
Шул чагында табарсың син көйнең
Илаһи бер бөек ноктасын...

Илдар Юзеев иҗаты — нигездә, шул «нокта»ны табудан туган поэзия, бәхетле поэзия. Аның укучы күңеленә хуш килгән барлык шигырьләре тартылган кыл, киерелгән җәя угы сыман. Җыентыкның «Борчылу» дип исемләнгән бүлегенә берләштерелгән шигырьләрдә, мәсәлән, бу үзенчәлек гади күзгә дә күренерлек дәрәҗәдә.

Җиргә яңа туган сабый мин,
Һәм сугышта үлгән абый мин.

Илдар Юзеев әзер фикер сөземтәсе китерми, укучыга уйлану-иҗат итешү рәхәтлеген бүләк итә:

Әйтик:
бердәнбер көнне
Кояш кире кайтмаса?
. . . . . . . . . .
Кешe нишләр иде?

Бу уйчан поэзияне, гамьле поэзияне тудырган көч, хәрәкәт иттерүче көч — шагыйрьнең тынгысыз җаны. Ә шагыйрьнең тынгысызлыгы кайдан килә? Тукайча, Такташча, Җәлилчә кайнар йөрәкле булырга, халык күңеленең камертоны булырга омтылудан. Әнә шул сыйфатлары белән «Өзелмәс кыллар» җыентыгы якты идеалларга хезмәт итүче шигъриятебезнең олылыгын, яшәүчәнлеген раслый.

**МӨДӘРРИС ВӘЛИЕВ.**

# ҖИТДИ ХЕЗМӘТ

Бөек Октябрь социалистик революциясе тарихы инде менә 60 елдан артык вакыт галимнәребезнең игътибар үзәгендә тора. Аңа багышлап күп кенә китаплар, мәкаләләр басылды, симпозиумнар, конференцияләр уздырылды. Шуңа да карамастан, бу тарихи вакыйганы әле һаман тулысынча өйрәнелгән дип әйтеп булмый. Бу — фәннең чиге булмау белән генә дә аңлатылмый. В. И. Ленин күрсәтүенчә, Бөек Октябрь революциясе тарихы вакыт узган саен актуальләшә генә бара. Чөнки Россия башлап җибәргән революцион эпохага яңадан-яңа халыклар, дәүләтләр килеп кушыла. Бөтен дөнья масштабында революцион процесс дәвам итә. Ә Октябрь тәҗрибәсе әйтеп бетергесез әһәмияткә ия. Менә шуның өчен дә тарихчыларыбыз бу мәсьәләне өйрәнүне үзләренең изге бурычлары саныйлар, аны тагын да тирәнрәк өйрәнергә омтылалар.

Бу өлкәдә безнең республика тарихчылары бүген дә армый-талмый эшли, эзләнүләрен дәвам итәләр. Алар арасында тарих фәннәре докторлары, профессорлар М. К. Мөхәррәмов, Р. И. Нәфиков, И. М. Ионенко, Я. Ш. Шәрипов, М. З. Тутаев, А. Л. Литвин, тарих фәннәре кандидатлары И. Р. Таһиров, Р. К. Вәлиев, М. А. Мөлеков, М. А. Сәйдәшева һ. б. иптәшләрнең фәнни хезмәтләре әһәмиятле урын алып тора.

Тарих фәннәре кандидаты, Казан дәүләт университеты доценты Индус Ризакович Таһировның бу мәсьәләгә багышланган ике китабы бер ел эчендә дөнья күрде[1].

---

[1] И. Р. Тагиров. Революционная борьба и национально-освободительное движение в Поволжье и на Урале (февраль-июль 1917 года). Из-во Казанского ун-та, 1972; И. Р. Тагиров. В борьбе за власть Советов (Октябрь и национально-освободительное движение в Поволжье и на Урале, июль 1917 — март 1918 гг.). Казань, Таткнигоиздат, 1977.

Хронологик яктан берсен-берсе дәвам иткән бу китаплар — авторның 15 еллык эзләнүләре нәтиҗәсе, һәм алар галимнең бу өлкәдә яңа җитди адым ясавын күрсәтәләр.

Дөрес, әлеге хезмәтләрне Идел һәм Урал буе татарлары милли-азатлык хәрәкәте турындагы беренче китап дип әйтеп булмый. Чөнки бу планда тикшеренүләр тегә яки бу күләмдә инде 20 нче еллардан бирле бара. Бөек Ватан сугышыннан соң бу эш шактый киң колач алды. Шул исәптән тарих фәннәре докторлары, профессорлар М. К. Мөхәррәмов, Р. И. Нәфиков һ. б. авторларның соңгы 10—20 елда матбугатка чыккан хезмәтләре аеруча тирән һәм бай чыганакларга таянып язылган.

Индус Таһиров исә, әлегә кадәр чыккан хезмәтләргә таянып, бу катлаулы проблеманы өйрәнүдә күп кенә яңа проблемалар күтәргән, тарихи чыганакларны киңәйткән һәм ул кайбер бәхәсле мәсьәләләр буенча яңача карашны алга сөрә. Болар, үз чиратында, авторга регионны тагын да киңәйтергә, ә хронологик рамканы тагын да тарайтырга мөмкинлек биргән.

Китаплар бай чыганакларга таянып язылган. Автор Идел һәм Урал буе шәһәрләре архивларында җентекләп казынган, Мәскәү архивларында эшләгән, рус һәм татар телендә чыккан вакытлы матбугатка зур әһәмият биргән. Бигрәк тә татар телендә басылган, заманында үз тирәсенә революцион көчләр туплаган «Кызыл Байрак», «Алга», «Аваз», «Ирек» кебек газеталардан алынган материаллар игътибарга лаек. Шулай ук материалларга бай, ләкин тәнкыйть күзе таләп иткән «Вакыт» газетасын өйрәнү дә чыганакларны шактый киңәйткән. Рус телендә чыккан буржуаз «Каспий», «В мире мусульманства» газеталарының да киң файдаланылуын күрсәтеп үтәргә кирәк.

Тарих фәннәре докторы, профессор М. К. Мөхәррәмов редакциясендә чыккан беренче китап кереш сүз, өч бүлек һәм сүз ахырыннан тора. Кереш сүздә автор кыскача гына мәсьәләнең өйрәнелү тарихына туктала, аерым китапларга бәя бирә, һәм кайбер принципиаль мәсьәләләр, чыганакларны яктырта.

Беренче бүлектә татар җәмгыятендәге сыйныфларга, социаль группаларга анализ ясала, милли-азатлык хәрәкәтендәге юнәлешләр һәм тенденцияләр күрсәтелә. Монда татар буржуазиясе һәм пролетариаты формалашу турында да шактый гына яңа материал бирелә, крестьяннар хәленә тукталына.

Автор Октябрь алдыннан авылда беренче һәм икенче социаль көрәш өчен бөтен шартлар барлыкка килүен, шул ук вакытта икенче социаль көрәш өчен сәбәпләрнең күбрәк булуын күрсәтә (51 бит). Бу уңайдан шактый гына кызыклы материаллар табылган. Мәсәлән, кайбер губерналарда крестьяннар алпавытларга, кулакларга һәм буржуаз Вакытлы хөкүмәт администрациясенә генә түгел, ә бәлки муллаларга да каршы чыгуларын күрсәтә (53 бит). Болар, бөтен ил халкындагы кебек үк, татарлар арасында да сыйнфый каршылыкларның артуын ышандырырлык итеп дәлилли торган фактлар.

Культура һәм мәгариф эшләре, татар интеллигенциясе арасындагы юнәлешләр турындагы материаллар һәм фикерләр дә шулай ук зур кызыксыну белән укыла. Бу өлкәдә буржуазиянең ролен күрсәтеп, автор аның һәр вакыт үз сыйнфый интересларыннан чыгып эш итүен хаклы рәвештә күрсәтеп уза. Мәсәлән, аның сәүдә мәктәпләре ачуын, профессиональ мәктәпләр булдыруын яза. Кайбер татар буржуазиясе вәкилләренең хәтта чит илләрдә дә белем алуын әйтә. «Вакыт» газетасы күрсәтүенчә, 1913 елда Бейрут шәһәрендә Америка коллегиясендә унбер татар укый, шулай ук АКШның Сан-Франциско һ. б. шәһәрләрендә дә татарлар укуы билгеле.

Икенче бүлек Февраль революциясеннән соңгы берничә ай эчендә булган вакыйгаларны чагылдыруга багышланган. Анда милли мәсьәләнең төрле партияләрнең программа документларында һәм тактикаларында чагылышы, большевиклар партиясенең интернациональ фронт төзү өчен көрәше, татар буржуазиясенең сыйнфый йөзе күрсәтелә.

Милли-азатлык хәрәкәтенең кочәюе соңгы өченче бүлектә тикшерелә. Автор бу чорда барлыкка килгән төрле политик оешмаларны барлый, аларның юнәлешен күрсәтә, гаҗәп дәрәҗәдә күп санлы съездларның резолюцияләрен анализлый. Монда революцион-демократик көчләр алып барган көрәшнең тирәнәя баруы күрсәтелә.

Татарстан китап нәшрияты чыгарган икенче китап әлеге хезмәтнең дәвамы

булып тора. Аңарда хронологик яктан 1917 елның июле һәм 1918 елның март айлары колачланып, революциянең тирәнәюе, иске властьны бәреп төшерү һәм Совет властен урнаштыру турындагы мәсьәләләр карала.

Билгеле булганча, Февраль революциясеннән соң килгән буржуаз ирекләрдән, күп төрле сәбәпләр аркасында, башта вак буржуаз партия вәкилләре — эсерләр һәм меньшевиклар киң файдаландылар. Моңарга вак буржуаз стихиянең чәчәк атуы, революциягә миллионлаган, моңарчы политикага бәйләнмәгән, артта калган массаларның килеп кушылуы, аларның партияләр арасындагы аермаларны баштарак чамалап җиткермәүләре сәбәпче булды.

Хезмәттә әлеге чордагы вакыйгалардан генерал Корнилов авантюрасы белән көрәш аерым урын алып тора. Ул большевиклар партиясенең йогынтысы көннәнкөн арта баруын һәм аларның көчен күрсәтте. Бу көрәштә мөселман большевикларының роле һәм кайбер мөселман оешмаларының өлеше турында И. Таһиров китабында шактый кызыклы яңа материаллар китерелә. Революциянең тирәнәя баруы милли оешмаларда да чагылыш таба — халык массалары милләтче оешмалардан суынালар, аларны ташлап китәләр. Монда, әлбәттә, большевиклар һәм революцион-демократлар алып барган аңлату эшләренең дә роле зур булуын искәртергә кирәк. Нәтиҗәдә милләтче оешмалар таркалалар. Хезмәт ияләре буржуазия вәкилләрен тыңлаудан баш тарталар, ә вакыт-вакыт үзләрен кыйнап та ташлыйлар. Мондый процесс 1917 елның августында Казан губерна Милли шурасына сайлауларда ачык чагылыш тапты. Революцияне алга этәрүчеләр рәтендә барган Мулланур Вахитов 3452 тавыш алса, милләтчеләрнең җитәкчесе кадет Садри Максудовка бары 1807 тавыш кына бирелә.

Шул ук вакытта китапта татарлар арасында барлыкка килгән большевистик оешмалар эшчәнлеген яктыртуга да зур урын бирелә. Аерым алганда, Уфада, Оренбургта, Сызраньда, Чиләбедә, Бакуда, Донбасста барлыкка килгән оешмалар турында сөйләнелә. Баһау Нуриманов, Сибгат Гафуров, Халикъ Садри, Хәнәфи Терегулов, Сәхибгәрәй Сәидгалиев кебек большевикларның эшчәнлеге күрсәтелә. Ә бу эшчәнлекнең нәтиҗәсе Вакытлы буржуаз хөкүмәтне бәреп төшерүдә ачык күренә. Автор Идел һәм Урал буе губерналарында Совет властен урнаштыру өчен барган көрәшне күрсәтә, рус һәм башка халыклар белән кулга-кул тотынып, большевиклар партиясе җитәкчелегендә татар эшчеләре һәм күпчелек хезмәт ияләренең бу тарихи вакыйгаларда актив катнашуын тарихи материаллар белән дәлилли. Соңгы бүлек Идел һәм Урал буе шәһәрләрендә Совет властен урнаштыру вакыйгаларына багышланган.

Кыскача алганда, авторның искә алынган хезмәтләрендә каралган мәсьәләләр менә шулар. Аның кайбер уңай яклары турында әйтелде инде. Һәм алар турында шактый күп сөйләргә мөмкин. Әйтелгән мәсьәләләр өстенә, авторның шактый оригиналь аргументлар белән милли гаскәри частьларның барлыкка килү тарихын аңлатуын, милли съездлар эшчәнлегенә тирән анализын күрсәтергә мөмкин. Халкыбызның күренекле улларын, революцион көрәш сәхифәсеннән яңа исемнәр ачуның әһәмияте шактый зур.

Еш кына дусларча өңгәмә алып барганда, безнең язучы иптәшләребез тарихчылар стиленең шактый җансыз һәм авыр булуын искәртеп торалар. Бу сүздә, һичшиксез, дөреслек бар. Бу бигрәк тә тарихи әсәрләребезнең киң катламга барып җитүе өчен әһәмиятле.

Соңгы елларда безнең республика тарихчылары арасында да бу мәсьәләгә игътибар бирүчеләр артты. Бәйрәм ашы — кара-каршы, дигәндәй, үз нәүбәтебездә, без дә язучы дусларның Михаил Шолохов, Леонид Леонов, Вячеслав Шишков кебек тирән тарихи полотнолар калдыру өчен әле шактый күп эшләселәре булуын искәртергә телибез.

Индус Таһиров китабы бай әдәби тел белән язылган. Урыны-урыны белән аерым шәхесләргә кызыклы, хәтердә калырлык образлы, җанлы әдәби тел белән характеристика бирелә. Бу бигрәк тә кайбер вак буржуаз партия вәкилләренә кагыла. Авторның ренегат меньшевик Ибраһим Әхтәмовның «тимер» логикасына анализы, Ильяс Алкин, Беглов кебек фраза һәм поза геройларына биргән характеристикасы зур кызыксыну белән укыла.

Хезмәтләрдә җитешсезлекләр, бәхәсле урыннар һәм төгәлсезлекләр юк түгел. Югарыда без авторның революция елларында узган һәртөрле милли съездларны җентекләп тикшерүен әйтеп узган идек инде. Әмма бу өлкәдә әле тагы да тирәнгәрәк керергә мөмкинлекләр бар.

Мәсәлән, съезд делегатларының социаль һәм партия составын тикшерү алар чыгарган резолюцияләрнең эчтәлеген киңрәк аңларга ярдәм итәр иде. Шул ук вакытта бу съездлар составы һәм карашлары буенча һич кенә дә бер төрле түгел. Тарихчыларыбыз әйтүе буенча, аларда еш кына демократик агым да күренекле урын алып торган. Социаль көрәш турында сүз барганда, кайбер статистик материаллар да китерелсә, авторның йомгаклау сүзләре тагын да ышандырырлык булыр иде. Идел һәм Урал буенда яшәүче башка халыклар — башкорт, чуваш, мари, удмурт, мордва күршеләребез арасында барган милли-азатлык хәрәкәте турындагы материалларны да тагы да киңрәк бирү зыян итмәс иде.

Китапта аерым төгәлсезлекләр дә киткән. Мәсәлән, монографияләрнең икенчесендә: 1918 елның 7 нче гыйнварында, Учредительное собрание куып таратылган, В. И. Ленин Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Маннатовларны кабул итте дип күрсәтелә (160 нчы бит). Ә документлардан билгеле булганча, В. И. Ленин янында М. Вахитов белән Ш. Маннатов кына булалар. Г. Ибраһимов алар арасында бу көнне булмый. Аның В. И. Ленин белән әңгәмәсе соңрак вакытка туры килә.

Беренче монографиянең 135 битендә автор Февраль революциясеннән соң төрле шәһәрләрдә барлыкка килгән Мөселман хәрби комитетлары (алар Советлар дип тә йөртеләләр) турында сүз алып бара. Гомумән алганда, аларның политик юнәлешенә һәм эшчәнлегенә дөрес бәя бирелә. Ләкин Уфа Мөселман хәрби советының барлыкка килүе большевиклар Шәһит Ходайбердин һәм Ф. Әхмәдуллиннарның актив катнашында булды, дип күрсәтү документлар белән расланмый.

Минем үземә берничә еллар элек Башкорт дәүләт архивында бу оешманың протоколларын тикшерергә туры килгәне бар. Алар күрсәтүенчә, Уфа Хәрби Советында да, күп кенә урыннардагы кебек үк, баштарак вак буржуаз партия вәкилләре активлык күрсәтә. Протоколларда Шәһит Ходайбердин һәм Ф. Әхмәдуллин исемнәре Октябрь революциясе чорында гына күренә башлый. Шуның өстенә Шәһит Ходайбердин ул вакытта әле большевиклар партиясе члены да булмый. Ул фәкать 1918 нче елның март аенда гына сул эсерлар партиясе белән араны өзә һәм большевиклар партиясенә член булып керә. Бу очракта Индус Таһиров нәтиҗә чыгарырга ашыга төшкән.

Авторның Иран революционерлары тарафыннан Кавказда оештырылган «Адаләт» группасын вак буржуаз демократлар оешмасы дип санавы белән дә һич килешеп булмый. Ул, әзербайҗаннар арасында барлыкка килгән «Һиммәт» оешмасы (җитәкчесе Нариман Нариманов) кебек үк, белгечләр тарафыннан большевистик оешма дип карала. Һәм бер дә очраклы түгел — алар үзара тыгыз элемтәдә революцион эш алып баралар.

Сүз дә юк, югарыда күрсәтелгән кайбер җитешсезлекләр генә доцент И. Р. Таһиров хезмәтләренең дәрәҗәсен төшерергә сәләтле түгел. Аларның һәр икесе тиешле теоретик югарылыкта язылган. Автор үз алдында торган проблемаларны тирәнтен аңлый, чыганаклардан зур осталык белән файдалана. Болар исә татар халкының революцион һәм милли-азатлык хәрәкәтен өйрәнү юлында җитди адым ясалган дигән йомгак сүзен әйтергә мөмкинлек бирә.

**РИФ ХӘЙРЕТДИНОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

## Галимҗан Латыйп

### Безнең сыер

Чиләк тулы су иде,
Тамчысы да калмаган.
Суы беткәч чиләкнең
Төбен сыер ялаган.

Белмим инде нишлисе,
Докторгамы барасы.
Әллә сыер корсагына
Кармак салып карасы?

Балыгымны йоткан бит,
Суы белән чөмереп.
Салган идем чиләккә
Су буеннан мендереп.

Балык шулпасы булып,
Тоелганмы ул аңа.
Йөзеп йөргән балыкны
Күрмә инде, дивана.

Безнең сыер шундый ул,
Талымламый берсен дә,
Куе сөтенә кушып,
Балык мае эчерә.

### Кар көтәм

Көтте Мәхмүт кар явар дип,
Калмады бер чарасы...
Аннары чормага менеп,
Алып төште чанасын.

Йөри малай чана тартып,
Кара җирдә, туң җирдә.
Чана табаны балчыкта
Шуа алмый тилмерә.

— Мәхмүт энем, нишлисең? — дип,
Сорау бирә бер агай.
— Кар көтәм, Кышны чакырам! —
Дип җавап бирә малай.

## Рөстәм рәсем ясый

Кайчы белән кисеп-кисеп
Безнең Рөстәм рәсем ясый.
Ат. Күсе. Сыер. Сарык...
Кролик кишер ашый.

Ләкин аларның төсе ак;
Кишере дә, сыеры да,
Күсе дә ак.
Печәне дә, сарыгы да,
Бәрәңге кабыгы да.

— Рөстәм энем, ник димен,
Болар бар да ак кына? —
Карап алды рәсемнәргә,
Елмайды ул чак кына:

— Әнә тышта кыш көне,
Кыш бабайның эш көне.
Өсләренә кар яуган,
Алар шуңа агарган.

## Кардәш

Безгә бүген кунак килде,
Урал ягы — Әрдәштән.
Әни әйтә: алар, улым,
Безнең якын кардәшләр.

Кардәшләрнең малае бар,
Тартынып тормый бер дә.
Әйтерсең без аның белән
Үсәбез икәү бергә.

Исемең ничек, дигән идем,
Әбелманов Дәдәт, ди.
Әнисе дөресли аны:
— Дәдәт түгел, Җәүдәт, — ди.

Бүлмәләргә керә, чыга,
Дөнья белән таныша.
Бар да кызык, бар да яңа,
Искитмәле, аныңча.

Пианино бармагына
Басып-басып карады.
Ничек кенә тырышса да,
Көй чыгара алмады.

Китап киштәләренә дә
Күз төшерде, тикшерде.
Өстәлдәге эскәтерне
Тартып кына төшерде.

Җитешмәгән бер җире юк,
Ашыгыпмы-ашыга.
Мине эзләп табыгыз, дип,
Кача өстәл астына.

Тапсак кызык түгел аңа.
Без тапмыйбыз, янәсе.
«Кая гына китте икән?»
Дигән була әнкәсе.

И эзлибез, и эзлибез,
Сөенепме-сөенә.
Кунак бит дип, без гел аның
Торабыз үз көенә.

# «ЯШЬЛЕК УТРАВЫМ» ПОВЕСТЕН УКЫГАЧ...

*
* *

Мин очраклы рәвештә язучы Әдип Маликовның «Яшьлек утравым» исемле русча чыккан китабын укып чыктым. Китап миңа бик ошады. Ул җиңел укыла, беренче битләреннән үк кызыксыну уята, мавыктыра. Повестьның геройлары — яшь солдатлар, разведчиклар. Алар Бөек Ватан сугышы елларында Ерак Көнчыгышта хезмәт итәләр. Көньяк Сахалинны япон самурайларыннан азат итүдә катнашалар.

Китап күтәренке рухта, патриотик хисләр белән язылган. Аның геройлары бүгенге яшь буын өчен үрнәк булырлык. Бу китапны Донбасс заводларында һәм шахталарында эшләүче башка яшьләр дә яратып укыгандыр, мөгаен.

**Т. С. ЧАЙКА.**
Донецк шәһәре.

*
* *

Мин Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны. Якташым Әдип Маликовның «Яшьлек утравым» исемле повесть-истәлеген укып чыккач, әсәр турындагы фикерләремне язмыйча булдыра алмадым.

Мәскәүдә, Кызыл мәйданда Җиңү салюты яңгыраганга да утыз елдан артык вакыт үтте. Әмма Бөек Ватан сугышы темасы тарих булып кына калмады, искермәде. Батырлык бөеклеге һәм сугыш фаҗигасе күп милләтле совет әдәбиятының иң мөһим һәм үзәк темаларының берсенә әйләнеп бара. Сугыш темасы, аның мораль-этик тәҗрибәсен яңача аңлау, үзләштерү процессы күп кенә яхшы әсәрләрнең дөньяга килүенә булышлык итте.

Фронтовик-язучы Әдип Маликовның үз тәҗрибәсе, кичерешләре аерым кешеләр язмышы аша киләчәк өчен көрәшүче бөтен бер халык язмышын, аның батырлыгын күрсәтергә мөмкинлек биргән. Әсәрдәге Әхнәф Мәүлитов, аның иң якын дусты Миңнулла Миңлекәев, лейтенант Орлов һәм башкаларның образлары миңа бик якын да, таныш та. Аларның иң авыр очракларда да төшенкелеккә бирелмичә, авырлыкларны кыю җиңә белүләре, Ватанга бирелгәнлекләре белән һәр укучыга, бигрәк тә яшь буынга, батырлык үрнәге булып тора.

«Яшьлек утравым»дагы күп кенә эпизодлар минем дә фронттагы авыр кичерешләремә, сугыштан соңгы тормышыма охшаш. Повестьтагы Әхнәф кебек, мин дә Бөек Ватан сугышында катнаштым. Башкалабыз Мәскәүне саклаштым. Повестьтагы кебек мин дә авыр яраланып госпитальгә эләктем. Повестьтагы кебек мин дә сугыш бетеп күп еллар узгач, 1976 елда герой-шәһәр Мәскәүдә Кызыл Байраклы 5 нче армия ветераннарының очрашуында катнаштым... Шуңа микән, әлеге китапны мин бик яраттым. Аның дәреслегенә ышандым.

**Рәшит КӘРИМОВ.**
Башкортстан, Югары Тәтешле авылы.

# ПУШКИНГА ЯЗЫЛГАН ХАТЛАР

А. С. Пушкинның «Пугачев фетнәсенең тарихы»н язу өчен материал туплаган чагында Казанда булуы билгеле инде. Ә менә шагыйрьнең Казан университетының грек, латин телләре һәм француз әдәбияты профессоры Жабор Альфонс-Жан-Батист белән хат алышуы һәркемгә мәгълүм түгелдер.

Красноярск краеның дәүләт архивында Жаборның Пушкинга язган ике хаты саклана. Профессор шагыйрьнең «На выздоровление Лукулла» исемле одасын тәрҗемә итә. Хат алышу шуннан башлана да. Әлеге тәрҗемәне һәм хатны алгач, Пушкин тәрҗемәне «кинаяле, сокландыргыч» дип бәяли, әмма матбугатка бирмәвен үтенә. Жабор исә: «Сезгә буйсынам, ләкин вакытлыча гына», — дип җавап бирә. Соңыннан бу галим Россиядән китә. Үзенең Петербургта, Мәскәүдә, Казанда алган тәэсирләрен ул брошюра итеп, 1854 елда Венада бастырып чыгара. Ләкин Жабор бөек рус шагыйре турында китабында искә дә алмый.

Жабор Казан университетында 1822—1824 нче елларда эшли. Эшләгән чорында ул университет идарәсе белән дә, халык мәгарифе министры белән дә һәрчак низаглашып яши, аларны гаделсезлектә гаепли. Шуңа күрә күп укытучылар аны яратмыйлар, аңа каршы чыгалар. һәм ул Казаннан китәргә мәҗбүр була. Әлеге тәрҗемәгә дә ул Пушкинның шигъриятен яратканнан түгел, бәлки мәгариф министры С. Уваровтан үч алу нияте белән генә алына. Александр Сергеевичка беренче хатын җибәргәндә Жабор Уваровка аталган чәнечкеле хатын да сала.

Әлеге хатлар Красноярскига ничек килеп эләгә соң?

XIX йөз ахырларында, XX йөз башында Себердә сәүдәгәр В. Юдин яши. Аның кул астында алтын приискалары, җир биләмәләре, спирт заводы була. Ул шул ук вакытта китап һәм әдәбият белән дә кызыксына. Аның китапханәсендә рус классикларының төрле басмалары туплана. В. Юдин А. С. Пушкинның әсәрләрен аеруча бөртекләп җыя. Аны хәтта тыелган китаплар да кызыксындыра, китаплар белән беррәттән, кыйммәтле документлар да җәлеп итә. Мәсәлән, ул үзенең китапханәсендә тарихчы Погодинның архивын, Төньяк Америкага беренче булып күчеп утырган руслар турындагы материалларны туплый... 80 меңнән артык томлы бу китапханәне бөтен Россия белгән. Китапханә иясе бик күп эре китап сәүдәгәрләре белән, нәширләр һәм библиофиллар белән дә элемтәдә торган. Петербургта, Мәскәүдә, Казанда еш булган. 1897 елда Шушенскоега сөргенгә китеп барышлый, В. И. Ленин да Красноярскида туктала, «Россиядә капитализмның үсеше» исемле хезмәтенә материал туплау өчен шушы китапханәдә була.

Жаборның Пушкинга язган хатлары да, шулай ук Казанда чыккан кайбер китаплар да Юдинга эләгә. Беренче рус революциясеннән соң сәүдәгәрнең финанс хәлләре какшый. Ул китапханәсен сатарга ниятли. Кайбер университетларның әлеге хәзинәне сатып алуларын сорап, Юдин патшага мөрәҗәгать итә, ләкин уңай җавап ала алмый. Шуннан соң китапханәсен Америкага сатарга мәҗбүр була. Аның китапханәсе хәзер АКШ Конгрессы Милли китапханәсенең славян бүлегендә төп өлешне тәшкил итә.

Шулай да документларның бер өлеше, шул исәптән Жаборның Пушкинга язган хатлары да, Юдинда кала. Ул үзе 1912 елда үлә. Октябрь революциясеннән соң Юдиннан калган материаллар Красноярск край архивына тапшырыла.

Француз телендә язылган әлеге хатлар тарихчылар һәм әдәбият белгечләре өчен, һичшиксез, кыйммәтле документлар.

**А. МӨСЛИМОВ,**
Казан.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ФӘННИ-ПРАКТИК КОНФЕРЕНЦИЯ

25—26 октябрьда Казанда «Нык ускән социализм шартларында әхлак тәрбиясе» дигән темага республика фәнни-практик конференциясе үткәрелде. Анда партия оешмалары секретарьлары, агитколлектив һәм политинформаторлар группалары житәкчеләре, пропагандистлар, предприятие, мәктәп, техникум, профессиональ-техник училище директорлары, колхоз председательләре, шәһәр, район һәм күп тиражлы газеталарның редакторлары, вуз һәм фәнни-тикшеренү институтлары работниклары, халык депутатларының шәһәр һәм район советлары башкарма комитетларының культура бүлекләре мөдирләре, «Белем» җәмгыятенең шәһәр һәм район оешмалары җаваплы секретарьлары, лекторлар, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, партия һәм комсомолның шәһәр һәм район комитетларының идеология эшенә җитәкчелек итә торган секретарьлары, профсоюз работниклары, республиканың идеология оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре катнашты.

Пленар утырышта конференциядә катнашучылар КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиевнең «Хәзерге этапта хезмәт ияләрен әхлакый тәрбияләүнең актуаль бурычлары» дигән докладын, шулай ук КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйровның, ТАССР юстиция министры Ә. Г. Тажетдиновның, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты беренче секретаре В. Е. Борисовның, партиянең Чаллы шәһәрендәге Автозавод райкомы секретаре Д. В. Свирскаяның, профсоюзларның Татарстан өлкә советы секретаре К. Г. Әхметовның, ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Ш. Р. Агеевның, КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге лекторлар группасы җитәкчесе А. Н. Калагановның өстәмә докладларын тыңладылар.

«Эшчеләр сыйныфының һәм хезмәт коллективларының югары әхлаклы шәхес тәрбияләүдә җитәкчелек роле», «Авылда әхлак тәрбиясе һәм хәзерге этапта аны камиллаштерү юллары», «Нык ускән социализм шартларында фән-техника интеллигенциясен әхлакый тәрбияләүнең актуаль проблемалары», «Художество интеллигенциясе һәм совет кешеләрен коммунистик әхлак рухында тәрбияләү проблемалары», «Укучы яшьләрне коммунистик әхлак рухында формалаштыру проблемалары», «Советча яшәү рәвешен пропагандалау — әхлак тәрбиясенең состав өлеше» дигән секцияләрдә хезмәт ияләрен әхлакый тәрбияләү теориясе һәм практикасы проблемалары, югары әхлак сыйфатларына ия булган шәхесне формалаштыру эшенең нәтиҗәлелеген тагын да күтәрү юллары һәм методлары һәрьяклап тикшерелде.

Конференциядә КПССның XXV съезды карарларының яктылыгында әхлак тәрбиясенең комплекслы системасын киң кертүгә юнәлтелгән рекомендацияләр кабул ителде.

Йомгаклау утырышында секцияләрнең эш йомгаклары турында аларның җитәкчеләре — КПСС өлкә комитетының бүлек мөдирләре А. А. Родыгин, Ю. М. Воронин, М. М. Мусин, Ә. С. Миндубаев, КПСС өлкә комитетының бүлек мөдире урынбасары А. Н. Леонов, КПСС өлкә комитетының лекторлар группасы җитәкчесе А. Н. Калаганов информация ясадылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны идарә председателе Гариф Ахунов алып барды. Утырыш, нигездә, яшьләр иҗатына кагылышлы мәсьәләләргә багышланды. Анда күптән түгел Казанда булып узган яшь иҗат көчләренең республика семинары йомгаклары һәм декабрь аенда Азнакайда булачак чираттагы семинарга әзерлек турында Язучылар союзы идарәсе председателенең яшьләр белән эшләү буенча урынбасары Илдар Юзеев чыгыш ясады.

Азнакайда булачак семинар Апас, Чаллы, Арчада уздырылган яшь язучылар конференцияләренең дәвамы булачак оештырыла. Анда нефть ягы — Азнакай, Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә, Сарман, Баулы районнарында яшәүче яшь язучылар иҗатына анализ ясалачак.

Арча конференциясендә СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим ителгән шагыйрьләрдән Нәҗип Мадьяров, Шамил Маннапов, Әхмәт Рәшитов һәм Разил Вәлиев бертавыштан СССР Язучылар союзына член итеп кабул ителде.

* * *

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы җыелышында «Нык үскән социализм шартларында әхлак тәрбиясе» дигән темага булып узган фәнни-практик конференция йомгаклары буенча җитди сөйләшү барды. Анда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов доклады тыңланды. Докладта әлеге мәсьәләнең бүгенге шартларда гаять әһәмиятле һәм актуаль булуы билгеләнде.

күп милләтле совет әдәбияты һәм татар әдәбиятының бу юлда ирешелгән уңышлары күрсәтелде. Партия өешмәсе секретаре Т. Миңнуллин рухи тәрбия мәсьәләләре яктылыгында язучылар алдында торган конкрет бурычлар турында сөйләде.
Фикер алышуда Д. Вәлиев, М. Е. Скороходов, Р. Ишморатова һәм Р. Хафизова чыгыш ясадылар.

## ТУКАЙ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

15 октябрьда язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында халык шагыйре Г. Тукай әсәрләренең дүрт томлык яңа басмасын тикшерүгә багышланган җыелыш булды. Аны, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы белән берлектә, ТАССР Язучылар союзының тәнкыйть секциясе оештырды. Бу кызыклы сөйләшүдә язучылар, галимнәр һәм нәшрият хезмәткәрләре катнашты.
Җыелышны кереш сүз белән тәнкыйть секциясе председателе Ф. Мусин ачты. Аннары филология фәннәре докторы И. Нуруллин һәм филология фәннәре кандидаты М. Бакиров докладлары тыңланды. Фикер алышуларда С. Хәким, Н. Исәнбәт, Г. Ахунов, Ә. Исхак, М. Мәһдиев, Г. Шамуков, Н. Юзиев, Г. Халит, Р. Гайнанов, Ф. Фасиев, Ә. Булатов катнашты.
Җыелышта Тукай әсәрләренең яңа басмасы мисалында бездә, гомумән, классиклар иҗатын фәнни нигездә җыю һәм бастырып чыгаруның торышы, бу өлкәдә алда торган бурычлар турында эшлекле сөйләшү булды. Яңа басманы Тукай әсәрләрен чын гыйльми принципларга нигезләнеп чыгару юлында житди адым дип бәяләү белән бергә, докладларда һәм чыгышларда бу өлкәдә безнең әдәбиятчылар алдында әле зур бурычлар торуы күрсәтелде, күп кенә конкрет тәкъдимнәр ясалды.
Җыелышта катнашучылар Г. Тукайның 100 еллык юбилеена аның әсәрләренең тагын да тулырак академик басмасын әзерләргә кирәк дигән фикерне әйттеләр.

## Х. ФӘЕЗХАНОВКА БАГЫШЛАП

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында күренекле галим һәм мәгърифәтче Хөсәен Фәезхановның тууына 150 ел тулуга багышланган фәнни утырыш булды. Аны кереш сүз белән институт директоры, профессор М. К. Мөхәррәмов ачты.
Хөсәен Фәезхановның тормыш юлы, иҗаты, тарих һәм тел фәннәрен үстерүгә керткән өлеше һәм аның иҗтимагый фикер тарихында тоткан урыны, татар мәгърифәтчеләр хәрәкәте турында доклад белән философия фәннәре кандидаты, доцент Я. Абдуллин чыкты.
Филология фәннәре кандидаты Ф. Хәкимҗанов, фәнни хезмәткәр М. Юсупов чыгышлары да күренекле галимнең күп кырлы эшчәнлегенең аерым якларын ачык чагылдырды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

*
* *

Татарстан Язучылар союзы каршындагы драматурглар секциясенең отчет-сайлау җыелышы булды. Информация белән секция бюросы җитәкчесе Аяз Гыйләҗев чыкты. Яңа бюро составына А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Р. Хәмидуллин, Г. Зәйнашева, И. Илялова керделәр.
Шул ук утырышта Г. Зәйнашеваның «Суфия апа» исемле яңа драмасын тикшерү булды. Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, И. Юзеев һәм Ә. Гаффар яңа әсәр турында автор белән фикерләрен уртаклаштылар.

*
* *

Татарстан Язучылар союзы каршында эшләүче тәрҗемәчеләр секциясенең чираттагы утырышында рус һәм дөнья әдәбиятлары классиклары әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү эше, аларның республика китапханәләренә таралыш дәрәҗәсе һәм китап укучыларның бүгенге ихтыяҗлары турында эшлекле сөйләшү булды. Утырышта шушы мәсьәлә буенча доклад белән СССР Язучылар союзы члены, тәрҗемәче Саимә Ибраһимова чыкты.
Зур җанлылык белән үткән фикер алышуда СССР Язучылар союзы членнары, тәрҗемәчеләр Я. Халитов, Р. Даутов, секция бюросы председателе Т. Нурмөхәммәтов, язучы һәм тәрҗемәче Л. Хәмидуллин, шулай ук ТАССР Мәгариф министрлыгы инспекторы Н. Нуришанова, «Совет мәктәбе» журналының баш редакторы В. Зыятдинов чыгыш ясады.
Утырышта катнашучылар рус һәм дөнья әдәбияты классикларының күренекле әсәрләрен тәрҗемә итү һәм татар укучыларына житкерү өлкәсендә җитди проблемаларны хәл итү максатыннан үзләренең киңәш һәм теләкләрен белдерделәр.

*
* *

Ноябрь аенда поэзия секциясенең отчет-сайлау җыелышы булып узды. Утызга якын шагыйрь катнашкан бу җыелышта секциянең соңгы ике елдагы эше турында аның җитәкчесе Радиф Гатауллин сөйләде.
Доклад буенча фикер алышулар бүгенге поэзия, аның гражданлык активлыгын үстерү, секциянең эшен тагын кызыклырак, җанлырак үткәрү зур сөйләшүгә әйләнде. Шагыйрьләр С. Хәким, Х. Туфан, Н. Арслан, Ә. Баянов, Ш. Маннур, И. Юзеев, Г. Рәхим, М. Әгъләмов, Ш. Маннапов, тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев, Язучылар союзы идарәсенең председатель урынбасары Ф. Миңнуллин эшлекле, кызыклы тәкъдимнәр белән чыктылар. Бюроның эше канәгатьләнерлек дип табылган бу җыелышта секциянең Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан, Ә. Баянов, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин,

Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, Ә. Рәшитов, Ш. Маннаповлар составында яңа бюросы сайланды. Шул ук көнне бюроның оешты-ру утырышы булып, бюро җитәкчесе (Р. Гатауллин), секретарь (Ә. Рәшитов) расланды.

## ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЛАРЫ ПЛЕНУМЫ

17 ноябрьда Казан дәүләт консерваториясенең Актлар залында Татарстан Композиторлар союзының иҗат яшьләренә багышланган XVI пленумы ачылды. Ленин комсомолының 60 еллыгы хөрмәтенә үткәрелә торган бу музыкаль форумда Мәскәүдән, Удмуртия, Чувашия, Мари автономияле республикаларыннан килгән композиторлар, музыкантлар, музыка белгечләре катнашты.

Пленумны кереш сүз белән ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе Мирсәет Яруллин ачты. Аннары ике бүлектән торган симфоник музыка концерты булды. Башлап Р. Билаловның шагыйрь М. Хөсәен шигыренә язылган «Партия, комсомол» дигән яңа җыры башкарылды.

Концертта яшь композиторлар П. Четвергов, К. Хөснуллин, Р. Еникеева, А. Руденко, Ш. Тимербулатов, Л. Батыркаева, А. Миргородскийның төрле жанрдагы симфоник әсәрләре яңгырады. Концертта Казагыстанның һәм Татарстанның халык артисты Фуат Мансуров дирижерлыгында Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз конкурслары лауреаты Татар дәүләт симфоник оркестры катнашты.

Татарстан Композиторлар союзы пленумын ачуда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев һәм ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

Пленум үзенең эшен дүрт көн буе дәвам итте.

Йомгаклау утырышында «Яшь композиторлар иҗаты» дигән доклад белән ТАССР Композиторлар союзының иҗат яшьләре белән эшләү секциясе председателе Р. Н. Билалов чыкты.

Доклад буенча фикер алышуда композиторлар Л. Любовский, Л. Хәйретдинова, Ә. Шәрәфиев, Л. Блинов, Б. Мулюков, Казан дәүләт консерваториясенең кафедра мөдире профессор А. Луппов, музыка белгечләре М. Нигъмәтҗанов, М. Фәйзуллаева, РСФСР Композиторлар союзының оешты-ру-иҗат комиссиясе председателе А. А. Бузовкин, РСФСР Композиторлар союзы правлениесе секретаре, «Музыкальная жизнь» журналының баш редакторы Н. Е. Попов катнашты.

Пленумның йомгаклау утырышында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

Соңыннан РСФСР Композиторлар союзының IV съездына делегатлар сайланды.

## СССР ПЕДАГОГИЯ ФӘННӘРЕ АКАДЕМИЯСЕ

СССР Педагогия фәннәре академиясенең гомуми җыелышында СССР Педагогия фәннәре академиясенең яңа действительный членнарын сайлау булды. Алар арасында безнең якташыбыз, күренекле Казан галиме, СССР Педагогия фәннәре академиясенең профессиональ-техник педагогика фәнни-тикшеренү институты директоры Мирза Исмәгыйлович Мәхмүтов та бар.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

Октябрь ахырында Казан шәһәренең Төзүчеләр культура сараенда язучы һәм драматург Нурихан Фәттахның 50 еллыгына багышланган әдәби кичә булып узды. Әдипнең күп кырлы һәм бай иҗаты турында докладны аның каләмдәше, Казан дәүләт университеты доценты Мөхәммәт Мәһдиев ясады. Кичәдә язучының прозасыннан өзекләр укылды, «Кол Гали» драмасыннан аерым эпизодлар күрсәтелде. Шәһәребез хезмәт ияләре, яшьләр һәм иҗат интеллигенциясе күп җыелган бу бәйрәм зур күтәренкелек белән узды.

*
* *

Беренче декабрьда Казан шәһәренең Төзүчеләр культура сараенда күренекле шагыйрь Шәүкәт Галиевнең 50 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Шагыйрьнең лирикасы, сатира-юмор һәм балалар өчен язылган әсәрләреннән төзелгән әдәби-музыкаль композициядә танылган артистлар, җырчылар зур уңыш белән чыгыш ясады. С. Хәким, М. Мәһдиев һәм Г. Рәхимнәр шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләделәр. Шәһәребез хезмәт ияләре, яшьләр һәм иҗат интеллигенциясе күп җыелган иҗат бәйрәме зур күтәренкелек белән узды.

*
* *

15 ноябрьда Казан шәһәренең Мәскәү районы Пионерлар йортында укучылар шагыйрь Шәүкәт Галиев белән очрашу кичәсе уздырдылар. Татарстан китап нәшрияты редакторы Ю. Әминов кичәдә катнашучыларны шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды. Аннары Пионерлар йорты каршындагы «Салават күпере» исемле әдәби театр һәм «Яшьтәш» поэтик клубы (җитәкчесе З. Е. Бернадская) членнары Ш. Галиев әсәрләреннән төзелгән «Ә тимурчылардан без калышмаска тиешбез» дигән әдәби монтаж башкардылар.

Пионерлар йорты директоры Н. М. Фәйзрахманова 50 яшь тулу уңае белән шагыйрьгә котлау адресы тапшырды, пионерлар юбилярга чәчәкләр бүләк иттеләр.

Шәүкәт Галиев, кичәнең азагында чыгыш ясап, күрсәтелгән хөрмәт өчен рәхмәт белдерде, балаларга үзенең яңа шигырьләрен укыды, сорауларга җавап бирде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

* * *

Октябрь аенда Лениногорскидагы «Чишмә» әдәбият берләшмәсендә отчет-сайлау җыелышы үткәрелде. Отчет докладе белән берләшмә җитәкчесе Әсрар Галиев чыкты. Фикер алышуда катнашучы язучылар Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов, яшь язучылар Альберт Хәсәнов, Шәригә Таһирова, Разим Вәлиуллин, Хәким Хәйруллин, яшь композитор Фәйзи Хөснуллин берләшмә членнарының иҗат активлыклары турында сөйләделәр, эштәге кимчелекләрне тәнкыйтьләделәр.

Җыелышта Татарстан Язучылар союзы Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Әдип Маликов, КПССның Лениногорск шәһәр комитеты инструкторы Рөстәм Фәттахов чыгыш ясады.

Әдәби берләшмә җитәкчесе итеп яшь шагыйрь Разим Вәлиуллин сайланды. Шеф консультант итеп язучы Җәмит Рәхимов расланды.

* * *

Әлмәт милиция бүлегендә комсомолның 60 еллыгына багышланган кичәдә комсомол ветераны шагыйрь Әдип Маликов чыгыш ясады, яшьләргә багышланган яңа шигырьләрен укыды.

* * *

Нефтьчеләрнең «Ромашкино» санаториясендә шагыйрә Клара Булатова белән очрашу кичәсе булды. Республикабызның төрле районнарыннан килгән ял итүчеләр шагыйрәнең чыгышын кызыксынып тыңладылар, сораулар бирделәр.

* * *

Әлмәт әдәбият берләшмәсе утырышында яшь авторлардан Лут Юнысов, Шәриф Хисамиев хикәяләре һәм Роберт Рәкыйпов шигырьләре тикшерелде. Берләшмә членнары һәм шагыйрә Сажидә Сөләйманова авторларга әсәрләрен камилләштерү юнәлешендә файдалы киңәшләр әйттеләр.

Яшь иҗат көчләренең республика киңәшмәсендә катнашкан Фәрит Гыйльметдинов һәм Роберт Рәкыйпов үзләренең шунда алган тәэсирләре белән уртаклаштылар.

## КУЛЬТУРА ЯҢАЛЫКЛАРЫ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының бер группа артистлары сентябрь-октябрь айларында Урал һәм Себер шәһәрләрендә гастрольдә булып кайттылар. Алар анда К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», Т. Миңнуллинның «Дилэфрүзгә дүрт кияү» спектакльләре белән чыгыш ясады. Ижевск, Свердловск, Омск, Новосибирск, Новокузнецк, Прокопьевск, Томск, Красноярск, Иркутск шәһәрләрендәге гастрольләрдән соң чорыбызның гигант төзелеше булган Байкал — Амур магистраленең баш шәһәре Тындада, Могот эшчеләр поселогында чыгыш ясадылар. Артистлар бу гастроль дәвамында шәһәр предприятиеләрендә эшчеләр белән, Прокопьевск шәһәрендә мактаулы якташларыбыз — шахтерлар белән кызыклы очрашулар уздырдылар. В. Минкина, Р. Таҗетдинов, Р. Шәрәфиев, Н. Гәрәева, Х. Җәләлов, А. Харисова, Ф. Әхтәмова, И. Хәйруллин һ. б. артистларның чыгышларын тамашачылар бик җылы каршыладылар.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

* * *

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм илле яше тулу уңае белән язучы **Шәукәт Галиев (Шәукәт Галиевич Һидиятуллин) «Почет билгесе» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен художник **Виктор Иванович Куделькинга РСФСРның атказанган художнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен художник **Виктор Петрович Игнатьевка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең музыкаль-әдәби лекторие җырчысы **Идея Васильевна Алексеевага Татарстан АССРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исем бирелде.

## *Хөрмәтле укучылар!*

Журналыбызның март санында Ә. ЕНИКИнең «Тынычлану» дигән күләмле хикәясен укырсыз. Бу әсәрдә бүгенге көн вакыйгалары һәм замандашларыбызның образлары гәүдәләнә.

Хатын-кыз авторлардан С. СӨЛӘЙМАНОВАның «Гөлбадран» повесте, К. БУЛАТОВА, Л. ШАКИРҖАНОВА, Б. РӘХИМОВА һәм Ф. БӘШИРОВАның шигырьләре урнаштырылачак. Язучы Л. ИХСАНОВАның «Стелла — йолдыз дигән сүз» исемле очеркы басыла.

Март аенда тугандаш Башкортстан АССР оештырылуга 60 ел тула. Шул уңай белән журналда башкорт халкының олы бәйрәменә багышланган язмалар һәм әдәби әсәрләр тәкъдим ителә. Ә. МИРЗАҺИТОВның «Бөек Октябрь һәм Башкортстан әдәбияты» дигән мәкаләсе ут күршеләребезнең әдәби казанышлары белән таныштыра. М. КӘРИМ, С. КУДАШ, Н. НӘҖМИ, Х. ГЫЙЛӘҖЕВ, М. ГАЛИ, Ш. БИККОЛ, Г. РАМАЗАНОВ, Ә. АТНАБАЕВ һәм башка шагыйрьләрнең поэтик әсәрләре Башкортстан җиренең бүгенге матурлыгын сурәтли, туган илгә дан җырлый, халыклар дуслыгын олылый. Прозаик Ф. ИСӘНГОЛОВ «Агыйделнең аръягында» дигән хикәясе белән катнаша.

Быелгы март ае әдәби юбилейларга бай. Күренекле әдип Әмирхан Еникигә 70 яшь тула. «Рухи матурлык җырчысы» дигән язма аның иҗатына багышлана. Әнвәр Давыдовның туууына 60, Г. Сәгъдинең тууына 90 ел тулу уңае белән материаллар биреләчәк.

Бу санда да «Бүгенге поэзия турында сөйләшү» дәвам иттерелә. «Елмаеп та, көлеп тә...» бүлегендә Ш. ГАЛИЕВнең «Хикмәтле сүзләр»е урын алачак. «Мәсәлчеләр мәҗлесе»ндә ЛАФОНТЕН катнаша. «Нәниләр дөньясы»нда Р. МИҢНУЛЛИНның балалар өчен шигырьләре урнаштырыла.

Гадәттәгечә, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият тарихына караган материалларга киң мәйдан бирелә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210